Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

Казан • Казань
2022

# РУХИ МИРАС

## Эзләнүләр һәм табышлар

*15 нче чыгарылыш*

**Г. Рәхим. Г. Газиз.**
**Татар әдәбияты тарихы.**
**Борынгы дәвер**

# ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ

## Поиски и открытия

*Выпуск 15*

**Г. Рахим. Г. Газиз.**
**История татарской литературы.**
**Древний период**

УДК 82.0
ББК 83.3(2=632.3)
Р 82

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

Проект «Татар халкының милли үзтәңгәллеген саклау (2020–2024)»
ТР Дәүләт программасы кысаларында
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Язма мирас үзәге тарафыннан гамәлгә ашырыла

**Редколлегия:**
***Д. Ф. Заһидуллина** (җаваплы мөхәррир), **Ә. М. Закирҗанов,
Л. Р. Надыршина, И. Г. Гомәров** (проект җитәкчесе һәм фәнни мөхәррир)*

**Төзүчеләр һәм текстларны әзерләүчеләр:**
***Г. А. Хөснетдинова, А. М. Ахунов, И. Г. Гомәров, Л. Ш. Гарипова***

**Р 82** **Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. Татар әдәбияты тарихы. Борынгы дәвер = Духовное наследие: поиски и открытия. Г. Рахим, Г. Газиз. История татарской литературы. Древний период** / төз., текст., иск. һәм аңл. әзерл.: Л. Ш. Гарипова, Г. А. Хөснетдинова, А. М. Ахунов, И. Г. Гомәров; кереш сүз авт. Д. Ф. Заһидуллина. – Казан: ТӘһСИ, 2022. – 15 нче чыг. – 300 б.
ISBN 978-5-93091-452-8

Җыентык татар халкы рухи мирасының нигезен тәшкил итүче әсәрләрне өйрәнү, аз билгеле язма чыганакларны бастырып чыгару, татар текстларын өйрәнү барышындагы яңа табышлар белән укучыларны таныштыру традициясен дәвам итә.

Сериянең чираттагы санында татар галимнәре Гали Рәхим (1892–1943) һәм Газиз Гобәйдуллин (1887–1938) тарафыннан әзерләнгән һәм 1922–1924 елларда 3 том булып нәшер ителгән «Татар әдәбияты тарихы» тәкъдим ителә. Әлеге китапта басманың «Татар әдәбияты тарихы өчен материаллар җыю юлында бер тәҗрибә. Мәдхәл» дип аталган беренче томы һәм «Татар теле һәм әдәбиятының тарихи язмышы» дип исемләнгән икенче томының «Коман мәҗмугасы», «Каберташ язулары», «Ярлыклар» дигән кисәкләре һәм «Идел буенда чыгтай әсәрләре» кисәгенең бер өлеше («Кыйссас әл-әнбия», «Диване хикмәт, «Сөләйман Бакыргани һәм аның әсәрләре») туплап бирелә. Икенче томның калган өлеше һәм өченче том материаллары сериянең киләсе санында урын алачак.

Хезмәт, гарәп язуыннан гамәлдәге хәрефләргә күчерелеп, беренче тапкыр нәшер ителә.

Басма белгечләр, татар тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынучы киң катлау укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-93091-452-8

© ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2022

## КЕРЕШ СҮЗ

Гали Рәхим һәм Газиз Гобәйдуллин… Олы гыйльми һәм әдәби мирас калдырган, халыкка хезмәт итүнең үрнәге, татар гуманитар фәненең горурлыгы һәм вөҗданы булган әлеге галимнәрнең милли-мәдәни тарихыбызда үз урыннарын, үзләренә лаек бәяне тулысынча алганы юк әле. Чөнки бу мирасның иң асыл җәүһәрләре совет дәверенең оныттыру сөременнән арынмаган, фәнни әйләнешкә кайтмаган. Бу хезмәт – шушы юлда яңа бер адым, аларның үз милләтенә эшләп калдырган төп тикшеренүләренең берсе – «Татар әдәбияты тарихы». Үзе кабат басылмаган булса да, аның тәгълиматы-концепциясе һәм фактик асылы-материалы бүгенге көнгә кадәр татар әдәбияты һәм мәдәнияте тарихын өйрәнүнең төп магистраль юлын билгеләп тора.

Гали Рәхим һәм Газиз Гобәйдуллинның тормыш юлы – гомерне фәнгә һәм милләткә багышлау тарихы ул. Алар биографиясендә охшаш һәм кисешкән урыннар да бик күп.

Газиз Салих улы Гобәйдуллин – 1887 елның 26 июнендә, Мөхәммәтгали Мөхәммәтшакир улы Габдерәхимов 1892 елның 4 ноябрендә сәүдәгәр гаиләсендә туганнар. Аларның этиләре шәһәрдә билгеле бай Исхак Айтугановның кызларына өйләнгән була: Өммегөлсем – Газизнең, Бибигайшә – Галинең әниләре. Гаилә хәлләре дә охшаш – җитеш, мул тормышта, чын татар тәртипләре хөкем сөргән йортларда, аралашып үсәләр. Вакыты җитүгә, Газизне – кайчандыр этисе укыган кадим «Халидия» (1895–1904), Галине җәдит «Мөхәммәдия» (1898–1905) мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Зиһенле, акыллы яшүсмерләр укуда алдынгы була. Әмма мәдрәсә белеме генә аларны канәгатьләндерми: өйгә укытучылар чакырып, рус һәм Европа телләрен, әдәбиятларын, тарих, фәлсәфә кебек фәннәрне, гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнәләр.

Шуннан соң күпмедер вакытка аларның юллары аерыла. Газиз, өйдә әзерләнеп, 3 нче Казан гимназиясен тәмамлау турында аттестат ала һәм Казан император университетына укырга керә

(1909–1916). 1907 елдан татар милли матбугатында хикәяләре, фәнни һәм тәнкыйди мәкаләләре басыла башлый. Университетны тәмамлагач, Троицк шәһәренең мәдрәсәләрендә укытып ала һәм 1919 елны Казан университеты аспирантурасына укырга керә.

Галинең әтисе Мөхәммәтшакир, улын да үз эзеннән җибәрергә теләп, 1905 елны аны Казандагы Сәүдә (Коммерция) училищесына керергә күндерә. 1913 елны училищены тәмамлагач, Мәскәүдәге Коммерческий институтның икътисад бүлегенә җибәрә. Гали әдәбият һәм фән белән кызыксына, 1909 елны, рус телендәге «Вокруг света» дигән китапка нигезләнеп, мәдрәсәләр өчен «Җир йөзе» дип аталган география дәреслеге бастырып чыгара. Актив рәвештә татар вакытлы матбугатында язышa, беренче шигырьләрен, хикәяләрен, мәкаләләрен яза. Әтисе үлгәннән соң (1917), институтны ташлап, Казанга кайта һәм гомерен гуманитар фәннәргә багышларга карар кыла.

Шундый ук адымны Газиз дә ясаган була: юридик факультетның беренче курсын тәмамлагач, ул үз теләге белән университетның тарих-филология факультетына күчә һәм Н.Н. Фирсов, М.М. Хвостов, Н.Ф. Катановлар җитәкчелегендә төркиләр һәм монголлар тарихын өйрәнә башлый.

Инкыйлабка кадәр Гали белән Газиз, аларның эне-сеңелләре Казан татар яшьләре арасында үзләренең таланты, хөр фикере белән аерылып тора. (Газизнең белемле, күп телләр белгән энесе Кадыйр һәм сеңлесе Мәрьям дә университет тәмамлыйлар, беренче татар этнографларыннан булалар.) Татарлар оештырган күп кенә милли-мәдәни чараларда башлап йөриләр, аларда катнашалар; Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Ә. Хәсәни, Г. Коләхмәтов һәм башка татар зыялылары белән аралашып яшиләр. 1907 елда Г. Гобәйдуллинның беренче хикәяләре басыла, 1911 елны Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре хакындагы күләмле аналитик язмасы татар әдәбияты мәйданына үзенчәлекле фикерле тәнкыйтьче килүне хәбәр итә. Шушы вакыттан ул, һәм галим, һәм язучы буларак, вакытлы матбугатта даими рәвештә күренә. Әдәби әсәрләре арасында «Бер хыял» (1913),

«Җомга көн» (2013), «Әкиятләрдән берсе» (1914), «Юлдаш эзләгәндә» (1914) «Вәсвәсә» (1915), «Хәкимә әби» (1915), һ.б.; тәнкыйди-аналитик язмалардан, «Сәгыйть Рәмиев шигырьләре тугрысында» (1913), «Яшь әдәбиятыбызда – «Яшь йөрәкләр» (1913), күпсанлы рецензияләр; фәнни хезмәтләр буларак, «Сәет Баттал гази хикәясе тугрысында» (1911), «Иске тел вә миллият» (1913), «Милләтне ничек аңлыйсыз?» (1913), «Мәрҗани хатирәсе» (1914), «Марко Поло хакында бер тәҗрибә» (1915), «Мәрҗанинең голүм, фөнүн вә сәнаигъка карашы» (1915), «Мәрҗанинең тарихи хезмәтләре» (1915), «Алтын Урданың эчке корылышы» (1917), «Милләтчелекнең бәгъзы әсаслары» (1917) һ.б. язмалар – бу мирасның зур булмаган бер өлеше генә. 1918 елда аның мөстәкыйль хикәяләр җыентыгы басылып чыга, 1919 елда тагын бер хикәяләр тупланмасы дөнья күрә.

Гали Рәхим әдәби барышка 1913 елны күпсанлы хикәяләре белән килеп керә: «Эч пошканда», «Яз экиятләре», «Хан мәчетендә», «Серле-серле экият» кебек хикәяләр яңа нәшер ителә башлаган, ләкин татар дөньясында зур шау-шулар уяткан «Аң» журналында тәкъдим ителә. Шул ук елны Г. Рәхим тәнкыйтьтә дә үз сүзен әйтерлек әзерлекле булуын дәлилли. «Аң»да дөнья күргән «Тукаев – халык шагыйре» язмасы аны әдәбият теориясе һәм поэтикада иркен «йөзүче», Европа, рус, шәрык әдәбиятлары тарихын яхшы белүче аналитик итеп күрсәтә. 1914 елны Г. Рәхим «Аң»да «Халык әдәбиятыбызга бер караш» дигән мәкаләләр циклы белән чыга. «Галия» (1914), «Яз экиятләре» (1913), «Шагыйрь» (1914), «Җиткән кыз» (1915), «Әбү Сәгыйд» (1915), «Хыял дәрьясында» (1915), «Миләүшәләр арасында» (1915), «Ярыш (булган эш)» (1916), «Догаи Сәйфи» (1916) һәм башка хикәяләре аны кеше психологиясен яхшы белүче прозаик буларак таныта. Ул шигырьләр яза, драматургия өлкәсендә дә үз көчен сынап карый: «Дача кайгысы» (1914) комедиясе, «Җанвар» (1919) драмасы үз вакытында билгеле әсәрләрдән булып, «Сәйяр» труппасы тарафыннан сәхнәгә куела. Татар театры хакындагы мәкаләләре аның сәнгать мәсьәләләрендә үзен иркен хис итүе хакында сөйли.

Октябрь инкыйлабыннан соң Газиз дә, Гали дә Казандагы төрле вузларда, курсларда укыталар, фән белән җитди шөгыльләнәләр, фәнни хезмәтләрен бастыралар. Аларның тирән белеме, күп телләр белүе, энциклопедик мәгълүматлылыгы һәм, туктаусыз хезмәттә булып, гомерләренең һәр минутын фәнни эзләнүләргә яки иҗат эшенә багышлавы хакында замандашларының истәлекләрендә сакланып калган.

Г. Гобәйдуллин фәндә аеруча тарих һәм әдәбият мәсьәләләре белән ныклап шөгыльләнә. 1918 елда инде ул тарих (төрки-татар тарихы, дин тарихы, Русия тарихы) дәреслекләре нәшер итә. «Идел буенда көрәш тарихыннан» (1923), «Пугачев явында татар-башкортлар» (1923), «Борынгы болгарлар» (1924), «Пугачев явы» (1924), «Татарларның килеп чыгышы һәм Алтын Урда» (1924), «Татар тарихы» (1925), «История народов СССР в эпоху феодализма» (1931) кебек хезмәтләр аның кызыксыну өлкәләренең гаять колачлы булуын күрсәтеп тора. 1925 елдан башлап, Г. Гобәйдуллин азәрбайҗан, үзбәк тарихына, төрки халыкларның борынгы тарихына һәм мәдәниятенә караган эзләнүләр алып бара, хезмәтләр яза.

1917 елдан соң Г. Рәхимнең татар әдәбиятындагы зур әсәрләр хакындагы мәкаләләре пәйда була. Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романы, К. Насыйри, Г. Гобәйдуллин, Һ. Такташ иҗаты турындагы язмалар әдәби җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уята. Бигрәк тә 1925–1932 елларда, күпсанлы мәкаләләр, чыгышлар, докладлар авторы буларак, исеме һәрдаим матбугатта яңгырап тора. Галим берничә юнәлештә актив эзләнү алып бара: халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю һәм анализлау методикасы; сәнгать, поэтика һәм халык авыз иҗаты бәйләнешләре; сәнгатьнең килеп чыгуы хакындагы концепцияләр; әдәби иҗат теориясе һәм психология; тарих һәм этнография. Татарстанны өйрәнү җәмгыяте кысаларында милли тарихка караган чыганаклар һәм мәгълүматларны бастырып чыгаруы, әдәбият тарихына караган мәкаләләре, Гыйльми үзәк кушуы буенча төзегән «Фольклор һәм халык әдәбиятын җыю өчен кулланма» (1926), «Авылны өйрәнү өчен жен-

текле кулланма-программа» (1930) кебек хезмәтләре дә – шушы кызыксыну-эзләнүләр нәтиҗәсе. Болардан тыш, ул иҗат эшен дә ташламый. Балалар өчен хикәяләр, романслар, «Көзге хикәя» (1918), «Бер шагыйрьнең өйләнүе» кебек хикәяләр, «Идел» (1921) повесте – әдәби мирасының иң затлыларыннан.

Кызганычка каршы, 1917 елда илгә килгән үзгәрешләрне кабул иткән, татар милләтен үстерү-үзгәртү өчен инкыйлабны файдалы дип ышанган мондый шәхесләр язмышы аяныч тәгәлләнә. Илдә яңа тәртипләр урнашып бара, ышанычсызлар исемлегенә эләккән Г. Гобәйдуллин гаиләсе белән 1925 елны Бакуга күченергә мәҗбүр була. Ул бирედә көнне төнгә ялгап эшли, төрки халыклар өчен заманча гуманитар фән юнәлешләре булдыруга өлеш кертә. 1928 елдан профессор дәрәҗәсенә лаек була, Казан белән дә араны өзми: мондагы зур гыйльми проектларда катнаша.

Г. Гобәйдуллин 1937 елның 18 мартында кулга алына һәм октябрь аенда атып үтерелә. 1957 елның 12 октябрендә реабилитацияләнә.

Гали Рәхимне 1930 елның маенда кулга алалар, ул Ак диңгез – Балтыйк каналында эшли, 1934 елның 22 августында азат ителә. Әмма 1937 елның язында кабат кулга алына. 1940 елның 27 февралендә суд Г. Рәхимне 8 ел концлагерьга җибәрергә хөкем итә. Аннан каты авыру хәлендә кайтып, 1943 елның 3 мартында гүр иясе була. 1958 елның 2 февралендә реабилитацияләнә.

Гали Рәхим һәм Газиз Гобәйдуллин калдырган мирас арасында алар бергәләп әзерләгән фундаменталь «Татар әдәбияты тарихы» бар. Төрки халыклар тарихын, фольклорын, күпсанлы чыганакларны өйрәнеп, борынгы кульязмаларны барлап язылган хезмәт милли сәнгать тарихын чишмә башыннан алып күзәтеп, бәяләп чыгуны күз алдында тотып уйланыла. 1922–1923 елларда «Татар әдәбияты тарихы»ның икенче һәм өченче кисәкләре басылып чыга. 1924 елны – беренче кисәге, 1925 елны «Феодализм дәвере» исеме белән кыскартылган икенче басма дөнья күрә.

«Татар әдәбияты тарихы өчен материаллар җыю юлында бер тәҗрибә. Мәдхәл» исеме белән аталган беренче кисәктә рун,

уйгур һәм гарәп язулы гомумтөрки истәлекләр, суфичылык һәм аның шәрык әдәбиятына тәэсире, уйгур, чыгтай, сәлҗук һәм госманлы әдәбиятлары турында мәгълүматлар бирелә.

«Татар теле һәм әдәбиятының тарихи язмышы», «Идел буенда иң борынгы тел ядкәрләре», «Идел буенда чыгтай әсәрләре», «Идел буенда госманлы әсәрләре» дигән өлешләрне берләштергән икенче кисәктә татар әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсүе, борынгы тел ядкәрләре буларак «Коман мәҗмугасы», каберташ язулары, ярлыклар игътибар үзәгенә куела. Рабгузиның «Кыйссас әл-әнбия»се, Сөләйман Бакыргани әсәрләре, «Сөбат әл-гаҗизин», «Кисекбаш китабы», «Сәйфелмөлек» кебек әдәби әсәрләр аерым-аерым тикшерелә.

Өченче кисәк XVII, XVIII, XIX йөзнең беренче яртысында иҗат иткән әдипләр мирасына, аларның әсәрләренә, халык авыз иҗатына, сәяхәтнамәләргә, васыятьнамәләргә күзәтү ясый, татар әдәбиятының зур этапларын бәяләп һәм тикшереп уза.

Хезмәт татар дөньясында зур шау-шу тудыра. Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди һәм башка галимнәр, гомуми уңай бәя бирү белән бергә, авторларны марксизм-ленинизм ысулын кулланмауда гаеплиләр. Татар әдәбияты тарихын Идел буе белән бәйләргә чакыралар. Дөрес, башкача бәяләр дә яңгырый. Мәсәлән, Җ. Вәлиди хезмәтне татар өчен генә түгел, бәлки бөтен төрки халыклар әдәбияты тарихын өйрәнү өчен үрнәк дип атый. (Рецензия «Безнең юл» журналының 1924 елгы 4–5 нче санында дөнья күрә.) Чыннан да, китап, басылып чыгуга, күп кенә төрки халыкларның югары уку йортларында дәреслек итеп кулланыла башлый.

Хезмәтнең әһәмиятен аңлау өчен, иң беренче чиратта ул заманда татар әдәбияты тарихының фән буларак эшләнмәгәнлеген, аның нинди концептуаль нигезгә салыначагы ачыкланмаганлыкны, кайсы дәверләрдән башланырга тиешлеге расланмаганлыкны әйтергә кирәк. Бу юнәлештә Г. Рәхим һәм Г. Газизләр – беренче, һәм аларның татар әдәбияты тарихын гомумтөрки мәдәният кысаларында өзлексез барыш итеп тезә алуы гаять зур ачыш, казаныш була. Мондый концептуаль ни-

гезне, әлбәттә, чын мәгънәсендә гыйлем ияләре, һәм Европа, һәм шәрык фәненнән мәгълүматлы шәхесләр генә булдыра алуы шиксез.

Татар тарихы, теле һәм әдәбияты тарихының бүгенге үсеш баскычында без нәкъ менә Г. Рәхим һәм Г. Газизләр концепциясенең дөрес икәнлеген таныйбыз, төрки-татар әдәбияты барышын алар билгеләгән вакыт кысаларында, Орхон-Енисей ташъязмаларыннан башлап өйрәнәбез дә. Шул ук вакытта аларның ачышлары ХХ гасыр дәвамында фәнни әйләнештә булса, күп кенә сукмакларда татарны өйрәнү фәненә үсеп китәр өчен нигез булыр иде дигән үкенеч тә бар.

Г. Рәхим һәм Г. Газизләрнең «ышанычсызлар» исемлегендә булуы үзе үк китапның таралышына тискәре йогынты ясый. Авторлар «шәхес культы» тегермәненә эләгү аларның исемнәрен дә, хезмәтләрен дә фән тарихыннан һәм татар тарихыннан алып ташлауга китерә. «Татар әдәбияты тарихы» хезмәтенең әһәмиятен аңлаган зыялылар әлеге китаптагы фактик материалларның бер өлешен, чыганагын күрсәтмичә генә, үз фәнни хезмәтләренә кертеп җибәрә. Асылда, бүген дә татар әдәбияты тарихының, тел һәм мәдәният тарихының Г. Рәхим һәм Г. Газизләр салган нигездә үсүе бәхәссез. Әмма бу тикшеренүләрнең кемнеке икәнлеген әйтү өчен, аларның хезмәтен бастырып чыгару, тулы килеш, үз исем-фамилияләрен куеп нәшер итү кирәк иде.

Үзгәртеп корулар ачкан мөмкинлекләр дулкынында, 1990 еллардан башлап, Гали Рәхимнең һәм Газиз Гобәйдуллинның исемнәре халыкка кайта башлады, аерым хезмәтләре, әдәби әсәрләре дөнья күрде. Әмма аларның таҗ хезмәте, бүгенге көнгә кадәр һәм бүген дә тюркология фәнендә фундаменталь нигезне хасил иткән китапларның берсе – «Татар әдәбияты тарихы» – кирилл хәрефләрендә укучы кулына кергәне юк иде әле. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының «Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясендә әзерләнеп нәшер ителүе символик мәгънәгә ия. Хезмәт институтның милли тел, әдәбият, сәнгать тарихына караган 80 еллык эшчәнлеге Гали

Рәхим һәм Газиз Гобәйдуллин фәнни тикшеренүләренең дәвам иттерелеше, үстерелеше булуын тагын бер кат исбатлый.

Әлбәттә, бер гасыр элек язылган хезмәттә бүгенге фәнни күзаллаулар белән туры килми торган, инде яңа дәлилләр табылып үзгәргән аерым моментлар да юк түгел. Әмма без аларга аерым игътибар биреп, XX гасырның беренче чирегендәге фикерләр белән бәхәсләшеп торуны комментарийлар-шәрехләр дәрәҗәсендә дә дөрес булмас дип санадык.

Хезмәтнең фактик материалга бай, концептуаль төзек, теоретик нигезле булуын аерып күрсәтергә кирәк. Авторларның Монголия, Кытай, Алтай, Урта Азия, Европа тарихларын белүе, дин тарихын һәм төрки мәдәният тарихын яхшы аңлаулары аларга татар мәдәниятенең барлыкка килүен һәм үсешен Евразия тарихы фонында язарга мөмкинлек биргән. Кытай чыганакларын, Европа сәяхәтнамәләрен, В. Радлов, В. Бартольд, А. Самойлович, В. Томсен, С. Малов, Ф. Корш һ.б. рус телле фундаменталь хезмәтләрне дә, шәрык-мөселман һәм татар галимнәре, мәгърифәтчеләренең (аерым алганда, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдинов, З. Вәлиди) карашларын да яхшы белү, чагыштыра, шулай ук борынгы текстларны укый, аңлый, анализлый алу аның чыганакчылык-историография ягыннан көчле, ышанычлы, дәлилле булуын тәэмин итә.

Хезмәтнең кереш өлешендә әдәбият тарихының киң мәдәни барыш итеп каралуы искәртелә: «…бу китап Идел буенда төрк телендә язылган вә укылган әсәрләрне бер яктан гына карамыйча, аларның заманга, мәдәни мохиткә, заманасының фикри хәятына мөнәсәбәтләре, шулай ук телләре, өслүбләре, ниһаять, әдәби кыйммәтләре ягыннан да карап тикшерәчәктер. Әлхасыйль, чынлыкта бу әсәр бер әдәбият тарихы булудан өстен, Идел буе татарларының мәдәният тарихларының зур бер кисәген эченә алачактыр». Чыннан да, материал авторларның караш киңлеге белән аерылып тора һәм татар халкы, аның күзаллаулары, ышанулары, иҗади аңы формалашу тарихын тергезә.

Авторлар сүзне бик борынгы төркиләрнең тарихы, дөньяга мөнәсәбәте турында сөйләүдән үк башлап китәләр. Күчмә

һәм патриархат яшәү рәвеше мәдәниятнең нигезе итеп карала. Аерым алганда, ырулар-нәселләр арасында якын мөнәсәбәтләр саклану, пантеизм, ягъни табигатьне җанландырып кабул итү, гомумән табигатьне Аллаһ итеп карау, кешене җир һәм күк, югары һәм түбән дөньялар арасында дип күзаллау, күчмәләрдәгечә «кунакчыллык, гайрәт вә сугышчанлык» һәм башка сыйфатлар аерып чыгарыла, иҗади фикерләүгә аларның йогынтысы күзәтеп узыла. Музыка, риторика нык үскәнлек, әдәбиятның сөйләмә формасы, импровизация сәнгате популяр булу шуның белән аңлатыла.

Төрки-татарларның холык-фигыле, менталитетына караган күзәтүләр китап буенча сибелеп һәм шәрехләнеп барыла. Әйтик, Орхон ташбилгеләрен тикшерүгә багышланган бүлекчәдә борынгы төркиләрдә ханнарның, башка шәрык халыклары белән чагыштырганда, залимлеге белән түгел, «халыкка хезмәт итү, файда китерү шикелле эшләр белән мактануы» билгеләнә. Бу күренеш төркиләрдә ыруглык бәйләнешләренең көчле булуы белән бәйле.

Яки Казан ханлыгы егылганнан соңгы дәвер әдәбиятын күзәтүдә татар халкына хас төп сыйфатларның берсе итеп гыйлем-мәгърифәткә һәвәслек күрсәтелә: «...нинди генә кысулар да безнең халыкта уку-гыйлем дәртен бетерә алмады; киресенчә, дини кысынкылыклар халыкның фанатизмын уятып, аны “дин өйрәнү” шәкелендә тәсаувыр ителгән “уку”га сәвекъ итте». Шушы сыйфат авторларга гомумтөрки әдәбиятның татар әдәбияты үрнәкләре дип исәпләнә башлавын аңлатырга мөмкинлек бирә: «Әмма татарның үз арасыннан язучылар чыкмады; халыкның ихтыяҗын капларлык әсәрләр тумады. Менә шул кирәген тутыру өчен, татар үзенә кирәкле әсәрләрне үзенең кардәшләре булган башка төрк халыкларының әдәбиятларыннан алырга тотынды. Чыгтай, госманлы әдәбиятларыннан берничә дистә әсәрләр бурычка алынып, ахрысында, «түләнмәс бурыч»ка әйләнеп, татар халкының төп үз малына әверелеп, аның рухани тормышы, дөньяга карашы белән органик рәвештә багландылар.

Шулай итеп, читтән килгән байтак гарәпчә, фарсыча китаплар белән бергә-бер такым төркичә «килмешәк» әсәрләр дә безнең халык гаммәсе арасына кереп, тәгъмим ителеп, аның өчен үз телендәге әдәбият урынын тотып, әдәби ярлылыгын каплап килделәр. Шуңар күрә дә без бу әсәрләрне татар әдәбияты рәтеннән тикшерергә мәҗбүр булабыз».

Татар әдәбияты тарихына Идел буенда туган әсәрләрне дә, гомумтөрки әдәбиятта мирас булып килгән җәүһәрләрне дә, Мавәраэннәһердә, Урта Азиядә, Алтайда яки Иран-Төркия җирләрендә язылып та, кардәш халыклар белән аралашу нәтиҗәсендә татарларга килеп ирешкән, шулай ук чыгтай яки уйгур, госманлы әдәбиятының татарлар тарафыннан кабул ителеп, аларның тәмам үз әсәрләре булып киткән мирасын да кертеп карау шул рәвешле аңлатыла һәм дәлилләнә.

Шулай итеп, Г. Газиз һәм Г. Рәхим беренчеләр рәтендә милли әдәбиятның тирән тамырларына игътибар итәләр, әдәбият тарихында гомумтөрки әдәбият, Идел буе әдәбияты кебек дәверләрне аерганда, алар нигез итеп өч факторның: хронологик, территориаль һәм халык иҗади фикерләвендәге традицияләрнең үрелүен ала.

Хезмәт әдәбият тарихына хронологик якын килүне үзәккә куя. Авторлар фикеренчә, Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбияты дип аталган дәвер XIX гасыр ахырына кадәр сузыла. Татар әдәбиятындагы Яңа заман исә XVIII гасыр ахырыннан, Хәлфиннар, Фәезхановлар, Мәрҗаниләр, К. Насыйри, Акмуллалар иҗатыннан башлана. Шул рәвешле, бер дәвердән икенчесенә күчү арасында бер гасырлык күчеш чоры булып чыга. Кызганычка каршы, алардан соң чорларга бүлү мәсьәләсендәге күп кенә буталчыклыклар, аерым алганда, Яңа заманның башлану вакытын әле XIX йөз башы, әле уртасы, әле соңгы чирегә дип билгеләүләр шушы үзенчәлекне исәпкә алмауга, бер дәвернең беткән ноктасын икенчесенең башланган вакыты итеп карау белән бәйле иде. Безгә, бу мәсьәләдә Г. Рәхим белән Г. Гобәйдуллин фикеренә әйләнеп кайтып, Яңа заман әдәбиятына күчеш аралыгының

XVIII гасыр ахырыннан XIX гасырның ахырына кадәр сузылуын тану таләп ителә. Күп кенә Европа әдәбият тарихларында, шул исәптән төрек әдәбияты тарихы фәнендә дә ул шулай.

Төрки халыкларда язу сәнгате – әлифбалар, хәреф-билгеләрнең әйтелеш һәм язылыш үзенчәлекләренә караган күзәтүләр гаять җентекле. Авторларның Орхон, уйгур, самит, дүрткел, төрки язуларын яхшы үзләштергән булуы күренә. Төрле фараз-карашларны күзәтеп, хезмәттә аларның үз версияләре билгеләнеп барыла һәм олы гомумиләштерүләр ясала. Мәсәлән, Билге каһан һәм Күлтәгин язмаларын анализлап, аларның вәзене «төрк халыкларына махсус бик борынгы вәзен булып, хәзерге көнгә кадәр төркләрдә югалмаган. Аның үлчәве белән безнең татар халык йырларының үлчәве бер үк әсаска бина кылынган» дип, авторлар мондый нәтиҗә ясап куялар: «Йоллык Тәгинне безгә мәгълүм булган беренче төрк әдибе дип, аның язып калдырган ташларын да беренче төркчә әсәрләр дип атарга мөмкин».

Текстлар белән эшләү – аларны шәрехләү, урынын билгеләү һәм аңлату – заман югарылыгында, аерым бер очракларда бүгенге көн өчен дә актуаль дәрәҗәдә. Мәсәлән, «Суфилык һәм аның шәрык әдәбиятларына тәэсире» бүлекчәсе суфи әдәбиятка хас сыйфатларны берәмләп күрсәтеп уза: киная һәм аллегориягә корылу; сурәтләү объекты Аллаһка мәхәббәт икәнлек; лирик геройның Аллаһ гыйшкыннан исерек зат булуы; ике мәгънә аңлатырлык символлар кулланылу; фикер ирeклеге, хөрлеге. Бу сыйфатлар фәнебездә XXI гасырда гына аңлап һәм кабул итеп җиткерелде. Суфичылыкның иҗатчыга сүз иреге – «хөррияте кәламия» бирүе хакындагы фикер исә бүгенге фән өчен дә яңа һәм әдәбиятка үзгә позицияләрдән якын килү кирәклекне искәртеп тора.

Хезмәт татар халкының милли тарихына караган бик күп фактик материаллары белән дә гаҗәпләндерә. Авторлар татар мәдәниятен шәрык һәм гареб синтезы итеп карыйлар: «Идел елгасы буенда яшәп, шәрык вә гаребне бер-берсенә тоташтыручы, шәрык вә гареб мәдәниятен бергә кушучы, мәдәният ташучы –

татар милләтенең мәдәнияте». Хезмәттә татар ханлыклары, этнографик төркемнәр барлыкка килү кебек мәсьәләләр дә игътибарга алына. Анда «татар кем?» соравына җавап та бар. Бу җавап бүгенге тарих фәне җавабы белән тәңгәл килә: «Татар» дигән сүзне без беренче мәртәбә VIII гасыр мәнбәгъларыннан булган Орхон язуларында ук очратабыз. Анда әйтелә: «Угыз бодун утыз татар берлә тәрилиб кәлти». (Угыз халкы утыз татар кабиләсе белән берләште.) Орхон язуларында сөйләнә торган «татарлар»ның угыз бодуныннан аерым бер халык икәне күренеп тора». «Татар тарихы»ның 7 томлыгында да татар этнонимының беренче тапкыр «утыз татар кабиләсе» атамасында телгә алынуы күрсәтелә.

Бүгенге фәндә рус теленнән атама белән йөртелә торган бик борынгы төркиләрне (прототөркиләр) авторлар Европа историографиясеннән мәгълүм «ту-күә» термины белән атыйлар. Алар болай дип яза: «Кытайларның IX гасыр тарихи мәнбәгъларында «татар» исеме очрый. Алар аны «тата» һәм «tha-thaeul» рәвешендә язалар, чөнки кытайлар «р» хәрефен әйтмиләр. Алар шуның өчен «төрк» дигән сүзне дә «ту-куе» рәвешендә язалар». Мондый терминнарның бүген кабат фәнни әйләнешкә керүен күзәтәбез.

Хезмәттә татар тарихы һәм мәдәниятенә караган бик күп мәсьәләләр күтәрелә һәм аңлатыла. Әйтик, аерым әдәби ядкәрләрнең тел үзенчәлекләре заманга тәңгәл килмәү – кульъязмаларны күчереп язучылар күп булу белән, кайсы китапларның халык арасында урнашып-популярлашып калуы халыкның ихтыяҗы, аның менталитеты белән бәйләп шәрехләүләр дәлилле һәм ышандыра.

Әлбәттә, киң эрудицияле, тирән белемле авторларның хезмәте хакында күп фикерләр әйтергә мөмкин. Безнең өчен аның бүген дә актуальлеген җуймаган булуы аерата мөһим.

*Д.Ф. Заһидуллина,*
*филология фәннәре докторы*

# БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

## МӨКАДДИМӘ

Укучыларга тәкъдим ителә торган бу китап «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче җилден[1] тәшкил итеп, татар әдәбиятының борынгы дәверенә багышлана. Борынгы дип без тәмамән борынгы ислам шәркы[2] тәэсирендә генә туган иске әдәбият дәверен атыйбыз.

«Татар әдәбияты тарихы»ның бу беренче җилде өч бүлеккә (өч китапка) аерылып нәшер ителде. Ләкин бу эш бары тик кайбер матди сәбәпләр тәказа кылганга[3] күрә генә эшләнде. Юкса әсәр органик рәвештә өч кисәккә аерылмый, бәлки күләмнәре бик төрлечә булган алты кисәккә аерыла ки, алар шушылардыр: 1) Мәдхәл[4], 2) Татар теле вә әдәбиятының тарихы язмышы, 3) Идел буенда иң борынгы тел ядкәрләре, 4) Идел буенда чыгтай әсәрләре, 5) Идел буенда госманлы әсәрләре, 6) XVII, XVIII һәм XIX гасырларда иске әдәбият.

Бу алты кисәктән беренчесе булган «Мәдхәл» кыйсеме җилднең беренче бүлеген тәшкил итәдер. Бу бүлек татар әдәбияты тарихының борынгы дәверенә генә түгел, бәлки бөтен татар әдәбияты тарихына мәдхәл булып хезмәт итәргә тиеш. Бу мәдхәл борынгы төрк[5] халыкларының мәдәният, язу вә

[1] Җилден – кисәген.

[2] Авторлар «борынгы әдәбият»ны ислам дине тәэсирендә туган әсәрләр белән чикләүләрен әйтәләр. Әмма мәдәни мирасны күзәтү вакытында, хәзерге әдәбият белемендәге шикелле, исламга кадәрге, мәҗүсилек яки будда дине тәэсирендә туган әсәрләр дә борынгы төрки-татар әдәбиятына кертеп карала.

[3] Тәказа кылганга – таләп иткәнгә.

[4] Мәдхәл – кереш.

[5] «Төрк» дигәндә төрки халыклар күздә тотыла. Билгеле булганча, XIX гасыр ахырында В.В. Радлов, В.В. Бартольд хезмәтләрендә телләргә кагылышлы «төрк теле/төрки тел» һәм «төрки халыкларның телләре» арасында чик уздырыла. Халыклар атамасы нисбәтеннән бу традиция XX гасыр урталарына гына ныклап урнашып җитә. Текстның үзендә авторлар төрек халкына нисбәтле «госманлы төрк» атамасын кулланалар.

әдәбиятларына багышланган. Анда борынгы төркләрдәге шаманлык идеологиясенә һәм халык әдәбиятына, алардагы язу сәнгатенә, аларның иң борынгы язма әсәрләренә (Орхон ташларына, уйгурча әсәрләр), безнең татар әдәбиятының барышына зур тәэсир ясаган ике бөек төрк әдәбиятына (чыгтай вә госманлы әдәбиятларына), ниһаять, шуларда вә алар аркылы күчеп, безнең татар әдәбиятының да борынгы дәверендә хөкем сөргән идеологиянең төп гонсырын[1] тәшкил иткән суфилык (тәсаувыф) нәзариятына гомумән бер күз йөртеш ясап чыгылды.

Идел буе татарларының әдәбиятына керә торган әсәрләрнең тел вә өслүбләре, алардагы фикер вә идеяләр, бер яктан, үзүзеннән, җирле гамилләр тәэсире астында мәйданга килгән булсалар, икенче яктан, алар төркләрнең иң иске ватаннарында, бергә оешып торган вакытларында ук туган булып, тәварис буенча[2] киләләр; өченче яктан исә, алар башка шәрык халыкларыннан (гарәп, Иран вә башкалардан) үзләренең мәдәниерәк кардәшләре булган Урта Азия вә госманлы төркләре аркылы күчеп, тәэсир вә тәкълид[3] аркасында хасил булганнар. Шуның өстенә тагы безнең татарлар арасына элек-электән бөтен-бөтен чыгтай вә госманлы әсәрләре килеп кереп, гаммә каршында мәкъбүл[4], халык арасында укыла торган китаплардан булып киткәннәр. Әлхасыйль[5], бөтен төрк кавемнәре өчен уртак булган тел, өслүб вә язу ысулларын, тәварис буенча килә торган фикер вә карашларны, тәэсир вә тәкълиднең ничек булуын, ниһаять, турыдан-туры башка төрк әдәбиятларыннан кергән әсәрләрне, аларның үз әдәбиятларында тоткан урыннарын аңлау өчен, борынгы замандагы төрк кавемнәренең мәдәният вә тормышларына, аларда булып узган әдәби агым вә эволюцияләргә иҗмалән[6] генә булса да тукталып

[1] Гонсырын – элементын, состав өлешен.
[2] Тәварис буенча – мирас булып.
[3] Тәкълид – иярү.
[4] Гаммә каршында мәкъбүл – халык арасында кабул ителгән, яраклы.
[5] Әлхасыйль – нәтиҗәдә, җыеп әйткәндә.
[6] Иҗмалән – кыскача.

узмый мөмкин түгел. Ул да булса, бу әсәрнең «Мәдхәл»енең мөндәриҗәсен[1] тәшкил итәдер.

2 нче, 3 нче, 4 нче, 5 нче кисәкләр китапның икенче бүлеген тәшкил итәләр. «Татар теле вә әдәбиятының тарихы язмышы» аталган 2 нче кисәк озын бер мәкаләдән гыйбарәт булып, исеменнән үк күрелгәнчә, татар әдәбияты тарихына бер мөкаддимә шәкелендәдер. Анда «татар» исеменең кайдан килеп чыгуы, Идел буенда хәзер «татар» атала торган төрк халкының ясалышы, аның сөйләшү һәм әдәби телләренең ясалышлары, башка төрк телләре вә әдәбиятларының Идел буе әдәбиятына тәэсире хакында сөйләнә. 3 нче кисәк «Идел буенда иң борынгы тел ядкәрләре» аталып, анда «Болгар ташлары», «Коман мәҗмугасы», «Ярлыклар» шикелле, үзләре әдәби әсәрләрдән булмыйча, «әдәбият» рәтеннән саналмаска тиеш булган язу нәмунәләре[2] турысында сөйләнә. Бердән, алар безгә, соңыннан Идел буе татарларын тәшкил иткән халык гонсырларыннан калма, аларның язу телләренең ничек булганлыгын күрсәтә торган бердәнбер нәмунәләрдән булганга, икенчедән, ул дәвердән һичбер төрле чын әдәби әсәрләр сакланып калмаганга, алар безнең әдәбият тарихыбыз өчен бик зур әһәмияткә хаиз[3] булган әйберләрдер. «Идел буенда чыгтай әсәрләре» һәм «Идел буенда госманлы әсәрләре» сәрләүхәле[4] 4 нче, 5 нче кисәкләрдә безнең татарлар арасына чыгтай вә госманлы әдәбиятларыннан кереп, гасырлар буенча халык арасында укылып, татар халкының үз мәдәни малы хөкеменә кереп, борынгы татар әдәбиятының аерып алынмаслык бер кисәгенә әверелеп киткән әсәрләрнең иң мәшһүр вә гомумиләшкәннәре аерым-аерым тикшерелде.

Татарларның, сәяси истикъляльләрен югалтканнан соң, мәхкүмият[5] дәверендә, җирле үз язучылары тарафыннан тәэлиф

[1] Мөндәриҗәсен – эчтәлеген.
[2] Нәмунәләре – үрнәкләре.
[3] Хаиз – ия.
[4] Сәрләүхәле – исемле.
[5] Мәхкүмият – хөкем астында.

ителгән[1] әсәрләр «XVII, XVIII һәм XIX гасырларда иске әдәбият» сәрләүхәсе астында китапның беренче җилденең соңгы, 6 нчы кисәген тәшкил итәләр. Бу кисәк китапның бөтен өченче бүлеген аладыр. Үзләре бик аз (XVII, XVIII гасырлар өчен берничәшәр генә әсәр) булганга, бик күп әсәрләрнең язылу тарихлары тәгаен мәгълүм дә булмаганга, соңгы өч гасыр эчендә Идел буе татарлары тарафыннан мәйданга китерелгән әдәбиятны дәверләргә бүләргә имкян[2] да, лөзүмият[3] тә күрелмәде. Шуңарга күрә ул гомуми сәрләүхә астында бер тезмәдән генә сөйләнде.

Татар әдәбияты тарихы – моңар кадәр бер дә диярлек кул тимәгән, эшләнмәгән бер гыйлемдер. Мөәллифләрнең[4] бу әсәрне язганда күз алдында тоткан максатлары – әдәбиятыбызның тарихы хакында үзебезгә беренче мәртәбә мөфассалрак[5] бер хисап биреп карау, әдәбият тарихыбызны фән шәкеленә кертү, системага салу юлында бер тәҗрибә ясап, беренче адым атлау, беренче нигез ташларын салудыр.

Бер әдәбиятның тарихын фән рәвешенә китерү өчен, билгеле, анда бер система булырга тиеш; чөнки системадан башка һичбер төрле белем дә фән була алмый. Әдәбият тарихы системасын исә берничә төрле әсаста[6] төзергә мөмкин: шәхесләр игътибары белән, тип игътибары белән (типологическ.[7]), заман игътибары белән (хронологическ.[8]).

Беренче нәүгъ[9] әсас әдәбиятта зур роль уйнаган мәшһүр язучыларны алып, шуларның тәрҗемәи хәлләрен төп нигезгә салып, бөтен әдәбиятны шул затларның шәхесләре аркылы карап

[1] Тәэлиф ителгән – язылган.
[2] Имкян – мөмкинлек.
[3] Лөзүмият – кирәклелек.
[4] Мөәллифләрнең – китап төзүчеләрнең.
[5] Мөфассалрак – җентеклерәк.
[6] Әсаста – нигездә.
[7] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[8] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[9] Нәүгъ – төр.

тикшерүдән гыйбарәт. Без ике төрле сәбәптән бу юлны ихтыяр итә алмыйбыз: бер яктан, без тарихта шәхесләрнең аз роль уйнауларына ышанучыларданбыз. Дөрес, әдәбият галәмендә икътисади вә башка гамилләр[1] хәзерләгән идеяләр аерым шәхесләр аркылы кәгазьгә язылалар. Шулай булса да, шәхесләр – мөхәррирләр – үзләре үз мохит, заман, сыйныф вә гыйркларының[2] коллары; алар, нишләсәләр дә, ни язсалар да, шул мохит, заман, сыйныф, гыйрк шикелле хосусиятләрдән читкә чыга алмыйлар; шуның өчен дә дәверләрнең фикер, идея вә тасвирларын шәхесләр аркылы түгел, бәлки, киресенчә, шәхесләрнең фикер, идея вә тасвирларын дәверләр аркылы күрсәтү – турырак юлдыр.

Борынгы әдәбият тарихыбызны аерым язучыларны тикшерү ысулында тәртип итүнең башка яктан да уңайсызлыгы юк түгел. Гомумән, Идел буе татарлары элеккеге гасырларда, ни өчендер, әдәбият бабында бөек шәхесләр җитештерә алмадылар. Бәлки, алар булгандыр да, ләкин тарихыбызның мәнбәгълары[3] бик аз калганга, ул мәнбәгълар дә күбрәк рус әсәрләреннән гыйбарәт булганга, андый шәхесләрнең исемнәре дә аз сакланган. Болгарда галимнәр, язучылар, мөәррихләр[4] булуы мәгълүм булса да, борынгы болгарлардан һичбер язучының әсәре сакланмаган. Алтын Урдага килгән сәйяхлар тарафыннан һәм шул заманнан калма ярлыкларда зикер кылына торган мәшаих[5], суфи, талиб вә фәкыйһләрнең исемнәре дә юньләп билгеле түгел, әсәрләре дә безнең заманга кадәр сакланмаган диярлек. Казан, Хаҗитархан, Касыйм дәүләтләрендә дә хәл шулай ук; Хисамеддин Мөслими[6]

[1] Гамилләр – факторлар, хәрәкәткә китерүче көчләр.

[2] Гыйркларының – нәсел-нәсәпләренең.

[3] Мәнбәгълары – чыганаклары.

[4] Мөәррихләр – тарихчылар, тарих язучылар.

[5] Мәшаих – ишаннар, дин галимнәре.

[6] Хисамеддин Мөслими – Хисаметдин бине Шәрәфетдин Болгари-Мөслими, XVIII гасырның ахыры – XIX гасырның башында яшәгән гыйлем иясе, «Тәварихе Болгария» («Болгар тарихы») хезмәтенең авторы.

шикелле берничә зат мәгълүм булса да, коры язучы исемнәреннән генә, әлбәттә, әдәбият тарихы төзергә мөмкин түгел.

Тип игътибары белән дә әдәбиятыбыз тарихының материалын әсаслы[1] рәвештә бер җепкә тезәр хәл юк. Моның өчен бөтен материал тикшерелгән, фән фактлар эзләү дәвереннән үтеп, гомумиләштерү, материалны социология калыбына салу дәрәҗәсенә килеп җиткән булырга кирәк, ләкин, тәәссефкә каршы[2], безнең әдәбиятның үткәнен өйрәнү әле ул дәрәҗәгә җиткәне юк.

Соңгы әсас исә, ягъни татар әдәбиятының үтмешен хронология тәртибенчә, заман артыннан заманга күчеп тасвир итү – фикеребезчә, хәзергә иң асат вә уңайлы юлдыр. Затән[3], «тарих» мәфһүме[4] үзеннән-үзе хронология тәртибен аңгартып[5] тора. Моңар кадәр һич тикшерелмәгән тарихи материалны башта еллар тәртибенчә төзеп күздән кичерү табигый төсле тоелды да, без әсәребезгә кергән материалларны мөмкин булган кадәр шул рәвешчә урнаштырырга карар бирдек. Ләкин бу да безнең өчен мөкәммәл[6], һәр яктан канәгатьләндерерлек юл булып чыкмады. Чөнки борынгы дәвердән калма бик күп әсәрләрнең язылу тарихлары тәгаен мәгълүм түгел; аларны чама белән генә билгеле бер урынга куярга мөмкин. Аннан соң саннары байтак булган бер төркем әсәрләр бар ки, хронология ноктаи нәзарыннан аларны кайда да куярга имкян юк: ул булса, чыгтай вә госманлы әдәбиятларыннан кергән әсәрләрдер. Аларның берсенең дә диярлек татар арасына кайчан килеп керүләре мәгълүм түгел.

Гомумән алганда, материал заман тәртибенчә төзелсә дә, әдәбият юлында хезмәтләре күрелгән һәм аның агымына мөнәсәбәте булган шәхесләргә дә тиешлечә әһәмият бирелеп тукталынды; шулай ук бер-берсенә охшаулары аермачык күз-

[1] Әсаслы – нигезле.
[2] Тәәсеффкә каршы – үкенечкә каршы.
[3] Затән – нигездә.
[4] Мәфһүме – аңлатмасы, төшенчәсе.
[5] Аңгартып – аңлатып.
[6] Мөкәммәл – камил.

гә бәрелеп торган әсәрләр, аерым-аерым группаларга оештырылып, берәр тип буларак каралды (мәсәлән, «Сугыш китаплары», «Кыйсса китаплары», «Догалыклар» шикелле).

Материалны хронологиягә бина кылып[1] төзүнең иң зур уңайсызлыгы әдәбият тарихын дәверләргә бүлү мәсьәләсендә сизелде. Безнең дәверләргә бүлгәндә тоткан әсасыбыз, ягъни идеология әсасы буенча барганда, борынгы (билкөлли[2] шәрык тәэсирендә булган) әдәбият бөтен XIX гасыр буенча сузылып килеп, шул гасырның актыкларында гына юкка чыга. Яңа (Гареб[3] тәэсирендә мәйданга килгән) әдәбиятны исә XVIII гасырның ахырларыннан (Хәлфиннардан) башлап, Фәезхановлар, Мәрҗани, Насыйри вә Акмуллалар[4] аркылы яңа заман әдәбиятына ялгарга туры килә. Шулай итеп, хронология ягыннан караганда, дәверләр бер-берсенә керешле булып чыгалар. Бу

---

[1] Бина кылып – нигезләнеп.

[2] Билкөлли – тулаем.

[3] Гареб – Европа.

[4] «XVIII гасырның ахырларыннан (Хәлфиннардан) башлап, Фәезхановлар, Мәрҗани, Насыйри вә Акмуллалар...» Әдәбият тарихын чорларга бүлгәндә, авторлар борынгы чорны XIX гасыр ахырына кадәр җиткерәләр. Бер үк вакытта Яңа заман әдәбиятының башлангычын XVIII гасыр ахыры дип билгелиләр. Нәтиҗәдә ике чор арасында, күчеш дәвере буларак, бер гасырлык вакыт билгеләнә. Сәгыйт һәм Ибраһим Хәлфиннар башлаган, Ш. Мәрҗаниләр, Х. Фәезхановлар дәвам иткән иҗтимагый-мәдәни хәрәкәт мәгърифәтчелек әдәбияты тудыруга әзерлек буларак урынын таба. К. Насыйрилар, М. Акмуллалар әдәбиятында мәгърифәтчелекнең беренче чаткылары барлана.

Әмма совет әдәбият белемендә, иң беренче чиратта рус әдәбияты тарихына нисбәтле, тәмамланган һәм башланган ноктаны бер итеп билгеләү кабул ителә. Нәтиҗәдә, озак вакытлар дәвамында татар әдәбият белемендә дә уртагасырчылык дәверенең төгәлләнгән һәм Яңа заман әдәбиятының башланган вакытын бер сан белән атау яши. Әмма озак вакытлар дәвамында бу мәсьәләдә төрлелек хөкем сөрә. XX гасырның икенче яртысыннан – ахырына кадәр татар әдәбиятында әлеге күчеш ноктасы дип XVIII гасыр ахырын, XIX гасыр башын яки икенче яртысын күрсәтү яшәп килә. Бары тик XX гасыр ахырында гына М. Госманов, Р. Әмирханов хезмәтләрендә XIX гасырның соңгы чиреге дигән караш урнаша.

Шунысы игътибарга лаек: чит илләр әдәбият белемендә, Г. Газиз һәм Г. Рәхимнәр хезмәтендәге кебек үк, күчеш аралыгын калдыру кабул ителгән. Мәсәлән, төрек әдәбият белемендә ул шулай.

тәртипнең беркадәр уңайсызлыгы, әлбәттә, мәгълүм. Ләкин без, беренче сукмакны салучылар, үзебезнең тоткан принцибыбыз даирәсендә бу читенлекне тагын да уңышлырак рәвештә хәл итә алмадык. Киләчәктә, әдәбият тарихыбыз тагын да эшләнә төшкәч, бу мәсьәләдә башка, канәгатьләнерлек юллар табылыр дип өмет итәбез. Китапның соңгы кыйсеменең сәрләүхәсен[1] «XVII, XVIII һәм XIX гасырларда иске әдәбият» дип куюыбызның да сәбәбе менә шулдыр.

Мөәллифләр[2] бу әсәрдә «әдәбият» дигән мәфһүмгә[3] киң бер караш белән карадылар. Бары шигъри – нәфис әдәбиятка керә торган әсәрләрнең (поэзиянең) генә тарихын язып, башка әсәрләрне тарихның бүтән кыйсемнәренә (мәдәният вә фикер тарихларына) калдыру гадәте, әлбәттә, бар; шулай эшләү һәм мәгъкуль[4] дә. Ләкин бу урында, әдәбиятын яза торган халыкның хосусиятен дә, дәрәҗәи мәдәниясен[5] дә хәтердән чыгармаска тиеш. Безнең Идел буе татарларының вә аларны оештырып бер халык итеп чыгарган болгар, хәзәр, коман һәм монголларның икътисади тормыш шарты аларга нәфис әдәбият белән шөгыльләнергә артык ирек бирмәде. Алар, Яурупаның[6] башка халыклары шикелле, юнан вә руманың әзер мәдәният мохитенә килеп утырмадылар. Болар ярым вәхши күчмә халыклар булып, Азиянең киң сахраларында урын тарайгач, яхшы җәйләү, торырга яңа урыннар эзләп, мәдәният галәменнән ерак торган шәркый Яурупага килеп чыгып, мәдәният баскычында түбән дәрәҗәдә торган фин вә эслаулар[7] янына урнаштылар яисә, бер җиргә дә төпләп урнашмыйча, буш сахраларда күчеп йөри башладылар. Аларга бөтен икътисади, мәдәни дәрәҗәләрне баштан үтәргә туры килде. Шуның өчен алар язу һөнәренә тиз

[1] Сәрләүхәсен – исемен.
[2] Мөәллифләр – авторлар.
[3] Мәфһүмгә – төшенчәгә.
[4] Мәгъкуль – урынлы, дөрес.
[5] Дәрәҗәи мәдәниясен – мәдәниятенең дәрәҗәсен, торышын.
[6] Яурупаның – Европаның.
[7] Эслаулар – славяннар.

өйрәнә алмадылар; башка халыклар шикелле, халык әдәбиятын язма әдәбиятка әверелдерү аларга тиз генә мөмкин булмады. Шуңар күрә дә Идел буе төрк татарларының язган нәрсәләре, безгә кадәр сакланып калган калдыкларына караганда, күбесенчә шигъри әсәрләр булмаенча, кабер ташы, ярлык шикелле тарихи документлар һәм дини вә тарихи әсәрләрдән генә гыйбарәт булды. Шуның өчен мөәллифләргә Идел буе татарларының, әдәбият тарихларына караганда, бигрәк аларның язулары вә әдәби телләре тарихын тикшерергә туры килде. Димәк, бу китап Идел буенда төрк телендә язылган вә укылган әсәрләрне бер яктан гына карамыйча, аларның заманга, мәдәни мохиткә, заманасының фикри хәятына мөнәсәбәтләре, шулай ук телләре, өслүбләре, ниһаять, әдәби кыйммәтләре ягыннан да карап тикшерәчәктер. Әлхасыйль[1], чынлыкта бу әсәр бер әдәбият тарихы булудан өстен, Идел буе татарларының мәдәният тарихларының зур бер кисәген эченә алачактыр.

Бу әсәр мәктәпләрдә дәреслек итеп куллану өчен түгел, бәлки моталәга[2] һәм татар әдәбияты дәресләре укытучы мөгаллимнәргә кулланма итеп истигъмаль итү[3] өчен, шуңа каратыбрак тәртип ителде. Мәктәптә турыдан-туры шәкерт кулына биреп укыту өчен, бу китап һәм озын, һәм уңайсызрак булачак; анда дәреслектә булмаска тиеш булган бик күп озын мөляхәзә[4] вә бәхәсләр, мәхыз[5] фәнни әсәрләрдә генә була торганча тәфтиш[6] вә тикшерүләр бар. Затән[7], моңар кадәр һич тикшерелмәгән бер гыйлем бабында язылган беренче җитди әсәрнең шулай фәнни төстә булып чыгуы табигый. Бер фәннән азмы-күпме эшкә яраклы дәреслек тәртип итү өчен, иң элек ул фәннең,

[1] Әлхасыйль – нәтиҗәдә, җыеп әйткәндә.
[2] Моталәга – уку. Б и р е д ә : «уку дәресе» мәгънәсендә.
[3] Истигъмаль итү – файдалану, куллану.
[4] Мөляхәзә – фикер йөртү.
[5] Мәхыз – фәкать.
[6] Тәфтиш – тикшерү, эзләү.
[7] Затән – нигездә.

кирәгенчә эшләнеп, мөгайян[1] бер система хәленә китерелүе лязим. Татар әдәбияты тарихы исә бу көнгә кадәр җыелмаган, тикшерелмәгән таркау материал шәкелендә иде. Бу әсәр – шул төрле җирдә таралган материалны җыю юлында беренче тәҗрибәдер[2].

Бу әсәрнең мәдхәлдән башка кыйсемнәре аерым-аерым (мөстәкыйль) фикъpә-монографияләр[3] ысулында тәртип ителде. Һәрбер аерым исемдәге фикъpә үз башына мөстәкыйль бер тәфтиш шәкелендә булып, башкалары белән зәгыйфь рәвештә генә багланган. Ләкин китапка кергән фикъpәләрнең, билгеле, бер-берсенә мөнәсәбәтләре юк түгел: алар, югарыда сөйләнеп узылганча, мәгълүм бер әсаста бер-бере артлы тезелеп, һәммәсе бергә бер көллият[4], бер бөтен тәшкил итәләр. Яңа тикшерелә торган материалны бергә оештыру өчен, без хәзергә монографияләр ысулын иң уңайлы ысул таптык.

Аерым фикъpәләр аерым мөәллифләр тарафыннан язылып, имзалар фиһристтә[5] күрсәтелде. Бер фикъpәне язуда мөәллифләрнең кайсысы иң зур хезмәт куеп башкарып чыккан булса, аның астына шуның имзасы куелды. Ләкин фикъpәләрне тәкмил вә тәхрир[6] эше һәр ике мөәллиф тарафыннан уртак рәвештә эшләнде. Үзара эш, беркадәр истисна[7] белән, шушы рәвештә бүленде: госманлы кыйсеме – Г. Газиз, чыгтай кыйсеме, башлыча, Г. Рәхим тарафыннан, «Борынгы тел ядкярләре» – Г. Газиз, мәхкүмиять дәверендәге иске татар әдәбияты, башлыча, Г. Рәхим тарафыннан язылды.

---

[1] Мөгайян – анык.

[2] Китаптагы материалның тәртибе мәсьәләсендә безгә Галимҗан иптәш Ибраһимовның шактый булышлыгы тиде. Урынлы киңәшләре өчен аңар тәшәккер бәян итеп китәргә үзебезне бурычлы санproblemsйбыз. *(Авт. иск.)*.

[3] Фикъpә-монографияләр – монографик планда язылган бүлекләр.

[4] Көллият – җыйналма.

[5] Фиһристтә – эчтәлек битендә.

[6] Тәкмил вә тәхрир – камилләштерү һәм редакцияләү.

[7] Истисна – аерма.

Шуны да әйтеп китәргә кирәк ки, бу китап бер такым гыйльми-фәнни, кыйсмән[1] компилятив тәфтишләрдән гыйбарәт булса да, гомуми укучылар массасына да аңлаешлы булсын өчен, без аны шактый садәләштердек[2], урыны туры килүенә карап, гади укучы өчен һәртөрле бабтан гомуми изахлар[3] да биреп китәргә тырыштык. Өслүбне мөмкин кадәр җиңел, гади укучыны да кызыктырырлык рәвештә җанлы вә тасвири итүне һәрвакыт күз алдында тоттык. Сыйрыф[4] гыйльми әсәрләргә махсус булган ифадәнең[5] корылыгыннан белә торып качтык.

Тизлектә, шушында җыелган материалга бинаән[6], икенче баскыч мәктәпләрнең һәм техникумнарның югары сыйныфларында укыту өчен, педагогика һәм методика кагыйдәләренә туры китереп тәртип ителгән кыскача әдәбият тарихы дәреслеге язып чыгару ниятебез юк түгелдер. Ләкин аерым дәреслек чыкканчыга кадәр бу китапның үзен мәктәпләргә дәреслек урынына куллана торырга мөмкин. Аның артык вә кирәкмәс җирләрен төшереп калдырып, шәкертләр өчен җиңел булган шәкелгә китерү әдәбият мөгаллимнәренең үзләренә тапшырыла.

Татар әдәбияты тарихының борынгы дәверенә хасланган[7] «нәмунәлек» (хрестоматия) тиз көннән тәртип ителеп нәшер ителәчәктер. Анда бу китапта сөйләнгән борынгы әдәби әсәрләрнең, мөмкин кадәр һәммәсеннән нәмунәләр[8] алыначак, тикшерелгән язучыларның да әйберләреннән алынган кисәкләр – катгаләр[9] кертеләчәктер. Кирәк моталәга кылганда[10], кирәк

[1] Кыйсмән – өлешчә.
[2] Садәләштердек – гадиләштердек.
[3] Изахлар – аңлатулар.
[4] Сыйрыф – тулысынча.
[5] Ифадәнең – аңлатуның.
[6] Бинаән – нигезләнеп.
[7] Хасланган – багышланган.
[8] Нәмунәләр – үрнәкләр.
[9] Катгалар – кисәкләр.
[10] Моталәга кылганда – укыганда.

мәктәптә укытканда булсын, әдәбият тарихының нәзари кыйсеме белән нәмунәлеге һичбер вакыт бер-берсеннән аерылып йөртелмәскә тиеш. Чөнки әдәбият тарихы өчен коры нәзария генә бирү, бу фәнне гамәлилектән чыгару, схоластика юлына кую димәктер. Хәтта, әдәбият тарихын өйрәнгәндә, әсәрләрнең текстларына алар хакында сөйләнгән фикер вә мөляхәзәләргә[1] караганда артыграк әһәмият бирелергә тиеш булуы – соңгы заманның тарихы әдәбият методикасы тарафыннан күптән игътираф ителгән[2] хакыйкатьләрдәндер. Аерым хрестоматия чыгарылачак булганга күрә, китапның эчендә мисаллар күп алынмады. Әсәрнең күләмен чамадан тыш зурайтмас өчен, мисалларның да мөмкин кадәр иң кирәклеләрен һәм кыскаларын гына алырга тырышылды.

*Г. Газиз, Г. Рәхим*

[1] Мөляхәзәләргә – уйлауларга, фикер йөртүләргә.
[2] Игътираф ителгән – әйтелгән.

# МӘДХӘЛ

## I
## Борынгы төркләрдә дөньяга караш һәм халык әдәбияты

Бертөрле дә күршеләрнең тәэсиренә бирелмәгән, бары үз тормышы эченә генә батып утырган борынгы төрк халыкларын тарихи бер хакыйкать итеп тасвир итәргә мөмкин булса да, ул эш тарих гыйльме күз карашыннан дөрес булачак түгелдер. Чөнки моның өчен шундый бер караңгы, борынгы заманга чумарга кирәк булыр иде ки, ул замандан тарихи дәвергә кадәр нә бер мәнбәгъ[1], нә дә бер мәгълүмат сакланып калмаган. Дөрес, асаре гатика фәне[2] актарып чыгарган каберләрдән, курганнардан табылган беркадәр нәрсә бар. Ләкин ул курганнарның, бер яктан, төркләрнеке икәне тәмам исбат кылынып җитмәгән, икенче яктан, ул курганнар, каберләрнең вә аларда табыла торган нәрсәләрнең тарихы (хронологиясе) тәмам тәгаен кылынып та бетмәгән әле. Шуның өчен болардан алынган мәгълүмат белән төркләрнең иң борынгы замандагы тормышларын мөҗәррәд иттереп[3] тасвир итү гыйльми яктан хата булачак.

Яурупа голямасының күбесе шикелле, Яурупа археологиясенә истинадән[4] вә хәзерге вәхшиләрне тикшергән соңында, борынгы төркләр вә аларның кардәшләре монголларның тарихи дәверләрендәге «искелек калдыклары» буенча борынгы төркләрнең тормышын тасвир кылуда шактый хата булырга мөмкин. Бу ысул белән барганда бераз хакыйкатькә якын килеп булса да, аның биргән бөтен нәтиҗәләрен катгый хакыйкатькә хисаплау

[1] Мәнбәгъ – чыганак.
[2] Борынгыдан калган матди мирасны өйрәнүче фән, археология.
[3] Мөҗәррәд иттереп – катлаулы итеп.
[4] Истинадән – таянып.

да зур ялгышлык булуы һаман да истисна ителми[1]. Ләкин бу мәсьәләне тикшерү өчен мөәррихнең[2] кулында бер газамәтле[3] корал бар ки, ул да булса «тел фәне»дер. Бу юл белән барып, хәзерге төркләрнең төрле кавемнәрендә булган уртак сүзләрне җыеп, шул сүзләргә истинадән борынгы төркләрнең тормышын тасвир итәләр. Бу корал белән ари[4] җенесенә мәнсүб булган[5] халыкларның тормышына даир күп нәрсәләр кәшеф кылынып[6], кайсысы тәмам хакыйкать дәрәҗәсенә килгән инде. Ләкин хәзергә кадәрле төркләрнең телләрен тикшерү мәсьәләсе әле ибтидаи[7] дәрәҗәдә тора. Аны тикшерүдән соң тормыш тасвирларын бирү хакында моңарчыга кадәр бары Вамбери[8] тарафыннан гына бер тәҗрибә ясалган[9]. Әгәр инде бик борынгы төркләрнең тормышын гомумән тасвир кылу да шактый уңайсыз булса, шул ук төркләрнең фикри хәятларын, аларның ышануларын тасвир итү – тагы да читенрәк бер эштер.

Төрк халкының тарихка мәгълүм булган борынгы заманы – патриархат тормышыдыр. Дөрес, ул патриархат тормышында

---

[1] Истисна ителми – аерып куелмый.

[2] Мөәррихнең – тарихчының.

[3] Газамәтле – олы.

[4] Ари – борынгы ари (һинд-фарсы) телендә сөйләшүче халыкларның атамасы. Төшенчә борынгы фарсы һәм һинд халыкларының тарихи үзатамасыннан (б.э.к. I–II гасыр) килеп чыккан дип исәпләнә. Бу очракта ул шушы мәгънәдә кулланыла.

Жозеф Гобиноның «Эссе о неравенстве человеческих рас» (1853, 1855) хезмәте басылып чыкканнан соң, XIX гасырда ул Аурупада яшәгән борынгы халыкларның атамасы булып йөри. Термин алман национал-социалистлары тарафыннан файдаланыла. XX гасырның беренче яртысында бу концепция кире кагыла һәм кулланылыштан чыгарыла, чөнки аның эчтәлегендә лингвистик һәм антропологик характеристикалар бергә кушыла.

[5] Мәнсүб булган – караган.

[6] Кәшеф кылынып – ачылып, өйрәнелеп.

[7] Ибтидаи – башлангыч.

[8] Арминий Вамбери яки Герман Бамбергер (1832–1913) – күренекле мажар галиме, сәяхәтче һәм шәрыкшинас.

[9] Vambery. Die primitizoe Kultur der Turko-TatarischenVolkes, 1879. *(Авт. иск.)*

катыннарны[1] хөрмәт, олы катын һәм аналарның гаиләдә зур рольләре шикелле фактларда матриархат тормышының калдыклары күренсә дә, тарих төркләрнең чын-чын матриархат тормышы белән торган чакларын белми. Шулай итеп, борынгы төркләр өчен патриархат һәм күчмәле тормыш – бер тип булган иҗтимагый вә икътисади хәяттыр. Шушы икътисади һәм ул китереп чыгарган иҗтимагый халәтнең таләп кылуы буенча, алар да шушы тормышка мөнасиб рухи вә фикри хәятта хөкем сөрде.

Борынгы төркләрдә әле тарихи дәвердә дә хөкүмәт төзелеше бер катгыять алып китмәде. Күчмәле тормыш таләп кылуы аркасында чыккан көтү җирләрен (утлавыкларны) ыруглар арасында тигез вә бер мәгълүм микъдарда бүлү, ачлыктан гаҗиз булгач, сәхраларны ташлап, мөнбит[2] җирләргә күчү аркасында туган яисә Кытай, Иран монархияләренең аларны икътисади эксплуатацияләү өчен тәҗавезләре[3] аркасында чыккан сугышлар төркләргә бик борынгы заманнарда ук дәүләтләр ясарга ярдәм итте. Ләкин бу сәхра империяләре һаман, икътисад таләп кылган сәбәпләр беткәч тә, кире сүтелеп, тәхлил кылынып[4], төркләр кире ыруг вә кабиләләргә бүленеп тордылар[5]. Димәк, борынгы төркләр XVIII гасыр башкортлары вә хәзерге кыргызлар күк ыруг тормышы белән тордылар. Боларда хакимият тә шулай ук ыруг башлыклары кулында булды.

Мәгълүм ки, адәмнәр мәгъбүдләрне[6] үзләренә ошатып ясыйлар. Шуның өчен без борынгы төркләрнең әсасларында пантеизм, ягъни бөтен табигатьне җанландырып табыну һәм сансыз күп мәгъбүдләргә яисә тәңреләргә ышануны күрәбез. Тәңреләргә ышану исә җир вә күкнең бөтен көчен мәгъбүд ясаудан

[1] Катыннарны – хатыннарны.

[2] Мөнбит – уңдырышлы.

[3] Тәҗавезләре – чиктән узулары.

[4] Тәхлил кылынып – аерып.

[5] Моның бик матур мисалларын Радлов «Котадгу белег»кә язган мөкаддимәсендә китерде. Das Kudatku Bilik (Einleitung) и «К вопросу об уйгурах». *(Авт. иск.)*

[6] Мәгъбүдләрне – потларны.

гыйбарәттер. Затән[1], «тәңре» дигән сүз, Вамберинең фикеренчә, «таң» (яктылык) дигән тамырдан алынган[2]. Ләкин борынгы төрк пантеизмын сөйләгән чакта, аларның бу тәңреләргә ничек итеп ышанулары хакында катгый бер сүз әйтүе уңайсыз. Мәгълүм ки, мәдәниятнең түбән дәрәҗәсендә торган халыкларның мантыйкы вә аларның тойгылары безнеке төсле үк булмый. Шуның өчен безнең алардагы игътикад вә фикерләр хакында сөйләгән һәр сүзебез тәхмини[3] генә булып, мәдәни кешенең гакылындан кайнап чыккан бер хыял гына булачакдыр. Шулай да төркләр «тәңреләр»не һәрбер аерым вакыйгада иштиракь кылучы[4] булулары сыйфаты белән аерым мәгъбүдләр итеп танысалар, икенче яктан, «тәңреләр» бөтен галәмгә комга сеңгән су шикелле сеңеп киткәнлекләреннән, табигатьне бер мөҗәррәд (абстрактный)[5] мәфһүм[6] рәвешендә «тәңре» санап яисә бөтен тәңре белән тулган галәмне мәгъбүдләр рәвешендә берләштереп аңлап, «тәңре» яисә «җир-су» дип тә аташтыргалаганнар.

Гомумән, борынгы вәхшиерәк халыкларның диннәрендә бер система эзләү – хата бер эштер. Алардагы дини тойгы гакылларның бергә кушылып хәрәкәт итүеннән гыйбарәт була. Шуның белән бергә, бер үк кавемнең төрле кабиләсе вә ыруглары төрле икътисади халәттә торып, дини тойгылары да шул мөнәсәбәттә төрле-төрле булырга мөмкин. Шуның өчен төрле икътисади халәттә торган күчмә вә ярым утрак төркләрнең диннәрен, гомумиләштереп, бер системага салырга азаплану – фәнни яктан ялгыш бер эштер. Бит борынгы юнаннар[7] Татарстанның бер кантоны кадәрле кечкенә генә җирдә һәммәсе

---

[1] Затән – нигездә.
[2] Vambery. Die primitiwe Kultur… s. 240. *(Авт. иск.)*
[3] Тәхмини – чамалы, якынча.
[4] Иштиракь кылучы – катнашучы.
[5] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[6] Мәфһүм – төшенчә.
[7] Юнан – грек.

тәхминән[1] бертөсле тормыш белән торсалар да, аларның диннәрен дә бер системага салу шактый читен бер эш булды. Шуның өчен без төркләрдә бөек дәүләтләр ясалу дәверләрендә, бәгъзы вакытта аларның хыялларында үзләренең сәяси тормышларына кыясән[2] ясалган мөселман Алласы сымак мөстәбид[3] «хан тәңре»не дә очратабыз. Мәсәлән, мәдәниятнең түбән дәрәҗәсендә торган XIX гасырның мәҗүс чувашларында – «зивалды тура», ягъни бөек тәңре, Орхон төркләрендә «ил бирүче тәңре»[4] бар иде. Борынгы төркләрнең мифологиясендә дә, нәкъ борынгы бабилләрдәге[5] күк югарыдагы күк белән түбәндәге җир кушылганнар да, шулардан кешеләр яратылганнар.

Тәңре, «җир-су»дан башка борынгы төркләрдә без башка мәгъбүдләрне[6] дә очратабыз. Болар шул тәңреләрнең сыйфатлары гынамы, әллә аерым мәгъбүдләрме, билгеле, аны хәл итү югарыда сөйләнгән сәбәпләргә бинаән[7] читен. Мәсәлән, «Аллаһ» мәгънәсендә уйгурчада – «укан», чыгтайчада «уган» сүзе бар. Әгәр бу мәгъбүдләр баш тәңренең бер сыйфаты шикелле генә булсалар, бу сүзләр «укмак» масдарыннан алынганга күрә, «бөтен нәрсәне белүче, аңлаучы» мәгънәсендә булалар. Шулай ук уйгур телендә «баят» яисә «бият» дигән Аллаһ исеме бар. «Бай би», «югары» мәгънәсендә булганга, моны «бөтен нәрсәдән югары» (всевышний)[8] дип тәрҗемә кыларга кирәк була. Уйгур вә Алтай төркләрендә «мәнки», «мәнкү» дигән исем дә очрый. Бу сүз күп вакытта «тәңре» сүзенә кушылып, монголларда «манчутәңре» рәвешендә йөртелә. Гомумән, академик

---

[1] Тәхминән – якынча.

[2] Соңгы елларда Ашмарин кайбер борынгы мәҗүс чуваш мәгъбүдләренең исемнәре Алтын Урда чиновникларының исемнәре белән бер икәнен исбат итте. *(Авт. иск.)*

[3] Мөстәбид – баш; өстен.

[4] Тәңре (тәре)дән монхәрәф булса кирәк. Вамбери, 241 сәхифә. *(Авт. иск.)*

[5] Бабилләрдәге – вавилонлылардагы.

[6] Мәгъбүдләрне – потларны. Б и р е д ә : «илаһи затларны» мәгънәсендә.

[7] Бинаән – таянып, нигезләнеп.

[8] Кирилл хәрефләре белән язылган.

Бартольдның[1] фикеренчә, «тәңре» мәфһүме астында төркләр мадди күкне ирад[2] иткәннәре төсле, мәгънәви күк, ягъни «мәгъбүд»не дә аңлыйлар иде. Хәтта төркләр XI һәм XII гасырларда да күкне мәгъбүдләштереп ышаналар. Шул сәбәпле мөселман Иран мөәррихләре төркләрнең «күк-тәңре» дип ике бер үк мәфһүмне кушып әйтә торган сүзләрен «күктәңресе» дип аңлап, төркләр күкнең аерым бер Алласы бар дип ышаналар дип йөриләр иде. Орхон язулары дәверендә, инде төркләрнең сәяси бер дәүләт ясаган заманнарында «төрк тәңресе» дигән мәфһүм дә хөкем сөрәдер иде[3]. Бу вакыйга бәни Исраилнең[4] «Исраил – Яхва халкы, Яхва – Исраил Алласы» дигән игътикадына бик охшый. Менә шуның өчен дә XIII гасырда төрк-монголларга сәяхәт кылучы Рубрук[5] һәм Плано Карпини[6], мәсьәләне католик гакылына[7] салып, үлчәп, «алар бер аллага ышаналар» дип ышанып кайттылар. Госманлыларда «Чәләб» дигән тагы бер мәгъбүд исеме очрый. Әгәр бу сүз Вамбери әйткәнчә, «чал» һәм «аба» (ата) дигән сүзләрдән мөрәккәб[8] булса, ул чакта бу мәгъбүднең башта бабайлар рухын мәгъбүд итеп танудан гыйбарәт булганын күрәчәкбез. Шулай ук борынгы төрк әдәбиятында тагын бер төрле мәгъбүд исемнәре бар. Алар исә – хәзер дә безнең татарларда очрый торган «ия»ләр. Бу уйгурларда – «итеиде», чыгтайчада инде «изи, әгә, игә» формасында истигъмаль

[1] Бартольд Василий Владимирович (1869–1930) – күренекле шәрекшинас, тюрколог, гарәп теле һәм ислам белгече, тарихчы. Россия шәркыятьчелек мәктәбенә нигез салган галимнәрнең берсе.

[2] Ирад – мисал, дәлил итеп китерү.

[3] Bartold. Die Historische Bedeutung der Altturkiscen Jnschriften. *(Авт. иск.)*

[4] Бәни Исраил – яһүд халкы; Яхва (Иегова) – иудаизмда һәм христианлыкта Алла исемнәренең берсе.

[5] Гильом де Рубрук (якынча 1220–1293) – 1253–1255 елларда француз короле Людовик IX кушуы буенча монголларга сәяхәт итә. «Шәрык илләренә сәяхәт» китабының авторы.

[6] Джованни Плано Карпини (1182–1252) – беренче булып Монголия империясенә сәяхәт иткән европалы, Италиядән.

[7] Гакылына – акылына.

[8] Мөрәккәб – ясалган, кушылып ясалган.

ителә[1]. Алтай татарлары әле дә, безнең Идел буе татарлары шикелле, «ту әясе» (тау иясе), «иш әясе» (урман иясе), «су әясе» бар диләр. Шулар белән бергә борынгы төркләрдә «умай» исемле йорт мәгъбүде дә бар.

Моңарчы сөйләгән мәгъбүдләр – һәммәсе дә яхшылык китерә торган «хәер»[2] мәгъбүдләре. Ләкин төркләрнең мәгъбүд галәме хәерлеләр белән генә бетми. Башка пантеистлардагы шикелле аларда начарлык, явызлык (шәрр) мәгъбүдләре дә бар. Мәсәлән, шулардан берсе – «әрлик» яисә «әрник» аталган җир асты мәгъбүде – бездәге «өрәк» белән бер булган. Алтайлыларда – «үрәкән», чыгтайда – «ирәк», маҗарларда[3] «үрәк» исемле яман мәгъбүдләр очрый. Болардан котылу өчен, корбан яисә «чачлык» бирергә кирәк[4]. Аларны ничек булса да үзеңә якынайтырга, зарарсызландырырга кирәк. Ләкин алар белән дуслашырга вә мөнәсәбәткә керергә һәркем дә булдыра алмый. Аларны «баглар» яисә «бәйләр» өчен аерым догалар яисә «арбаглар» (ар – көч, баг – бау) кирәк. Бу эшләрне «кам» яки «камкатын»нар яисә «баксы», «багучы» һәм «күрәзәләр» генә эшли алалар. Болар гына «багны чишә» алалар, болар гына һәрнәрсәне алдан «багып-күреп», мәгъбүдләрнең зарарларыннан халыкны вә кешене котылдыра алалар. Болар гына кешенең «котын» (җанын) яман көчләрнең шәрренән «коткара» һәм «котыру»дан саклап кала яисә шуннан сәламәтләндерә һәм кешене «котлуг» (бәхетле) итә алалар.

Димәк, борынгы төркнең идеологиясе, аның фикри хәяты бик садә: бөтен табигать – Алла. Ул «җир-су» (галәм), кешеләрне яраткан. Ләкин шул «котлы» (җанлы) галәм эчендә яман һәм яхшы көчләр бар. Менә шулар адәмнәр өчен бер-берсе белән мөттасил[5] көрәшәләр. Адәм бөтен гомерен начар көчләр белән

[1] Истигъмаль ителә – гамәлдә йөри, кулланыла.

[2] Хәер – яхшылык, изгелек.

[3] Маҗар – венгр.

[4] Vambery. Die primitiwe Kultur… s. 246. Борынгы бер кытай мәнбәгы «һәр алты айда бер ту-күәләр рухларга корбан чалырга җыелалар», ди. Chavannes, Documents sur les Tou-Kiue occedenteux, p. 15. *(Авт. иск.)*

[5] Мөттасил – өзлексез.

көрәштә үткәрә. Ләкин яхшы көчләр аңар ярдәм итәләр. Шуның аркасында бөтен галәмдә туктаусыз низаглар бара, тартыш хөкем сөрә.

Борынгы төркләрнең әхлакка карашлары да үзләренең икътисади халәтләренә мөнасиб[1] булып, аларда һәрбер күчмә халыкларда булган шикелле кунакчыллык, гайрәт вә сугышчанлык, һәрбер патриархат тормышында булган шикелле атага буйсыну, зинага зур гөнаһ итеп карау, хосусый милекне изге нәрсә итеп тану, шуның аркасында урлаган өчен зур җәзалар тәгаен кылу, атасы үлгәч – үги анасын, агасы яисә энесе үлгәч җиңгә яки киленне никах итү шикелле гадәтләр хөкем сөрә иде[2].

Шулай итеп, борынгы төркләрдә чын мәгънәсе белән бертөрле катгый идеология табарга мөмкин түгел. Булган идеологияләре дә аларның күчмә тормыш, патриархи-иҗтимагый дәрәҗә, шаман дине китереп чыгарган фикер вә тойгылардан гыйбарәт. Бу идеологияне үз күзе белән күрәсе килгән кешегә бары бер юл гына бар, ул да булса, халык теленнән алынып язылган «Коркыд»[3], «Сәид Баттал»[4], «Сары Салтык Гази»[5] шикелле дастаннар вә борынгыдан бирле авыздан-авызга әйтелеп йөртелә торган табышмак, мәкаль, җыр вә дастаннар шикелле халык әсәрләрен укып, алардагы ислам тәэсирен алып ташлап, чын төрк гонсы-

[1] Мөнасиб – ярашлы, тәңгәл.

[2] Бу хакта тәфсилле мәгълүмат Гирләнднең (*Гурлянд Я.И.*) «Степное законодательство» дигән әсәреннән табарга мөмкин. *(Авт. иск.)*

[3] «Коркыд» – «Китабе Коркыд» – төрки халыкларның борынгы эпосы. Атама IX гасырда Сырдәрья буенда яшәгән легендар акын, җырчы, әкиятче һәм композитор (кубызны уйлап табучы дип тә әйтәләр) Коркыт исеме белән бәйле, шуңа аны «Коркыт ата китабы» дип тә йөртәләр. Эпос мөстәкыйль сюжетлы күп тарихларны бергә туплый. Әмма аларның барысында да төп герой ролендә акыл иясе, әйдаман, күрәзәче Коркыт килә. Аның исеме «курку» сүзеннән алынган, эпос, иң беренче чиратта, төрки халыкларның яшәү һәм үлем, гомернең чиклелеге турындагы фәлсәфәсен үзенә туплаган.

[4] «Сәид Баттал» – ярым дини, ярым дөньяви, халык арасында телдән-телгә күчеп яшәгән каһарман эпосы. Сәид Баттал җитәкләгән сугышчыларның дин юлында кылган батырлыкларына дан җырлый.

[5] «Сары Салтык гази» – төрки әдәбиятларда таралыш алган ярым дини, ярым дөньяви дастаннарның берсе.

рын[1] гына калдырып караудыр. Димәк, иң борынгы төркләрнең идеологияләрен күрсәтүче көзге – халык әдәбиятыдыр.

* * *

Мәгълүм ки, борынгы төркләр өчен тип шәкелендә булган тормыш – күчмәлек иде. Мондый дәрәҗәи мәдәниядә торган халыкларда без, гомумән, халык әдәбиятының бай булуын күрәбез. Борынгы бәдәви гарәпләрдә халык әдәбиятының байлыгы – мәгълүм мәсьәләләрдәндер. Болай да язма әдәбият таралмас борын, халык әдәбияты һәммә гөруһ[2] халыкларда да бик тәрәккый иткән була. Бухарин[3] шикелле икътисад галимнәре халык җырларының вә музыкасының хезмәт белән бергә, коллектив рәвештә эшләгәндә килеп чыккан булучылыгын исбат иттеләр. Күчмә халыкларда, шул җөмләдән төрк халыкларында да бик борынгы заманнардан бирле җыр вә музыканың шактый таралган булуы, табигый, аларның икътисади хәятлары белән бергә багланган.

Борынгы күчмә төрк халыкларын шул ук тормыш вә кәсеп сугышчан булырга мәҗбүр итте: аларга хайваннарны, малтуарны erткычлардан сакларга, күчеп, яхшы кырлар эзләп, «кыр гизеп» йөргәндә, ят кабилә вә халыклар белән очрашырга, күп вакытта яңа утлавыкларны корал куәте белән сугышып алырга, шул ук Кытай, Иран шикелле мәдәни (вә заманасының империалист) илләрнең һөҗүменнән «йорт»ны, «олыс»ны, «ил»не сакларга кирәк була иде. Мал-туар үләт белән кырылган чакларда, ачлыктан гаҗиз булып, борынгы төркләр күрше илләргә, бай кабиләләргә һөҗүм итеп, талап азык табарга мәҗбүр булып тордылар. Шулай ук аксөяк ыруг, вә кабиләләр, карасөяк ыругларын үзләренә буйсындырып тору өчен, борынгы Спартадагы[4] хөкүмәт сөрүче сыйныфлар шикелле, һәрвакытта

[1] Гонсырын – элементын, состав өлешен.

[2] Гөруһ – төркем.

[3] Бухарин Николай Иванович (1888–1938) – революционер, совет сәяси һәм дәүләт эшлеклесе. Белеме буенча икътисадчы.

[4] Спарта – Борынгы Грециядәге шәһәр, колларны сугыштыруны сәясәт дәрәҗәсенә күтәргән антик аристократик дәүләт.

коралланып торырга; карасөякләргә дә, кысылуның чиге килеп җитә башлагач, баш ыругларга каршы тору өчен, найза[1], айбалта, кылыч вә ук-җәяләрен кулларыннан төшермәскә тиеш булды. Шуның өчен борынгы төркләр иҗтимагый тормышларын да унга бүлү әсасы[2] белән гаскәрилек рәвешендә эшләделәр. Менә шушы сугышчанлыкны саклау өчен, аларга рухны күтәрә торган музыка вә җырлар кирәк иде. Шуның өчен борынгы төркләр вә монголларда сугыш алдыннан кубыз уйнап гаскәрне кыздырып тору гадәте бар иде. Сугышлардан кайткач та, ил шагыйрьләре «узан»нар[3], «акын»нар, үләң әйтеп, борынгы батырларны мактап, хәзерге егетләрне җилкендерәләр иде. Русларның иске мәнбәгъларыннан[4] «Слово о полку Игореве»[5] безгә борынгы команполовецлардагы шундый гадәтне тасвир итә. Шулай ук түбәндә сөйләнәчәк борынгы сәлҗук төркләренең[6] халык дастаннары мәҗмугасы «Китабе Коркыд» та халык җырчысы узанның, «илдән илгә, бәйдән бәйгә» йөреп, борынгы сугышларны сөйләп, баһадирларның канын кыздырганын бәян кыла.

Икенче яктан, борынгы төрк халыкларында халык әдәбиятының тәрәккый итүенә сәбәп – күчмә халыкның шул эш белән шөгыльләнергә вакыты булуындадыр. Сугыштан тыныч чакларда күчмә төрккә артык эш юк. Аның бөтен йорт вә көнкүреш эшләрен хатыннары башкаралар, игенченеке төсле көн саен булып, күп хезмәт сорый торган шөгыльләр аларда юк. Шуның өчен академик Радлов борынгы төркләрдән мәдәни дәрәҗәдә артык алга китмәгән күчмә кыргызлар хакында сөйләгәндә, «матур сөйләү сәнгатен өйрәнергә кыргызның вакыты бар. Ул көн-төн сөйли, йокы белән ашау гына – аның сөйләвенә манигъ[7]

[1] Найза – сөңге.
[2] Әсасы – нигезе.
[3] Узан, озан, узанчы – җырчы, дастанчы, халык шагыйре.
[4] Мәнбәгъларыннан – чыганакларыннан.
[5] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[6] Сәлҗук – Х гасырда Урта Азиядә яшәгән төрки кабиләләр атамасы, төрки халыкларның угыз-төрекмән канатына карый.
[7] Манигъ – киртә.

була торган шөгыльләр; һәм дәрвакигъ кыргызлар фәсахәт вә матур сөйләү белән аерылалар», ди[1].

Халык әдәбиятының киңлеге, байлыгы ягыннан күчмәле төркләр никадәр утрак халыклардан алда торсалар, халык әдәбияты әсәрләрен иҗат һәм хәтердә саклау җәһәтеннән дә алар шулай ук югары торалар. Күчмәле төркләрнең кәсепче (профессионал) җырчылары шулкадәр күп әйбер күңелдән беләләр ки, мәдәни халыкларга аларның хәтер куәтләренең көчлелегенә гаҗәпләнергә туры килә. Алар ифрат озын дастаннарны, бихисап җырларны, әкият вә легендаларны күңелдән белә торган булалар. Профессионал җырчылар алар – күбесенчә шагыйрьләр дә. Телдән-телгә йөргән әдәбиятны тудыручылар, үзгәртүчеләр һәм саклаучылар да шулар. Ләкин алар халык әдәбиятында бик гам[2] булган шаблоннар (калыплар) буенча гына иҗат итеп, шагыйрьнең шәхсияте (индивидуальность)[3] әсәрләрендә аермачык күзгә ташланмаганга, гомум авыз әдәбиятындагы гадәт буенча, аерым шагыйрьләрнең намәләре хәтердә сакланмый, аларның әсәрләре дә гомумхалык әдәбияты массасына кушылып, халык малы булып китә. Шулай итеп, халык әдәбияты әсәрләре мәйданга килә.

Дала шагыйрьләре бик көчле рәвештә импровизация куәсенә дә малик[4] булалар. Ягъни алар тоткарсыз, фикерләренә килү белән, теләгән нәрсәләре хакында шигырь тезеп әйтә алалар. Язу сәнгатенең керүе аркасында мәдәни-утрак халыклар арасында инде бу куәт югалган. Чөнки алар һәрбер фикерләрен сөйләү аркылы түгел, бәлки кәгазьгә язу аркылы изһар итәргә[5] өйрәнгәннәр. Артык бер әйбер булып калганга, импровизация ташланган, онытылган. Мәдәни тормышта бик сирәк шагыйрьләрдә генә ул заһир була[6]. Әмма дала шагыйрьләре өчен бу бик гади

[1] Образцы народной литературы тюркских племен, ч. V, с. 4. Шул ук әсәрдә һәртөрле төрк халыкларының халык әдәбиятларыннан нәмунәләр табарга мөмкин. *(Авт. иск.)*

[2] Гам – гомуми.

[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[4] Малик – ия.

[5] Изһар итәргә – күрсәтергә.

[6] Заһир була – күренә.

нәрсә. Алар берничә сәгать тоташтан авызларыннан яңадан-яңа мәүзугларга[1] шигырьләр коеп тора алалар. Халык әдәбиятында күп мәүзугларга әзер калыплар, әзер гыйбарә вә җөмләләр, хәтта бөтен-бөтен мисраглар булганга, кәсепче җырчы өчен бу артык читен эш түгел. Аның бөтен осталыгы шул әзер кисәкләрне шома итеп ялгап җибәрүдән генә гыйбарәт. Мәсәлән, бер-бер җыен яки туйда шагыйрь-җырчы шунда хәзер булган кунакларны һәм йорт хуҗасын таусиф итеп[2] мактап, исемнәрен атап җырлый; хуҗаның дошманнарын сәлеб итеп[3], алардан көлә. Мәҗлескә яңа бер кеше килеп керү белән, ул, шигыренең агышын бозмастан, мәүзугны яңа килүчегә күчерә. Аңлаучылар даирәсе байлардан гыйбарәт икән – ул байларны, байлыкны, юмартлыкны мактап җырлый, ярлыларда[н] гыйбарәт икән – байларны яманларга, аларның начар сыйфатларын тезәргә тотына, чөнки халык өстендә туена торган халык җырчысына шулай тыңлаучыларына ярарга тырышмый ярамый. Аннан соң оста импровизаторлар бәгъзы мәҗлесләрдә үзара әдәби ярышлар ясыйлар, ягъни алар шигырь әйтешеп, сүз көрәштереп, бер-берсен илзам итәргә[4], җаваптан, дәвам итүдән гаҗиз итәргә тырышалар. Хәзерге дала казакъларында да бар бу гадәт. Бәгъзан[5] ике «әйткеч», бер-берсен җаваптан калдыра алмыйча, төннәр буенча шигырь әйтешеп чыгалар икән. Менә бу гадәтләр күчмәле төрк халыкларында борынгы заманнарда да, шөбһәсез, булгандыр, бәлки тагын да куәтлерәк хөкем сөргәндер.

Җыеннарда картлар, осталар җыелып курай уйнау, җырлау, самак әйтү[6] шикелле борынгы күчмәлектән калган гадәтләр безнең башкортларда да әле хәзергә кадәр сакланган. Күптән утраклыкка күчүләренә карамый, профессионал дастанчылар Анатулы[7] төркләрендә дә очрый. Болар хәзер авылдан авылга

[1] Мәүзуг – тема.

[2] Таусиф итеп – сурәтләп.

[3] Сәлеб итеп – кире кагып.

[4] Илзам итәргә – җавапсыз калдырырга.

[5] Бәгъзан – кайвакыт.

[6] Самак әйтү – көйле сүз әйтү; көйле сүз-фикер ярышы, шул ярышны илзамга – берәүнең җиңеп чыгуына китереп җиткерү.

[7] Анатулы – Анатолия (Төркиядәге шәһәр).

йөреп, кайчан калаларга да килеп, каһвәханәләрдә халык җыеп, «Сәид Баттал» шикелле ярым халык әсәре булган дастаннарны яки «Хуҗа Насреддин»[1] ләтыйфәләре күк халык иҗаты булган анекдотларны сөйлиләр. Төркиядә хәзер боларны мәддах («мактаучы») дип әйтәләр. Бу мәддахлар– шиксез, шул борынгы «Китабе Коркыд»та сөйләнгән илдән узаннарның варисларыдыр.

Борынгы төркләрнең халык әдәбияты үз вакытында язып алынмаганга күрә, бары мәнбәгъларда генә булган бәгъзы киналәр аркылы борынгы авыз әдәбиятының нинди булуы хакында катгый бер фикергә килергә мөмкин түгел. Чөнки заманнарның агышы белән бертуктаусыз үзгәреп тору – халык әдәбияты дигән нәрсәнең төп хассасыннандыр[2]. Шулай да мәсьәләне ачарга бөтенләй үк имкян юк дип әйтеп булмый. Ул да булса, хәзерге түбәнрәк мәдәни дәрәҗәдә торган, читләр вә дин тәэсирләренә азрак бирелгән төрк кабиләләренең халык әдәбиятын өйрәнеп, шуннан заманнар буенча катланып килгән катлауларны алып ташлау соңында, шул әсәрләр – борынгы заман әсәрләре (яки шуларга бик якын) дип танудыр. Вакыйган[3], без бу халык әсәрләрен борынгы заманныкы дип таный алабыз. Күчмә төрк халыклары, бөтен күчмә халыклар шикелле, шактый консерватор табигатьлеләр. Аларның бу әсәрләре ата-баба әсәрләре булу йөзеннән изге нәрсә ителеп танылганга, аларны җырчылар күңелләрендә саклыйлар (нәкъ безнең татар әбиләре куркылык, чалпу шикелле шаманизм калдыгы гадәтләрендә әйтелә торган сүзләрне саклаган төсле). Әгәр без моның өстенә «Коркыд», «Сәид Баттал», «Күр угълы», «Хуҗа Насреддин» шикелле, хәзер язылып алынган булса да, электә халык телендә йөргән дастан, кыйсса вә хикәяләрне дә арттырсак, төркләрдә борынгы халык әдәбиятының нидән гыйбарәт булуы хакында бер фикер ясый алабыз. Ләкин ничек тә аларның нинди әсәрләр булганлыгын тәгаенләп әйтеп булмый.

[1] «Хуҗа Насреддин» – Насретдин турында халык арасында яшәгән көлкемәзәкләр тупланмасы.

[2] Хассасыннандыр – үзенчәлегеннәндер.

[3] Вакыйган – чыннан да.

Шактый иске заманнарда язылып алынып сакланган халык әдәбияты әсәрләреннән иң мөһиме вә хәзер дә халык хәтереннән югалганы – мәшһүр «Китабе Коркыд»тыр. Бу әсәр нәсер белән язылган, ләкин төзелеш, мәүзуг[1] вә өслүбе белән ул – чын бер каһарман дастаны. Бу китап – борынгы төрк әсәрләре арасында бөтенләй аерым урын тота торган эре энҗеләрдәндер. Аның саф халык иҗаты булган (беркадәр Орхон язуларының өслүбен хәтерләтә торган) теле шулкадәр шигъри, матур вә фәсыйх[2], бәлигъ[3] ки, хәзерге көндә төрк әдипләре үз өслүбләрен шул юл белән алып барсалар, зур муәффәкыять[4] казанырлар иде. Үзенең әдәби кыйммәте белән бергә теленең дә ифрат борынгы (архаик) булуы аркасында, бу әсәр рус-яурупа галимнәрен бик кызыксындыра. Аңар зур әһәмият бирелеп, аның хакында шактый әдәбият та мәйданга килгән. Бу китап хәзергә бер-ике генә кулъязмада табылган. Анадулда табылып, борынгы җәнүб[5] төркчәсендә язылган булса да, госманлылар үзләре бу әсәр хакында бернәрсә дә белмиләр. Алар өчен юл тәмам югалган[6].

Бу әсәрне башта госманлы вә сәлҗук төркләренең бабалары угыз[7] төркләре арасында мәйданга килгән булырга кирәк дип чамалыйлар[8].

Мәгълүм ки, угызлар – хәзерге төрекмәннәрнең дә бабалары, шулардан ук госманлы халкы килеп чыккан. Китапның мөндә-

---

[1] Мәүзуг – тема.

[2] Фәсыйх – әдәби, килешле.

[3] Бәлигъ – төзек, тулы мәгънәле.

[4] Муәффәкыять – уңыш.

[5] Җәнүб – көньяк.

[6] Переводы отдельных рассказов В.В. Бартольда в Зап. Вост. Отд. Им. Арх. О-ва: VII, 203–219; XI, 175–194; XII, 37–59. *(Авт. иск.)*

[7] Угызлар – хәзерге Азәрбайҗан, Гыйрак, Иран, Сүрия, Төрекмәнстан, Төркия җирләрендә яшәгән төрки кабилә; угыз теле – төрки телләрнең бер тармагы. Угыз субэтник төркеменә төрекмәннәр, азәрбайҗаннар һәм төрекләр керә. «Угызнамә» – төрки халыкларның угыз тармагы тарихын һәм мәдәниятен чагылдырган борынгы эпосы.

[8] Статьи: в Зап. Вост. Отд. 1) Бартольд/ «Коркуд», IX, 272–274; 2) Его же. «Еще известье о Коркуде», XIX, 173–178; 3) Туманский. По поводу «Китаби Коркуд», IX, 269–272; 4) А. Диваев. О могиле свят. Хорхут-ата, X, 193–195, 5) Ditz, Den Wurdigen von Asien, II, 399. *(Авт. иск.)*

рижәсе[1] шулай: мөкаддимә (монда мәкальләр, афоризмнар, кыскача характеристикалар), унике данә аерым хикәя. Тел вә өслүбе бер булу, һәрбер хикәядә алда сөйләнгән кешеләрне, баһадир вә каһарманнарны, вакыйгаларны әйтеп китү, тәкрар кылулар – бу әсәрнең бер иттифакый[2] мәҗмуга гына булмыйча, «Илиада» вә «Одиссея» шикелле бербөтен поэма (дастан) булуын күрсәтәләр.

Хикәяләрдәге вакыйгалар күбрәк Әрмәнстан тауларында вакыйг булалар. Каһарманнарның дошманнары гөрҗи[3], Кара диңгез буендагы абхаз халкы һәм Трабзон румнары. Монда тасвир кылына торган каһарманнардан мәркәзи шәхес – угызларның баш ханы Баяндәр хан. Ул үзе сугышларда иштирәк кылмый[4]. Чын сугышчы каһарман исә аның кияве – Казан бәй.

Коркыд баба[5] булса, ул – баһадир түгел, бәлки илнең аксакалы, патриарх. Ул – бөтен төрк халкының хикмәтен үзенә җыйган бер кеше. Аның кем икәне мәгълүм түгел. Әсәрнең үзендә аның, Мөхәммәд заманында булып, хак мөселман булганлыгы сөйләнә. Ләкин аның тарихи шәхесме, әллә уйдырма, хыялдан туган бер кешеме икәне һаман да хәл кылынмаган. Шулай да борынгы гарәп мөәррихләре бер вакытта, XII гасырда угыз халкының башында Коркыд исемле кеше булганлыгын сөйлиләр, төрекмәннәрдә, кыргызларда һәм Кавказ таулары артындагы халыкларның телендә дә «Коркыд», «Хорхуд Ата» исемле каһарманнар сөйләнә. Бер рум мәнбагы угызларга якын булган пәчәнәкләрдә[6] дә бер «Коркыд» исемле башлык булганын

[1] Мөндәриҗәсе – эчтәлеге.
[2] Иттифакый – очраклы.
[3] Гөрҗи – грузин.
[4] Иштирәк кылмый – катнашмый.
[5] Куркыту фигыленьнән боерык сигасе. Татарча әйткәндә, Куркыт Баба булырга тиеш. *(Авт. иск.)*
[6] Пәчәнәкләр – бәҗәнәкләр, VIII–IX гасырларда төрки, шулай ук сармат, фин-угор кабиләләре оештырган бердәмлек. Н.А. Баскаков аларның телен төрки телләрнең угыз төркеменә кертә. В. Бартольд, гарәп чыганакларына таянып, аларны угыз кабиләсе дип белдерә.

Аурупа һәм юнан чыганакларында – «пацинаки», гарәп чыганакларында «бәҗнәк» һәм «бәҗәнә» вариантлары кулланыла. С.А. Плетнева атаманың төрки телдәге Бәче/Бәҗе (кабилә юлбашчысы) исеменнән килеп чыгуын фаразлый. О. Сөләйманов «баҗа/баҗанак» дигән туганлык атамасы белән бәйләп карый.

сөйли. Әлхасыйль[1], бу исем – борынгыдан килгән, угыз төркләре арасында мәшһүр булган бер кешенең яисә чынлыкта булмаган, хыялый бер шәхеснең исемедер[2].

«Китабе Коркыд»та һәрбер хикәя халык җырчысы (узан) исеменнән сөйләнә. Бу җырчы хакында «Кулҗа купыз күтәреп илдән илә, бәкдән бәкә узан кизәр. Ар җумрдин ар нәкисен узан белүр» (Кулына кубыз тотып, җырчы илдән илгә, байдан байга йөри. Ирнең гайрәтлесен һәм куркагын җырчы беләэ), диелә.

Бу хикәяләрнең кайчан ясалуын тәгаен әйтеп булмаса да, профессор Бартольдларның Солтан Баязид I заманыннан да (1389–1402) соң җыелмаган (бергә оештырылмаган) булуын дәгъва итә.

Дини буяуга буялган, каһарманы да гарәп булган «Мәнакибе Сәид Баттал» күбрәк гали сыйныф: баһадир, әмир, солтан, халифә, кайсар, вәзирләрнең хәятын сөйләсә, «Китабе Коркыд»та без «чобан» (көтүче) сыйныфын да тасвирны күрәбез. Бу сүзебезне исбат өчен, «Китабе Коркыд»тагы бер хикәянең хөласасен[3] алыйк. «Бервакытта, үзе юк чакта, кяферләр, Казан бәйнең йортын талап, аның ун мең куен алып китмәкче булдылар. Коралсыз көтүче (чобан), ике борадәре белән берләшеп, дошманны җиңделәр. Бервакытны Казан бәй кайтып, көтүчене орышырга тотынды. Чобан исә аңар шулай дип җавап бирде: “Бәем, агам Казан! Ник миңа ачуланасың? Әллә синең йөрәгеңдә иман юкмы? Алты йөз кяфер минем өстемә килделәр. Минем ике кардәшем дә үлделәр. Мин өч йөз кяферне үтердем һәм аларга синең симез куйларыңны бирмәдем. Өч урыннан яралы булдым. Минем кара башым бөгелде. Мин ялгыз калдым. Минем гаебем шундамыни? Бир син миңа күк атыңны, бир озын сөңге, бир ак калкан, бир кара булат, бир үзеңнең калчаныңнан уклар, бир каты җәя – мин аларны үтерермен, үземнең арка һәм

[1] Әлхасыйль – нәтиҗәдә, җыеп әйткәндә.

[2] Иностранцев К. Коркуд в истории и легенде, с. 40 (зап. вост. отд. том 20). *(Авт. иск.)*

[3] Хөласа – йомгак.

йөземнән кан агызырмын!” Казан ачуланып китте. Чобан да аның артыннан китте. Бераз баргач, Казан аңар әйләнеп әйтте:

– Кая барасың син, углым чобан?

– Агам, Казан! Син йортыңны алыр өчен барасың, мин үз кардәшләремнең үчен алыр өчен барам.

– Углым чобан! Ач мин, синдә ашарга бирәр нәрсә юкмы?

Чобан бәйне туйдырды. Шуңар Казанның башына шундый уй килде: “Әгәр мин көтүче белән бергә барсам, башка угыз бәйләре мине сүгәрләр һәм чобаннан башка Казан кәферләрне җиңә алмас иде диярләр”. Шуннан соң Казан, көтүчене бер агач янына чакырып китереп: “Бу агачны тамыры белән алып ташла. Әгәр шуны эшләмәсәң, сине бүреләр һәм кошлар ашарлар”, – диде. Көтүче агачны тамыры белән алып, аркасына күтәреп, Казан бәйнең артыннан йөгереп куып җитте. Казан сорады:

– Бу нинди агач, чобан?

– Агам, Казан! Син кяферләрне җиңәрсең, карының ачар. Бу агачны яндырып, мин сиңа аш пешерермен.

Казанга бу җавап бик ошады. Кяферләрне җиңгәч, Казан көтүчене зур дәрәҗәле кеше ясады».

Менә мондый халык хәятын тасвир иткән хикәяләрне без сугыш китапларында бик сирәк очрата алабыз. Әсәрдә дини фанатизм да ул кадәр күп түгел. Мондагы сугышлар да күбрәк «кяфер»ләр белән булса да, борынгы төркләрдә булганча, сугышның үзенә табыну әсәре дә бар. Сугыш эшендә үзен күрсәтеп, ат казанмаган егеткә Коркыд бабай бервакытта да ат кушмый. Егетләр, исем алыр өчен, «баш кисәргә, кан түгәргә» тиешләр. Коркыд китабындагы каһарманнарда исламга мәхәббәт тә алай ук юк. Мәсәлән, атасыннан разый булмаган угыл, яисә ханнан нәразый[1] бәй һәрвакытта «христианнар арасына китәрмен, аларның кулын үбәрмен», дип куркыта. Батырлар, дуңгыз ите ашамасалар да, аракыны бик сөеп һәм ачыктан-ачык эчәләр. «Китабе Коркыд»та иске төркләрнең мәҗүс гадәтләре

[1] Нәразый – разый түгел.

дә очрый. Без анда бөтен төрк халыкларында изге хисапланган «корд» (бүре)не хөрмәтләүне күрәбез. Мәсәлән, бер урында «корд йөзе мөбарәк», диелә. Шулай ук «Хәсән илә Хөсәеннең хәсрәте – су, Гайшә илә Фатыйманың никахы – су» дигәннән мөселман изгеләре белән бергә мөкаддәс «су»га да хөрмәтне күрәбез. Шулай ук «Деле Дөмрел», ант иткәндә, «гарш, көрси» белән бергә «җир танык булсын! Күк танык булсын!» дип, төркләрдә мөкаддәс булган «җир һәм күк»не гуаһлыкка чакыра.

«Китабе Коркыд»та без, гареб[1] рыцарьләрендәге шикелле, хатын-кызны хөрмәтләүне дә очратабыз. Хикәятләр эчендә Деле Дөмрел исемле бер батырның үлем фәрештәсе Газраил белән көрәше хакында хикәя бар. Сугышның ниһаятендә Газраил җиңеп, Дөмрелнең күкрәгенә менеп утырып, җанын алмакчы була. Дөмрел, Тәңрегә мөрәҗәгать кылып, котылдыруны сорый. Дөмрелнең сүзе Тәңрегә хуш килеп әйтә: «Йә, Газраил, Деле Дөмрел җаны йәренә җан булсун[2]. Анун җаны азад улсун», – ди. Дөмрел, карт атасы белән карчык анасына минем өчен җаныгызны бирегез, дип мөрәҗәгать кыла. Ләкин Дөмрелгә атасы да, анасы да бер бәһанә табып җаннарын бирмиләр, «җан газиз», диләр. Өметен кискән Дөмрел, Газраилдән хатыны белән күрешергә генә миһләт[3] сорап: «Яд[4] кызы хәләлем[5] вар. Андан минем ике угланчыгым вар. Аманәтем вар, асмарларәм[6] анларә. Андан сукрә мәнем җаным аласән», – ди. Шуннан соң ул «хәләле янына килде. Әйдер: билүрмисән нәләр улды? Күк йөзендән ал канатлы Газраил очып килде, агҗә мәнем күксәме[7] басуб кунды, татлы мәнем җанымны алур улды. Бабама[8] вир дидем җан – вирмәде. Анама вардым – җан вирмәде. Дө-

[1] Гареб – көнбатыш.
[2] Тапсын. *(Авт. иск.)*
[3] Миһләт – вакытны кичектереп тору.
[4] Ят кеше. *(Авт. иск.)*
[5] Хатыным. *(Авт. иск.)*
[6] Асмарладым – тапшырам. *(Авт. иск.)*
[7] Минем ак күкрәгемне. *(Авт. иск.)*
[8] Атама. *(Авт. иск.)*

нья ширин[1], җан татлы, диделәр. Әмди юксәк-юксәк[2] карә тагларым сәка[3] йәйлак[4] улсун, суык-суык суларым сәка ичт улсун, таулә-таулә шаһбаз атларым сәка бәнт улсун. Алтун бан аем сәка күлкә улсун, катар-катар дүәләрем сәка юкәлт улсун, агаелдә агҗә каюным сәка шулән улсун, күзәк кеме тутәрсә күкләк кеме сурсә сән ака варгыл аки угланчыгы үксез кумагыл, диде Горт. Бурада сөйләмеш күрәлем ханым нә сөйләмеш идәр нә диерсән нә сөйләрсән күз ачыб күрдүкем күкел виреб сүдекем куҗ йекедем, шаһ йекедем татлу дәмаг виреб суращдыгым бер йасдыкда баш куюб амещдәкем каршы йатан карә тагларәк сәндән сукрә мән ниләрем йыйлар улсәм, мәнем күрәм улсун, суык-суык суларуң эчәр улсәм, мәнем каным улсун, алтун акчәк хуҗәләр улсәм, мәнем кәфтем улсун. Таулә-таулә шаһбаз атуң бинәр улсам, мәнем табутым улсун. Сәндән сукрә бер йекеде сүеб варсам билә ятсам, ала йылан улуб мәне суксун. Сәнең ул михнәт анаң-бабаң бер җандә нә вар ки сәка кыймамышлар гареш танигъ улсун, көрси танигъ улсун, йир танигъ улсун, күк танигъ улсун, Кадир Тәңре танигъ улсун, мәнем җаным сәнең җанкә корбан улсун, диде. Разый улды Газраил хатуның җанын алмага килде адәми урыны йулдашына кыямды Аллаһ Тәгаләйә бурадә ялвармыш күрәлем ничә ялвармыш идәр йужәләрдән йуҗәсән кемсә белмәз ниҗәсән күрклү Тәңре чук җаһилләр сәне күкдә арар йирдә астәр сән худ мөэминләрең күкелендә сән даим туран җаббар Тәңре улу йуллар үзренә гыймарәтләр йапаем».

«Китабе Коркыд»ның телендә игътибар итәргә тиешле нокта – асылда җәнүб[5] төркчәсе булуы белән бергә, анда башка төрк телләре белән (мәсәлән, татарча) уртак сүз вә сарфи[6]

---

[1] Дөнья татлы. *(Авт. иск.)*
[2] Биек-биек. *(Авт. иск.)*
[3] Сәка – сәңа – сиңа.
[4] Җәйләү. *(Авт. иск.)*
[5] Җәнүб – көньяк.
[6] Сарфи – грамматик.

формаларның очравыдыр. Хәзерге әдәби госманлычада алар урынына башка сүзләр һәм формалар истигъмаль ителә[1].

Борынгы төрк халык әдәбиятында гадәттә була торган һәр төрле төрләр: баһадирлык дастаны (богатырский эпос)[2], экиятләр һәм риваятьләр (легенда), көлке анекдотлар һәм мәсәлләр, табышмаклар, мәкальләр һәм сүз җыелмалары[3], җырлар, шаман теләкләре вә тылсымнары, хәтта ибтидаи драматик әсәрләр – һәркайсы булгандыр.

Төрк халыклары шикелле күчмәле һәм сугышчан халыклар арасында һәрвакыт баһадирлар дастаны (хыялый яки ярым тарихи батырларның каһарманлыклары хакындагы поэмалар) халык әдәбиятының иң көчле һәм таралган бүлекләреннән була. Хәзердә дә әле без борынгы замандагы төсле тормыш белән тора торган төрк кавемнәрендә бу нәүгъ[4] әдәбиятның куәтле булганын күрәбез. Мәсәлән, хәзерге кара кыргызлардагы «Манас»[5] исемле батыр хакындагы дастаннарны бу төрле әдәбиятның иң яхшы нәмунәләреннән[6] хисапларга мөмкин. Аның башыннан үткән төрле вакыйгаларны сөйли торган җырлар озын бер тезмә (бер группа) тәшкил итеп, җырчы-акыннар тарафыннан бәгъзан[7] озайтылып, төрле калыпларга сугылып җырланалар. Әле күптән түгел генә күчмәле, сугышчан халык булган башкортларда әле дә булса ярым тарихи, ярым хыялый батырлар хакындагы дастаннарның калдыклары сакланып, карт җырчылар тарафыннан көйләнәләр[8]. Менә шуларга кыяс кылганда[9], борынгы төркләрдә баһадирлар дастанының бик нык хөкем сөргәнлеген чамаларга мөмкин. Сугыш вә баһадирлык бөтен идеалын тәш-

---

[1] Истигъмаль ителә – кулланыла.

[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[3] Сүз җыелмалары – әйтемнәр, фразеологизмнар.

[4] Нәүгъ – төр.

[5] «Манас» – кыргыз героик эпосы, шул исемдәге баһадирның батырлыкларын бәян итүгә багышлана.

[6] Нәмунәләреннән – үрнәкләреннән.

[7] Бәгъзан – кайчак, кайвакыт.

[8] Башкортлар үзләре моңа «самак әйтү» диләр. *(Авт. иск.)*

[9] Кыяс кылганда – чагыштырганда, мисал иткәндә.

кил иткән халык өчен батырлар хакындагы әдәбиятның иҗтимагый әһәмияте дә була: үтмештәге батырларның батырлыкларын тыңлау яшь сугышчыларның канын кыздыра, гайрәтләрен арттыра, дастандагы батырлар төсле булырга кызыктырадыр. Борынгы угыз төркләренең дастаннарыннан беркадәресе югарыда сөйләнгән «Китабе Коркыд»та сакланып калган. Ләкин андагы дастаннар нәсер белән язылган. Гадәттә исә баһадирлар дастаны күбесенчә көйле формага салынган була.

Борынгы төркләрдәге әкияткә килсәк, аларының электә ничек булганын без белмибез, чөнки төрк әкиятләре борынгы заманда язылып алынмаганнар. Ләкин халык әдәбиятында әкият кыйсменең гомумән бик мөхафәзәгяр[1] бер гонсыр[2] булып, күп әкиятләрнең бик аз гына үзгәреш белән борынгы заманнардан бирле сөйләнеп килүләрен чамаларга мөмкин. Борынгы көлке анекдотлардан беркадәресе шактый заман элек язылып алынганга бераз мәгълүм. Ул да булса Хуҗа Насреддин ләтыйфәләредер[3]. Алар хакында әсәребезнең икенче бүлегендә озын сөйләнәчәк. Табышмаклар вә бераз мәкальләр исә «Коман мәҗмугасы» аталган XIV гасыр кульъязмасында сакланып калган. Бу хакта беркадәр мәгълүмат һәм мисаллар шул ук бүлектә бар.

Гомумән, күчмәле халыкларда лирика эпос (риваять)кә караганда түбәнрәк, арт пландарак тора. Төрк халкы исә, авыр, сабыр табигатьле бер халык булып, аның торган төп ватаны да каты табигатьле, могтәдилдән[4] салкынрак җирләр булганга, лирика тудырырга артык мөстәгыйд[5] булмагандыр. Шулай да төрк халкы үзенең кайгы-хәсрәтен, куаныч-сөенечен, гыйшык-мәхәббәтен һәрвакытта җыр белән сөйләргә яраткан. Моны безгә хәзерге кыргызларның һәм шәркый Себер төркләренең җырлары бик ачык күрсәтәләр. Әмма сәлҗук госманлылар шикелле җылы

[1] Мөхафәзәгяр – консерватив; саклый торган.
[2] Гонсыр – элемент.
[3] Ләтыйфә – көлкеле кыска хикәя, мәзәк.
[4] Могтәдилдән – уртачадан.
[5] Мөстәгыйд – сәләтле.

һавалы, матур табигатьле мөнбит[1] җирләргә килеп утырганнары исә бу төр әдәбиятны тагы да тәрәккый иттергәннәрдер. Госманлыларның хәзерге халык әдәбиятлары шуны күрсәтә.

Шаман диненең догалары булган теләкләр вә һәртөрле серле җөмләләрне им-том иткәндә, кеше вә мал эченә урнашкан явыз көчләрне (рухларны) куганда укыла торган вәзенле[2] сүзләрне дә халык әдәбиятыннан хисаплыйлар. Шаман динендә булган халыкларда бу төрле «әдәбият» бик куәтле булганга, борынгы төркләрдә ул хәзергегә караганда да киңрәк булгандыр дип уйларга мөмкин. Кыргыз-казакъ баксыларында[3] җен вә авыру куалый торган бик озын тасвирый вә матур телле «арбау»ларның булуы безгә шуны күрсәтә. Хәтта безнең Идел буе татарлары арасында да бик иске (архаик) телле, бәгъзан[4] аңлашылмасдай сүзләр һәм әллә нинди борынгы рух вә тәңре исемнәре белән булган имләү сүзләре сакланып калгалаган.

Драматик (ягъни диалоглы, кара-каршы әйтешә торган) әсәрләр булса, алар халыкта күбрәк бик садә, бездәге шамакай уеннары, «Алырым кош – бирмәм кош», «Күкдәниләр бар?» уеннарында, тагы да тәрәккый төшкәннәрнең Анатулыда госманлыларда һәм хәзерге кыргызлар арасында сакланып калуы борынгы заманда моның көчле бер әдәбият вә сәнгате нәфисә тармагы булганлыгын күрсәтәдер.

Утраклыкка күчү, язу сәнгатенең таралуы дин вә аның руханилары тәэсире белән бара торгач, төрк халыкларында халык әдәбияты кимергә тотынды. Яңа шәраит[5] астында халык, акрынлап, үзенең идеологиясен үзгәрткәне шикелле, әдәбиятын да алмаштыра, үзгәртә башлады. Әүвәлге мәҗүс каһарманнары Гали, Хәсән, Хөсәенгә – мөселман изге вә батырларына әйләнәләр. Әүвәлге шаман догалары мөселман динечә булган төрки догаларга алма-

[1] Мөнбит – уңдырышлы.
[2] Вәзенле – үлчәүле; ритмлы.
[3] Баксы – борынгы төрекләрнең йола фольклорына караган җыр, әйтем. Шаманнар тарафыннан камлау йоласын үтәгәндә башкарылган.
[4] Бәгъзан – кайвакыт.
[5] Шәраит – шартлар.

ша башладылар. Тәңреләр Аллага һәм мөселман изгеләренә әверелделәр, шаманның ролен дә мулла алды. Кыргызлар әйтмешли, «кара сүзләр» бетә башлап, «китап үлән» гә әйләнделәр. Ләкин төп әсаси[1] аһәң калды. Халык арасына таралган төрле мөселман хорафаты, легенда вә әкиятләре үзләре акрынлап тәмсил ителделәр[2], төркләштеләр. Язма әдәбият куәтләнгәнче, матбугат туганчы, халык әдәбиятының эволюциясе менә шулай барды.

## II
## Борынгы төркләрдә язу сәнгате

Төрк халыклары арасында язу сәнгате шактый иртә мәйданга килеп, язма әдәбиятның зоһурына[3] юл ачты. Дөрес, күчмәле тормыш белән торучы халыклар арасында язу сәнгате тиз тәрәккый итә алмый. Чөнки язу – ул асылда мәдәният, утраклык, шәһәр тормышының җимеше. Бер халык утраклыкка күчеп, икътисади тормышын җиргә, хосусый милеккә вә сәүдәгә бик нык бәйләгәннән соң гына, тормыш тәказа[4] кылганга, ул халыкта язу һөнәренең кирәклеге хис ителә башлый. Шул вакытта халык, бер әлифба ихтираг итеп[5] яки күршеләреннән икътибас итеп[6], язулы халык булып китә. Шуның аркасында мәктәп, мәгариф, китап, язма әдәбият һәм аерым бер таифә[7] язучылар вә әдипләр мәйданга киләләр. Күчмәле халыкларның тормышында исә язуның кирәклеге һич диярлек сизелми. Мәктәп, китап гыйлеме, язма әдәбият – күчмәлеләрнең тормышына ят нәрсәләр; алар – шәһәр тормышының продуктлары. Яңа күчмәлектән чыга башлап, дәүләт тормышына күчә башлаган халыкларда (мәсәлән, тарихка мәгълүм булган иң борынгы төркләрдә) язу сәнгате булса да,

[1] Әсаси – нигез.
[2] Тәмсил ителделәр – йотылдылар.
[3] Зоһурына – мәйданга чыгуына.
[4] Тәказа – теләгәнгә.
[5] Ихтираг итеп – уйлап табып.
[6] Икътибас итеп – үрнәк итеп.
[7] Таифә – төркем.

башта ул күбрәк хөкүмәт, идарә, дипломатия, гомумән, канцелярия кирәкләре өчен генә истигъмаль ителеп, халык арасында гам бер әйбер буларак таралып китә алмый. Язма хокукый кануннар урынына гадәт-йола йөргәне шикелле, язма әдәбият урынына да, авыздан авызга, колактан колакка күчү белән генә тарала торган «халык әдәбияты» тора. Ләкин борынгы төркләр Кытай вә Иран шикелле мәдәни илләр белән күрше булып торганлыкларыннан, алар белән ихтилятның[1] башлануы төркләр арасында язу сәнгатенең тууына тизлек бирде. Кытай мәнбәгълары[2], 545 ел вакыйгаларын язганда, төркләрнең язулары булганлыгын һәм аларның сөңге очы белән язганнарын сөйлиләр. Шулай ук 580 елда Бизанес кайсары Юстинга[3] төркләрдән сәфарәт килеп, «эскиф характерында» язылган хат китергәне мәгълүм[4]. Кытай вәкаигънамәләренең хәбәр бирүенә күрә, тарихка мәгълүм иң борынгы төрк җәмгыяте булган «һун-ну» (һюныг-ну, һун)ларда да язу бар иде. Ләкин бу язу нинди булган, бу вакыттагы төркләрнең үзләренә махсус әлифбалары булганмы, юкмы, әллә алар Кытай я башка бер-бер халыкның әлифбасы белән файдаланганнармы – без моны аермачык белә алмыйбыз, чөнки һун төркләреннән һичбер төрле язма документлар сакланып калмаган.

Борынгы заманнарда төркләрдә, ханнар вә башка атаклы кешеләр үлгәч, алар хөрмәтенә язулы ташлар, һәйкәлләр утырту,

---

[1] Ихтилятның – аралашуның.

[2] Мәнбәгълары – чыганаклары.

[3] Юстин – Византия императоры Юстин II (Флавий Юстин, якынча 520–578 еллар).

[4] 568 елда Константинопольгә Юстин II янына килгән төрки илче Маниахның каһаннан «скиф язулы» хәбәр алып килүе турында Византия тарихчысы Менандр язып калдырган була. Гомумән әйткәндә, хезмәтнең бу өлеше фундаменталь хезмәтләргә таянып язылганлыгын аерып билгеләргә кирәк.

Күренекле галим, борынгы төрки чор буенча белгеч С.Г. Кляшторный Маниах илчелеге белән бәйле вакыйгадан 15 еллап вакыт узганнан соң урнаштырылган, Төрки каһанлык чорыннан сакланып калган иң борынгы язма – Богыт язмасын (Үзәк Монголия) укып, әлеге «скиф язуының» Төрки Каһанлыкның беренче 30 елдагы хәле, Таспар-каһанның эш-гамәлләре турында сөйләвен билгели. Кара: Кляшторный С.Г., Савинов Д.Г. Степные империи древней Евразии. – СПб.: Филол. фак-тет СПбГУ, 2005. – Б. 158–160.

гыйбадәтханәләр бина кылу гадәте булган. Зур «бәгү таш» (мәңге таш)ларга үлгән кешеләрнең тәрҗемәи хәлләрен, эшләгән эшләрен, кылган изгелекләрен яза торган булганнар. Мондый каберташлары Азиянең борынгы төркләр торган урыннарында (Монголиядә, җәнүби[1] Себердә, Җиде Су вилаятендә[2], Кытай Төркестанында) күп табылалар. Иң әүвәл шундый ташларны моннан ике йөз еллар элек Петр I тарафыннан сугышта әсир алынып Себергә сөрелгән бер гыйлем сөюче швед әфисәре[3] Янәсәй (Енисей) суының югарыгы агымында (җәнүби Себердә) табып, беренче тапкыр алар хакында яурупалыларга хәбәр биргән. Бу ташлардагы язулар борынгы скандинавиялеләрнең «рун» аталган язуларына ошаганга күрә, швед әфисәренең дикъкатен җәлеп иткән булырга кирәк. Ләкин ул вакытта бу язуларны укый белүче булмаганга, ул ташларның кемнәр тарафыннан куелуын һәм нинди телдә язылган булуын белә алмаганнар. Скандинавиянең рун язулары борынгы финнарда да мөстәгъмәл[4] булганга, Финляндиядән дә бер гыйльми һәйәт[5] барып, бу ташларны тәфтиш иткән[6]. (Соңыннан бу ташларның кара кыргызлар[7] тарафыннан утыртылганы мәгълүм булган.) 1889 елда «Җәгърафия җәмгыяте» тарафыннан мөстәшрикъ Ядринцев[8] тәхте риясәтендә[9] Монголиягә җибәрелгән фәнни һәйәт тарафыннан Орхон суы буенда борынгы

[1] Җәнүби – көньяк.

[2] Җиде Су вилаяте – Семиречье, 1917 ел инкыйлабына кадәр кулланылышта йөргән Үзәк Азиядәге географик өлкә атамасы. Ул төньякта Балхаш күленнән, төньяк-көнчыгышта Сазкүл һәм Алакүлдән, көньяк-көнчыгышта Җунгар Алатавыннан алып, көньякта Тян-Шаньга кадәр араны били. Атама бу җирләрне төп җиде елга кисеп үтү белән бәйле.

[3] Әфисәре – офицеры.

[4] Мөстәгъмәл – кулланылган.

[5] Һәйәт – төркем, делегация.

[6] Тәфтиш иткән – тикшергән.

[7] Кара кыргыз – төрки кабиләләрнең берсе.

[8] Ядринцев Николай Михайлович (1842–1894) – Себерне һәм Урта Азияне өйрәнүче, Орхон елгасы буенда, Чыңгызханның башкаласы Кара-Корым һәм Монголиядәге Уйгур каһанлыгының башкаласы Орду-Балык янындагы борынгы төрки һәйкәлләрне беренче булып ачкан кеше.

[9] Тәхте риясәтендә – җитәкчелеге астында.

Карабалгасун[1] (Каракорым) шәһәренең хәрабәләре якынында (15 чакрымнарда) бу төрле ташларның иң мөһимнәреннән Күлтәгин вә Билге каһан ташлары табылгач, Яурупа мөстәшрикъларында бу язуларны уку дәрте куәтләнгән. 1891 елда Петербург дарелголүме[2], бу тарихи документларны тикшерү өчен, Монголиягә мөстәшрикъ Радлов риясәтендә хосус бер һәйәт җибәргән. Һәйәт яңа тарихи табылдыклар хакында бөтен кылырга мөмкин булган тәфтишләрне[3] ясап, ташлардагы язуларның дөрес күчермәләрен алып кайткач, аларны укырга имкян ачылган. Ташларның бер ягындагы язулар кытайча булганга, шуларның мөндәриҗәсенә бинаән, икенче ягындагы язуларның төркләр тарафыннан төрк телендә язылган булулары тәхмин ителгән[4]. Кулда шуннан артык мәгълүмат булмаса да, данияле тюрколог Томсен бу нәмәгълүм язуны укуның юлларын тапкан. Ташлардагы язулар иске, онытылган бер төрк телендә язылганлыгы беленгән. Әлбәттә, һичкем белмәгән хәрефләр белән язылган язуны танып уку нәкъ бер башваткыч табышмакны табу шикелле мөшкел эш булган. 1893 елда ташлардагы язулар, тәмамән укылып, Радлов һәм Томсен тарафыннан[5] тәрҗемә кылынганнар. Орхон язулары борынгы

[1] Карабалгасун – Уйгур каһанлыгының (VIII–IX) борынгы башкаласы, «кара шәһәр» мәгънәсендә. Икенче исеме – Орду-Балык.

[2] Дарелголүме – университеты.

[3] Тәфтишләрне – тикшерүләрне.

[4] Тәхмин ителгән – якынча билгеләнгән.

[5] Радлов Василий Васильевич (Фридрих Вильгельм Радлов, 1837–1918) – күренекле шәрыкшинас һәм тюрколог, этнограф, археолог, төрки телләрне һәм халыкларны чагыштырма-тарихи планда өйрәнә башлаучыларның беренчеләреннән. Ул 1891 елда Монголиягә гомумбилгеле Орхон экспедициясен оештыра, шушы тикшеренүләр вакытында Орхон-Енисей рун язулы һәйкәлләре табыла һәм бу хакта дөньяга мәгълүм була. Радлов унлап билгене укырга ачкыч таба, әмма бу язуларның серен беренче булып Данияле тел белгече В. Томсен чишә. Ул 1893 елда барлык билгеләрнең нәрсә аңлатканын ачыклаганлыгын хәбәр итә. 1894 елда исә В.В. Радлов, Томсен ачышларына нигезләнеп, тәрҗемә эшен төгәлли һәм текстларны бастыра. 1895 елда ул, үзе тапкан һәм фин экспедициясе материаллары нигезендә, 40 язуның тәрҗемәсен дөньяга чыгара. 1898 елда Радлов Турфан экспедициясен оештыра (аны Д.А. Клеменц җитәкли), шул вакытта табылган борынгы уйгур истәлекләрен өйрәнүне башлап җибәрә. 1899 елда Тоньюкук хөрмәтенә куелган ташның транскрипциясен һәм тәрҗемәсен нәшер итә.

төрк тарихын тергезү өчен зур материал биргәнлеге шикелле, шул төркләрнең үзләренә махсус язу – әлифбалары булуын да мәйданга чыгарган.

Орхон буендагы кабер ташлары шул вакыттагы төркләрнең үзләренә махсус хәрефләр белән язылганнар. Бу хәрефләрне «орхон әлифбасы» дип атау гадәт булып киткән. Бу язуның язылу тәртибе кытай язуыныкы шикелле: юллар югарыдан түбәнгә таба язылып төшеп, беренче, икенче дип уңнан сулга таба хисаплаактар, ләкин төрк язуының кытай язуына ошавы шуннан артыкка бармый. Мәгълүм ки, кытай язуы «хәреф»ләрдән түгел, бәлки «һируглиф»лардан гыйбарәт; ягъни һәрбер аерым сүз өчен аерым галәмәт[1] истигъмаль ителә[2]. Шуның өчен Кытай язуында төрле галәмәтләрнең саны ничә меңнәргә җитә. Орхон язуы исә, кыйсмән[3] хәзерге мәдәни халыкларның язулары шикелле, аерым-аерым хәрефләрдән, кыйсмән һәрберсе берәр мәгълүм иҗек яки куш хәреф булып укыла торган галәмәтләрдән тора. Орхон әлифбасының тавышларны күрсәтүе нык әсаслы бер системага бина кылынмаган. Орхон әлифбасында барысы 37–38 галәмәт. Бу галәмәтләрдән бары бишесе генә аерым самит[4] хәрефләр буларак укылалар (*ч, ш, з, п, ң, м* тавышлары өчен булган билгеләр), мәд[5] хәрефләре өчен аерым дүрт галәмәт булып, аларның һәрберсе икешәр тавышлы хәрефкә йөриләр [ихтимал]). Калган галәмәтләрнең күбрәге берәр тавышлы аваз белән берәр самит аваздан гыйбарәт булган иҗекләр итеп укылалар. Мондый галәмәтләрнең күбесе самит авазларның *а* һәм *ә* авазлары белән ялгануыннан гыйбарәт; урынына карап, һәрбер галәмәт шул ук тавышлардан тәшкил ителгән ачык вә ябык иҗекләр булып исәпләнә. Мондыйлар барысы 23 галәмәт *(қа – ақ, ға – ағ, та – ат, да – ад, ба – аб, са – ас, на – ан, ла – ал, ра – ар, па – ап; кә – әк, гә – әг, тә – әт,*

[1] Галәмәт яки галямәт – аваз, билге.
[2] Истигъмаль ителә – кулланыла.
[3] Кыйсмән – өлешчә.
[4] Самит – тавышсыз.
[5] Мәд – сузык аваз.

*дә – әд, бә – әб, сә – әс, нә – ән, лә – әл, рә – әр, я – әй; қы – ық, қу, қу – уқ, уқ; кү, кү – үк, үк).*

Галәмәтләр арасында өчесе ике самит авазының кушылуыннан хасил булган кушма авазны күрсәтәләр *(нт – нд, лт – лд, нч).* Димәк, гомумиләштереп әйткәндә, Орхон әлифбасына әсас итеп аерым авазлар түгел, бәлки иҗекләр алынган дип әйтергә мөмкин. Әлбәттә, әлифбаның бу әсаска куелуының кимчелекләре вә уңайсызлыклары күп. Орхон язуындагы галәмәтләр – хәзерге Яурупа әлифбаларының басма хәрефләре шикелле бер-берсенә кушылып язылмый торган ялгыз (аерым) хәрефләр. Һәрбер аерым сүз икенчесеннән ике янәшә куелган нокта белән аерыла.

Орхон әлифбасын төркләр каян алганнар, дигән мәсьәләдә фән әһелләре арасында төрле фикерләр булган. Башта, бу язу кирәгенчә тикшерелгәнче, аның тышкы яктан беркадәр борынгы Скандинавиядә һәм готларда[1] истигъмаль кылынган «рун» аталган әлифбага охшавына алданып, Урта Азия халыкларына бу әлифбаның шимали Яурупадан[2] күчеп килеп кергәнлеген дәгъва итүчеләр дә булган[3].

Борынгы заманда бер-берсеннән ничә мең чакрымлык мәсафә[4] белән аерылган шушы халыклар арасында сәүдә мөнәсәбәтләре булган да шуның аркасында шимали Яурупа язуы Монголиягә барып чыккан, имеш (!). Орхон әлифбасының төп ватаны хакындагы бу асылсыз фикер хәзер ташланган. Соңгы вакытта аның төбе борынгы арамия[5] әлифбасы булуы фикере куәтләнгән. Арамия әлифбасы элек борынгы иранлыларга кереп үзгәртелеп,

[1] Готлар – борынгы алман кабиләләре союзы, б.э.к. II гасырдан б.э. VIII гасырына кадәр тарихта зур роль уйный.

[2] Шимали Яурупадан – төньяк Европадан.

[3] Элизе Реклю. Человек и земля. *(Авт. иск.)*

[4] Мәсафә – ераклык.

[5] Арамия дип борынгы заманда Гарәбстан ярыматавының шимали кыйсеме (Сүрия, Фәләстыйн, Халидия, Месопотамия) аталган. Бу җирләрдә тора торган борынгы сам кавемнәре (гарәпләр, яһүдләр вә сүриялеләрнең бабалары) арам теле дип аталган телдә сөйләшкәннәр. Аларның үзләренә махсус язулары булган, Ассурия вә бабиллеләр һәм кәлдани (халди)ләр дә сам гыйркыннан булганнар. *(Авт. иск.)*




Орхон әлифбасы

иранлылар аркылы төркләргә күчкән, имеш. Орхон әлифбасын тикшерүче галимнәрдән Томсен һәм Радлов Орхон әлифбасының асылы борынгы сам кавемнәренең әлифбасы булу фикерен алга сөргәннәр. Радловның уенча, Орхон әлифбасындагы сузынкы (мәд) хәрефләр – аның асылы самиләрдән кергән булуына дәлилләр; чөнки Орхон әлифбасында төрк телендәге тавышлы авазларга җитәрлек галәмәтләр юк[1]. Югарыда күрелгәнчә, аның да мәд хәрефләре самиләрдәге шикелле «әлиф, уау, я»гарак кайтып кала.

Ләкин Радлов Орхон әлифбасына рун язуларының да тәэсирен бөтенләй үк инкяр итми. Урта гасырларның башында бөек халык күчеше вакытында шәркый Яурупада торган готларда рун язуы гамәлдә булган. Атилла кул астында һуннар Яурупага килеп чыккач, готлардан бәгъзы бер затлар Атилланың сараенда тәэсирле урыннар ишгаль иткәннәр[2]. Ихтимал, шул заманда готлар аркылы рун әлифбасы төрк язуына тәэсир итеп, андагы галәмәтләрнең шәкелләре үзгәрүгә, рун язуындагы галәмәтләргә охшаулы хәрефләр килеп чыгуга сәбәпче булгандыр. Борынгы һуннарда (һун-нуларда), Радлов фикеренчә, шул ук Орхон язуы кулланылган[3].

Икенче бер фикер буенча, Орхон әлифбасы төркләрнең борынгы ыруг тамгаларыннан үзгәртелеп (тамгаларны хәрефкә әйләндерү аркылы) ясалган. «Тамга» – төрк халыкларына махсус диярлек бер нәрсә, һәрбер ыругның үзенә аерым билге – галәмәтләре булган. Шул галәмәтләрне тамга дип атаганнар. Тамга салу борынгы төркләрдә кул кую (имза) урынына торган, шулай ук көтүдә бергә йөргән хайваннарны бер ыругныкыннан икенчесенекен аеру өчен тамгалый торган булганнар, ягъни һәрбер ыруг үз хайваннарының тәненә кызган тимер белән тамгаларын басканнар. Бу рәвешле галәмәтләр хайванның тәнендә гомере буена калалар. Тамгалар хәзердә дә төрк халыкларында бар, хәтта ул безнең татарда да сакланган. Бездә һәрбер авыл кешесенең үзе

[1] Radlov W. Die vorislamitischen Schriftarten der Turken. *(Авт. иск.)*
[2] Ишгаль иткәннәр – биләгәннәр; алып торганнар.
[3] Radlov W. Die vorislamitischen Schriftarten der Turken. *(Авт. иск.)*

иттихаз иткән[1] билгесе – тамгасы була. Язу белми торган авыл кешеләре кул кую урынына үзләренең тамгаларын куялар. Шулай ук кырда, чәчкән җирләренә дә сука белән үз билгеләрен төшерәләр, шуннан аерып җирләрен таныйлар. Тамгалар нәрсәгә охшасалар, шуның исеме белән аталып йөртеләләр, мәсәлән, «тарак тамга», «сәнәк тамга», «чыршы тамга» дигән шикелле. Орхон әлифбасындагы галәмәтләр дә үзләренең шәкелләре белән бәгъзы төрк тамгаларын хәтерләтәләр. Шуңар карап, Орхон хәрефләре тамгалардан үзгәреп хасил булмадымы икән дип уйлыйлар. Бу ике төрле фикерне бергә җыеп, төркләр башта хәрефләрне самиләр әлифбасыннан алсалар да, җитмәгән хәрефләрне үзләренең тамгалары арасыннан алып тутырганнар дип тә уйларга мөмкин.

Һәрхәлдә, бик борынгы заманнарда ук төркләрнең үзләренә махсус язулары булган. Хәзер бөтенләй онытылган булса да, заманасында Азиянең зур бер кыйсемендә бу язуның таралган булуы мәгълүм. 580 миладида бер төрк ханының Бизанес кайсарына үзенең илчеләре аркылы күндергән мәктүбе шул Орхон язуы белән язылган булган. Бу язу белән язылган кабер ташлары Урта Азиядә – Әүлия ата тирәләрендә, Янәсәй[2] елгасының югарыгы агымында, Абакан далаларындагы, шимали Монголиядә – Сәләңә[3] (Селенга) һәм Орхон буйларында, Монголиянең шәрыгында Кәрүлән[4] елгасына кадәр табыла. Шәркый Төркестанда Турфан шәһәре тирәсендәге борынгы төркләрдән калма мәгарәләрнең диварларында һәм Тарбагатай тауларының кыяларында чокып язылган шундый ук язулар табылган.

Орхон әлифбасының төркләрдә кайчаннан бирле истигъмаль ителгәнлеге[5] тәгаен мәгълүм түгел. Һәрхәлдә, алар арасында ул бик күптәннән бирле кулланылган булырга кирәк, чөнки

[1] Иттихаз иткән – кабул иткән.

[2] Янәсәй – Енисей.

[3] Сәләңә – Селенга – Монголия һәм Россия территорияләре аша ага торган зур елга. Байкал күленә коя.

[4] Кәрүлән – Керулен – Монголия һәм Кытай җирләре аша ага торган зур елга.

[5] Истигъмаль ителгәнлеге – кулланылганы.

Орхон суы буенда табылган ташларда без инде имланы яхшы ук эшләнгән, тәмам бер эзгә утырып җитеп, мәгълүм бер системага салынган хәлдә табабыз. Ул бу халәткә килгәнче, әлбәттә, шактый заманнар узгандыр. Бәгъзы бер куелу тарихлары тәгаен билгеле булмаган ташларда (мәсәлән, Янәсәй буендагыларда) әле без имланың эшләнмәгән, бу дәрәҗәдә юлга куелмаган булуын күрәбез. Мәсәлән, Орхон әлифбасында булган бәгъзы галәмәтләрне без аларда очратмыйбыз. Уйларга мөмкин ки, алар Орхон буендагы ташлардан берничә йөз ел элек утыртылганнардыр.

Орхон язуының иң югары дәрәҗәгә ирешүе Орхон-Сәләңә хаузасында[1] ту-күәләр[2] хөкем сөргән дәвердә VII–VIII гасырларда булган. Бу язу VII гасырда Мәгыйлән каһанның атасы Илтәрәс каһан тәхеткә утырганнан соң, аның кытай тәрбиясе алган укымышлы вәзире Тоньюкукның тәшәббесе[3] белән төрк илендә рәсми хөкүмәт язуы буларак кабул ителгән булырга кирәк[4]. Бу Тоньюкукның кабере өстенә утыртылган шактый озын язулы таш та хәзерге көнгә кадәр сакланган.

Борынгы төркләрдә, Орхон әлифбасыннан башка, тагы бер төрле әлифба истигъмаль ителгән; бу әлифбаны, башлыча уйгур төркләре арасында таралганга күрә, «уйгур язуы» дип атыйлар. Уйгур әлифбасы уйгурлар Монголиядә торган вакытта шимали вә шимали-гарби[5] Монголиядә дә таралган булып, аның иң

[1] Хаузасында – бассейнында.

[2] «Ту-күә» яки «ту-куе» төшенчәсе төркиләрнең бик борынгы бабаларын аңлата. Бүгенге фәндә аларны рус теленнән алынган прототөркиләр (прототюрки) атамасы белән йөртәләр. XVI гасырда самилар телендә төрки кабиләләрнең атамасы «турк» рәвешендә яңгырый, күплек санда – «туркут». Шуннан кытай теленә кереп, ул «ту-куе» («туцзюе» – «тюркют») төсендә урнашып кала. Чөнки төрки халыклар һәм Кытай арасындагы дипломатик мөнәсәбәтләр башта самилар ярдәмендә, сам телендә алып барыла. Кара: Кляшторный С.Г., Султанов Т.И. Государства и народы Евразийских степей: от древности к Новому времени. – СПб.: Петербургское востоковедение, 2009. – 105 б.

[3] Тәшәббесе – тапкырлыгы; инициативасы.

[4] Radlov W. Die vorislamitischen Schriftarten der Turken. *(Авт. иск.)*

[5] Шимали-гарби – төньяк-көнбатыш.



Орхон ташларындагы язулардан нәмунә.
Уң яктан беренче юлдагы сүзләр:
«Тәңре тәг тәңридә булмуш түрк Билге каһан».
*(Клише З. Вәлидинең «Төрк-татар тарихы»ннан алынды)*

мәкъбүл[1] урыны шәркый һәм гарби Төркестанда булган. Бу язу башлап уйгурларга кергән. Ул уйгурлар арасына (алар әле Монголиядә чакта) христиан дине белән бергә кереп таралган. Уйгур әлифбасының асылы – борынгы Сүрия әлифбасы. Аны V гасырдан соң Бизанес[2] дәүләтенең чикләреннән куылган Нәстури[3] раһибләре[4] алып килгәннәр. Алар, үзләренең мәзһәбләрен тараткан вакытта, дини китаплары язылган Сүрия язуын да төркләр арасында татбикъ кылганнар[5].

Ләкин уйгурлар Сүрия әлифбасын шул көенчә генә кабул итмәгәннәр: үз телләренең, үз мәдәни мохитләренең хосусиятенә карап, шактый үзгәрткәннәр. Ахырда Сүрия әлифбасы, танымаслык дәрәҗәдә үзгәреп, үзенә бертөрле төрк язуына әверелеп киткән. Сүрия әлифбасындагы 32 хәреф урынына уйгурлар бары 17 генә хәреф истигъмаль иткәннәр. Уйгурларда төрле мәдәниятнең тәэсире булуы шушы язу мәсьәләсендә бик ачык күренә. Алар, Сүрия хәрефләрен алсалар да, язу рәвешендә кытайларга ияреп, сүриялеләр шикелле уңнан сулга түгел, бәлки сулдан уңга язганнар. Сүриялеләр үз язуларын камыш каләм белән пергамент (ягъни тиредән ясалган калын кәгазь) өстенә язалар икән. Кытайлар исә язу өчен мамыктан ясалган йомшак, ялтыравыксыз кәгазь кулланганга, аларда кечкенә пумала белән язу гадәт булган. Ул якта башка төрле кәгазь булмаганга, уйгурлар да пумала белән язарга мәҗбүр булганнар. Шуңар күрә Сүрия хәрефләренең шәкелләре беркадәр үзгәреп, үзенә бертөрле «уйгур әлифбасы» мәйданга килгән. Гарәп язуының да асылы Сүрия язуыннан алынганга күрә, уйгур язуы беренче карашка гарәп язуына беркадәр охшый. Уйгур язуында да гарәпнеке шикелле баш, урта, ахыр вә ялгыз хәрефләр бар. Шуңар күрә сүзләр бертоташтан

[1] Мәкъбүл – кабул ителгән.

[2] Бизанес – Византия.

[3] Нәстури – несторианство, христологик дин гыйлеме, аның килеп чыгышын Константинополь архиепископы Несторий (428–431) белән бәйләп карыйлар. Рәсми христиан дине тарафыннан 431 елда кире кагыла.

[4] Раһибләре – монахлары.

[5] Татбикъ кылганнар – яраклаштырганнар.

язылa. Сүрия әлифбасында булып та, сам телләре өчен генә махсус булган авазларның галәмәтләрен уйгурлар ташлаганнар. Әмма, шуның белән бергә, *ч, п, ң* шикелле төрк теленә махсус булган хәрефләр өчен алар яңа галәмәтләр ихтираг итмәгәннәр[1]; шул хәрефләргә мәхрәҗ[2] ягыннан якынрак булган берәр хәрефкә ияртеп, ике яки өч хәрефкә бер галәмәт алганнар. Уйгур әлифбасының галәмәтләргә ярлылыгы шуннан килеп чыккан.

Уйгур әлифбасындагы 17 хәреф, әлбәттә, төрк телендәге авазларның бары ярты кадәресен генә язарга җитә. Шунлыктан уйгур имласында буталчыклык булган. Уйгур язуында нибарысы дүрт мәд[3] галәмәте бар. Бу галәмәтләрнең өчесе *а-ә, ий-и, у-ү, о-ө* авазларына йөриләр. Дүртенчесе, *у-ү* һәм *и* галәмәтләренең кушылуыннан гыйбарәт булган кушма бер хәреф булып, бары сүзләрнең төпләрендә генә *у-ү* авазына йөри. Самит хәрефләрдән[4] мәхрәҗләре бер-берсенә якын булып, яңгыравыклылык вә саңгыраулык белән генә аерыла торганнары өчен уйгурлар берәр генә төрле галәмәт[5] алганнар. Самит хәрефләр уйгур әлифбасында 13. Алар шушы авазлар урынына йөриләр: *б-п, җ-ч, д-т, з-с, р, з-с (ш), ғ-қ , ң-ш, г-к, л, м, ң-н, в.* Яңгыравыклы һәм саңгырау хәрефләр өчен аерым галәмәтләр булмавы уйгур хәрефләре белән язылган язуны укуны читенләштерә. Хәзерге уйгурларның сөйләшүләренә карап кына, уйгур теле вә хәрефләре белән язылган язуларны беркадәр дөрес укырга мөмкин.

Орхон язуы борынгыракмы, яисә уйгур язуымы, кайсы әлифба төркләрдә элегрәк истигъмаль ителгән – бу сөальгә аермачык җавап бирү читен. Ике төрле әлифба да тарих белә башлаганнан бирле байтак гасырлар буенча янәшә истигъмаль ителгәннәр. Орхон әлифбасы – башлыча Монголиядә, мәркәзи Азиядә,

[1] Ихтираг итмәгәннәр – уйлап тапмаганнар.

[2] Мәхрәҗ – авазның ясалу урыны, артикуляция.

[3] Мәд – сузык аваз.

[4] Самит хәрефләрдән – тавышсыз хәрефләрдән, ягъни саңгырау тартыклардан.

[5] Галәмәт – билге.

соңгырак заманнарда ту-куе төркләрендә вә алар тәэсирендә булган халыкларда, уйгур әлифбасы исә уйгурларда вә алар тәэсире астында булган өлкәләрдә кулланылган. Өстенә һәм Орхон, һәм уйгур хәрефләре белән язылган иң иске һәм бердәнбер таш шимали Монголиядә, Карабалгасун шәһәренең хәрабәсендә табылган. Бу таш милади 784 елларда куелган булырга кирәк дип чамалана. Ул уйгур ханнарыннан «Тәңрикән тәңридә кут булмыш алып Билгә-тәңри уйгур каһан» аталган затның каберенә утыртылган. Һәр ике төрле төрк әлифбасы белән язылган бу ташбилге – VIII гасырда төркләр арасында ике әлифбаның да бердәй истигъмальдә булганын күрсәтә торган фактлардандыр[1]. Орхон әлифбасының төркләрдә кайчаннан бирле истигъмаль ителгәнен без белә алмыйбыз[2]. Ихтимал, борынгы һун-нулар (уйгурларның бабалары) бик иске заманнардан бирле аның белән язганнардыр. Ләкин бик борынгы Орхон язулы документларның кайчан язылулары мәгълүм түгел; тарихлары мәгълүм булган язулар – VIII гасырга гаид булганнары[3] гына. Шул ук VIII гасырга гаид уйгур хәрефләре белән язылган документлар да табылган. Ләкин уйгур язуы нәстури раһибләре[4] тарафыннан китерелгән булганга, аның төркләр арасында таралуы милади VIII гасырдан да элек булуы, әлбәттә, мөмкин түгел. Вә халәнки[5], VI гасырның ахырында төркләр тарафыннан Бизанес кайсарына[6] язылган хат Орхон хәрефләре белән язылган булырга тиеш дип карар кылсак, Орхон язуының уйгур язуына караганда борынгырак булуы фикере хакыйкатькә якынрак булып чыга.

Уйгур дәүләтенең шәүкәтле дәверендә бөтен Азиядә уйгур язуы бик таралган вә мәкъбүл язу булган. Аны Кытайда да, Бизанеста да, ислам мәмләкәтләрендә дә укыганнар. Бу өлкәләрнең

[1] Radlov W. Die vorislamitischen Schriftarten der Turken. *(Авт. иск.)*

[2] Орхон язмалары арасында VI гасырга караганнары табылу бу мәсьәләгә ачыклык кертә.

[3] Гаид – караган, бәйләнешле.

[4] Нәстури раһибләре – несториан монахлары.

[5] Халәнки – чынлыкта.

[6] Бизанес кайсарына – Византия императорына.




Уйгур әлифбасы

хөкүмәтләре төркләргә язган рәсми кәгазьләрен дә шул язу белән язалар икән. Уйгур мәмләкәте мөнкариз булып[1], уйгур әдәбияты тәмам сүнгәннән соң да, ул байтак заманга кадәр төркләрдә истигъмаль ителгән. Мәдәният ташучылар буларак, уйгур галимнәре Чыңгызханның сараенда зур урыннар ишгаль иткәннәр[2]. Шулар аркылы уйгур язуы монгол ханнарының хөкүмәт даирәләрендә канцелярия теле булып киткән һәм ничә гасырлар буенча төрле монгол дәүләтләрендә хөкүмәтнең рәсми язуы хезмәтен үтәп килгән. Кублай хан[3] тарафыннан сөнге рәвешендә ясатылып, милли монгол язуы буларак гамәлгә куелырга теләнгән «дүрткел» язу[4] да рәваҗ[5] табып уйгур язуын истигъмальдән чыгара алмаган. Шул вакытта ул Җүҗи (Җүчи) балалары хөкем сөргән Идел буена да килгән. Тимер Котлыг[6] вә Туктамыш[7] ханнарның XIV гасырга гаид уйгур язуы белән төрк телендә язылган берничә ярлыклары һәм монгол теле белән язылган «пайза»лар (көмеш тактага язылган рәсми язулар) сакланып калган[8]. Аксак Тимер аны үзенең рәсми хөкүмәт язуы итеп кабул иткән. XV гасыр буенча ул Төркестанда рәсми язу буларак истигъмаль кылынуда дәвам иткән. Мәшһүр Бабирның атасы Гомәр

---

[1] Мөнкариз булып – бетеп, юкка чыгып.

[2] Ишгаль иткәннәр – биләгәннәр.

[3] Кублай хан – Хубилай хан (1215–1294), Чыңгызханның оныгы, Юань монгол дәүләтенә нигез салучы. Марко Поло язмаларына «Кублай-хан» исеме белән кергән.

[4] Дүрткел язу (квадратное письмо) – 1269 елда барлыкка килеп, Юань чорында бу дәүләттә яшәгән барлык халыклар тарафыннан, шулай ук халыкара аралашу өчен кулланылган язу рәвеше. Аны Хубилай хан империя өчен махсус Тибет ламасы Дрогон Чогьял Пагпадан (Пагба-лама) эшләткән дип санала.

[5] Рәваҗ – таралыш.

[6] Тимер Котлыг (1370–1400) – 1395–1399 елларда Алтын Урда ханы.

[7] Туктамыш хан (1342–1406) – 1380–1395 елларда Алтын Урда ханы, 1400 елдан – Себер ханы.

[8] Пайза (пайцза, төркичә байса яки басма) – металл яки агачтан эшләнгән һәм хан тарафыннан хакимият билгесе буларак тапшырыла торган символик язу. Бау яки чылбыр белән муенга яки билгә тагып йөртелгән. Ярлык – хан грамотасы.



Уйгур язуында бирелгән «Котадгу белег» китабыннан бер бит
*(Клише З. Вәлидинең «Төрк-татар тарихы»ннан алынды)*

Шәех[1] заманында 1429 елда бирелгән ярлыклар да уйгур хәрефе белән язылганнар[2].

XV гасырда Урта Азиядә уйгур язуы әдәбиятта да истигъмальдә булган. «Мигъраҗнамә», «Тәзкирәи әүлия», «Бәхтиярнамә»[3] шикелле чыгтай телендәге[4] әсәрләрнең шушы гасырга гаид уйгур язуы белән язылган нөсхәләре табылган.

Уйгур әлифбасы белән язылган язуларның иң соңгылары XVIII гасыр башларына туры килә. Шуннан соңгы уйгур язулы әсәрләр хәзергә кадәр табылганы юк. Исламият белән бергә килгән гарәп язуы акрын-акрын уйгур язуын истигъмальдән чыгарган. XIV гасырда әле Урта Азия төркләре арасында һәр ике язуны очратып була. Әмма соңгырак гасырларда ислам динендәге төркләр аны бөтенләй ташлаганнар. Голяма[5] аңар «мәҗүс язуы» диебрәк кырын караган булырга кирәк.

Ахырда бу язу бары будда динендә булган уйгурлар арасында, монастырь вә гыйбадәтханәләрдә дини максатлар өчен генә кулланыла торган булып калган. Бара-бара алар арасында да милли төрк язуы урынын тибет язуы тоткан. Хәзерге сары уйгурлар үзләренең борынгы язуларын хәтерләмиләр һәм белмиләр. Ләкин уйгур язуы, Орхон әлифбасы шикелле бөтенләй үк истигъмальдән чыгып, дөнья йөзендәге халыклар тарафыннан тәмамән онытылып, «үлек язу» булып калмаган. Хәзерге монголлар, калмыклар һәм маньчжурлар шушы борынгы төрк әлифбасы белән

[1] Бабир – Заһиреддин Мөхәммәд Бабур (1483–1530), Һиндстанда һәм Әфганстанда идарә иткән хан, Бөек Моголлар империясенә (1526) нигез салучы. Төрки шагыйрь, галим, фикер иясе. Әндиҗанда Фирганә әмире Гомәр Шәех II мирза гаиләсендә 1483 елның 14 февралендә дөньяга килә. Гомәр Шәех – Аксак Тимернең өченче улы Миран-шахның оныгы.

[2] Зап. Вост. Отд. Имп. Арх. О-ва. Т. VI, вып. I, стр. 5. *(Авт. иск.)*

[3] «Мигъраҗнамә», «Тәзкирәи әүлия», «Бәхтиярнамә» – дини-мифологик әсәрләр.

[4] Чыгтай теле – урта гасырларда Урта Азиядә кулланылышта йөргән төрки язма һәм сөйләмә тел. Гарәп графикасына һәм уйгур язуына нигезләнә. XV–XVI гасырның икенче яртысында гаять зур үсеш кичерә, төрки халыклар арасында багланышлар тыгыз булганга күрә, гомумән төрки телгә йогынтысы зур була.

[5] Голяма – галимнәр. Б и р е д ә : «руханилар» мәгънәсендә.

язалар, ләкин алар аны бераз гына үзгәрткәннәр. Шул хәрефләр белән аларның китаплары басыла, хәтта гәзитәләре нәшер ителә.

Ислам динен кабул иткән төрк халыклары арасында акрын-акрын гарәп язуы таралып, ахырда уйгур язуын кысрыклап чыгарган. Гарәп язуының уйгур язуы белән көрәше берничә гасырларга сузыла. Мәгълүм ки, Урта Азия төркләренең ислам белән мөнәсәбәткә керүләре VIII гасырлардан башлана; шул ук вакытлардан башлап Урта Азия Гарәп хәлифәтенә кушыла; шуннан төркләр арасында исламият таратыла башлый. Дин белән бергә гарәпләр үзләренең язуларын да алып киләләр. Х гасырда инде ислам дине нык таралган булып, гарәби уйгурлар да бу динне кабул иткән булалар. «Котадгу белег»нең[1] уйгур хәрефе белән соңгырак гасырларда күчерелгән нөсхәсендә аятьләр вә гарәби гыйбарәләр гарәп язуы белән язылганнар. Корьәннең гарәп хәрефләреннән башка хәреф белән язылырга ярамавы, гомумән, уйгур әлифбасының гарәп сүзләрен язар өчен сәлахиятсез[2] булуы, гыйлем теленең гарәп теле булучылыгы, төркләрнең дә әдәби теленә бик күп гарәп сүзләренең керүе мөселман төркләрен, үз язуларын ташлап, гарәп әлифбасын кабул итәргә мәҗбүр иткән.

Урта Азия төркләре арасында соңга табарак, иранлылар тәэсирендә, алар тарафыннан ихтираг ителгән[3] тәгъликъ һәм шикәстә язулары[4] гомумиләшеп киткән.

Идел буе төркләреннән борынгы болгарларда гарәп язуыннан башка язуның истигъмале хакында тарих кулында һичбер мәгълүмат вә документ юк. Азиядән килгәндә, болгарларның үз язулары булмаган булырга кирәк, чөнки аларның җәнүбкә

---

[1] Йосыф Баласагунлының «Котадгу белег» (1069–1070) поэмасы.

[2] Сәлахиятсез – яраксыз.

[3] Ихтираг ителгән – уйлап табылган.

[4] Тәгъликъ һәм шикәстә – гарәп язуының төрләре. Тәгъликъ – Иранда XIII гасырда барлыкка килгән классик язу төре. Гадәттә, фарсы әдәби әсәрләре бу стиль белән язылган. Хәрефнең вертикаль элементлары кыскарак һәм нечкәрәк, ә горизонталь өлешләре дулкын сыман сыгылмалырак. Шикәстә – язу стиле, тәүкигъ һәм тәгъликъ стильләре кушылудан туган тиз язулы курсив стиль.

аерылып киткән ботагы, Балкан ярыматавына барып чыккач, юнан әлифбасын кабул иткәннәр. Болгарга баш-баштан, ислам кабул итү белән үк, гарәп язуы кереп киткән булырга кирәк. Һәрхәлдә, тәңкәләрдә булсын, кабер ташларында булсын – без гарәп язуын гына очратабыз. Шунысы кызык ки, XIV гасырда куелган ташларда да әле күфи язуы кулланыла. Шул ук күфи язуын[1] без Алтын Урда акчаларында да күрәбез. Күфи язуы тормышта истигъмаль өчен уңайсыз булганга, аны шул кабер ташы һәм тәңкәләрдә генә кулланганнар булса кирәк. XIV гасырда, рәсми хөкүмәт язуы уйгурныкы булуга карамый, гарәп язуы халык арасында шулкадәр гомумиләшкән булырга кирәк ки, Тимер Котлыг шикелле ханнар инде, мөһимрәк рәсми язуларны (пайзалар) уйгур хәрефе белән язсалар да, гомум халык тарафыннан укылуы вә аңлануы матлуб[2] булган документларны, мәсәлән, Тархан ярлыкларын, һәр ике язу белән берьюлы астлы-өстле ике юл итеп язарга мәҗбүрият күргәннәр. Кырым канцелярияләрендә дивани[3] язуы бик мәкъбүл булган. Бу язу белән язылган бик мәшкый[4] каләмле ярлыклар кырымлылардан күп сакланып калган. Госманлы төркләренә гарәп язуының һәр төрлеләре кергән. Шуның өстенә тагы соңгы гасырларда госманлылар, тиз язу өчен уңайлы булган, рокъгә[5] ихтираг итеп[6], Төркиядә шул язу гомумиләшеп киткән. Шулай итеп, рокъгә – гарәп язуының төркләр тарафыннан үзгәртелеп миллиләштерелгәнедер.

---

[1] Күфи язуы – гарәп язуының иң борынгы төре, VII гасырда Күфә шәһәрендә барлыкка килгән. Бу төр язуда хәрефләр очлы һәм калын, монументаль булуы белән аерылып тора. Иң беренче Коръән китаплары бу стиль белән язылган. Архитектур корылмаларның бизәлешендә, рәсми эш кәгазьләрендә кулланылган.

[2] Матлуб – теләнгән, таләп ителгән.

[3] Дивани – гарәп язуының каллиграфик бер төре. Хәрефләрнең берберсенә тыгыз урнашулары, катлаулы һәм берникадәр авыш язылышлары белән аерылып тора. Госманлы төрекләр тарафыннан XVI гасырда уйлап табылган дип санала.

[4] Мәшкый – матур язулы.

[5] Рокъгә – гарәп язуының бер төре. Тиз язу өчен файдаланыла.

[6] Ихтираг итеп – уйлап чыгарып.

## III
## Орхон ташбилгеләре

Читләр, күршеләр тәэсиренә бирелмичә, төркләрнең үзләрендә ясалган идеологиягә бина кылынган беренче язма әдәбият әсәрләре Орхон язуы белән язылган документлардан гыйбарәтдер. Боларның да әдәби яктан иң зур әһәмияткә малик[1] булганнары – шимали Монголиядә ту-күә төркләре заманында ташларга язылып калган язулардыр. Аларның кайчан куелганнары тәгаен мәгълүм булганнары, шулай ук мөндәриҗә[2] һәм өслүб ягыннан да иң мөһимнәре Орхон суы буенда табылган, VII гасырда Билге каһан һәм Күлтәгин батыр шәрәфенә утыртылган ике зур таш булганга, аларга без озаграк тукталып узабыз.

Ту-күәләрнең мәмләкәте Азия кыйтгасының шәрыктан гарбенә кадәр бик күп җирләрен үзенең эченә алган булган. Аның мәркәзе исә шул ук борынгы һун-нулар мәмләкәтенең мәркәзе, шимали Монголия, җәнүби Себер, Янәсәй елгасының башлары һәм Байкал күле тирәләре икән. «Ту-куе» яки «ту-күә» – кытай вәкаигънамәләре тарафыннан бу халыкка вә мәмләкәткә тагылган исем. Бу сүзне кытай тәләффызынча[3] бозып әйтелгән «төрк» дигән сүз булырга кирәк дип уйлыйлар. Үз язуларында алар үзләрен «төрк» дип кенә атыйлар. Бу мәмләкәт VI гасырның урталарында тәшкил ителеп, ике йөз ел микъдары дәвам иткән. Борынгы заманда төрк мәмләкәтләре күбесенчә сөяләләргә[4] карап йөртелгәннәр; бер яңа хан сөяләсенең башлануы күбесенчә башка, тирә-күршедәге чит халыклар күзендә яңа патшалык төзү булып күренгән, чынлыкта исә бер үк урында берсе артыннан берсе төрле исемдәге төрк ханлыкларының төзелүен бер үк төрк илнең дәвамы, бары тик төрле төрк кабиләләренең хакимият башына чыгуы, алдан хөкүмәт

[1] Малик – ия.
[2] Мөндәриҗә – эчтәлек.
[3] Тәләффызынча – әйтелешенчә.
[4] Сөяләләргә – нәселгә, ыруга.

сөргәннәренең арткы планга күчүе дип карарга мөмкин. Без сөйли торган замандагы төрк сөяләсенең башы Бумын[1] исемле каһанда башланып киткән булырга кирәк. Бу сөяләлә хөкем сөргән заманда төрк иленең иң куәтле вакыты VI гасырның ахырыннан алып VII гасырның урталарына кадәр булган. Шуннан соң ул акрынлап инкыйразга таба йөз тота башлый. Үзара низаглар, эчке сугышлар китә; хөдүдләрдән[2] чит халыклар кысрыклый башлыйлар. Төркләр белән гомергә чиктәш булып торган кытайлар, төркләрнең искедән килгән дошманнары, бу үзара тартышудан, төрк мәмләкәтенең зәгыйфьлегеннән файдаланып, төрк иленә баш булалар. Ләкин төркләр, тагы күтәрелеп, өстләреннән кытай тәсәллытын[3] алып ташларга муаффәкъ булалар[4]. Милади VIII гасыр башында Мәгыйлән (Билге)[5] исемле каһан белән аның энесе, гаскәр башы каһарман Күлтәгиннең[6] иҗтиһадлары, армас-талмас сугышлары аркасында, авыр бара торган төрк мәмләкәте, яңадан күтәрелеп, элекеге шәүкәтле хәленә кайта яза. Бу ике шәхес, төрк халыкларын берләштереп,

---

[1] Бумын – Төрки Каһанлыкка нигез салучы (552 ел). Халыкларның Бөек күченүе вакытында һуннарның бер өлеше Ашина кул астында Алтай тавы итәкләрендә яшәп кала. Әмма аларны Жужан каһанлыгы үзенә буйсындыра. 534 елда бу төрки кабиләләрнең башлыгы булып Бумын кала. 542 елда аның җитәкчелегендә төркиләр Алтайдан көнчыгышка – Кытай чигенә, Хуанхэ елгасына кадәрге җирләрне яулап ала. 545 елны Кытай империясенең хакиме Юйвэнь Тай Бумынга илче җибәрә. Бу вакыйга тарихка төрки кабиләләр берләшмәсен рәсми халыкара тану буларак керә. Бумын төрки кабиләләрне берләштерә башлый. 551 елда зур гаскәр белән жужаннарга каршы сугыша һәм җиңә. Шулай итеп көчле империя – Төрки каһанлык нигезләнә. Бумын – Каһан (Илхан) дигән титул ала. Әмма 552 елда ул үлә.

[2] Хөдүдләрдән – чикләрдән.

[3] Тәсәллытын – биләп алуын.

[4] Муаффәкъ булалар – ирешәләр.

[5] Мәгыйлән яки Билге каһан – Көнчыгыш Төрки каһанлыкның 716–734 елларда каһаны. Ташъязмаларга караганда, 683 елда туа, Әлтериш каһанның олы улы.

[6] Күлтәгин – Билге каһанның энесе, сугышчы-каһарман. 731 елны үлә, аңа ташны һәм һәйкәлләр комплексын Билге каһан куйдыра. Билге каһан, Күлтәгин һәм Тоньюкук идарә иткән заманда каһанлык зур үсешкә ирешә, Тан империясе белән солых төзелә (721).

бер яктан, кытайларга, икенче яктан, яңа гына Мавәраэннәһергә килеп чыккан гарәпләргә, өченче яктан, каһанга баш тартып илгә хыянәт иткән төрк кабиләләренә каршы сугышалар; гарәпләрнең шәрыкка таба омтылуларына чик куеп, мөселман гаскәрен Тимер капудан ары уздырмыйлар. Ләкин икътисади сәбәпләр тәэсирендә егылырга мәхкүм булган[1] бу төрк мәмләкәте озакламый, Билге каһан белән Күлтәгин үлгәннән соң, VIII гасырның урталарында тарала.

Ту-күә төркләренең кыскача сәяси тарихы менә шуннан гыйбарәт. Менә шул тарихи мәгълүмат, хосусән, таш куелган затларның үзләре заманындагы яки аларга якынрак булган замандагы вакыйгалар мәшһүр Орхон ташларындагы язуларның башлыча мөндәриҗәсен тәшкил итәләр. Мәдәни хәлләренә килсәк, алар шул беренче бабта тасвир ителгәнчә, гомум күчмә төрк халыкларындагыча булган. Ләкин аларда беркадәр утраклыкка күчү башланган булса кирәк. Чөнки шәһәрләренең дә булганлыгы мәгълүм (мәсәлән, «Ту-күә»ләрнең пайтәхете Карабалгасун[2] шәһәре шикелле). Аларның яшәгән җирләре ифрат мөнбит[3] вә иген үстерергә сәлахиятле[4] җирләр, мөнбит вадилар (су буйлары), дала характерындагы таулыклар (плоскогория)[5] булган. Ту-күә төркләре иген игү белән дә шөгыльләнгәннәр булырга кирәк. Чөнки Орхон һәм Сәләңә (Селенга) буйларында бик борынгы заманнан калган җир сугару өчен эшләнгән су юллары – арыкларның эзләре әле һаман да бар икән[6]. Хәзерге монголлар исә җир эшләү белән аз шөгыльләнәләр; алар күбрәк чын

[1] Мәхкүм булган – хөкем ителгән.

[2] Карабалгасун шәһәренең хәрабәләре Орхон буенда. Хәрабәләрнең буе 8 чакрымга сузыла. Карабалгасун электә уйгурларның пайтәхете булган. «Ту-күә»ләр заманында да ул булып, алар өчен дә шул ук вазифаны үтәгәндер, дип уйлана. Соңрак заманда (XIII гасырда) шул ук урында Чыңгызның пайтәхете Каракорым булгандыр, дип чамалана. *(Авт. иск.)*

[3] Мөнбит – уңдырышлы, яхшы.

[4] Сәлахиятле – яраклы.

[5] Кирилл язуы белән язылган.

[6] Сборник трудов Орхонской экспедиции, IV. *(Авт. иск.)*

күчмәле тормыш белән торып, хайван асрау белән генә көн күрәләр. Иң якын мәсафәдә торган мәдәни халык булганга күрә, ту-күә төркләре кытайлар белән һәрвакыт иң якын сәяси, икътисади вә мәдәни мөнәсәбәттә булганнар. Бер яктан, алар кытайлар белән сугышсалар, аларны хираҗ[1] түләргә мәҗбүр итсәләр яки үзләре аларга икътисади коллыкка төшсәләр, икенче яктан, аларның бер-берсе белән солыхпәрвәрәнә мөнәсәбәтләре, алыш-бирешләре, мәдәни икътибаслары[2] да һичбер вакыт тукталып тормаган. Шәһәр мәгыйшәтенә махсус мәдәният әсәрләре, мәсәлән мигъмарчылык[3], ташчылык шикелле сәнгатьләрдә төркләр бөтенләй кытайлар артыннан барганнар. Мондый мәдәни кирәкләрен аларга Кытай осталары башкарып биргәннәр. Бары язу сәнгатендә генә төркләр кытайларга бөтенләй иярмәгәннәр, аларның үзләренә махсус язулары булган.

«Орхон ташлары» яки «Орхон ташбилгеләре» дип мәшһүр булган ике таш шимали Монголиядә, Байкал күленең җәнүб тарафында, шул күлгә коя торган Сәләңә (Селенга) елгасының тармакларыннан Кукшин-Орхон (Кокшин-Орхон) исемле кечерәк агымсуының буенда «Кушу-Цайдам» аталган җирдә булып, югарыда исемнәре зикер кылынган ту-күәләр ханы Мәгыйлән (Билге) каһан белән Күлтәгин батыр шәрәфенә утыртылган булганнар. Бу урын табигатьнең газамәтле[4] бер урыны булып, тирәсе биек таулар белән кыршатылган биек яр өстендәге табигый бер мәйдан шәкелендә. Ташлар бер-берсеннән бер чакрым ераклыкта куелган. Һәр ике ташның яннарында гыйбадәтханәләр дә булган булырга кирәк. Ләкин яндырылмаган кирпечтән салынганга, алар заманның үтүе белән җимерелеп, җир белән тигез булып калганнар. Бу мәгъбәдләрнең[5] эчендә ниндидер кешеләрнең (хан һәм аның якыннарының булырга

[1] Хираҗ – налог.
[2] Икътибаслары – алыш-биреш.
[3] Мигъмарчылык – төзүчелек.
[4] Газамәтле – мәһабәтле.
[5] Мәгъбәдләрнең – гыйбадәтханәләрнең.

кирәк) мәрмәр ташыннан юнылган сыннары, шулай ук арыслан вә болан шикелле хайваннарның һәйкәлләре булган. Бу һәйкәлләрнең Кытай осталары кулыннан чыкканлыклары күренеп тора. Ләкин сыннарның һичберсе диярлек бөтен килеш сакланмаган: кемнәрдер бик тырышып аларны ваткалап бетергәннәр.

Мәгъбәдләр эчендә, корбан яндырыр өчен, махсус ташлар куелган. Язулы ташлар үзләре соры төсле мәрмәрдән юнылып, шул ук таштан ясалган гөберле бака һәйкәлләренең аркаларына утыртылган булган. Хәзер ташлар егылып, берничә кисәккә ватылганнар.

Билге каһан ташының биеклеге 3 метр 45 сантиметр, киңлеге 1 метр 74 сантиметр, калынлыгы 48 сантиметр; Күлтәгин ташының биеклеге 3 метр 15 сантиметр, киңлеге бер метр 24 сантиметр, калынлыгы 41 сантиметр. Ташларның өсләре кытай стилендә аждаһа сурәтләре белән бизәлгән; өске почмакларында ханнарның тамгалары чокып төшерелгән. Ташлардан башлап, бер-берсеннән биш-алты (бәгъзан өч) сажин ераклыкта итеп, бер-бер артлы таш баганалар утыртылып киткән. Бу баганалар күбесенчә ике аршын чамасы биеклектә булып, тупас кына адәм кыяфәтендә яки башлары гына кеше башы рәвешендә юнылган. Хәзерге көндә бу баганаларның күбесе ауганнар яки сынганнар. Шушы багана тезмәләренең озынлыгы Билге каһан ташыннан өч чакрымга, Күлтәгиннекеннән дүрт чакрым ярымга сузыла[1].

Борынгы заманда төркләрдә шундый гадәт булган: бер атаклы кеше үлгәч, шул кеше үз гомерендә сугышта ничә дошман үтергән булса, шуның санынча таш багана утырта торган булганнар. Бу баганалар гүя үтерелгән дошманнарның садәләштерелгән һәйкәлләре булган. Төркләрдә ирнең фазыйләте[2] – батырлык белән, батырлык исә сугышта үтерелгән дошманнарның саны белән хисаплана икән. Үтерелгән дошманнарның саннары бер дә саташтырылмыйча саналып (регистрация ясалып!)

[1] Сборник трудов Орхонской экспедиции, IV. *(Авт. иск.)*
[2] Фазыйләте – яхшылыгы, өстенлеге.

барылып, ихтимал, бәгъзан[1] юри арттырыла да булгандыр. Бу ташлар «балбал» аталып[2], балбалларның күп булуы төркләрнең «ма биһи-л-ифтихар»ы[3] булган. Иң атаклы дошманның балбалы иң башта, ягъни кабер ташына иң якын торып, башкалары үзләре тәҗәссем иттергән[4] затларның дәрәҗәләре буенча тезелә икән. Димәк, башта – патшаларның, ханнарның, аннан соң бикләрнең, түрәләрнең, батырларның, иң соңыннан гади сугышчыларның балбаллары тезелгән. Балбалларны төркләрнең үз осталары ясагандыр дип уйлыйлар.

Хасиле[5], хәзерге калдыкларына караганда, бу һәйкәлләр, мәгъбәдләр барысы берлектә заманасында яхшы ук мәһабәт бер манзара тәшкил иткәннәр. Ханнарның каберташлары тирәсенә вакыт-вакыт мәмләкәттәге төрк кабиләләре тәгъзия[6] өчен җыелып, меңнәрчә халык зур җыелышлар, тантаналы зыяфәтләр[7] ясыйлар икән. Шуның өчен мәкъбәрәләр[8] халык җыелырга уңайлы киң мәйданда, далада ясалган. Әмма ханнарның күмелгән урыннары бу ташлар астында булмыйча, башка бер урында булган булырга кирәк; таш утыртылган җирләр бары тик рәсми тәгъзия вә гыйбадәт урыннары гына булгандыр, диләр, чөнки тәфтиш һәйәтләре[9], никадәр таш астындагы җирне казыштыргалап карасалар да, һичбер төрле кабер әсәре тапмаганнар. Дошманнар тарафыннан тәхфиф ителүдән[10] куркып, ханнарның мәетләрен халык белми торган яшерен урынга күмү төркләрдә гадәт булган[11].

---

[1] Бәгъзан – кайчак, кайвакыт.

[2] Борынгы рус телендә санәм – пот мәгънәсендә булган «болван» сүзе, төркләрдән алынып, «балбал»дан үзгәртелгән булырга кирәк. *(Авт. иск.)*

[3] Ма биһи-л-ифтихары – аның белән мактаныла торган нәрсәсе, мактанычы.

[4] Тәҗәссем иттергән – гәүдәләндергән.

[5] Хасиле – нәтиҗә ясап әйткәндә.

[6] Тәгъзия – үлгәннәрне искә алып күңел юату.

[7] Зыяфәтләр – хөрмәтләүләр.

[8] Мәкъбәрәләр – каберлекләр.

[9] Тәфтиш һәйәтләре – гыйльми экспедицияләр.

[10] Тәхфиф ителүдән – җимерүләрдән, кимсетелүдән.

[11] Сборник трудов Орхонской экспедиции, IV. *(Авт. иск.)*

Үлгән ханнарны искә төшерү урыннарының шәп вә һәйбәтле булуына караганда, ту-күә төркләренең мәдәнияттә яхшы ук алда торганлыкларын аңларга мөмкин. Гәрчә аларның үзләре арасында бу бина вә һәйкәлләрне эшләрлек сәнгаткярләр булмыйча, бу эшләрдә алар Кытай осталарының хезмәте белән файдалансалар да, мондый нәрсәләрнең кирәклеге хис ителү үзе шактый югары дәрәҗәи мәдәниятне күрсәтәдер. VI гасыр миладида ту-күәләргә барган, Бизанес кайсарының сәфире[1] Симархның сәяхәтнамәсендә ту-күә каһаннарының сарайларын тасвиры да моңар дәлаләт итә[2]. Ләкин бу мәдәниятнең тышкы ягы гына булып, күршеләре кытайларга тәкълидтән[3] килеп чыккан булырга кирәк. Мәдәният кабыгы, әлбәттә, югары сыйныфларда гына булгандыр; халык исә аннан ерак булып, чын күчмәле дала көнкүрмеше белән яшәгән. Чынлап караганда, ханнар үзләре дә матди вә рухани тормыш ягыннан халыктан артык аерылмаганнар. Язу һөнәре халык арасында таралган бернәрсә булмаенча, бары тик хөкүмәт кирәкләре өчен генә истигъмаль ителгән[4] булырга кирәк. Аларның язуларының тиз язу өчен уңайсыз булуы да моны ачык күрсәтәдер.

Күлтәгин һәм Билге каһан ташларының дүрт ягы да язулар белән капланган. Бу язулар ташка тирән казылып язылганга, заманның озынлыгы белән таш ашалуга карамый, яхшы сакланганнар: бозылган, танымастай урыннары ул кадәр үк күп түгел. Ташны чокып язу эше дә Кытай осталары тарафыннан үтәлгән булырга кирәк. Ташларның бер ягы – төркчә, бер ягы кытайча язулар белән капланган; кырыйлары да язулар белән тулы; почмаклары да коелып төшерелеп, анда да язулар язылган. Ташларның бит ягындагы язуларны – «зур язулар», кырыйлардагыларын «кечкенә язулар» дип йөртәләр.

[1] Бизанес кайсарының сәфире – Византия императорының илчесе.
[2] Дәлаләт итә – дәлил булып тора.
[3] Тәкълидтән – иярүдән.
[4] Истигъмаль ителгән – кулланылган.

Орхон ташларындагы кытайча язуларның мөндәриҗәсе төркчәләре белән бер түгел. Кытайча язуларда бу биналарның вә ташларның Кытай патшасының әмере белән эшләнгәнлеге сөйләнгән; кытайлар белән төркләрнең мөнәсәбәтләре хакында солыхпәрвәранә сүзләр язылган; Күлтәгин һәм Билге каһан мәдех ителгән[1].

Күлтәгин һәм Билге каһан ташларындагы язуларның төркчәләре гаять саф телдә язылганнар. Чит телдән кергән сүзләр анда бер дә диярлек очрамый; очраса да алар тик «шад, кунчуй» шикелле кытайчадан кергән сарай вә түрәлек дәрәҗәләрен аңлата торган истыйляхлар[2] гына; алар да төркләштерелеп үзгәртелгәннәр. Бу тел шул заманда ту-күә төркләренең сөйләшкән теле булганмы, әллә заманасында гомум төрк халыклары язуда истигъмаль иткән бер «әдәби тел» булганмы – моны тәгаенләп әйтү, әлбәттә, читен. Сафлыгына, шуның белән бергә әдәбилегенә карап, бу шул заман төркләренең халык әдәбияты теленә якын бер тел булырга кирәк дип чамаларга мөмкин. Хәзерге заманда бу телдә сөйләүче төркләр юк. Борынгы, онытылган тел булганга күрә, аны аңлау шактый авыр. Аны аңлар өчен, төрле төрк шивәләрен белергә кирәк. Шунда да язуларның байтак урыннарының мәгънәсенә тирән моталәгадан[3] соң гына төшенеп була. Бәгъзы җирләре никадәр моталәгадан соң да тәмамән аңлашылмыйча, шөбһә астында калганнар. Чөнки бу телдә бик күп борынгы, югалган сүзләр, искереп истигъмальдән чыккан, онытылган формалар вә гыйбарәләр очрый. Бәгъзы сүзләрне хәзерге төрк телләрендәге сүзләргә кыяс белән[4] генә аңларга мөмкин. Орхон язулары – безгә моннан мең ике йөз еллар элек төрк телләренең нинди булуын күрсәтә торган нәмунәләрдәндер[5]. Бу язу калдыкларына карап, без хәзерге төрк телләренең борынгы-

[1] Сборник трудов Орхонской экспедиции, III. *(Авт. иск.)*
[2] Истыйляхлар – атамалар, терминнар.
[3] Моталәгадан – укып тикшергәннән.
[4] Кыяс белән – охшату, чагыштыру белән.
[5] Нәмунәләрдәндер – үрнәкләрдәндер.

ларына караганда никадәр үзгәргәнлеген күрәбез. Орхон язуларының телен хәзерге төрк телләре шәгъбәләреннән[1] кайсына да кертүе уңайсыз. Анда Радлов таснифы[2] буенча билгеләнгән һәрбер дүрт шәгъбәнең дә бәгъзы хосусиятләрен табарга була. Ихтимал ки, моннан меңике йөз ел элек әле төрк телләре арасында хәзерге төсле дифференциация ясалмаган, алар бер-берсеннән ул кадәр күзгә бәрелерлек аермалар белән аерылмаган булганнардыр. Орхон язуларының телендә җәнүби төркләрнең сүзләрен, тәләффызларын[3], сарфи[4] формаларын бик күп очраткан шикелле, шәркый төрк телләренең дә хосусиятләрен очратырга мөмкин. Шулай ук кайбер яктан ул урта һәм гарәби төрк телләренә дә охшый; мәсәлән, анда без «бүре, сыңар, бай, хатын, ир-ат, үлүҗиту (үлә-йитә), иң элек (әң әлиг)» шикелле безнең татарчада да булып, шул ук (яки шул ук диярлек) мәгънәдә йөртелә торган сүзләрне, «каһанын» дигән шикелле татарча төсле сарфи формаларын очратабыз. Радлов Орхон язулары язылган телне үзенең элегрәк ясаган таснифында җәнүби төрк телләре рәтеннән санап, хәзерге җәнүби төрк (госманлы, төрекмән) телләренең бабасы (төбе) дип хисаплаган. Ләкин үзенең соңгы таснифында, бу фикердән кайтып, аны шәркый телләрнең бер тармагы дип күрсәткән. Хәзерге җәнүби төркләрнең бабалары угызлар, әлбәттә, тукүә төркләре булган заманда ук дөньяда булганга, Орхон телен җәнүб төркләренең асылы дип танып булмый[5].

Орхон язуларының өслүбе дә бик матур, хәтта урыны-урыны белән тасвири (художественный). Һәрхәлдә, гарәпләрнең фәсыйх-бәлигъ[6] дигән тәгъбирләре аңар бик туры килә. Бу язуларны тәртип итүче – Билге каһанның кардәшләреннән

---

[1] Шөгъбәләреннән – төркемнәреннән, тармакларыннан.

[2] Таснифы – бүлгәләве, классификациясе.

[3] Тәләффызларын – әйтелешләрен.

[4] Сарфи – грамматик.

[5] Самойлович А.Н. Некоторые дополнения к классификации турецких языков. *(Авт. иск.)*

[6] Фәсыйх-бәлигъ – матур, килешле, әдәби.

Йоллык[1] Тәгин[2] исемле зат булган. Ул әдип вә шагыйрь кеше булган булырга кирәк. Язуларның күбрәге нәсер белән язылган, ләкин шигырь белән язылган бәгъзы җөмләләр дә бар. Мәсәлән, ташларның коелып төшерелгән почмакларына язылган кыска язуларның кайберсендә, бу язуларның яхшы ук бозылган булуына карамый, вәзен аермачык күренеп тора. Мәсәлән, Йоллык Тәгиннең имза иткән җөмләләре шикелле:

Бунча битиг битигмә
Күлтәгин атысы
Йоллык Тәгин битидим.
Йәгирми көн улуруп,
Бу ташка бу тамга күп
Йоллык Тәгин битидим.

(Мәгънәсе: Бу кадәр язуларны мин, Күлтәгиннең кардәше, Йоллык Тәгин яздым. Егерме көн утырып, бу таш өстенә тамгалап мин, Йоллык Тәгин яздым).

Бу шигырьнең вәзене төрк халыкларына махсус бик борынгы вәзен булып, хәзерге көнгә кадәр төркләрдә югалмаган[3]. Аның үлчәве белән безнең татар халык җырларының үлчәве бер үк әсаска бина кылынган. Шулай итеп, Йоллык Тәгинне безгә мәгълүм булган беренче төрк әдибе дип, аның язып калдырган ташларын да беренче төркчә әсәрләр дип атарга мөмкин.

Билге каһан һәм Күлтәгин ташындагы язулар бер-берсеннән бик аз гына, бары аларның хосуси каһарманлыкларын вә эшләрен санаган урыннарда гына аерылалар: юкса һәр ике ташның да мөндәриҗәсе бер үк дияргә ярый. Ике ташта да сүз каһан

[1] Йоллык каһан – Билге каһанның улы, әтисе үлгәч, 734–739 елларда ил белән идарә итә. Билге каһанга ташны ул куйдыра. Төркиләрдән беренче тарихчы дип санала.

[2] «Тәгин» сүзе борынгы төркләрдә хан нәселеннән булган кешеләрнең исемнәре артына тагыла торган, титул сымак сүз булган. Соңгырак заманда сәлҗук солтаннары арасында «Сөбектәгин», «Алыптәгин» шикелле исемнәр күп очрый. *(Авт. иск.)*

[3] Корш Ф. Древнейший народный стих турецких племен. Зап. Вост. Отд. Имп. Русского Арх. О-ва, г. XIX, вып. II–III. *(Авт. иск.)*

исеменнән сөйләнә. Күлтәгин агасы Билге каһаннан берничә ел элек үлгән. Ташны аңар агасы утырткан. Каһан үлгәч, шул ук язуларны бераз гына үзгәртеп, аның үз кабер ташына язганнар. Билге каһанның үз ташындагы язулар артыграк бозылып, танылмый торган урыннары күбрәк булганга, без Күлтәгин ташын тикшерү белән генә канәгатьләнәбез; аның да әһәмиятлерәк вә тулырак мөндәриҗәле булган зур язуын алабыз.

Билге каһан ташының вә һәр ике таштагы кечкенә язуларның игътибар итәрлек бер ноктасы булса, ул да аларның башлангыч сүзләредер. Билге каһан ташының Зур язуы шушы сүзләр белән башлана: «Тәңре тәг, Тәңре яратмуш түрк Билге каһан сабм». Мәгънәсе: «Күккә тиң, күкнең яратканы белекле төрк ханы сүзем»[1]. Һәр ике кечкенә язу шушылай башлана: «Тәңри тәг, Тәңридә булмуш түрк Билге каһан бу өдкә (бүдкә) улуртум». Мәгънәсе: «Күккә тиң, күктән булган белекле төрк ханы бу вакытта (тәхеткә) утырдым». Менә бу «Тәңре тәг, Тәңре яратмыш (Тәңредә булмыш) төрк Билге каһан» дигән җөмләне ту-күә каһаннарының титулы булырга кирәк дип уйлыйлар. Бу каһанны Кытай мөәррихләре[2] Мәгыйлән (Моцзилян яки Могилян[3]) дип атыйлар. Ләкин таштагы кытайча язуларда аның исеме «Бикә кәхан» (Бикя кэхан[4] – Билге каһан) дип язылган. Төркчә язуларда да ул Мәгыйлән (яки Магыйлан) дип йөртелми. Башлангыч җөмләләрдән башка урында аның исеме зикер кылынмый, чөнки андагы сүзләр ханның үз исеменнән (үз авызыннан) сөйләнәләр. Баштарак, баш җөмләдәге һәм кытай язуларындагы «Билге каһан» тәгъбиренә карап, аның Билге исемле булуын ихтимал тотканнар. Ләкин «Билге» сүзе, «белекле» мәгънәсендә булып, ту-күә каһаннарының титулларына керә торган бер мактау сүзе булганга, каһанның хас исеме булмаска тиеш дигән фикер дә булган.

[1] Бу рәвешчә элек хан үзенең исем вә титулын әйтеп, аннан соң «сүзем» дип башлап китү төрк халыкларына махсус рәсми өслүб; соңрак заманда Алтын Урда ханнары да үзләренең ярлыкларын шулай башлаганнар. *(Авт. иск.)*

[2] Мөәррихләре – тарихчылары.

[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[4] Кирилл хәрефләре белән язылган.

Затән[1], Кытай тарихлары да шушы фикерне куәтлиләр. Кытайлар төрк исемнәрен бик ялгыш язганнар. Бу аларның язуында һәм кытай телендә төркләргә махсус хәрефләрнең җитешмәвеннән килә. Кытайлар тарафыннан, ни сәбәптәндер, бәгъзы төрк ханнарының исемнәре бөтенләй башкача язылган. Мәсәлән, шул ук Мәгыйлөннең атасы төркчә язуларда «Әлтәрәс» – «Бумын» дип, кытайча язуларда «Гудулу» дип аталган. Уйларга мөмкин ки, Мәгыйлән исеме дә хата тәләффыз белән яки бөтенләй үк төркләр үзләре әйтмәгәнчә язылгандыр. Бер кереп киткән гадәт буенча, без бу каһанның исемен Билге дип кенә йөрттек.

Орхон язуларыннан шул замандагы төркләрнең диннәре хакында да беркадәр мәгълүмат алып була. Ту-күә төркләре шаман динендә булганнар, бөтен кяинәткә[2] коллык кылганнар. Табигать вә аның көчләре алар каршында төрле мәгъбүдләр[3] шәкелендә тәҗәссем иткән[4]. Баш мәгъбүд Тәңре булган, ул күкне тәҗәссем иттергән. Борынгы төрк телендә «Тәңре» – «күк» (сәма, небо[5]) мәгънәсендә, шул ук вакытта ул бер мәгъбүднең дә исеме. Соңгырак заманда, төркләр ислам кабул иткәч, «Тәңре» сүзе Алла (мөселман Алласы) мәгънәсендә генә истигъмаль ителә башлап, «сәма» мәгънәсен аңлатыр өчен, аның төсеннән алынган сыйфат исеме – «күк» сүзе кулланыла башланган. Орхон язуларында «Тәңре» сүзе һәр ике мәгънәдә китерелә: «Тәңре ярлыкаганга күрә», «Тәңре көч биргәнгә күрә» шикелле җөмләләрдә ул – «илаһ» мәгънәсендә, «Өстдә күк Тәңре, астда кара җир ялгач, ике арада кешеләр яратылган», «Өстдән тәңре басмаса, астда җир ярылмаса» шикелле урыннарда гади «күк» – «сәма» мәгънәсендә килә. Төркләр игътикадынча[6], дөнья вә кешеләрне яратучы (халикъ) шул Тәңре булган. Аның

[1] Затән – нигездә, гомумән алганда.
[2] Кяинәт – дөнья, галәм.
[3] Мәгъбүдләре – табына торган затлары.
[4] Тәҗәссем иткән – гәүдәләнгән.
[5] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[6] Игътикадынча – ышануынча.

хакында «ил бирүче Тәңре» дип әйтелә. Ханнар үзләренең хакимиятләрен шул ук Тәңре тарафыннан бирелгән итеп хисаплыйлар; үзләрен Тәңрегә тиңләштерәләр, аның сөйгәне дип атап, нәсел-нәсәпләрен дә аңар илтеп териләр[1].

Аннан соң без Орхон язуларыннан төркләрнең Җир-су (Ярсүб) исемендә икеле бер мәгъбүдләре[2] булганын күрербез. Бу мәгъбүд – Күкнең хатыны урынында булган икенче бер зур мәгъбүд булырга кирәк. Тәңре белән Яр-сүб һәр икесе берлектә төрк халкының кайгысын кайгырталар. Яр-сүб та, Тәңре сүзе шикелле үк, ташларда ике төрле мәгънәдә истигъмаль ителә. Мәсәлән, «югарыда төрк Тәңресе, җир-суы: төрк халкы юк булмасын... дигәннәр» дигәндә, ул мәгъбүд булу йөзеннән, әмма «Күгмән җир-суы иясез калмасын...» дигәндә, гади җир-су мәгънәсендә кулланылган. Шулай ук язуларда Умай исемле бер мәгъбүд зикер ителә. Умай – хатын мәгъбүд. Билге каһан, анасы хакында сөйләгәндә: «Умайга тиң анам – хатын», – ди. Умай атлы мәгъбүд хәзерге шамани алтай төркләрендә дә бар. Ул аларда аналыкны тәҗәссем иттерә торган, яшь балаларны яклаучы, рәхмәтле мәгъбүд исәпләнә. Орхон язуларында төркләрнең табына торган, изге урыннары, «Идук»лар да зикер ителгәли[3].

Күлтәгин ташындагы язу дөнья яратылуын сөйләп башлап «Өстә зәңгәр күк, аста кара җир яралгач, шуларның ике арасында кеше угыллары яратылган» (Өзә күк Тәңре, асра ягыз яркылындукта, экин ара кише углы кылынмуш)[4] дип әйтә дә, шунда «кеше угылларын» төркләрдән генә гыйбарәт булган шикелле итеп, «Кеше угыллары өстеннән олуг бабам Бумын каһан – Истәми каһан хан булып утырган» (Кише углында өзә

[1] Безнең татардагы «Көн күрмәгән көн күргән – Тәңре белән тиң булган» дигән мәкальнең төбе-тамыры, ихтимал, бик ерак заманнарга бара торгандыр. *(Авт. иск.)*

[2] Мәгъбүдләре – табына торган затлары.

[3] Зикер ителгәли – искә алынгалый.

[4] Борынгы төрк телендәге *о* һәм *ӧ̈* авазлары өчен «و» һәм «ؤ» хәрефләре алынды. Урынына карап «и» язылганча булса да, «ө» дип укырга да мөмкин. Тәрҗемәләр Радлов буенча. *(Авт. иск.)*

әчүм апам Бумын каһан – Истәми каһан улурмуш), ди. Бу хан ту-күәләр сөляләсен[1] башлап җибәрүче беренче хан булырга кирәк. Шуннан ту-күәләр мәмләкәтенең тарихыннан кыскача мәгълүмат бирелеп узыла. Бумын каһан бик белекле батыр хан булган, түрәләре, бикләре дә белекле вә батыр булган, халкы да сәдакатьле[2] булган. Шуның аркасында ул иленә күп яхшылыклар кылган; дошманнарын җиңеп, илне тынычландырган, җайга салган. Ул үлгәч, тирә-яктагы һәммә халыклар аны тәгъзиягә килеп кайгырышканнар, аннан соң хан булганнар лиякатьсез[3] кешеләр булган; илне хәраблыкка төшергәннәр. Бикләр, үзләренең төрк булуларын онытып, Кытай тәэсиренә бирелгәннәр. Бөтен төрк халкы кытайларга кол булып, аларга гаскәрлек хезмәте итеп, үз илләрен үзләре дошманнарга сугышып алып бирешкәннәр. Бу хакта Билге каһан бик тәэссеф итеп[4] түбәндәгечә сөйли:

«Бәгләре будуны төз сиз үчүн, табгач будун тәбләгин күрәләгин үчүн, армакчысын үчүн, әниле-әчиле кәкшуртүкин үчүн, Бәгле-будунлыг юңшуртукыйн үчүн түрк будун әллә дүк әлин ычгыну идмүш; каһанладук каһанин ийтрү идмүш; табгач – будунка бәгләк уры углыйн кул булты, силик кыз углыйн күң булты; түрк бәгләр атин этте, табгачгы бәгләр табгач атыйн тутубан табгач каһанга кермеш. Әлиг ел әсиг-күчәг бәрмеш; илгәрү – күн тугсукта Бөкле каһанка тәге сүләйү бәрмеш; курыгару Тәмир капыгка тәге сүләйү бәрмеш; Табгач каһанка әлин-торусин али бәрмеш».

Татарча мәгънәсе: «Бикләре, халкы сәдакатьсез булганга күрә, Кытай (табгач) халкының котыртуы, якынлыгы сәбәпле, сихерчеләре сәбәпле, энеле-агалы дошманлашканга күрә, бикләре-халкы (бикле-халыклы) бер-берсенә зарар иткәнгә күрә төрк халкы торган (илләгән) илен кулыннан ычкындырган, хан

[1] Сөляләсен – нәсел-нәсәбен, династиясен.
[2] Сәдакатьле – тугрылыклы, дустанә.
[3] Лиякатьсез – булдыксыз.
[4] Тәэссеф итеп – үкенеп, кайгырып.

булган (ханлаган) ханын үтергән; кытай халкына көчле ир балалары кол булды. Гыйффәтле кыз балалары кәнизәк булды; төрк бикләре төрк исемен ташлап (атды), кытай бикләре (шикелле үзләренә) кытай атлары тагып, кытай ханының (хезмәтенә) кергәннәр (буйсынганнар); илле ел (буенча аңар) эшләрен-көчләрен биргәннәр; алда – көн туушында Бөкле ханга тикле барып сугышканнар, кирәге Тимер капуга тикле барып сугышканнар; Кытай ханына (үз) ил-түрәләрен алып (алышып) биргәннәр».

Ләкин бикләр сатылса да, кытайлар коткысына бирелеп алдансалар да, төркнең кара халкы бу эшкә түзеп тора алмаган. Халык һаман кытайларга каршы дошманлык саклап, читләр кул астында торырга теләмәгән; илне ташлап, мәмләкәтнең чигеннән тышка күчеп киткән. Бу хакта ташларда без шушы сүзләрне укыйбыз: «Түрк кара камыг будун анча тәмеш: “Әллиг будун әртим – әлим мате кани? Кәмкә әлиг казганурман?” тәр әрмеш; “каһанлыг будун әртим – каһаным кани? Нә каһанка әсиг – көчиг бәрүрмән?” тәр әрмеш; анча тәб табгач каһанга ягы булмуш ягы булуп , әтинү, йаратуну умдук яна иҗикмеш».

Мәгънәсе: «Төрк кара халкы шулай дигән: “Илле халык идем – данлы илем (илемнең даны) кая? Кемгә илләр казанырмын?” ди икән (диәр ирмеш); “ханлы халык идем – ханым кая? Нинди ханга эшем – көчем бирермен?” ди икән; шулай дип Кытай ханына дошман (яу) булган; дошман булып, рәтләнү, яраклану өмете белән кире (үз җирләренә далага) чиккәннәр». Төрк мәгъбүдләре төрк халкының юк булуын теләмәгәнгә, төрк халкының бәхетенә каршы, Билге каһанның атасы Әлтәрәс каһан ханлыкка утыра. Илен сөйгән, халкын кайгырткан бу хан теге, хакимиятеннән разый булмыйча читкә күчеп киткән халык арасына китеп, гаскәр җыярга, халыкны баш күтәрергә котыртырга керешкән. Акрынлап аның янына күп кенә гаскәр җыелган. Алар ихтилял[1] куптарып, илне читләр тәсәллытыннан[2] коткарганнар.

[1] Ихтилял – фетнә, баш күтәрү.
[2] Тәсәллытыннан – хөкеменнән.

Бертуктаусыз мәшрикътан мәгърибкә[1] барып, төрк халкының дошманнары белән сугыш кылып, таштагы язуларның матур, тасвири өслүбе буенча, «иллеләрне илсез иткәннәр, ханлыларны хансыз иткәннәр, дошманнарны басканнар, тезлеләрне тез чүктергәннәр, башлыларны баш идергәннәр». (Тәңре йарлыкадук үчүн әллигиг әлсирәтмеш, каһанлыгыг каһансыратмуш, ягыг базкылмуш, тизлигиг сөкүрмүш, башлыгыг йүкүндүрмүш). Шулай итеп, илне төзеп, җайга салып, Әлтәрәс каһан вафат булган. Аның урынына Билге каһанның агасы хан булып утырган. Бу да яхшы хан булган. Язуларның өслүбе белән әйткәндә, «төрк халкын җайга салган, хәлен яхшырткан, ярлыны бай кылган, азны күп кылган» (Түрк будунуг иечә этте, әгитте, чөгаиг бай кылты, азыг үкүш кылты). Агасы ханлык сөргәндә, Билге каһан Тардуш халкына «шад» (наместник, каим мәкам) булып торган. Агасы белән алар күп сугышлар кылганнар, илне җайга салырга тырышканнар. Төрк халкының хәле яхшыланган; хәтта бу вакытта «аларның коллары да үзләре колларга хуҗа булганнар».

Бу ханның заманында, төрк халыклары арасында тагын чуалулар, баш тартулар башланган. Аларга каршы тотылган сәясәтләр хакында тәфсилле сөйләнә. Баш тарткан халыклар хакында бик лаконик рәвештә[2] генә: «Ялгыштылар, безгә каршы языклы булдылар, шуңар күрә ханнары үлде (ягъни үтерелде), бикләре дә үлде, халкы имгәк күрде», – дип әйтелә. Шул чуалышлар мөнәсәбәте белән Билге каһан төркләргә түбәндәге йөрәктән чыккан сүзләр белән хитаб кыла[3]: «И сез, төркнең угыз бикләре[4], халыкы! Ишетегез! Өстән күк басмаса, астан җир ярылмаса, төрк халкы, синең илеңне-төреңне кем хараб итә алыр иде? Син буйсынучан төрк халкы идең. Үкен! Синең тугърылыгың аркасында гына күтәрелгән ханыңның җайга сала алганы изге

[1] Мәшрикътан мәгърибкә – көнчыгыштан көнбатышка.

[2] Лаконик рәвештә – кыска һәм аңлаешлы итеп.

[3] Хитаб кыла – эндәшә.

[4] Угыз бик дигән сүз хәзерге башкортларның халык әдәбиятында, мәсәлән, «Зыятүләк белән Сусылу» самагында очрый. *(Авт. иск.)*

иленҗә каршы языклы булдың, куркакларча эш кылдың! Сине тараткан бу сугыш дәрте каян килгән сиңа? Сине әллә кайларга сөреп илтә торган бу сугышчанлык каян килгән сиңа? Син, изге Өтүкән йиш[1] халкы, бездән аерылып киттең. Мәшрикъка бардыңмы, мәгърибкә бардыңмы – барган җиреңдә күргән игелегең шул булды: каның су күк акты, сөягең тау-тау өелде, көчле ир балаларың кол булды, пакь кыз балаларың кәнизәк булды».

Аннан соң Билге каһан үзенең хан булуын, энесе Күлтәгин белән бергә халык өчен тырышуларын, кылган сугышларын сөйли; аннан ары Күлтәгиннең сугышларын, сугышта күрсәткән батырлыкларын тәфсилләп санарга керешә. Аның кайсы сугышта ни төсле вә ни исемле атларга атланган булуын, ул атларның кайсы сугышта үлүләрен берәм-берәм бәян кыла. Атларның тәрҗемәи хәлләре хуҗаларныкы белән бергә йөртелүе сугыш атларының төркләр өчен нинди әһәмиятле, кадерле булганлыкларын бик яхшы күрсәтә. Күлтәгиннең кайсы сугышта ничә дошман гаскәрен үз кулы белән үтерүен, аларны нинди рәвештә атыпмы, чәнчепме, кылыч белән чабыпмы үтергәнлекләрен бик зур игътибар белән сөйли. Угызлар белән булган бер сугышта Күлтәгин урданы дошман кулыннан котылдырып кала. Шул ук сугышта, ихтимал, Күлтәгин үтерелгәндер, чөнки шушы вакыйгадан соң ук аның вафаты турысында сөйләнеп китә. Билге каһан аның өчен кайгыруын түбәндәге сүзләр белән бәян итә: «Энем Күлтәгин үлде, мин кайгырдым, күрер күзем күрмәстәй, белер белегем белмәстәй булды. Кайгырдым. Тәңре генә мәңге яши, адәм балалары һәммәсе үләр өчен туганнар. Шулкадәр кайгырдым; күздән яшь килгән кадәр, күңелдән сыктау килгән кадәр, кайта-кайта кайгырдым. Бик каты кайгырдым. (Арка таянычым булган?) ике шадымның, кардәшләремнең, угланнарымның, бикләремнең, халкымның күзе-кашы (хәле) яман булачак инде дип кайгырдым». (Иним Күлтәгин кәргәк булты. Үзүм сакындым, күрүр күзүм күрмәз тәг, билир билигим билмәстәк

[1] Йиш – тау өстендә үскән куе (еш) урман. Руслар «чернь» дип тәрҗемә итәләр. Себергә махсус тәгъбир булырга кирәк.*(Авт. иск.)*

булты. Үзүм сакындым. Үд тәңре йәшәр, киши углы әкүб үлгәли тиримиш. Анча сакындым. Күздә йәш кәлсәр эттә, көңүлтә сәгат кәлсәр, йандыру сакындым, катыгды сакындым. Әли шад улийу арка гүним, угланым, бәгләрим, будунум күзе-кашы йаблак болтачы тәп сакындым.) Төрле халыкларның вәкилләре бүләкләр белән Күлтәгиннең тәгъзиясенә килүләрен, аңар таш куеп, өстенә зиннәтле төрбә салу өчен, Кытайдан атаклы таш остасының килүен сөйләү белән таштагы Зур язу тәмам була.

Орхон язуларыннан борынгы төркләрдә хан белән халыкның бер-берсенә мөнәсәбәте хакында мөһим мәгълүмат алып була. Халык яки милләт мәгънәсендә Орхон ташларында «будун» сүзе истигъмаль ителә. «Төрк будун» – бу аерым бер төрк кабиләсенә түгел, бәлки бер илгә кергән бөтен төрк кабиләләренә бирелә торган исем булган[1]. Бу сүзне бик иркен без аңлый торган, хәзерге мәгънәсендә «милләт» тәгъбире белән алмаштырырга мөмкин. Илдән баш тартып фетнә чыгарган Түргәш кабиләсенең ханы хакында, мәсәлән: «Түргәш каһан төркүмез – будунымыз әрти...» (Түргәш ханы үз төркебез, үз халкыбыз иде...) дип әйтелә. Менә Орхон язуларында һәрвакыт шушы «будун»ның – төрк халкының файдасы, аның интереслары күз алдында тотылуы күзгә ташлана. Тәңре бер-бер тәдбирле[2], белекле кешене ил өстенә хан күтәрә икән, бу эшне ул бары тик «будун» югалмасын, «будун» хәраб булмасын дип, халык мәнфәгатен күз алдында тотып эшли. Яхшы ханнар да бары шул «будун» өчен генә, аның хәлен яхшырту өчен генә тырышалар, шуның өчен генә бөтен гомерләрен сугышларда үткәрәләр. Мәсәлән, Билге каһан үзенең ханлыкка утыруын сөйләгәндә: «Мин хәле яхшы, бай халыкка хан булмадым, эштән чыккан ярлы, эче ашсыз, тышы киемсез халыкка хан булдым», – ди. Ул гомере буенча, энесе Күлтәгин белән берлектә, шул начар хәлдә булган төрк халкының көнен-тормышын яхшылатыр өчен тырыша. Үзенең

[1] Ихтимал, бездәге көллиятне аңлата торган «бөтен» сүзе белән «будун» арасында бер мөнәсәбәт бардыр. *(Авт. иск.)*

[2] Тәдбирле – эшнең ахырын уйлап эшләүче, алдан күрүче.

әйтүенчә, ул төрк халкы өчен төн йокламаган, көндезләрен дә утырып тормаган. Халыкның хәлен төзәтергә, икътисади тормышын күтәрергә муаффәкъ булганын[1] сөйләгәндә, ул бу эшне эшли алуы өчен үзен бик бәхетле итеп исәпли: «Тәңре ярлыкаганга күрә, бәхетем булганга, тәкъдирдә өлешем булганга күрә, үләргә якынлашкан халыкны терелттем, ялангач халыкны – киемле, ярлы халыкны – бай, аз халыкны күп кылдым», – ди. Кем белә, ихтимал, бу сүзләрне Билге каһан мактаныбрак сөйли торгандыр, бәлки, ул үз-үзен тәүсыйф[2] кылганча ук идеал дәрәҗәсендәге хан булмагандыр. Ләкин мәсьәлә анда түгел, бу – хосуси бер вакыйга. Әмма ханның мактанган, ифтихар иткән[3] вакытта да, шул халыкка хезмәт итү, халыкка файда китерү шикелле эшләр белән мактануы – бу игътибар итәрлек бер нокта. Чынлыкта «каһарман»нар, хакимиятне үз кулларында тотучылар, бит алар үзләренең бөтен эшләрендә вә фикерләрендә мохитләренең, кул астларындагы гаммәнең[4] даирәи фикриясеннән[5] артык читкә чыга алмыйлар. Бер тәкъдир, әйтик, Билге каһан үзенең фәгалияте вә эшләгән эшләрендәге төп нияте хакында ялганлаган булса да, бары тик әфкяре гаммәгә[6] үзен яхшы яктан танытыр өчен ялганлаган булып чыга. Әфкяре гаммә ханның шундый булуын теләве, ханның да әфкяре гаммә белән хисаплашуы – үзе хан белән халыкның мөнәсәбәтен аерым бер яктан яктырта торган бер хәлдер. Әлхасыйль[7], борынгы төркләрдә хан халыкка нисбәтән башка шәрык халыкларының патшаларына караганда бөтенләй башка бер урын тоткан. Шәрык патшалары күбесенчә һәрберсе бер залим-деспот булсалар, Ассурия патшалары шикелле, ташка язып калдырган язуларында

[1] Муаффәкъ булганын – тырышканын, омтылганын.

[2] Тәүсыйф – сурәтләү.

[3] Ифтихар иткән – горурланган.

[4] Гаммәнең – гади халыкның.

[5] Даирәи фикриясеннән – фикер даирәсеннән.

[6] Әфкяре гаммә – күпчелек карашы, җәмәгать фикере. Б и р е д ә : «фикерле катламга, зыялыларга» мәгънәсендә.

[7] Әлхасыйль – нәтиҗәдә, җыеп әйткәндә.

үзләренең халыкка кылган җәбер-золымнары белән мактансалар, төрк каһаннары үзләренең язып калдырган язуларында халык кайгысын кайгыртучы булып күренергә тырышалар; шәрык хөкемдарлары үзләренең шәхесләрен вә шәхси мәнфәгать һәм рәхәтләрен асыл максат итеп куеп, бөтен мәмләкәткә вә рәгыйяләренә[1] шул шәхси мәнфәгатьләренә ирешү өчен корал дип кенә карасалар, төрк ханнары, халыкны төп максат итеп танып, үзләрен халыкның хезмәтчеләре яки аның мәнфәгатен күзәтүне үзләренә бурыч итеп йөкләнгән аталары дип белгәннәр. Әлбәттә, моны төркләрнең башка халыкларга караганда мәдәниерәк булуыннан яисә ниндидер булса харикылгадә[2] фазыйләтеннән килгән бер эш дип карарга ярамый. Бу – һаман да шул төркләрнең мәдәни дәрәҗәләреннән, дөресрәге, мәдәнияттә балалыгыннан, икътисади вә иҗтимагый тормышларының хосусиятеннән килеп чыккан бер нәрсә. Югарыда сөйләнгәнчә, төркләр күчмәле халыкларга махсус ыруг тормышы белән торганга, аларның ханнары да шул ыруг башлыкларыннан, аксакаллардан, тәкәммел итеп[3] кенә хөкемдарларга әверелеп киткән кешеләр булган. Димәк, алар бер патша булуга караганда, бер «патриарх», ягъни олуг ата – ыруг атасы булганнар; тормышта, халыкка мөнәсәбәттә әле алар да бик садә, бик гаиләчә генә булган.

## IV
## Суфилык һәм аның шәрык әдәбиятларына тәэсире

Дөньядагы башка халыклар шикелле, төркләр дә бик иртә бер заманда чит халыклар белән ихтилят[4] башладылар. Борынгы төркләрнең күчмә халык булып Кытай чикләре вә Урта Азия белән Шәркый Яурупа вә Дунай буйлары арасында, хәтта Анату-

[1] Рәгыйяләренә – бер дәүләт эчендә яшәгән халыкларга.
[2] Харикылгадә – гадәттән тыш.
[3] Тәкәммел итеп – үсеп җитешеп.
[4] Ихтилят – аралашу.

лы эчендә Кызыл Ермак буйларына кадәр килеп күчеп йөрүләре аларны борынгы заманның өч мәдәни галәме белән таныштырды.

Төркләр, бер яктан, Иран чикләренә кадәр килеп җитеп, иранлылар белән булган мәшһүр Иран-Туран көрәшләрендә иштирак кылулары[1], солых вакытларында алыш-биреш ясаулары аркасында Иран мәдәнияте һәм Иранның милли дине зәрдәштлек белән бик иртә таныштылар, алардан үзләренә җитешмәгән күп мәдәни сүз вә истиляхатны[2] алганнары шикелле, зәрдәштлек тәэсире астында утны хөрмәт [итү] шикелле игътикадларны[3] да йоттылар.

Икенче яктан, һун, авар, пәчәнәк шикеллеләре, Урта Азиядән чыгып, җәнүби, гареби Яурупаның чикләренә җитеп, Бизанес вә рума мәдәнияте белән бәрелешеп, алардан бик күп нәрсә оттылар. Сәлҗукилар исә, шул ук Бизанес белән Кече Азиядә бәрелешеп, Рум мәдәниятен, бик күп сүзләрен, гадәтләрен вә һөнәрләрен алдылар.

Шул ук төркләр элек голям[4] булып, ниһаять, гарәп хәлифәләренең преториан (хас) гаскәрләре булып китеп, аларның башлыклары «дәрәбәйләр»гә әверелеп, ислам-гарәп мәдәниятенә чумып киттеләр дә, бара торгач, үзләре шул мәдәниятне ташучы бер гонсыр[5] булдылар.

Идел буендагы сәүдә юлын кулларында тотып торган хәзәр төркләре исә Бизанес вә Хилафәттән[6] куылган яһүдиләрнең килүе, араларына керүе аркасында яһүд – бәни Исраил мәдәниятен, язуын вә фикерен алдылар.

Кытай чикләрендә торучылары исә, Кытай белән ихтилят[7], алыш-биреш һәм Кытайның империализмына каршы көрәш аркасында, борынгы галәмнең иң зур шәрык мәдәниятләреннән берсе булган кытай-чин мәдәниятен кабул иттеләр. Шулар

[1] Иштирак кылулары – катнашулары.
[2] Истиляхатны – атамаларны, терминнарны.
[3] Игътикадларны – ышануларны, инануларны.
[4] Голям – хезмәтче.
[5] Гонсыр – элемент.
[6] Хилафәттән – Гарәп Хәлифәлегеннән.
[7] Ихтилят – аралашу.

аркылы һинд мәдәнияте продукты булган буддизм вә аның фәлсәфәсе бик иртә төркләр арасына җәелә башлады.

Шуның өстенә дә төркләрнең һәр дингә бертигез карый торган гадәтләре бәрәкәтендә алар арасына якын шәрыктән качкан төрле «һаретик»[1] (бәдмәзһәб) христианларның килүе аркасында, христианлыкның манлык (манихеизм), несторилык (несторианизм) рәвешендәгеләре алар эченә таралды.

Урта Азиядә VIII гасре миладидан башлап, төркләр эченә ислам тәгълиматы керү аркасында, төрк халыклары гарәп мәдәнияте белән якынлаштылар. Шуның нәтиҗәсендә төркләр арасында ислам идеологиясе җәелеп, төрк теле – ислам мәдәниятенең өченче теле, төрк дәүләтләре исә ислам идеологиясенә әсасланган[2] падишаһлыклар булып киттеләр. Шул рәвешчә шаман-мәҗүс төркләренең иске идеологияләре урынына, бер яктан – буддизм, икенче яктан – зәрдәштлек калдыгы фикерләре, өченче яктан – несторилык һәм манилык шикелле христиан һаретик (бәдмәзһәб) тәгълиматы, Идел буе төркләренә бер заман яһүд дине идеологиясе[3], ниһаять, ислам тәгълиматы агып керә башлады.

Бу фикерләрнең төрлесе төрле төрк кабиләләренә керде. Ләкин төрк халыклары миладидан дүрт гасыр соңында һун, тукүә, уйгур, сәлҗук, монгол, Тимер империяләре шикелле зур падишаһлыклар ясап, күп төрк халыклары сәяси яктан күчмә халыклар булганлыктан, төрле тәгълиматны – идеологияне кабул иткән кабиләләр күчеп йөреп, бер-берсе белән катышып торганлыкларыннан, аларда һәртөрле фикер вә тәгълиматлар мөттасил[4] кушылып торды. Ниһаять, бу тәгълиматлар эчендә заһири[5]

[1] Һаретик – еретик.

[2] Әсасланган – нигезләнгән.

[3] Хәсдәй бине Шапрутка Хәзәр хаканы Йосыфның язган хатларыннан ачык рәвештә Идел буенда яңа «Сион» ясау, беткән Исраил дәүләтен яңадан тергезү кук фикерләр күренеп тора. Бу хатларның русча тәрҗемәсен укырга теләгән кеше Гаркавиның «Хәзәр хатлары» дигән мәкаләсен укысын (Еврейский сборник, том V). *(Авт. иск.)*

[4] Мөттасил – тоташ, эзлексез.

[5] Заһири – күркәм, фикерләре ачык.

ислам җиңеп чыкты. Бара торгач инде Чыңгыз империясе ясалыр көннәрдә төркләрнең күпчелеге ислам кабул иткән иде. Ләкин һәрбер тәгълимат вә диннәр, бер мәгълүм икътисади мохиткә керүләре белән, һәрвакытта шул мохиткә мәгъкуль рәвештә алмаша. Бу – тарихның катгый кануннарыннан. Шуның өчен ислам, төркләр арасына керү белән, исемен сакласа да, маһиятен[1] алмаштырырга мәҗбүр булды. Бер яктан, төркләрнең үзләрендә табигый рәвештә туган шаманлыклары исламның эченә кереп китеп, аны шактый үзенә таба үзгәртте. Гасырларча төрк халыклары мохитендә төрле тәгълимат вә фикерләрнең бер-берсе белән кушылулары процессы да нәтиҗәсез калмады. Һәм буддизм, һәм зәрдәштлек, һәм еретик христианлык, комга сеңгән су шикелле, төрк исламы арасына җәелделәр. Менә шуларның кушылуыннан төркләр арасында ислам хиркасын[2] бөркәнгән яңа төрле дини идеология туды. Ул да булса, башта Иранда шул ук буддизм, зәрдәштлек һәм христианлык тәэсирләре белән вөҗүдкә килгән суфилык иде.

Төрк халыклары арасында һәм аларның әдәбиятында суфилыкның ни өчен рәваҗ табуы[3] мәсьәләсенә килсәк, без анда ике төрле сәбәп күрәбез. Беренчесе шул чит халыклардан кергән идеологиянең тәэсире булса, икенчесе – төрек халыкларының күчмә тормыш вә сахра чүлләрнең җәгърафи[4] халәте тудырган рухи хосусиятендәдер. Төрк тарихын нык тикшерүчеләрдән Леон Кахунның[5] бу хактагы мөляхәзәсен[6] китерәбез,

[1] Маһиятен – табигый сыйфатын, асыл нигезен.
[2] Хирка – дәрвишләрнең өс киеме.
[3] Рәваҗ табуы – уңышлы таралуы.
[4] Җәгърафи – географик.
[5] Кахун Леон (1841–1900) – күренекле француз галиме, сәяхәтче, язучы һәм шәрыкшинас. Азия халыклары, борынгы монгол һәм төрк кабиләләре тарихы, этногенезы һәм гореф-гадәтләре турында язылган күпсанлы фәнни хезмәтләр авторы. Биредә сүз аның «Introduction à l’histoire de l’Asie: Turcs et Mongols» (Азия тарихына кереш: төркләр һәм монголлар, 1896) хезмәте турында бара.
[6] Мөляхәзәсен – фикерләрен, карашларын.

ул әйтә: «Төрк халкының рухи тынычлыкка (quietisme) маил[1], авыр (flegmatique) табигатьләренә килешә торган дин – буддизмдыр. Алар – үзләренең рухларының хосусияте, мәзаҗләре[2] белән, шиксез, табигый буддистлардыр. Исламият аларга чит вә сонгый[3] бер дин булды. Шуның өчен төрк телендә ислам дине хакында әдәбият та юк диярлек ярлы, чын төрк телендә һәм иранлылар тарафыннан язылмаган дини әсәрләр – алар барысы да поэмалар булып, өслүбләре, рухлары җәһәтеннән буддизм рухы белән тулганнар. Чын төрк каныннан килгән төрк әдипләренең әсәрләре форма җәһәтләреннән – мөселман, әмма фикерләре ягыннан – буддист»[4]). Димәк, төркнең рухи хосусияте «тәрке дөнья»лыкка[5] – суфилыкка бик әзер[6], аның, госманлылар әйтмешли, «куянны арба белән аулый торган» табигате шуңарга мөсагыйд[7]. Шуның өчен дә без ислам кабул иткән төркләрдә әдәбиятның суфилык белән тулганлыгын күрәбез.

Чыгтай вә госманлы әдәбиятлары ничә йөз еллар буенча суфилык идеологиясе белән сугарылып килде. Шул әдәбиятлар тәэсире аркылы бу идеология безнең татар әдәбиятының да борынгы дәверендә бөтен куәте белән хөкем сөрде. Иске шәрык тәэсирендә булган әдәбият өчен ул бердәнбер идеология булып хезмәт итте. Суфилыктан башка борынгы татар әдәбиятын тәсаувыр итү[8] дә мөмкин түгел. Менә шуның өчен без монда суфилыкның нидән гыйбарәт булуы һәм аның әдәбиятта ингыйкясе[9] мәсьәләсендә шактый тәфсилле рәвештә тукталып китәргә мәҗбүрият күрәбез.

[1] Маил – һәвәсле, тартым.
[2] Мәзаҗләре – характерлары.
[3] Сонгый – ясалма.
[4] Introduction à l’histoire de l’Asie: Turcs et Mongols, 66–67. *(Авт. иск.)*
[5] Тәрке дөнья – дөнья эшләрен читкә кую; аскетлык.
[6] Крымский А.Е. История Турции и ее литературы, Т. 1. С. 258. *(Авт. иск.)*
[7] Мөсагыйд – мөмкинлек бирә.
[8] Тәсаувыр итү – сурәтләү, гәүдәләндерү.
[9] Ингыйкясе – чагылуы.

* * *

«Суфи» исеменең зоһуры[1] хакында күп ихтиляф[2] бар. Бәгъзы галимнәр «суф» дигән сүз гарәпчә «йон» мәгънәсендә булып, суфи да – шул йон киемгә, дәрвиш хиркасына нисбәт бирелеп ясалган исем, диләр. Кайсылары исә «суфи» юнанча софос[3] (ягъни белем-гыйлем) дигән сүздән алынган диләр. Нитәкки[4], шул ук тамырдан гарәпләр «философ», «сафсата» сүзләрен алганнар. Ләкин соңгы тәфтишләр[5] бу сүзнең гарәпчә тамырдан булганын исбат итәләр[6].

Суфилык, гомумән, тәмам ясалып, эшләнеп беткән бер тәгълимат түгел. Бу фикередә рухи мәсләк халыкның гыйркы[7], икътисади, җәгърафи хосусиятенә карап төрле-төрле шәкелдә булды. Ләкин шулай булса да, без суфилыкта өч гонсыр[8] күрәбез; бу гонсырларның бер мәсләктә – берсе, икенчесендә башкасы куәтлерәк була; аның сәбәбе дә икътисади, гыйркый, җәгърафи гамилләрнең[9] хәрәкәтеннән буладыр. Ул гонсырлар исә: аскетизм (зөһед), мистицизм, пантеизм.

Суфилыкның килеп чыгуының иң зур сәбәпләре икътисади вә иҗтимагыйдыр. Суфилыкны күп тикшерүче Крымскийның әйтүенә күрә, аның иң күп тәрәккый иткән вә җәелгән чаклары халыкның икътисади зур каза вә бәлаләр күргән заманына туры килә[10]. Вакыйган[11], суфиларның атасы мәшһүр Хәсән Басри

[1] Зоһуры – килеп чыгышы.

[2] Ихтиляф – каршылык, карашлар төрлелеге.

[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[4] Нитәкки – шул рәвешле.

[5] Тәфтишләр – тикшерүләр.

[6] Бу хакта озын мәгълүматны Т. Нелдекенең «Sufi» исемле мәкаләсендә (Zeitschrift der Deutschen Morgenländischen Gesellschaft, 1848) һәм Дозинең «Тарихе исламият»нең 2 нче җилдендә, соңгы фикерләрне бигрәк тә Крымскийның «Древности восточные»дагы «Очерки развития суфизма» исемле мәкаләсендә табарга мөмкин. *(Авт. иск.)*

[7] Гыйркы – тамыры, килеп чыгышы.

[8] Гонсыр – элемент.

[9] Гамилләрнең – сәбәпләрнең, факторларның.

[10] Крымский А.Е. Очерки развития суфизма. *(Авт. иск.)*

[11] Вакыйган – чыннан да.

(Хәсән әл-Басри, 642–728) бөтен хилафәтне селкеткән, канга батырган Хөҗҗаҗ (Хәҗаҗ) заманында торган бер кеше иде ки, бу вакытта ислам дөньясында канунсызлык, фәкыйрьлек, ачлык хөкем сөрәдер иде. Суфилар үзләре, суфилыкның пәйгамбәр заманыннан[1] элек зоһур иткәнен сөйләп, Ибраһим, Гайсә пәйгамбәрләрнең суфи (заһид) булганлыкларын дәгъва кылалар. Билгеле, бу коры дәгъва булып, суфиларның үзләрен рәсми исламият сакчыларыннан мөдафәгә[2] өчен әйтелгән сүзләредер.

Зөһед (заһидлек, аскетизм) дип Алланың ризалыгын һәм аңар якынлык хасил итү өчен нәфесне тыеп, күңелне дөньядан биздерүгә әйтәләр. Заһидләр риязәт, ягъни тәнне зәгыйфьләндерү аркылы шуңар ирешергә тырышалар. Риязәт чигүче һәртөрле юллар белән үзенең дөньяви ләззәтләр тели торган нәфесен үтерергә, аны җиңәргә омтыла: ачлык, йокысызлык белән үзен җәфалый, хатыннар белән мөнәсәбәттән тыела. Озак, бәгъзан[3] ифтарсыз уразалар, төннәр йоклау урынына гыйбадәт белән уздырулар – заһидлек юлы белән баручының гади программасына керә торган эшләр. Ул йокласа да, катыга гына ятып йоклый, өстенә кигән киеме тәнне кычыттырып, мөттасил[4] газаплый торган тупас комачтан тегелгән була. Заһидләр хәтта кыш көне яланаяк, яланбаш йөри, үз-үзләрен камчылау шикелле эшләргә кадәр барып җитәләр. Чөнки заһидләрнең игътикадынча[5], никадәр тәнне зәгыйфьләндерсәң, шулкадәр күңел нечкәрә, рух сизгерләнә. Никадәр нәфесне тыйсаң, шулкадәр дөнья тормышы онытыла. Кеше маддият галәменнән мәгънәвият галәменә якынлашадыр.

Зөһедкә бирелгән кешеләр пәйгамбәрнең үзе заманасында ук бар иделәр. Сахабәләр арасында «әсхабе әс-сафәт» яисә «әһел әс-сафәт» (әһле суффә) аталган кешеләр булып, бер заманының юксыл сыйныфы, фөкарасы[6] иде. Кунарга урыннары булмаганга

[1] Б и р е д ә Мөхәммәд пәйгамбәр турында сүз бара.
[2] Мөдафәгә – яклау; саклау.
[3] Бәгъзан – кайвакыт.
[4] Мөттасил – тоташ, эзлексез.
[5] Игътикадынча – инануларына күрә.
[6] Фөкарасы – фәкыйрьләре.

күрә, алар төнне Мәдинә мәчете янындагы сәкеләргә (суффәгә) ятып йоклап уздыралар иде. Димәк, зөһед башта ислам галәменең иң ярлы сыйныфында туган. Шул беренче заһидләрдән Әбүзәр әл-Гифари[1] Чәһарьяр хилафәте[2] вакытында гаскәрнең ганимәт[3] мал җыюына каршы хәрәкәт кыла, аны фөкараи исламга[4] өләшүне таләп кыладыр иде. Шуның өчен Мөгавиянең[5] шикаяте буенча хәлифә Госман аны тәүкыйф[6] итеп, Әбүзәр әл-Гифари зинданда үлгән иде.

Ислам галәмендә зөһеднең тәрәккый итүенә янә шул ук икътисади, иҗтимагый бәла вә казалар сәбәп булдылар, ислам галәмендә мондый казалар шулкадәр күбәйделәр ки, кешеләр дөньяда рәхәт табудан ваз кичтеләр, «тәрке дөнья»лыкта гына бу бәлаләрдән котылырга мөмкинлек игътикадына килделәр. Рухи җәһәттән кешеләрне икегә бүләргә мөмкин: аларның бер нәүгысе[7] күбрәк – гакыл, икенче төрлесе тойгы, йөрәк-калеб белән торалар. Исламият туу белән, хәзер бу ике тип билгеләнде. Кайсы галимнәр ислам өчен катгый кануннар, игътикадлар вә аларны исбат өчен гаклый дәлилләр ясау белән шөгыльләнделәр, кайсылары исә, мистицизмга бирелеп, исламның канун вә игътикадларына бары тик ышану, аларны йөрәк-калеб белән генә аңлау ягында булдылар. Беренчеләреннән – фәкыйһләр вә рәсми ислам тарафдарлары, икенчесеннән зөһед вә заһидләр килеп чыкты. Мондый тип кешеләр мәзһәб низагысы төсен алган ислам галәмендәге икътисади, сыйнфый вә гыйркый (хәтта гарәп, иран милләтләре низагысы шикелле милли) көрәшләрдә

[1] Әбүзәр әл-Гифари – Әбү Зәрр Җүндүб бине Җәнадә әл-Гифари (651 елда вафат) – Мөхәммәд пәйгамбәрнең сахабәләреннән берсе, мөхәддис, суфи. Беренчеләрдән булып ислам кабул итә, заһидләрчә тормыш итү тарафдары.

[2] Чәһарьяр хилафәте – Мөхәммәд пәйгамбәрнең дүрт сахабәсе (Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали хәзрәтләр) идарә иткән чор.

[3] Ганимәт – сугышларда кулга төшерелгән мал-мөлкәт, трофей.

[4] Фөкараи ислам – ислам динендәге фәкыйрьләргә.

[5] Мөгавия ибн Әбү Суфьян (603 яки 605–680) – Гарәп хәлифәтенең алтынчы хәлифе, Өммәвиләр хәлифәтенең (661–750) беренче хәлифе, әлеге династиягә нигез салучы.

[6] Тәүкыйф – тоткын.

[7] Нәүгысе – төре.

кан белән, тән белән һәм акыл белән көрәшә алмаган «тойгы кешеләре» үзләренә зөһед юлын таптылар. Шулай ук шәрыкның аңлы ярлылары «әһле әс-сафә» вә аларның варислары, сыйнфый көрәштә җиңелгәннән соң бу «дарел-горур»дан[1] ваз кичү белән генә рәхәт табарга мөмкин, диләр иде. Бу вакыйгада, бер дә шиксез, рума пролетариатының вә колларының христианлык зөһеденә бирелүләре белән якын бер кыяс[2] ясарга мөмкин.

Шуның өчен дә дөньядан, көрәштән туйган Хәсән Басри (Хәсән әл-Басри): «Мадам ки[3], дөньяда яхшылык юк, шуның өчен аннан ваз кичәргә кирәк, шул вакытта гына җанны котылдыру мөмкин», – ди иде.

Коръәннең үз эчендә дә кешеләрне зөһедкә тарта торган урыннар бар. Каһһар Алланың гөнаһлы кешеләрне җәза кылу, җәһәннәмнең куркыныч тасвирлары үзе дә заһидлеккә рухан[4] хәзерлеге булган кешеләрне пессимизмга тарта. Шуның өчен Хәсән Басри: «Кемдер исә Коръәнне ышанып укый, ул кеше ифрат куркырга һәм бик еш еларга тиеш», – дип әйтә, имеш. Шулай ук хәдис китаплары да чын аскетизм рухында булган хәдисләр риваять итәләр. Әлхасыйль[5], һәр яктан исламның үзендә дә зөһеднең зоһур[6] вә тәрәккыенә юл бар иде.

Суфилыкның икенче гонсыры – мистицизм, дигән идек. Аның килеп чыгуының сәбәбе – югарыда әйтелгәнчә, мөселманларның туктаусыз дини мөҗадәлә[7] вә моназарәләрдән[8] аруларыдыр. Әле исламият зоһур итеп, ныгып җитә алмады, фәкыйһ вә гыйльми игътикад ияләре үзләренең фикерләрен исбат өчен гакылга ябыштылар. Билгеле, гакыл-мантыйкны, ул исә, Арасту[9]

[1] Дарел-горур – тәкәбберлек йорты, дөнья.
[2] Кыяс – ошату, чагыштыру.
[3] Мадам ки – чынлыкта.
[4] Рухан – рухи яктан.
[5] Әлхасыйль – җыеп әйткәндә.
[6] Зоһур – барлыкка килү, таралу.
[7] Мөҗадәлә – сүз көрәштерү.
[8] Моназарәләрдән – бәхәсләрдән.
[9] Арасту – Аристотель.

вә Әфләтун[1] фәлсәфәләрен чакырды, шуның аркасында төрле моназарә вә мөнакашәләр[2] пәйда булды, халык арасында шөбһәләр туды. Чын иман әһеле, бары тик күңел белән ышанырга теләүчеләр ахырда бу талаш вә шөбһәләрдән ардылар, үзләренең җаннарының Алла белән һичбер дәлилсез, моназарәсез генә берләшүен теләделәр. Алар үзләрен бөтен мәзһәбләрдән югары торган итеп хис итәләр иде. Мәшһүр Газали дә «Мөнкиз ган әз-заляләт»[3] атлы әсәрендә үзенең, төрле фәлсәфи вә дини тарикатьләренең тәнәкызларын[4] белгән соңында, мистицизмга бирелергә мәҗбүр булуын сөйли. Суфиларның әйтүенчә, экстаз (халь) һәм моракабә[5] (созерцание) кешегә дини рәхәт вә рухи тынычлык кына түгел, бәлки үзенә махсус гыйлем дә бирә. Ибн Хәлдунның әйтүенә күрә, кеше экстаз һәм моракабә белән «Мин Гарше Аллаһ илә катрә әл-мәтар»[6] нәрсәләрнең әсасын вә серләрен белә ки, ул нәрсәләрне гакыл белән идрак итеп[7] булмыйдыр.

Ислам галәмендә мистицизмның җәелүенең янә бер сәбәбе исә рәсми исламның теократизмындадыр. Хилафәттә булсын, соңра башка ислам дәүләтләрендә булсын, хөкүмәт башы – дин башы, «Зыйлле Аллаһ фи-л-арз»[8], дин әһеле исә хөкүмәт мәэмүре[9] булганга, бөтен көчсезләргә каршы ясалган золым дин исеменнән ясала иде. Шуның өчен дә мәшһүр борынгы Иран шагыйре Гомәр Хәйям чиновниклар хакында: «Махун ризан хурим вә тухон кәсал»[10], – ди. Шулай булгач, табигый дини рухлы

[1] Әфләтун – Платон.
[2] Мөнакашә – бәхәс.
[3] Биредә күренекле рухани, дин галиме һәм философ, суфичылыкның теоретик нигезләрен тәртипкә салган Имам әл-Газалинең (1058–1111) «Ялгыштан коткаручы» исемле хезмәте турында сүз бара.
[4] Тәнәкызларын – каршылыкларын.
[5] Моракабә – Аллаһ турында уйга чуму; суфичылыкта рухи яктан пакьләнү аша Аллаһ Тәгаләгә якынаю юлында үзеңнең эш-гамәлләреңне, уйкичерешләреңне, эчке халәтеңне контрольдә тоту алымы.
[6] Алланың Гаршеннән [алып] яңгыр тамчысына кадәр. *(Авт. иск.)*
[7] Идрак итеп – төшенеп.
[8] Җирдә Алланың күләгәсе. *(Авт. иск.)*
[9] Мәэмүре – чиновнигы.
[10] Кешеләрдән кан суыралар. *(Авт. иск.)*

булган шәрыкның борынгы кешесе рәсми дин белән канәгатьләнми, диндә яңа эзләр эзли башлый. Алланы һичбер гакылның катышыннан башка, тойгы вә коры ышану белән таптым, дип уйлый башлый. Ниһаять, бәгъзы галимнәр мистицизмның тәрәккыена сәбәп – исламның Коръәне вә диннең теле Иран, төрк, хәтта гади гарәп тә аңламаслык классик теле булуы диләр, ягъни Коръәнне гади кеше аңламый, рәсми хотбә һәм вәгазьләрне дә аңламый, хәтта чын-чынлап гыйбадәт тә кыла алмый. Аның Аллага гыйбадәте бары бертөрле хезмәт, бурыч түләү төсе генә булып кала. Әмма суфилар тәгълиматларын күбрәк демократия арасында халыкның үз теле белән өйрәткәнгә, аларның тәгълиматы гаммәгә[1] тиз аңлашыла вә тиз җәелә иде.

Мистицизм, ягъни Алланы гакыл белән түгел, тойгы белән белү, аны мантыйк белән исбат итеп тормый, йөрәк (калеб) белән генә тану аңар халь (экстаз) белән ирешү идеясе пантеизм игътикады белән бик нык бәгланган. Вакыйган[2], әгәр Алла галәмнән башка бер зат булса, ул галәмнең падишаһы була торган булса, аның белән берләшү, аны эчке, йөрәк куәсе белән тану мөмкин булмаячак. Шуның өчен мистик «галәм Алладыр» дип әйтергә мәҗбүр була. Шуның өчен 873 елда үтерелгән Баязид Бистаминың өенә килеп: «Өйдә кем бар?» – дип сорасалар, «Өйдә Алладан башка зат булырга мөмкинме?» – дип җавап бирә икән. Шулай ук бервакытны аннан: «Баязид кайда?» – дип сораганнар икән, ул: «Бик күп вакытлар эзлим – таба алмыйм», – дигән. Шулай ук: «Алла хакындагы гыйлем кешедә, аны аңлау да кешедә, аның гыйшкы да кешедә, аның калебе кеше калебендә», – ди икән. «Тәзкирәт әл-әүлия»ның[3] әйтүенчә, Бистами: «Вә нитәкки[4] кешеләр Аллага сәҗдә кылабыз дип

[1] Гаммәгә – халыкка.
[2] Вакыйган – чыннан да.
[3] Мәшһүр фарсы мистик шагыйре Фәридеддин Гаттарның (1145–1221) туксан алты суфи-әүлиянең тормыш юлларын һәм кылган изгелек-кәрәмәтләрен сөйләгән агиографик эчтәлекле «Әүлиялар биографиясе» әсәре.
[4] Нитәкки – шул рәвешле.

уйлыйлар, алар үз-үзләренә сәҗдә кылалар», – ди икән. Шуның өчен дә ул Аллага хәмед әйтү урынына «Сөбхани, сөбхани» (Мин үземне мактыйм) дип әйтә торган булган. Шуның шикелле үк мәшһүр заһид[1], гарәп хәлифәсе тарафыннан үтерелгән Хәллаҗ да «Әнә әл-Хак»[2] (Мин – Алла), ди икән.

Пантеизм игътикадынча, галәм Алла белән як вөҗүд[3] булганга күрә кадимдер[4]. Аның башы юк. Галәм ул – Алланың тора торган урыны, икенче төрле итеп әйткәндә, ул үзенә Алланы сыйдырган савыт кына. Алла һәр җирдә бар; ул бөтен табигатькә таралган. Димәк, Алла галәмнән аерым булган бер «вөҗүде мотлак»[5] түгел. Шуның өчен дә суфилар Алланы кояшның урынына охшаталар. Ничек кояш яктысы галәмгә таралып бөтен нәрсәләрне гәүдәләндереп безгә күрсәтә, шулай ук Алла да бөтен галәмгә үтләшеп, аның көче мөттасил[6] агып (эманация ясап), дөньяда булган матди нәрсәләр хәлендә заһир була. Суфилар игътикадынча, хәвасе хәмсә[7] белән беленә торган матди галәм бары бер хыял гына, бөтен матди нәрсәләр бары тик Алланың нуры үзләрендә ингыйкяс итеп[8], аларны безгә белдерергә сәбәп булган «җәүһәри хәят» аркасында гына бар, әмма үз-үзенә матди бер нәрсә дә түгел.

Суфилыкка бер-бер төрле әзер нәзари тәгълиматлар тәэсир итмәдеме икән дигән мәсьәләгә килсәк, аңар читтән өч төрле тәэсир булганын күрергә мөмкин. Алар исә христианлык, буддизм һәм ишракыят, ягъни неоплатонизм[9] тәгълиматларының тәэсирләредер.

[1] Заһид – суфи, гностик.

[2] Исем ган әсмаиһи Тәгалә. Китаб әл-каринат ли-л-сәид әш-шәриф. 51 нче бит. *(Авт. иск.)*

[3] Як вөҗүд – бербөтен; яшәешнең, барлыкның берлеге.

[4] Кадимдер – борынгыдыр. Б и р е д ә : «башы-азагы юк» мәгънәсендә.

[5] Вөҗүде мотлак – абсолют барлык.

[6] Мөттасил – тоташ, өзлексез.

[7] Хәвасе хәмсә – биш тойгы (күрү, ишетү, ис сизү, тәм тату, тотып белү).

[8] Ингыйкяс итеп – чагылып.

[9] Бу мәсләкне шәрыктә «ишракыят» дип йөриләр иде, бу хакта Kremerның «Kulturgeschichtliche Streifzuge»сенең 45 нче битеннән кара. *(Авт. иск.)*

VIII гасыр суфиларыннан мәшһүр Ибраһим бине Әдһәмнең әйтүенә күрә, аның туры юлга (мәгърифәткә) керүенә Симон исемле нәсрани[1] бер монах сәбәп булган. Шулай ук беренче зөһеднең гарәпнең үз өлкәсендә түгел, башта христиан җире булган Сүриядә зоһур итүенә[2] дә игътибар итәргә кирәк.

Суфилыкның христианлык аскетизмы астында туганы Сүриядә, Бәйтел-мөкаддәс[3] тирәсендә тәрәккый итсә, һинд (буддизм) тәэсирендә хасил булганы Иранда, бигрәк тә Бәлх шәһәрендә тәрәккый итте[4]. Шуның өчен без суфилыкның әллә никадәр тарикатьләргә бүленгәнен күрәбез. Ләкин аның нәсрания вә буддизм тәэсирләре белән ясалганнары икесе дә «неоплатонизм»[5] аталган фәлсәфи-дини бер тәгълиматның зур тәэсире астында мәйданга килделәр. Бу тәгълимат – Искәндәр Македонидан соң һәллән (юнан) гыйркы[6] вә аның мәдәниятенең тәэсире якын шәрыкта таралгач килеп чыккан бер юл иде. Аның маһияте[7] Арасту белән Әфләтунның бер-берсенә каршы булган тәгълиматларының берләшүеннән хасил булган, ләкин төптән тикшереп карасаң, неоплатонизмның һәллән (юнан) фикеренең шәрык фикере белән катышуыннан гыйбарәт булуы күренә. Бу тарикать эволюция фикеренә хилаф «эманация», ягъни садә нәрсәләрнең гали[8] нәрсәләрдән хәлык ителүенә[9] ышанудан гыйбарәт иде. Моның белән ул Әфләтунның бөтен нәрсәнең «идея»дән хасил булуына даир булган[10] тәгълиматына якын киләдер иде. Бу неоплатонизм фәлсәфәсе мәгъбүдләрне[11] гакыл

[1] Нәсрани – христиан.

[2] Зоһур итүенә – барлыкка килүенә.

[3] Бәйтел-мөкаддәс – Иерусалим.

[4] Бәлх падишасы Ибраһим бине Әдһәмнең тәрҗемәи хәле үзе буддизмның башы Сакьямуниныкына ошый. Ул да, нәкъ Сакьямуни кук, падишалыгын ташлап китеп, зөһедкә бирелгән. *(Авт. иск.)*

[5] Платон – Әфләтун; неоплатонизм – яңа әфләтунчылык. *(Авт. иск.)*

[6] Гыйркы – килеп чыгышы, кавеме.

[7] Маһияте – нигезе, төп сыйфаты.

[8] Гали – югары.

[9] Хәлык ителүенә – барлыкка килүенә.

[10] Даир булган – караган.

[11] Мәгъбүд – табыныла торган зат. Б и р е д ә : Аллаһ.

белән белеп булмый, тойгы (хис) белән генә аларга ирешеп була дип өйрәтәдер иде: бөтен галәмдә иң гали әсас вә һәр нәрсәнең башы – Алла, аның белән кушылырга имкян бирә торган аерым бертөрле рухи халәт бар ки, аңар «экстаз» дип әйтәләр. Суфиларның әсәрләрендә исә без шундый ук фикерләр очратабыз. Бу тарикате фикрия[1], бер яктан, ислам суфиларына Сүриядән керсә, икенче яктан, Ираннан кергән. Исламның зоһуры дәверендә Иранда неоплатонизмның иң куәтле рәвештә тәрәккый иткән заманы иде. 529 елда Рум кайсары Юстиниан[2] бу мәзһәб әһелен мәмләкәттән кугач, алар Иранга киткәннәр. Мәшһүр Нәүширвани Гадел аларны бик хөрмәтләп каршы алган, соңра неоплатоникларның әсәрләре Иран туфрагында яһүди теленә дә тәрҗемә кылынган иде.

Озакламый рәсмән[3] «Лә рәһбанияат фи-л-ислам»[4] дип игълан кылган ислам галәмендә «ханәка», «челләханә» аталган монастырьлар килеп чыкты. Беренче ханәка 815 елда Димәшкъта салынды. Әбү Сәгыйд бине Әбелхәер исемле суфи шуңар ифрат будда монастырьлары уставына охшаган бер устав төзеде. Шундый ханәкаларда суфилар гыйбадәт вә әдәби эшләр белән мәшгуль булдылар.

Суфилык игътикадының иң зур гонсыры[5] – Алланы сөю, Аллага гыйшыкдыр. Бу гыйшыкны ачык рәвештә әйтә башлаучы – 135 нче сәнәи һиҗридә үлгән суфия Рабига-и Гадәвия иде. Ул үзенең мөнәҗәтендә «Илаһи тәхәррык би-н-нар кальбән юхиббукә» (Илаһи, сине сөюче йөрәкне син ут белән яндырасың), ди иде. Гомумән, суфи шагыйрьләр гыйшык хакында бик күп язалар. Аларның лирика әдәбияты бөтенләй шул «гашыйк»ның, ягъни шагыйрьнең мәгъшукына[6], ягъни Аллага мактау җыры,

[1] Тарикате фикрия – фикергә корылган юнәлеш.

[2] Рум кайсары Юстиниан – 527–565 елларда идарә иткән Византия императоры Юстиниан I (Флавий Пётр Савватий Юстиниан, 482–565).

[3] Рәсмән – рәсми рәвештә.

[4] Лә рәһбанияат фи-л-ислам – Исламда монахлык юк. *(Авт. иск.)*

[5] Гонсыры – элементы.

[6] Мәгъшукына – сөеклесенә.

сөю игъланы белән тулы. Аллага гыйшыкны Ләйлә – Мәҗнүн гыйшыклары, Йосыф – Зөләйха сөешүләре белән чагыштыралар. Эш шул кадәргә җитә ки, бу мотивны яхшы аңламаган яисә суфилык фикерләрен аңлый алмаган укучы бу серенада һәм көюяну җырларын чын кызга яки егеткә гыйшыкмы, әллә Аллагамы икәнен аңлый да алмый. Бара торгач, боларның Аллага гыйшыклары, аны сөюләре бөтенләй бер рухи авыру дәрәҗәсенә җитә. Алар мәгъшукларның «зарб» (сугу)ларыннан сабыр гына итеп калмый, бәлки Шәкыйк Бәлхи күк шуннан ләззәтләнәләр.

Суфиларның Аллага гыйшкы бәгъзы вакытта куәтләнеп киткәч, бөтенләй тәнасели[1] тойгыларга әйләнеп китә. Психиатрия гыйлеменең өйрәтүенә күрә, экстаз (суфиларның хәле) күп вакытта тәнасели хис белән бәгланган була[2]. Шуның өчен бәгъзы вакытта суфи шагыйрьләр, гыйшыкларын бәян кылганда, ифрат каба[3] тәгъбирләр кулланалар. Табигый, суфилык галәмендә бу бер ифрат[4] иде, ләкин бу ифрат Алланы «Каһһар»[5], «Җәббар»[6] бер падишаһ, «әмире мотлак[7]» итеп тасвир итүче фәкыйһләргә[8] каршы туган бер реакция, рухи бер протесттан килеп чыккан иде.

Һәрбер суфилыкка әзерләнүче кеше (талиб, мөрид-эстәүче), иң элек үзен бер юлбашчы (пир, шәех) кулына тапшырып (безнең татар истыйляхынча[9] әйтсәк, «ишанга кул биреп»), ничә еллар буенча аның хезмәтендә яки тәрбиясендә булынырга тиеш. Мөрид булган кеше үзенең бөтен ирек вә ихтыярын шәехе кулына бирергә тиеш. Ишанга итагать, аның сүзеннән чыкмау – мөриднең беренче вазифаларыннан. Менә шушы рухани тәрбия

[1] Тәнасели – нәсел арттыруга бәйле, җенси. Биредә: «интим хис» мәгънәсендә.
[2] Крымский, стр. 40. *(Авт. иск.)*
[3] Каба – начар, бозык.
[4] Ифрат – чамадан тыш арттыру.
[5] Каһһар – җәза бирүче, һәлак итүче. Аллаһы Тәгаләнең 99 исеменең берсе.
[6] Җәббар – җәберләүче, көчле. Аллаһы Тәгаләнең 99 исеменең берсе.
[7] Мотлак – абсолют.
[8] Фәкыйһ – дин галиме, фикъһ, шәригать белгече.
[9] Истыйляхынча – атамасы кебек.

вә юлбашчылык астында булачак суфи тәсаувыфның югары дәрәҗәләренә ирешү өчен, берничә дәрәҗә уздырырга тиеш. Бу дәрәҗәләрне үткәндә, кешегә бик күп мәшәкатьләр ихтыяр итәргә, үз-үзен ватарга, нәфесе белән көрәшергә туры килә. Бәгъзы нәзарияләр буенча үтелергә тиешле баскычлар – өч, бәгъзыларынча дүрттер. Без монда дүрт баскычлы һинд-иран суфилыгының дәрәҗәләрен күрсәтеп үтәбез.

Беренче дәрәҗә «тарикать» атала. Бу әле бары суфилыкның мөкаддимәсе[1] генә. Әле бу чакта яшь дәрвиш бөтенләй ислам шәригатенең кул астында тора; «әмре мәгъруф»ны[2] җиренә җиткерә. Мондый кешене әле «заһири» дип йөриләр. Чөнки бу кеше әле тышкы – заһири гыйбадәтләргә генә күбрәк әһәмият бирә. Бу дәвер азмы-күпме дәвам итә. Ниһаять, яшь дәрвиш, үзенең пире (ишаны) кул астында тырыша торгач, «һидаять»[3] дәрәҗәсенә ирешә. Бу дәвердә әле талиб (шәкерт, эстәүче) каршында Алла бер «вөҗүде мотлак»[4], галәмнән аерым бер мәфһүм[5] булуда дәвам итә. Әле талиб Алланы үзеннән тыш та эзли һәм аңар табына; әле ул – диндар бер мөселман.

Өченче дәрәҗәне «мәгърифәт» дип атыйлар. Бу дәрәҗәдә талиб өчен әхкяме шәргыя[6] – бары бер күренеш кенә, алар бертөрле дә артык әһәмияткә малик[7] түгелләр. Мондый талибны «гариф» диләр. Суфилар күз карашында гариф күренештән хакыйкатькә күчү арасында тора. Суфи бу дәвердә күбрәк тәсаувыф шагыйрьләрен уку белән шөгыльләнә. Җәлалетдин Руми, Хафиз Ширазиларның касыйдәләре, газәл вә мәснәвиләре – гарифның иң сөеп вә хөрмәт итеп укый торган нәрсәләре. Шулар белән илһамланып, ул Хакыйкатьне аңларга үзен хәзерли.

[1] Мөкаддимәсе – кереше, башлангыч өлеше.
[2] Әмре мәгъруф – изге эшләр. Коръән һәм сөннәт тарафыннан яхшы саналган эш-гамәлләр.
[3] Һидаять – туры юлга басу.
[4] Вөҗүде мотлак – абсолют яшәеш, абсолют барлык.
[5] Мәфһүм – төшенчә.
[6] Әхкяме шәргыя – шәригать хөкемнәре, кануннары.
[7] Малик – ия.

Шуның белән бергә, гариф үзенең нәфесенә каршы көрәшү белән дә шөгыльләнә. Моракабәгә[1] китә, будда монахы күк, тышкы хәятның тәэсиреннән котылырга тырыша; нәфесен үтерергә омтылып, «Вәхдәт» – берлеккә якынлашырга иҗтиһад итә.

Дүртенче дәрәҗәне «хакыйкать» яисә «йакыйн» дәвере дип атыйлар. Бу заманда инде дәрвиш суфилыкның иң югары ноктасына ирешкән була. Хәзер аның өчен Алла батыйни[2], ягъни үзенең эчендә хисаплана, ул инде үзен Алланың бер кисәге дип саный. Бу вакытта суфи өчен зыйдд[3] юк, дөньядагы эшләр «яхшы»га һәм «начар»га бүленмиләр, чөнки Җәлал Руми әйткәнчә, «Хода зыйддында рәдд» (Алланың киресе юк). Менә шуңар күрә бу актык дәвергә ирешкән суфи өчен «гөнаһ» мәфһүме дә юк. Ул, хәзер үзенең изгелегенә һич хәлал китермичә, ислам шәригате тарафыннан куелган гыйбадәтләрне кылмаска, хәтта шәригатьтә гөнаһ дип тыелган һәртөрле эшләрне эшләргә ирекле. Аның өчен хәзер кәлисә[4] белән мәчет арасында фәрекъ[5] юк. Бу дәрәҗәгә килгән суфи инде үзенең идеалына җиткән, «иршад»ка ирешкән була. Шуның өчен бу баскычта торган суфиларны «мөршид» дип тә атыйлар. Бу дәрәҗәгә җиткән суфи инде шәехеннән иҗазәт алып, үзе хәзерләнүче суфиларга юлбашчылык кыла (ягъни мөрид тәрбияли) ала.

* * *

Суфилык кешенең тойгысыннан туганга күрә, ул күбрәк үзен шигырь – лирика бабында күрсәтте. Лирика аның орлыклары үсәр өчен иң мөнбит[6] туфрак булды. Бер вакытларны бөтен ислам кабул иткән халыкларның әдәбияты суфилык белән тулган

[1] Моракабә – суфичылыкта үзеңнең уй-кичерешләреңне контрольдә тотуга, алар белән идарә итүгә нигезләнгән психофизик халәт; медитация. Илаһияткә якынаю юлында бер тукталыш.

[2] Батыйни – эчке, яшерен.

[3] Зыйдд – киресе.

[4] Кәлисә – чиркәү.

[5] Фәрекъ – аерма.

[6] Мөнбит – уңдырышлы.

булып, лирикада алга чыккан иранлылар һәм әдәбиятта аларның варислары булган төркләрнең әдәбиятлары бигрәк тә суфилык әсасына[1] корылган иде[2].

Иран әдәбияты башлыча X гасре миладидан XV [гасырга] кадәр, биш йөз еллык бер дәвердә тәрәккый итте. Иран шигыренә таза нигезләр шушы заманда салынып, иң атаклы шагыйрьләр дә шул биш гасыр эчендә җитештеләр. Иран әдәбиятының иң зур баганалары булган Шәех Сәгъди, Хафиз Ширази, Гомәр Хәйям, Җәлалетдин Руми, Низами вә Җамиларның диваннарында вә башка әсәрләрендә суфилык үзенең бөтен куәте вә шигърияте белән заһир булды[3]. Без, әлбәттә, бу урында бөтен Иран әдәбиятының тарихын сөйләргә алынмыйбыз; шулай да, аның төрк әдәбиятларына тәэсирен хәтергә алып, иң атаклы әдипләре хакында кыска гына мәгълүмат биреп узабыз.

Иран әдипләренең бөтен шәрыкка мәшһүр булганы – Шәйх Сәгъдидер (1184–1291). Сәгъдинең төп ватаны үзенең гүзәл вә йомшак табигате, былбыллары-гөлләре белән мәшһүр булган Җәнүби Иран (Фарсыстан, Шираз) иде. Ләкин аңар гомерен тыныч кына туган илендә уздырырга туры килмәде. Тәкъдир аны тәгъкыйб итеп[4], Һиндстаннан Сүриягә кадәр әле бер, әле икенче ят илдә, әллә ни төрле читен хәләтләргә куйды. Ул, үзенең бер гасырдан озынрак гомерендә башыннан нәкъ «Мең дә бер кичә» каһарманнарының гына башларыннан кичә торган вакыйгаларны кичергәннән соң, ахыр гомерендә генә ватанына кайтырга муафикъ булды[5]. Сәгъди – бик үткен фикерле әхлакчы һәм тирән тойгылы лирик суфи. Аның «Гөлстан» вә «Бостан»ы – бөтен шәрык вә гаребкә мәгълүм вә мәшһүр классик әсәрләрдер.

---

[1] Әсасына – нигезенә.

[2] Бүлекчәдә төрки әдәбиятларга тәэсир иткән фарсы суфи әдәбияты хакында сүз бара. Галим иң йогынтылы, махсус әдәби юнәлеш – суфичылык шигъриятен дөньяга китерүчеләр буларак аерып чыгарган шагыйрьләр бүгенге фәндә дә шушы дәрәҗәдә бәяләнәләр.

[3] Заһир булды – ачык булды, билгеле булды.

[4] Тәгъкыйб итеп – эзәрлекләп.

[5] Муафикъ булды – туры килде.

«Гөлстан» әхлак өйрәтә торган вак хикәя вә анекдотлардан мөрәккәб[1] бер мәҗмуга булып, эчендә һәртөрле мөнәсәбәт белән китерелгән бик күп робагыйлар вә башка төрле шигырь кисәкләре сибелгән. «Бостан» исә мистика әсасындагы касыйдә вә газәлләрдән гыйбарәттер.

Хафиз Ширази (1300[2]–1389) – Сәгъдидән соңгырак заман кешесе һәм аның ватандашы иде. Ул күбрәк газәлче булуы белән мәшһүр. Ул да – башка суфилар күк, киная тарикы[3] белән бакча, гөл, былбыл, мәгъшука, шәраб һәм исереклекләр хакында язучы бер шагыйрь. Шәйх Хафиз, суфи шагыйрьләрнең иң бөек вә даһиларыннан булып, лирика бабында иң югары ноктага ирешкән иде. Гомәр Хәйям белән берлектә Хафиз шәрыкның Яурупалылар тарафыннан иң сөелеп укыла торган шагыйрьләреннән булып, иң мәшһүр әсәре – «Диване Хафиз» (Диван Хафиз) аталган газәлләр мәҗмугасыдыр.

Гомәр Хәйям (1040–1129)[4] исә, хәзергә кадәр үзенең матур каләме, назик өслүбе белән бөтен гаребне хәйран калдырган шагыйрь булуы белән бергә, заманасының шөһрәтле философы, риязият, һәйәт һәм голүме диния галиме[5] дә булып, Ибн Синаның[6] эзеннән баручы бер адәм иде. Ул Нишапурда[7] мәшһүр Сәлҗук солтаны Мәликшаһның рәсадханәсенең мөдире[8] булып торып, фәнгә байтак хезмәте тиде. «Сәясәтнамә» иясе, мәшһүр вәзир Низам әл-Мөлек[9] аның хамиләреннән[10] иде. Хәйямны шөһрәтле иткән нәрсә – аның шәраб, тән гыйшкы вә кәеф-сафа

[1] Мөрәккәб – тупланган.
[2] Дөресе: якынча 1325 ел.
[3] Киная тарикы – киная юлы.
[4] Дөресе: 1048–1131 еллар.
[5] Риязият, һәйәт һәм голүме диния галиме – математика, астрономия һәм дини гыйлемнәр галиме.
[6] Ибн Сина – Әбу Гали ибн Сина (980 еллар тирәсе –1037) галим, фәлсәфәче, табиб, шагыйрь.
[7] Нишапур – Ирандагы шәһәр.
[8] Рәсадханәсенең мөдире – обсерватория җитәкчесе.
[9] Низам әл-Мөлек – галим, фәлсәфәче, җәмәгать эшлеклесе.
[10] Хамиләреннән – яклаучыларыннан.

хакында һәм фәлсәфи мәүзугларга язган[1] робагыяте иде. Бөтен шигъри иҗатын тәшкил иткән робагыйларының саны ике йөзгә тулмаса да, бу аның бөтен дөнья шагыйрьләре арасында иң югары урынга менеп утыруына манигъ[2] булмады. Хәйямның кайбер фәлсәфи шигырьләре тәмамән пессимизм вә дөньяның фанилыгы фикере белән тулган булса, башкалары кешене кәеф-сафага өндәү һәм дөньяви рәхәтне мактаудан гыйбарәт. Ләкин аның хатын-кызны, шәраб эчүне мактавына, шигырьләрендә мәйханә манзараларын тасвирына карап, Хәйям дөньяга бирелгән бер кеше булган икән дип уйланмасын, киресенчә, ул риязый тормыш[3] белән торучы чын заһид[4] вә суфи иде. Шулай ук Сәгъди белән Хафиз да тәсаувыф әһленең зурларыннан булып, мөхтәрәм шәех (ишан) иделәр.

Госманлы шагыйрьләренә яңа гасырларга кадәр илһам биреп килгән Җәлалетдин Руми (1207–1273) – суфи шагыйрьләрнең иң зурларыннандыр. Ул элек Кечек Азиядә (Коньядә) Сәлҗук солтаннары хозурында сарай шагыйре булып торса да, соңыннан дөнья тормышыннан бизеп, сарайдан ераклашып, гозләткә[5] бирелеп, мәшһүр тәсаувыф мәсләкләреннән «Мәүләви» тарикатен төзеде. Румда, ягъни Анатулыда[6] яшәгәнгә, аны «Руми» дип атаганнар иде. Аның «Диван»ы бик тирән тойгылы, гаять гүзәл кинаяләр белән язылган шигырьләр белән тулыдыр. Иң атаклы әсәрләреннән булган «Мәснәви»сендә ул, суфилыкның нәзариясенә керешеп китеп, мисал йөзеннән арада бик күп хикәя вә кыйссалар да язып үтә. Шуның өчен дә бу әсәр, нәкъ суфилыкның бер энциклопедиясе хөкемендә булып, бик күп тәсаувыф юлына керүчеләр өчен кулланма булып хезмәт итеп килгән.

[1] Фәлсәфи мәүзугларга язган – фәлсәфи темаларга язган.
[2] Манигъ – киртә.
[3] Риязый тормыш – ашау һәм эчүдә чикләнүче яшәеш.
[4] Чын заһид – дөнья эшләреннән ваз кичкән, гыйбадәт белән генә шөгыльләнүче ир кеше.
[5] Гозләткә – ялгызлыкка.
[6] Анатулы – Анатолия (Төркиядәге шәһәр).

Тәсаувыф идеяләре нәфис әдәбиятта ничек ингыйкяс итә[1] соң?[2]

Әдәбиятта тәсаувыфның тамыр җәйгән кыйсеме – лирика (хисси әдәбият) дигән идек. Тәсаувыф лирикасы тәмамән киная вә мәҗаз (аллегория)дән гыйбарәт була. Суфи шагыйрьләр моны үзләренчә болай дип юллыйлар: аларның рухи халәтләре, Алла белән галякадән[3] килеп чыккан хисләре шундый гали вә назик хисләр ки, аларны гади сүзләр белән сөйләп аңлату имкян хариҗендә[4]. Шуңар күрә аларны аңлату өчен, дөресе, алар хакында зәгыйфь кенә бер аң бирер өчен, чын тәсаувыф даирәсеннән тышта – суфилык галәменнән бик ерак булган тасвирлар алырга кирәк була. Гади инсаннарга хәвасе хәмсәдән[5] югары булган мәфһүмнәрне[6], рухи хәрәкәтләрне аңлатыр өчен, хәвасе хәмсә галәменә иңәргә, аларны гади мәфһүмнәр, гади хисләргә тиңләштерергә тиеш була. Шуның өчен дә, гадәттә, тәсаувыф юлында булган шагыйрь үзенең шигырьләрендә иң гади инсани хисләр, иң табигый (реальный) дөньяви нәрсәләр хакында яза. Әмма укучы исә алардан бөтенләй башка нәрсәләрне аңларга тиеш.

Суфилар үзләренең мәгъбүдкә[7] – Аллага мөнәсәбәтләрен «гыйшык» дип атыйлар. Гыйшыкның иң югары вә иң ялкынлы булган бу формасын, ягъни Алла гыйшкын тасвир өчен аны бары ирнең хатынга (бәгъзан шәрыкча – яшь егетнең) гыйшкы белән генә тиңләштерәләр. Бу гыйшык суфи шагыйрьләрнең әсәрләрендә бәгъзы вакыт иң назик «саф мәхәббәт» шәкелендә

[1] Ингыйкяс итә – чагылыш таба.

[2] Текстның алдагы өлеше суфичылык әдәбиятының үзенчәлекләрен барлауга багышланган. Әйтергә кирәк, биредә суфи әдәбиятка беренче тапкыр үз заманы өчен дә, бүгенге фән өчен дә гаять тирән, эзлекле методологик бәя бирелә. Бу бәядә суфичылык әдәбиятының асылы, максаты, поэтик үзенчәлекләре (лирик герой, символлар системасы) күрсәтелә, төп мотивлары билгеләнә. Шулай ук авторның суфи әдәбиятны шагыйрьләрнең тәнкыйтьләү, фикер хөрлеген саклау өчен файдалануы турындагы фикерләре дә кызыклы.

[3] Галякадән – бәйләнештән.

[4] Имкян хариҗендә – мөмкин түгел.

[5] Хәвасе хәмсәдән – биш тойгыдан (күрү, ишетү, ис сизү, тәм тату, тотып белү).

[6] Мәфһүмнәрне – төшенчәләрне.

[7] Гади мәфһүмнәр – гади төшенчәләр.

тасвир ителсә, бәгъзан бөтен тәфсиләте белән чын-чын хайвани гыйшык формасында тәлкыйн ителә[1]. Суфи шагыйрь ярга, мәгъшукка булган ялкынлы мәхәббәте турысында, мәхәббәтнең газаплары, аерылышу – фиракның катылыгы, ярның вафасызлыгы хакында сөйли икән, Алла хакында һичбер сүз булмауга карамый, моннан аның Аллага мөнәсәбәтен генә аңларга кирәк. Әгәр дә шагыйрь мәгъшукасын мактый икән, шуның белән ул Алласына сәна[2] әйтә; мәгъшукасы белән кавышуны, васләт яки висальне[3] тели икән, аның үбешләре, кочышлары хакында уйлый икән, ул бары тик Аллага юлыгу, рухан Алла белән берләшүне генә ирадә кыла[4]. Мәгъшуканың вафасызлыгыннан, аның илтифатсызлыгыннан суфиның Алласы белән турыдан-туры галякага[5] керә алмавын, аның белән үзе теләгәнчә мөнәсәбәттән рухан гаҗиз булуын аңларга кирәк. Суфилар гыйшык бабында Алла белән үзләрен шәрыктагы мәшһүр гашыйк мәгъшукларга – Йосыф белән Зөләйхага, Ләйлә белән Мәҗнүнгә, Фәрһад белән Ширингә тиңләштерәләр. Шулай ук алар, шәрык әдәбияты гадәтенчә, гөл белән былбыл хакында бик күп язарга яраталар. Шәрык әдәбиятында былбыл – сандугач, гөл – розаның гашыйгы итеп тасвир кылына. Бу – бик шаигъ булган[6] бер киная. Гөл вафасыз ярны тәҗәссем иттерә[7], былбылның янына килә алмый, аларга кушылырга гөлнең чәнечкеләре манигъ[8] булалар. Суфи шагыйрьләрчә, былбылны – гашыйк суфи үзе, гөлне – Алла, гөл үскән бакчаны галәм-дөнья мәгънәсендә аңларга тиеш.

Тәсаувыф шагыйрьләре исереклек, шәраб-мәй хакында да бик күп язалар. Суфилык лирикасының яртысы гыйшыкка багланган булса, икенче яртысы хәмер вә исереклеккә мәдех вә

[1] Тәлкыйн ителә – аңлатыла.
[2] Сәна – мактау.
[3] Васләт яки висальне – кушылуны яки кавышуны.
[4] Ирадә кыла – тели.
[5] Галякага – бәйләнешкә.
[6] Шаигъ булган – һәркемгә билгеле булган.
[7] Тәҗәссем иттерә – гәүдәләндерә, күз алдына китерә.
[8] Манигъ – киртә.

сәна укуга багышланган дисәк тә хата булмас. Суфи шагыйрьләр бертуктаусыз исерү – мәст булу[1], җырлау, гыйш-гыйшрәт, кәеф-сафа, мәйханә вә эчке мәҗлесләре турысында сөйләп торалар, исереклекне мактыйлар, шуңар дәгъвәт кылалар. Бу әйберләрдән шулай ук суфиларча мәгънә чыгарырга тиеш була; мәсәлән, исереклектән – суфиның Аллага күңеле белән юнәлү аркасында килгән кәшеф (экстаз) халәтен, үз-үзен һәм бөтен дөньяны онытуын, мәй вә шәрабтән яисә илаһи гыйшыкны, яисә Алланың суфига җибәргән илһамын аңларга тиеш. Мәйханәдәге шәраб коючыдан – сакыйдан – суфилар, бәгъзан Алланы, бәгъзан Алла белән ике арада илче булган шәех – пирны аңлыйлар[2]. Сакый күбесенчә матур яшь егет итеп тасвир ителә. Әгәр дә шагыйрь халыктан яшерен булган төнге эчке мәҗлесен, андагы башбаштаклыкларны, җырларны, мәгъшукалар белән уйнауларны тасвир итә икән, моннан суфиларның төнге мәҗлесләрен, хилка[3] ясап утырып, зикер әйтеп, гайре табигый халәте рухиягә (экстазга) килүләрен, Алланың да алар арасында хазир булуын аңларга кирәк. Бу мәйханә вә гыйш-гыйшрәт манзарлары бәгъзан фисык-фәсадның[4] иң түбән дәрәҗәдәгесен, эчеп-исереп кабак идәнендә туфрак арасында аунап ятуларны тасвирга кадәр барып җитә. Мәйханәдә эчүчеләр мәҗлесендә утыручы пар-мәгъшука да бер пакь җир фәрештәсе түгел, бәлки иң гади бер фахишә төсле булып күз алдына килә башлый.

Шагыйрь, гаклы сәлимгә[5], тәкъва кешеләрнең фикеренә ачыктан-ачык каршы килеп, алардан истиһза белән[6] көлеп, гакылсыз рәвештә исереп, азып-тузып гомер уздыруны идеал итеп куеп, дөнья мәшәкатьләреннән ваз кичеп, дөньяви байлыкка ис китми, шат вә исерек хәлдә яшәргә чакыра, ачыктан-ачык шуңар

[1] Мәст булу – исерек булу.

[2] Шәех – пирны аңлыйлар – дәрвишлек юлына чыгарган кешене, остазны аңлыйлар.

[3] Хилка – түгәрәк.

[4] Фисык-фәсадның – начарлыкның, бозыклыкның.

[5] Гакылы сәлимгә – сәламәт акылга.

[6] Истиһза белән – мыскыллы

өнди. Ул һичбер нәрсәгә кайгырмый, мәгъшукасы белән мәйдән башка нәрсәне теләми һәм уйламый. Бу тасвирда без, әлбәттә, бөтен матди дөньядан ваз кичкән, бер тиен малсыз, ялангач, бары тик Алласы турысында уйлап, Алла гыйшкы белән исереп яши торган дәрвишне күрәбез. Исерек-шагыйрь үзенең «эштән чыккан» кеше булуы хакында яза икән, – ул чынлап ук үз хәленә тәэссеф итә икән[1] дип уйламагыз; киресенчә, ул бу сүзләрне аерата бер горур белән сөйли: имеш, гади кешеләр, рәсми дин-шәригать ноктаи нәзарыннан караучылар каршында без шундый «эштән чыккан» кешеләр инде; әмма алар наданнар, алар безнең үзләренә караганда никадәр гали[2], аларның вак тормышларыннан ничаклы өстен булуыбызны аңлаудан да гаҗизләр!

Тәсаувыф әдәбияты үзенең гасырларча дәвамында үзенә махсус истыйляхлар[3] ясап чыгарган. Бу ике мәгънәле, мәҗази[4] истыйляхлар, һәрвакытта, һәркем тарафыннан бер үк мәгънәне аңлату өчен истигъмаль ителә торган тасвири сүзләр шулкадәр күп ки, аларның үзләрен генә җыеп бер лөгать китабы тәртип итәргә мөмкин. Шул истыйляхатны[5] белмичә торып, тәсаувыф әдәбиятын аңлау читен. Югарыда телгә алынган «яр», «сакый», «мәй», «гөл», «былбыл» шикелле мәфһүмнәрдән башка, «бәхре гамман»га чумып, аннан хәзинә чыгаручы «гаувас» кинаясе[6] дә тәсаувыф шигырьләрендә еш истигъмаль ителә. Монда «диңгез»дән морад – «вәхдәт диңгезе», ягъни мәгъбүднең очсыз-кырыйсыз «барлыгы», «гаувас»тан морад – суфи. Аның чумып энҗеләр, гәүһәрләр чыгаруы – илаһият белән берләшеп, Хакыйкатьне табуы. Шулай ук шагыйрь бәгъзан үзен диңгездә йөзүче, дәрья кичүче итеп тасвир итә. Аңар, яр кырыена барып җит-

---

[1] Тәэссеф итә икән – үкенә икән.

[2] Гали – югары, бөек.

[3] Истыйляхлар – төшенчәләр, аңлатмалар.

[4] Мәҗази – күчерелмә мәгънәле.

[5] Истыйляхатны – терминологияне.

[6] «Гаувас» кинаясе – биредә: суга чумып энҗе эзләүче кинаясе турында сүз бара. Суфичылык әдәбиятында ул тәсаувыф юлына басып, Хакыйкатьне эзләүче суфины символлаштыра.

кәнче, бик күп бәлаләр, давыллар, упкыннар белән көрәшергә туры килә. Йөзүче монда – әлбәттә, Алла белән кавышуга мәел итүче[1] суфи, каршы чыккан манигъләр исә – дөнья тарафыннан аңар бу юлда куелган киртәләр. «Җами җәм»нән «нуш итү» дә – суфи шагыйрьләрнең яраткан тәгъбирләре. Бу – Иран легендаларыннан алынган бер нәрсә. Имеш, бик борынгы заманда Җәмшид исемле бер шаһ булган. Бу шаһның бер кыйммәтле кадәхе[2] (җәм) булган. Шул кадәхкә шәраб салып эчкәндә, Җәмшид (яки «Җәм») аның эчендә ни теләсә шуны (бөтен дөньяны) күрә ала икән. Суфиларның дөньяга карашы өчен бу, әлбәттә, бик күп мәгънә аңлата торган аллегория була ала.

Суфилык хиркасы[3] белән капланып, суфи шагыйрьләр әдәбият бабында исламият ноктаи нәзарыннан бик артык дәрәҗәдә хөрлекләргә бирeләләр; гыйшык-мәхәббәт бабында пәрдәсез тасвирларга, ачыктан-ачык гөнаһ вә сәфаһәткә[4] өндәүгә, көфер сүзләр сөйләүгә кадәр барып җитәләр. Мәсәлән, үзләренең шәехләре хакында сөйләгәндә, аны алар потханәдә торучы «пире муган», ягъни мәҗүс каһиннәренең башлыгы дип кенә атыйлар. Гыйбадәтнең кирәксезлеге, мәсҗед белән чиркәү арасында аерма юклыгы шикелле сүзләр – тәсаувыф әдәбиятында бик гади нәрсәләр. Шәрыкта тәсаувыфның гакылларга тәэсире шул дәрәҗәгә килгән ки, иң тәкъва, иң диндар кешеләр дә, суфи шагыйрьләрнең һичнәрсә белән чикләнмәгән хөр фикерле, бәгъзан, әдәптән тыш шигырьләрен укыган чакта, дини хисләре тәхкыйр ителмәү[5] генә түгел, хәтта шул шигырьләрдән тирән мәгънәләр эзләп, дини хисләр тәэсиренә бирелергә тырышалар. Әмма мәгълүм бер ноктаи нәзардан торып карамаган гади укучы өчен аларның төп мәгънәсе бөтенләй яшерен кала, чөнки, күбесенчә, шигырьләрнең мөндәриҗәсеннән һич аларның

[1] Мәел итүче – күңел куючы, омтылучы.
[2] Кадәх – шәраб эчә торган савыт, бокал.
[3] Суфилык хиркасы – суфиларның өс киеме.
[4] Сәфаһәткә – бозыклыкка, начарлыкка.
[5] Тәхкыйр ителмәү – хурланмау.

мәҗази[1], кинаяле булуларын аңларга да мөмкин түгел. Шуның өчен дә бер кыйсем гади укучылар суфи шагыйрьләрнең әсәрләрен аларның тышкы, дөньяви мәгънәсе белән аңлап укыйлар һәм дөньяви ләззәт алалар. Мәсәлән, Хәйям вә Хафизның шигырьләре хәзер дә Иранда халык тарафыннан гади гыйшык җырлары урынына җырланып йөриләр.

Ислам Шәркында – шул мөтәгассыйб[2], һәрбер вак-төяккә шәригать ноктаи нәзарыннан карап, кылны кырыкка яра торган руханилар там рәвештә[3] хөкем сөргән ислам галәмендә – әдәбият шундый искиткеч ирекле бер юл алып киткән. Моның сәбәбе дә аның бу турыда шул ук дин белән коралланып мәйданга чыгуыннандыр, суфилыкның ислам дөньясында нинди зур иҗтимагый вә сәяси куәткә малик булуы[4] югарыда әйтелеп узылган иде. Шул формада язу бер гадәт хөкеменә кереп киткәннән соң, чын-чын, ифратка китмәгән[5]. Тәкъва суфиларга да, әгәр шигырьдә үзләренең хисләрен изһар итәргә[6] теләсәләр, ихтыярсыз шул юлны тотып, гыйшык, мәгъшук, шәраб вә исереклек турысында язарга туры килгән. Икенче яктан, һич тәсаувыфка мөнәсәбәте булмаган кешеләргә бу әдәби гадәт һәртөрле хөр фикерләр бәян итәргә, хөр тасвирларга киң юл ачкан. Тәсаувыф калканы белән капланып, алар теләсә нәрсә хакында яза алганнар. Руханилар аларга каршы авыз ачып сүз әйтүдән гаҗиз булганнар. Шунлыктан шәрык лирикасында бертөрле фикер чуалчыклыгы хөкем сөрә. Бәгъзан әдәбият мөтәхассыйслары[7] да кайбер шагыйрьләрне заһири мәгънәдә аңларгамы, әллә киная тарикынча[8] аңларгамы мәсьәләсендә тәрәддеддә[9] калалар. Хәтта суфи

[1] Мәҗази – символик, күчерелмә мәгънәле.
[2] Мөтәгассыйб – фанатик.
[3] Там рәвештә – тулы рәвештә.
[4] Малик булуы – ия булуы.
[5] Ифратка китмәгән – чамадан тыш китмәгән.
[6] Изһар итәргә – күрсәтергә.
[7] Әдәбият мөтәхассыйслары – әдәбият белгечләре.
[8] Киная тарикынча – киная аша, киная юлы белән.
[9] Тәрәддедтә – икеләнүдә.

шагыйрьләрнең пире[1] Хафиз хакында да, аның ахыр гомерендә чын суфи шәехе булуына карамый, шөбһәләр юк түгел. Шулай итеп, суфилык тарызы ифадәсе[2] шәрык шагыйрьләре өчен дини вә әхлакый цензурага каршы бер калкан ролен уйлап килгән. Хакимнәр вә руханиларның тәгъкыйбыннан[3] тәэмин итеп, хөррияте каләмия[4] биргәнгә күрә, һәр бабта каләмнәрен иркен йөртергә теләгән, ачыктан-ачык тәнкыйть ителергә ярамый торган әйберләрне тәнкыйть итәргә теләгән шагыйрьләр, гәрчә рухан суфилыкка һичбер мөнәсәбәтләре булмаса да, хәтта хилаф[5] булсалар да, тәсаувыф тарикатьләреннән берәрсенә интисаб итеп[6], бер-бер ишанга кул биреп, рәсмән үзләрен суфилар зөмрәсенә[7] кертә торган булганнар. Гомумән, суфилык һәм суфилану яки, һич булмаганда, суфиланган булып азаплану бу вакытта шәрыкта бик модадагы әйбер булган. Шуңар күрә дә шәрыкта суфи шагыйрьләрнең халис[8] әдәби-шигъри әсәрләренә тәсаувыфи шәрехләр баглау гадәте бик таралган булган. Шәрехчеләр, әлбәттә, аларның әсәрләрен кинаяле һәм дә бик тирән мәгънәле рәвештә аңларга вә изах итәргә[9] тырышканнар.

## V
## Уйгурларда әдәбият

Алда сөйләнгәнчә, төркләрдә төрле тәгълимат вә фикерләрнең кушылуын күрсәтүче бер көзге булса, ул да – уйгур әдәбиятыдыр. Уйгур төркләренең әдәбиятында без, бер яктан, иске шаман идеологиясеннән күчүнең үтү дәверен (переходной пе-

[1] Пире – башында торучы.
[2] Суфилык тарызы ифадәсе – суфилык системасыннан, суфилык карашларыннан чыгып аңлату.
[3] Тәгъкыйбыннан – эзәрлекләвеннән.
[4] Хөррияте каләмия – сүз ирекге.
[5] Хилаф – каршы.
[6] Интисаб итеп – бәйләнеп.
[7] Зөмрәсенә – төркеменә.
[8] Халис – саф.
[9] Изах итәргә – ачык итеп аңлатырга.

риод[1]) күрсәк, икенче яктан, уйгур мохитендә төркләр арасына кергән төрле тәгълиматның җәелү процессын һәм аларның бер-берсе белән чарпышуларын, ниһаять, шуларның үзара тәркибе[2] аркасында суфилык идеологиясе мәйдан алып, уйгур әдәбиятының чыгтай әдәбиятына әверелеп китүен күрәбез.

Ту-күә төркләренең дәүләте мөнкариз[3] булган заманнарда «уйгур» исемле бер төрк җәмгыяте күтәрелә башлый[4]. «Уйгур» сүзе хакында мәнбәгъларда[5] фикерләр беркадәр чуалчык. Башка төрк кабиләләре белән сугышып, алар тарафыннан җиңелеп, куылып, тора торган урыннарын алмаштыруларына, уйгур теле аталган аерым бер телләре булуына караганда, «уйгур» аталып йөртелгән халык төркеменең аерым бер төрк кабиләсе булуы аңлашылган төсле була. Бәгъзылар «уйгур»ны «ою» (оешу) масдарыннан чыгарып, борынгы заманда күчмәлектән утраклыкка күчкән төрк кабиләләренең һәммәсе шул исем астында йөртелгән, диләр; тарихта очрый торган уйгур, унгар (венгр), авар, хәтта болгар шикелле халык исемнәре дә шул «уйгур» сүзе белән бер төптән чыккан дип дәгъва кылалар. Кайбер тарихчылар исә, Әбелгазыйның «Шәҗәрәи төрки»сенә[6]

---

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[2] Тәркибе – кушылуы.

[3] Мөнкариз – бетерелгән, юкка чыккан.

[4] Уйгурлар – Шәркый Төркестанның төп төрки халкы, мөселман-сөнниләр. Уйгур теле төрки телләр семьялыгына керә. Беренче тапкыр этноним безнең эра башында, төрки телле *Теле* кабиләсе атамасы буларак пәйда була. Унтугыз кабилә берләшеп, Уйгур каһанлыгы оешкач (VII–IX гг.), этноним гомуми атамага әйләнә. Уйгур каһанлыгы таркалып, аның халкының бер өлеше Шәркый Төркестанга күченгәч тә, *уйгур* атамасы төрле кабиләләр исеме буларак кулланылышта йөри.

[5] Мәнбәгъларда – чыганакларда.

[6] *Уйгур* этнонимының килеп чыгышын төрлечә аңлатулар яши. Әбелгазый (1603–1663) «Шәҗәрәи төрк» елъязмасында этнонимны төрки телдәге «ою»дан «оештыручы, берләштерүче», «үз кеше» мәгънәсендә гомумбилгеле сүз белән аңлата, Угыз хан кабиләгә шундый исем бирде, дип яза. Рәшид әд-Дин дә, үзенә ярдәмгә килгән кабиләгә рәхмәт йөзеннән, Угыз-хан уйгур исемен бүләк итте дигән версияне алга сөрә. Мәхмүд Кашгари аны Александр Македонскийга нисбәт итә. Үзенә каршы торган җитез атлыларны Македонский «худхуранд» дип атаган, имеш. Тора-бара бу сүз «уйгур»га әйләнгән.

истиснадан[1], «уйгур» аерым бер төрк кабиләсенең исеме булмаган, бәлки бер төрк җәмгыятенә, бер хөкүмәт кул астына җыелып бер патшалык тәшкил иткән төрле төрк кабиләләренең сәяси оешмасына бирелгән исем булган, диләр. Ләкин, ничек кенә булмасын, тарихта шушы исем астына җыелган, тирә-яктагы башка халыклардан аерым бер төрк оешмасы, бер халык булган; без тарих сәхнәсендә шул халыкның үзенең теле, әдәбияты вә мәдәнияте булганлыгын күрәбез.

Милади VIII гасырның урталарында, мәркәзи Монголиядә Орхон елгасы буенда булган ту-күәләр империясе таралгач, аның урынына гареб тарафыннанрак (хәзерге Монголиянең шимали гарбендә), яңа бер көчле төрк патшалыгы – Уйгур мәмләкәте тәшкил ителә. Уйгурлар борынгырак заманнарда, милади III, IV гасырларда, Байкал күленең төшлек ягында, Орхон вә Сәләңә елгалары хаузаларында[2] торганнар. Пайтәхетләре Карабалгасун шәһәре булган. VI гасырда тунгус кавеменнән булган җуҗан дигән халык аларга һөҗүм итеп, гаребкәрәк күчеп китәргә мәҗбүр иткән. Кытай вәкаигънамәләреннән аңлашылуга күрә, уйгурлар борынгы «Һун-ну» мәмләкәтен тәшкил иткән төркләрнең токымнары, икенче төрле әйткәндә, шул ук халык булырга тиеш. Чөнки Кытай тарихчылары «уйгурларның телләре һун-нуларныкы белән бер», дип язалар. VI, VII, VIII гасырларда, ту-күә төркләре хөкүмәт сөргән чакларда, уйгурлар, Сәләңә вә Янәсәй елгаларыннан Тянь-Шань тауларына кадәр булган җирне биләп, ту-күәләр кул астында торганнар. VIII гасырның урталарында алар үзләре бер зур мәмләкәт төзиләр. Бу беренче уйгур мәмләкәте Байкал күленнән алып Алтай вә Тянь-Шань тауларына һәм Гоби чүленә кадәр җәелгән булган. Аның шәүкәтле дәвере IX гасыр урталарына кадәр дәвам иткән. IX гасырда аңар кара кыргызлар һөҗүм итеп туздыргач, уйгурлар

[1] Истиснадән – чыгармадан. Б и р е д ә : «әсәрдән чыккан фикергә ияреп» мәгънәсендә.

[2] Хаузаларында – бассейннарында.

җәнүбкә күчеп китәләр[1]. Шулай итеп, шимали Монголиядәге уйгур дәүләте урынына, X гасырда җәнүбтә ике кечерәк уйгур ханлыгы мәйданга килә, бу ханлыкларның берсе – хәзерге Шәркый Төркестан (Төркестан чины, кытай Төркестаны) урынында, икенчесе шәрыктарак, Кытайның хәзерге «Гән-су» аталган вилаятендә, Тянь-Шань вә Алтын-Тау буйларында, Луб-Нур күле тирәләрендә булган. Беренчесенең пайтәхете Биш-балык булса, икенчесенеке Кашгар икән. Патшаларын уйгурлар «илик» дип атаганнар. Шәркый уйгур ханнарының титулы – «идикот», гарби уйгур ханнарыныкы «Богра хан» булган. Бу ике ханлыкны без бәгъзан – бер хан кул астында идарә ителеп, бергә кушылган хәлдә, бәгъзан аерым-аерым ике мәмләкәт булып яшәгән хәлдә табабыз. XI гасырда Уйгур мәмләкәте бик куәтләнеп, шәрыкта Сәдде чинига[2], җәнүбтә Тибетка кадәр киңәйгән, хәтта Хәзәр диңгезенә[3] вә Иран чикләренә кадәр уйгур ханнарының хөкеме йөри икән. XII гасырда Хивада хөкүмәт сөргән харәзмиләр сөляләсе[4] уйгур ханнары белән Мавәраэннәһердә хакимият өчен тартышалар. Бу вакытта инде Уйгур мәмләкәте зәгыйфьләнеп, икегә аерылган булган. Шәрыктагы уйгурларның будда динендә булып, гаребтәгеләренең ислам кабул итүләре бу аерманы тагы да арттырган. Шәркый уйгур ханлыгы акрынлап үзенең

---

[1] Уйгур этносы формалашу озак гасырларга сузыла. Аларның борынгы күчмә бабалары Хун империясендә (б.э. кадәр III – б.э. IV гг.) зур роль уйный. Язма чыганакларда алар б.э. III гасырында телгә алына, борынгы Кытай елъязмаларында – гаоцзюй, аннары V гасырда теле (тегрег) дип исемләнә. Бу кабиләләрнең бер өлеше көнбатышка, Казакъстан далаларына һәм Европаның көньяк-көнчыгышына күченә. Урта Азиядә (Җунгария һәм Мавәраэннәһердә) калганнары төркиләр белән берләшә (яулап алына). 605 елда аларның бер өлеше Хангай тауларына китеп, «токуз огуз» буларак мәгълүм. V–VIII гасырларда уйгурлар – Төрки каһанлык составында. Аларның этник формалашуы VIII гасырда, Төрки каһанлык җимерелгәч, Уйгур каһанлыгы төзелү белән бәйле тәгалләнә дип күрсәтелә. 840 елдан аларның дәүләте таркала, үзләре Шәркый Төркестанга күченә башлый. X гасырдан уйгурлар арасында ислам тарала.

[2] Сәдде чини – Кытай стенасы.

[3] Хәзәр диңгезе – Каспий диңгезе.

[4] Сөляләсе – династиясе.

истикъляthough[1] югалтып, Кытай тәэсиренә төшкән. XIII гасыр башына, Чыңгыз чыгуга кадәр уйгур мәмләкәте сүнәр-сүнмәс яши дә, 1218 елда, өстенә килгән монгол ташуына каршы тора алмасын белеп, актыккы уйгур ханы үз ирке белән хакимиятне Чыңгыз кулына тапшыра. Чөнки бу вакытта инде аларның игенчелеккә, сәүдәгә бирелүләре аркасында сугышчанлыклары беткән иде[2]. Шул көннән башлап, Уйгур дәүләте дигән сәяси оешма тарих сәхифәсеннән югала.

Заманның үтүе белән, «уйгур» исеме үзе үк тарих сәхифәләрендә күренми башлый, уйгур дигән халык юкка чыга. Шәркый Төркестанда торган уйгурлар, яңа килгән башка төрк кабиләләре белән катнашып, башка исемнәр белән аталып китәләр, телләрен дә үзгәртәләр[3]. Шәркый уйгурлар исә, кытайлар вә тибетлылар тәэсиренә төшеп, инкыйразга йөз тоталар. Хәзер дә аларның калдыклары Кытай эчендә Гәнсу вилаятендә, Луб-Нур күленнән шәрыкка табарак (Суҗау һәм Гәнҗау дигән Кытай шәһәреннән җәнүбкә таба ике көнлек юлда), Тянь-Шань тауларының итәкләрендә бер утрау шикелле генә булып калганнар[4].

Уйгур халкы яхшы ук югары мәдәнияткә малик[5] булган. Уйгурлар ул вакыттагы төрк халыкларының иң мәдәниләреннән

---

[1] Истикъляլиятен – бәйсезлеген.

[2] Бартольд. «Туркестан в эпоху монгольского завоевания». С. 420. *(Авт. иск.)*

[3] Ихтимал, хәзер шунда тора торган таранчы төркләре борынгы уйгурлар нәселеннән килә торганнардыр. *(Авт. иск.)*

[4] Нибарысы ун мең җаннан артык булмаган бу халык калдыгында без инкыйразга йөз тоткан халыкларның бөтен хосусиятен табабыз. Алар фәкыйрьлектә көн кичерәләр, рухан бик түбәнләшкәннәр, бик зәбүн вә мәдәниятсезләр. Күршеләрендәге көчлерәк халыклар (кытайлар, тибетлылар) тарафыннан йотылып, каумиятләрен дә югалтып баралар. Хәтта инде алар үзләренең халык әдәбиятларын (җырларын) да онытып бетерә язганнар. Диннәре – будда дине. Дини телләре һәм язулары тибетча. Телләре борынгы уйгур әдәбияты язылган телгә бик якын. Ләкин алар хәзер үзләренең телләрен дә онытып баралар инде. Шулай булса да, исемнәрен онытмаганнар, үз-үзләрен «сарыг югур» (сары уйгур) дип атыйлар. Профессор С.И. Малов, 1910 елларда фәнни максат белән сары уйгурлар торган җиргә җибәрелеп, алар арасында елга якын торып, тормыш вә телләрен тәфтиш итеп, бик кыйммәтле материаллар җыеп кайткан иде. *(Авт. иск.)*

[5] Малик – ия.

булганнар. Алар, ярым утрак, ярым күчмәле тормыш белән торып, хайван асрау, игенчелек, сәүдә вә сәнәгать белән шөгыльләнгәннәр. Тора торган җирләре шәрыктагы вә гаребтәге зур мәдәни өлкәләр арасында, урталыкта ятканга, Кытайдан, Һиндстаннан – гаребкә, Идел буеннан, Бизанестан, Гарәп хәлифәлегеннән шәрык тарафына үтә торган сәүдә кәрваннары күбесенчә уйгурлар аркылы уза торган булганнар. Шул рәвешчә зур сәүдә юлында ятканга, уйгурлар сәүдә мөнәсәбәтләрендә төрле халыклар белән аралашканнар, танышып катнашканнар, аларның мәдәниятеннән өлеш алганнар. Бу җир һинд, Иран, Сүрия, ислам, кытай, тибет, төрк мәдәниятләренең бер-берсе белән очраша торган урыны булган. Уйгурларның яңа килеп урнашкан җирләре иген игәр өчен сәляхиятле[1], мөнбит[2] җирләр булганга, алар игенчелеккә керешкәннәр; сахра тормышыннан шәһәр, авыл тормышына күчә башлаганнар. Аларның мәдәни мәркәзләре, шәһәрләре булган. Пайтәхетләре Бишбалык[3] шәһәре булып, Кашгар, Карахуҗа, Баласагун вә башка исемнәрдә калалары булган.

Җәгърәфи мәүкыйгларының[4] мөсагыйдлеге[5] аркасында, Якын вә Урта шәрыкны бергә җыя торган юл өстендә ятканлыкларыннан уйгурлар арасында төрле мәдәниятләр бер-берсе белән катнашып беткән иде, моны күрү өчен, аларның диннәренә генә бер күз салып узу җитә. Аларда үзләренең борынгы диннәре шаманлыктан башлап һәртөрле диннәрне очратырга мөмкин. Буддизм, ислам вә христианлыкның берничә төрлесе (манихеизм, несторианизм) уйгурлар арасында таралган диннәрдән булган. Уйгурларның бик күптәннән бирле тотып килгән диннәре – будда дине. Бу дин аларга ике юл белән: кытайлар

[1] Сәляхиятле – яраклы.

[2] Мөнбит – уңдырышлы.

[3] Балык – борынгы төркчәдә «шәһәр», «кала» мәгънәсендә. Бу шәһәрнең хәрабәләре хәзердә Гүчән вә Турфан шәһәрләре тирәсендә. *(Авт. иск.)*

[4] Җәгърәфи мәүкыйгларының – географик яктан урыннарының.

[5] Мөсагыйдлеге – мөмкинлек бирүе.

аркылы һәм Тибет аркылы кергән. Электә уйгурлар арасында шимали[1] Ираннан килгән мани мәзһәбе (манихейство[2]) таралган булган. Бу мәзһәбнең төркләр арасында IV гасырдан ук тарала башлавын чамалыйлар (Радлов). Манилык – христианлыктан азып, Иранның борынгы диннәре тәэсиренә төшкән бер дини мәзһәб. Ул исламият таралуга кадәр шимали Иранда бик нык хөкем сөргән. Уйгурлар Монголиядә торганда (VIII гасырда), хәтта берзаман аларның ханнары да шул мәзһәбкә кереп, манилык рәсми хөкүмәт дине булып киткән. Бу дин уйгур халкы арасында берничә гасырлар яшәгән. X гасырда без әле аларда бу мәзһәбнең яхшы ук куәтле булганын күрәбез. XIII гасырда инде аның әсәре күренми. Христиан мәзһәбләреннән уйгурлар арасында нәстури мәзһәбе (несторианство[3]) таралган. Бу мәзһәбне башлап чыгаручы V гасырда Нәстури (Несторий[4]) атлы бер сүрияле булган. Башлыча Сүриядә таралган бу мәзһәбне тотучыларны нәстуриләр дип атаганнар. Рәсми дине ортодокс (православия) булган Бизанес хөкүмәте, башка бәдмәзһәбләрне тәгъкыйб иткәне[5] шикелле, нәстуриләргә да көн бирмәгән. Нәстуриләр, хөкүмәт тәгъкыйбеннән качып, чит мәмләкәтләргә, Иранга һиҗрәт иткәннәр. Аларның раһибләре[6] миссионерлык, мәҗүси халыклар арасында дин тарату максаты белән хәтта Монголиягә, Кытайга вә Һиндстанга барып чыкканнар.

Уйгурлар арасында да бу динне шул нәстури монахлары алып килеп таратканнар. Аның уйгурлар арасында иң могтәбәр вакыты VIII вә IX гасырлар булган. X гасырда исә, Шәркый Төркестанга күчеп килү белән, уйгурлар ислам дине белән очрашканнар. Шул вакытта алар арасында исламият тарала башлап, мани вә нәстури мәзһәбләре бу халык арасында акрын-акрын бөтенләй юкка чыккан. Шуны да әйтеп китәргә кирәк ки, соңгы-

[1] Шимали – төньяк.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[4] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[5] Бәдмәзһәбләрне тәгъкыйб иткәне – бозык мәзһәбләрне эзәрлекләгәне.
[6] Раһибләре – монахлары.

рак заманда нэстуриләрне иң нык тәгъкыйб итүчеләрдән берсе Аксак Тимер булган. Ислам, гомумән, башка диннәргә каршы мөтәгассыйб[1] вә мәдәнияттә түбәнрәк булып, бер диндә чыныгып җитмәгән халыклар арасына бигрәк тә а[н]сатлык белән таралучан бер дин булганга, тиз арада уйгурларның бик зур бер кыйсеме мөселман булып беткәннәр. Ислам бары буддизмда гына үзенә нык каршы торучы дошман тапкан. Буддизм куәтле булган җирдә ислам артык рәваҗ[2] таба алмый. Шуңар күрә ислам бигрәк гарби[3] уйгурлар арасында таралып, шәркый уйгурлар будда динендә калганнар.

Уйгур телендә, артык бай булмаса да, әдәбият булган булырга кирәк. Ләкин уйгурларның яшәгән җирләрендә бертуктаусыз булып торган сугышлар, төрле диннәрнең алмашынуы язма әсәрләрнең тәләф[4] булуына сәбәп булган. Хосусан исламият тәгассыбы[5] белән башка диннәргә тәгаллекъcouldы[6] уйгурча әсәрләр касдан[7] бетерелгәндер дип уйларга мөмкин. Уйгур телендәге әдәбиятның күбрәк кыйсеме исә дини әдәбият булгандыр дип уйланыла, чөнки хәзергә кадәр сакланып калган, буддизмга, мани вә нэстури мәзһәбләренә гаид[8] язма кисәкләр – һәммәсе диярлек дини әсәрләр.

Уйгур язуы белән төрк телендә язылган иң иске әсәр маниларның тәүбә догасы булырга кирәк. Бу доганың язылу тарихы VIII гасырлар дип тәхмин[9] итәләр. Аның теле бик борынгы, Орхон ташларының теленә бик якын, хәтта бөтенләй аны уйгурча түгел дип дәгъва итүчеләр бар. Радлов аны Орхон язуларыннан да элек язылган дип уйлый. Менә бу тәүбә догасының бер

[1] Мөтәгассыйб – фанатик.
[2] Рәваҗ – таралу.
[3] Гарби – көнбатыш.
[4] Тәләф булу – юкка чыгу, әрәм-шәрәм булу.
[5] Тәгассыбы – фанатизмы.
[6] Тәгаллекъле – бәйләнешле.
[7] Касдан – алдан уйланылып, белә торып.
[8] Гаид – бәйләнеше булган.
[9] Тәхмин – чамалана.

кисәге: «Төрт йәгирминч. Бир йылка йәти йәмәки улур сук тору бар әрти, бир айкы чаксапут тутмак кәргәк әрти, йәмә чайданта йәмәки улуруп, бачаг бачап, тәңри Бурканка бир билкин көңүлтә бәрү бир йылкы йазукумузни бушуну өтүмәк кәргәк әрти, тәңрим! Йәти йәмәки төкәти улуру уммадимиз әрсәр, бир айкы чакса пут әдгүти арыти тутту умма димиз әрсәр, йәмә чайданта йәмәки бачаг әдгути, нумча, төрүчә улур өммадимиз әрсәр, бир йылкы йазукумузни бир билгин көңүлтә бәрү бушуны колмадимиз әрсәр, нәчә әгсик кәргәк булти әрсәр, тәңрим, әмти йазукта бушуну өтүнүрбиз: manastar herz![1] Бәш йәгирминч. Күн сайу нәчә йавлак сакынч сакынурбиз, нәчә сөзләмәсик, иричүлүк сөз сөзләйүрбиз, нәчә ишләмәсик иш ишләйүрбиз, анг кылынычка иринчүкә кәндү өзүмүзнү әмгәтирбиз...»[2]

Татарча мәгънәсе[3]: «Ундүртенче. Бер елга җиде (тапкыр) аш уздыру гадәте (кануны) бар иде, бер еллык ураза тоту тиеш (кирәк) иде, янә «чайдан»да аш уздырганда догалар укып, тәңре – Бурханга[4] чын күңелдән бу елгы языгыбыздан пошынып (тәүбә кылып) үтенергә тиеш иде, тәңрем! Җиде ашны тулы итеп уздыра алмаганбыз икән (алмадык исә), бер айлык уразаны яхшы һәм пакь килеш тота алмаганбыз икән, янә «чайдан»да аш һәм догаларны яхшы гына, аиин һәм гадәт буенча үткәрә алмаганбыз икән, бер елгы языгыбызны (кичерүне) чын күңелдән пошынып сорамаганбыз икән, тиеш (эшләр)не үтәүдә никадәр кимчелек булган икән, тәңрем, инде языгыбызга пошынып үтенәбез: кичер мине! Унбишенче. Көн саен никадәр яман уй уйлыйбыз, никадәр сөйләмәскә тиешле сүз сөйлибез, никадәр эшләмәскә тиеш эш эшлибез, мәкер һәм әшәкелек аркылы үз үзебезне газапка салабыз...»

[1] Манастар зәртс! – бу сүз төркчә түгел. *(Авт. иск.)*

[2] О, ö авазлары урынына **у, ө** хәрефләре язылды. *(Авт. иск.)*

[3] Радловның немецча тәрҗемәсе аркылы тәрҗемә ителде. *(Авт. иск.)*

[4] «Буркан», «Бурхан» – асылда, «Будда хан» – төркләрдә буддизм тәэсирендә ясалган бер сүз булып, «Алла» мәгънәсендә истигъмаль кылына. *(Авт. иск.)*

Аннан соң VIII, IX гасырларга гаид[1] нәстуриләрнең дини китапларыннан бәгъзы бер кисәкләр табылган (мәсәлән, Инҗилнең Гайсә тууына гаид бер кисәге вә башкалар).

Уйгурча әсәрләрдән будда диненә гаид булганнары әһәмиятлерәк. Күптән түгел генә Кытайның Гәнсу вилаятендә Суҗау[2] шәһәре янындагы бер будда гыйбадәтханәсендә уйгур телендә, уйгур язуы белән язылган зур бер китап табылган. Бу китапны Казан мөстәшригы[3], уйгур теле вә әдәбиятының мөтәхассыйсләреннән[4] С. Малов[5] 1910 елда Шәркый Төркестанга сәяхәте вакытында табып алып кайткан. «Алтун ярук»[6] исемле бу әсәр – будда диненә даир[7] «Сутра» атала торган дини китап. Ул бөтен килеш диярлек табылган, зур кулда. 700 битләр чамасы, эре хәрефләр белән бик матур, мәшкый[8] язылган. «Алтун ярук» (ягъни «Алтын яктылык») XIII–XIV гасырлар чорында Бишбалык шәһәренең бер уйгур тарафыннан кытайчадан төркчәгә тәрҗемә кылынган. Табылган нөсхә – XVII гасыр күчергече. Бу китапның телендә әле гарәп-фарсы тәэсире бер дә юк, ул саф уйгур телендә язылган. Бу китапның табылуы борынгы уйгур телен өйрәнүче галимнәр өчен хәзинә табылу белән бер булган. Шуның аркасында уйгур әдәби теленең мөкәммәл

[1] Гаид – бәйләнеше булган.

[2] Суҗау – Сучжоу шәһәре. Бүген Кытайның Цзянсу провинциясенә керә.

[3] Мөстәшрикъ – шәрык белгече.

[4] Мөтәхассыйсләреннән – белгечләреннән.

[5] Малов Сергей Ефимович (1880–1957) – Россия һәм совет тел белгече, шәрыкшинас-тюрколог, СССР Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы. Төрки телләр белгече. Борынгы төрки рун язуларын укыган галим буларак билгеле. 1910 елда Кытайның Гәнсу төбәгендә экспедициядә вакытта Вуншигу (уйгурча Инҗән) дигән авылда «Алтын яруг» кулъязмасын таба. Ул иң тулы текст буларак билгеле. С. Малов соңрак аны В.В. Радлов белән берлектә бастырып чыгара. Кулъязма борынгы уйгур теленең тулы сүзлеген төзергә мөмкинлек бирә.

[6] «Алтын яруг» – борынгы уйгур язма истәлеге. Тулы исеме – *«Алтун онлук ярук ялтыраклы копта котирилмиш ном илики атлык ном»* (Алтын төсле ялтыраучы падишаһ-китап). Аңа кытай теленнән тәрҗемә ителгән «Алтын яктылысына тиң Сутра» һәм ике легенда – «Кү-Тау хакиме турында легенда» һәм «Принц белән юлбарыс турында легенда» керә.

[7] Даир – караган.

[8] Мәшкый – матур язу белән.

лөгатен[1] төзергә имкян ачылган. Шуның ошашлы будда диненә гаид дини китаплар тагын берничә нөсхә табылган. Аларның бәгъзысы – турыдан-туры һинд теленнән, бәгъзысы кытай теле аркылы тәрҗемә кылынганнар. Нәмунә[2] өчен «Алтун ярук» китабыннан кыска гына бер кыйтгане күчереп китәбез: «Йитиздә тутулмиш кылти түкәл билке тәңри тәңриси бурканниң билкүлики, күркүлүки идук таисиң умларка санлык үлкүланеҗсиз, таңланиҗсиз, титикъсиз, тутуксуз, йартикъсуз анҗа буң әдкү кылынҗларим әрсәр, уларны йәмә биш ажун тинлык угланыңкы әвирен тәкинүрмен. Такый йәмәмәниң...(?) умук сүзүң белкүкә йелинмамаң күңүлтин, белкүтин йәмә үңки булмасак күңүлтин тукмишинҗа буң әдкү кылынчларим әрсәр, ани алку ай барҗа биш аҗун тинлык угланиңка авирен тәкинүрмен»[3].

Бу әсәрләрдән башка тагы фән галәменә уйгур телендә язылган бик күп хокукый документлар (могаһәдә[4] вә гакыйднамәләр) дә табылган. Мәхкәмә эшләрендә истигъмаль ителгән[5] уйгур теленә нәмунә булу белән бергә, бу документлар борынгы уйгурларның икътисади тормышларын тасвир иткәнгә, аларның тарихи әһәмиятләре дә бар[6].

«Котадгу белег» шикелле әсәрләрнең булуына караганда, ислам кабул иткән уйгурларда яхшы ук киң әдәбият булган булырга кирәк. Ләкин ни өчендер мөселман уйгурлардан, шул бердәнбер китаптан башка, нә дини вә нә дөньяви булсын, әсәрләр сакланмаган. Хосусан мөселман булган халыкта дини китаплар булырга тиеш иде. Шулай да кайбер гарәп вә кытай тарихчылары уйгур хәрефләре белән язылган тарих китапларының булган-

[1] Мөкәммәл лөгатен – тулы сүзлеген.
[2] Нәмунә – үрнәк.
[3] «Алтун ярук»ның тәрҗемәсе хәзергә кадәр нәшер ителгәне юкка күрә, бу катганең татарчасын бирергә мөмкин булмады. Шулай ук татарча транскрипциянең дә хатадан хали булмавы мөмкин. *(Авт. иск.)*
[4] Могаһәдә – килешү, договор.
[5] Истигъмаль ителгән – кулланылган.
[6] Малов С.Е. Лекции по тюркологии, читанные в Сев.-Вост. Арх. Инст. (По записи с разреш. автора). *(Авт. иск.)*

лыгыннан хәбәр бирәләр; хәтта исемнәрен дә атап (Тарих ханы), үзләренең шул китапларда язылган мәгълүмат белән файдаланганнарын сөйлиләр. Ләкин бу китапларның берсе дә хәзергә кадәр табылганы юк[1].

«Котадгу белег»[2] – төрк телендә язылып та безгә мәгълүм булган китапларның иң борынгысы. Хәзерге заманда дөньяда аннан да элегрәк төрк телендә язылган бөтен бер китап сакланмаган. Бу китап хәзергә кадәр нибарысы өч нөсхәдә табылган[3]. Беренче нөсхәсе 1439 елда шимали Әфганстанда Һират шәһәрендә күчерелгән. Соңра Истанбулга килеп эләгеп, аннан яурупалылар кулына төшкән; хәзердә Венада корольнең сарай көтепханәсендә саклана. Бу нөсхә уйгур хәрефләре белән язылган. Кайбер урыннарыннан күчерүченең оста, мәшкый[4] каләмле кеше булганы күренсә дә, гомумән, нөсхә ашыгыч һәм пөхтәсез күчерелгән. Уртасыннан ун данә кәгазе төшеп югалган. Калганы – 190 бит.

«Котадгу белег»нең икенче нөсхәсе Мисырда Каһирә шәһәрендә Хидивның көтепханәсендә заһир булган[5]. Гарәп хәрефләре белән матур вә мәшкый язылган бу нөсхәнең бу кадәр еракка кайдан вә кай вакытта килеп кергәне мәгълүм түгел. Бу нөсхәнең күчермәсе хәзердә Петроградта «Азия музәханәсе»ндә саклана. Шулай ук гарәп хәрефләре белән язылган өченче

[1] Малов С.Е. Лекции по тюркологии. *(Авт. иск.)*

[2] «Котадгу белег» – Йосыф Баласагуни тарафыннан 1070 елда язылган әсәр, безнең заманга килеп җиткән борынгы төрки язма ядкәрләренең иң зурысы. Поэма ундүрт меңгә якын шигъри юл тәшкил итә. Йосыф Баласагуни аны Төркестанның Җидесу төбәгендәге Баласагун шәһәрендә 462 һиҗри / 1069–1070 милади елда тәмамлый һәм Кашгарның шахзадәсе Богра ханга бүләк итә.

[3] Бүгенге көндә дә «Котадгу белег» әсәренең өч нөсхәсе билгеле: беренчесе – 1439 елда Гератта күчерелгән, уйгур графикасында. Бүген Вена шәһәрендә Австрия милли китапханәсендә саклана. Икенче күчерелмә 1896 елда Каһирәдә Хидив китапханәсе мөдире тарафыннан табыла, гарәп хәрефләре белән язылган. Хәзердә Каһирә милли китапханәсендә исәпкә алынган. Өченче күчерелмә З. Вәлиди тарафыннан 1913 елда Нәмәнганда табыла. Бу күчерелмә шулай ук гарәп графикасында язылган, бүген Үзбәкстан Фәннәр академиясенең Әбү Рәйхан Бируни исемендәге шәрыкны өйрәнү институтында саклана.

[4] Мәшкый – матур язулы, каллиграфик.

[5] Заһир булган – табылган.

нөсхәсен 1914 елда Зәки Вәлиди гыйльми тәфтиш[1] өчен Төркестанга сәяхәте вакытында Фәрганәдә бер сарт кулында тапкан. Ләкин ул китапны кулына төшерә алмаган, күреп кенә калган. Шулай итеп, бу өченче нөсхә гыйлем әрбабының[2] кулына керер-кермәс югалган[3] .

«Котадгу белег» дигән сүзнең ни мәгънәгә туры килүе хакында электә беркадәр аңлашылмаулар булган. Уйгур ханнарының «идикот» дип йөртелүләренә карап, башта аны – «идарә белеме»[4], «патша булу гыйлеме» дип, аннан соң «кот»ның «бәхет» мәгънәсендә булуына истинадан[5], «бәхет бирүче гыйлем» дип тәрҗемә кылганнар. Радлов та шул фикердә булган[6]. Ахырысында данияле галим Томсен аңар дөрес мәгънә биргән: «Котадгу белег» – «бәхетле булу белеме» мәгънәсендә.

«Кодатку белег» дип тәләффыз итү[7] башта Радлов укуы буенча гомумиләшеп истигъмальгә кереп киткән. Чынлыкта «д»ны «т»га, «к»ны «г»га алмаштырып, «Котадгу белег» дип укылырга тиеш. Гарәп хәрефләре белән язылган нөсхәдә дә шулай язылган. «Котадгу» – уйгурча «кот» – бәхет дигән сүздән ясалган борынгы сүз формасы (исме масдар[8]). Борынгы төрк телләрендә хәзерге телләрдә «и» хәрефе истигъмаль ителгән урыннарның кайберендә «д» кулланылган; мәсәлән, аяк – адак, айгыр – адгыр, кое – кодык булган. Яңа телләрдә «д»ның «и»гә алмашуга таба мәеле[9] бар. Шулай ук «котадгу» сүзен дә хәзергечәләштереп әйтсәк, «котаю» булып чыга. Бу – «виргү» шикелле исме масдар. Төрк телләрендә, борынгыдан яңага таба килгәндә, «гъ» һәм «г»нең «у», бәгъзан[10] «е»гә әверелүгә мәеле бар. (Таг – тау,

[1] Тәфтиш – тикшерү.
[2] Гыйлем әрбабының – гыйлем әһеленең.
[3] Малов С.Е. Лекции по тюркологии. *(Авт. иск.)*
[4] La science du gouverment. *(Авт. иск.)*
[5] Истинадан – таянып.
[6] Радлов. Опыт словаря тюркских наречий. Т. II. С. 1001. *(Авт. иск.)*
[7] Тәләффыз итү – әйтү, сөйләү.
[8] Исме масдар – исем фигыль.
[9] Мәеле – авышлыгы, тартылуы.
[10] Бәгъзан – кайчакта.

олуг – олы, яг – яу, баргу – бару, биргү – бирү, гә – я). Масдар вә исме масдарлар борынгы төркчеләрдә «гу» һәм «гү» кушылып ясалганнар; соңыннан «гъ» белән «г» төшеп, «у» гына калган. Шулай итеп, «карт»тан «картаю», «иш»тән «ишәю» ясалган күк, «кот»тан «бәхетле булу» мәгънәсендә булган «котаю» (котайгу, котадгу) ясалган. «Белег» – «белем», «гыйлем» мәгънәсендә. Шул рәвешчә китапның дөрес исеме «Котадгу белег» булса да, гадәт булып кереп киткәнгә күрә без «Кодатку белек» дип яза бирдек.

«Котадгу белег» Баласагун шәһәренең[1] бер галим уйгур төрке тарафыннан язылган. Ул аны милади 1069–1070 елларда Кашгар шәһәрендә тәмам итеп, уйгур ханы Кара Богра ханга тәкъдим иткән. Шушы китабы өчен хан Йосыфны, аның сәясәт гыйлемендә мәһарәтен[2] күз алдында тотып, үзенә якынлаштырган. Аны үзенең якын киңәшчеләреннән кылып, сарайда зур дәрәҗә, хас хаҗиблек (киңәшче – хас вәзирлек) дәрәҗәсе биргән. Шунлыктан исеме «Йосыф хас хаҗиб» дип мәшһүр булган. Без бу мәгълүматны китапның башындагы, нәсер белән язылган мөкаддимәсеннән[3] алабыз[4]. Бу мөкаддимә китапның мөәллифе[5] тарафыннан язылмаган, бәлки соңыннан бер-бер күчерүче тарафыннан өстәлгән булырга охшый, чөнки мөкаддимәне язучы китапның мөхәррире хакында гаиб сигасында (ул дип) сөйли. Шулай ук бу китапның бик зур шөһрәт тотып төрле мәмләкәтләргә таралган булуы да мөкаддимәдә сөйләнә; аннан соң мөкаддимәнең теле дә аның соңгырак заманда язылуына дәлаләт итә[6]. Мөкаддимә уйгурча белән чыгтай арасындарак булган бер тел белән язылган. Уйгурчалык аңар сәнгый[7] рәвештә (әдәбиләштерү өчен) кертелгәнгә охшый. Китапның үзенең

---

[1] Бәласагун» яки Баласагун шәһәре хәзерге Җидесу вилаятендә Токмак шәһәре белән Ыссык күл арасында булган. *(Авт. иск.)*

[2] Мәһарәтен – осталыгын.

[3] Мөкаддимәсеннән – керешеннән.

[4] Моннан башка тагы китапның назым белән язылган мөкаддимәсе бар. *(Авт. иск.)*

[5] Мөәллифе – авторы.

[6] Дәлаләт итә – дәлил була.

[7] Сәнгый – ясалма.

телендә гарәп-фарсы сүзләре бик аз булып, мөкаддимәдә әҗнәбилек тәэсиренең[1] көчле булуы да аның соңгырак гасырда, чыгтай әдәбиятының башлану вә гарәп-фарсы телләренең тәэсире көчәю дәверендә язылган булуын күрсәтә.

Мөкаддимәне язучы «Котадгу белег» китабының төрле илләргә таралып дан тотканлыгын сөйли. Чинлылар аны – «Әдәб әлмөлүк» дип, мачинлылар[2] – «Әмин әл-мәмләкәт» дип, иранлылар – «Пәнднамәи мөлүк» дип, мәшрикълылар[3] «Зәйн әл-әмраи» дип атадылар, ди. Мачин (ягъни Кытай) галимнәре вә хакимнәре «Төркестан илләрендә, Богра хан телендә» моннан да яхшырак китап тасниф ителмәве[4] хакында иттифак иттеләр, ди. Чынлап та, заманасында бу китап шәрык галәмендә шактый игътибар казанган әсәр булган булырга кирәк. Аның бер нөсхәсенең Мисырга килеп төшүе шуны ачык күрсәтә. Җаек суының тамагындагы борынгы Сарайчык шәһәрендә кырыена «Котадгу белег» шигырьләре язылган бер вазаның табылуы аның Җүчи Олысы шикелле шактый ерак төрк илләрендә дә укылганын күрсәтәдер.

Гәрчә мөкаддимәче мөәллиф үзенең китабын «Чин-Мачин хәкимнәренең әмсалләре, әшгарләре[5] белән бизәкләгән», дисә дә, бу әсәргә башлыча заманасының ислам Шәркында, гарәп вә фарсыларның дини, әхлакый вә сәяси әдәбиятында хөкем сөргән фикерләр тәэсир иткәнлеге күрелә. Хосусан, сәлҗук солтаннары Алып-Арыслан белән Мәлик-шаһның галим-вәзире, мәшһүр шәрык сәясие Низам әл-Мөлекнең шул вакытларда (XI гасырда) чыккан «Сәясәт-намә»[6] исемле әсәренең Йосыфка зур тәэсире булган булырга кирәк.

---

[1] Әҗнәбилек тәэсиренең – чит телләр тәэсиренең.

[2] Чин вә Мачин – Һиндокытай һәм Кытай (Көньяк һәм Төньяк Кытай).

[3] Мәшрикълылар – «европалылар» мәгънәсендә.

[4] Тасниф ителмәве – язылмавы.

[5] Әмсалләре, әшгарләре – мисаллары, шигырьләре.

[6] Низам әл-Мөлек – мәшһүр фарсы дәүләт эшлеклесе Әбү Гали әл-Хәсән ибн Гали ибн Исхак әт-Тусинең (1018 яки 1019/1020–1092) идарәчелек титулы. 1063–1072 елларда сәлҗук солтаннары Алып-Арслан (1063–1072) һәм Мәлик-шаһ (1072–1092) идарә иткән елларда аларның вәзире була. Көчле үзәкләштерелгән дәүләт идеясен яклаган «Сәясәтнамә» хезмәтенең авторы дип санала. Сәлҗуклар һәм Габбаслыларның берләшүенә зур көч куя. Низамия исеме белән тарихка кергән мәдрәсәләр ача.

«Котадгу белег» яхшы ук саф төрк телендә язылган. Аның теле – беркадәр гарәби шивәләр тәэсирендә булган уйгурча[1]. Аңар катышкан гарәп вә фарсы сүзләренең саны йөздән артык түгел икән[2]. Ләкин алай да, бу сүзләр еш истигъмаль ителгәнгәме, гарәп-фарсы тәэсире күзгә бәрелә[3]. Сафлык ягыннан аны Орхон язуларының, хәтта «Алтын ярук»ның теле белән дә чагыштыру мөмкин булмаса да[4], чит сүзләр белән чуарланмау ягыннан ул чыгтай теленә караганда күп алда. «Котадгу белег»нең өслүбе җиңел һәм урыны-урыны белән матур, хәтта тасвири диярлек.

«Котадгу белег» төрк теле өчен шактый авыр булган «мөтәкариб» дигән гарәп вәзенендә[5] назым белән язылган. Ул – зур күләмле бер китап, 73 фасылга бүленеп, барысы 6500 дән артыграк ике мисраглы бәйттән гыйбарәт. Кафия[6] күбесенчә шул ике юллы бәйтләрнең һәркайсының үз эчендә генә. Мәүзуг[7] вә мөндәриҗә ягыннан караганда, «Котадгу белег»не фәлсәфи, әхлакый вә сәяси бер әсәр дип атарга туры килә. Аны бер билгеле мәүзугта язылган дип әйтеп булмый. Китапның башында, ислам Шәркындагы гомуми гадәт буенча, берничә фасыл Алла, пәйгамбәр вә сахабәләрне мактауга багышланып, аерым бер фасыл Богра ханны мактауга билгеләнгән. Аннан ары «адәм углының бәһасе белем белән булуын», гыйлемнең, аңның ни икәнен, тел һәм аның файда вә зарарларын сөйли торган фасыллар, китапның ни өчен алай аталуын белдерә торган, «китап иясе» үзенең гозерен бәян кыла торган аерым-аерым фасыллар

[1] Малов. Лекции... *(Авт. иск.)*

[2] Зәки Вәлиди. Төрк вә татар тарихы. Б. 14. *(Авт. иск.)*

[3] Караханча дип йөртелгән, караханлылар ханлыгында кулланылышта булган уйгур-карлук (хаканийә) телендә язылган. Фарсы һәм гарәп теленнән кергән сүзләр, калькалар еш очрый. Шул ук вакытта автор төрки халыкларның бай мәкальләренә, борынгы фикер ияләренең уй-карашларына зур урын бирә.

[4] «Алтын ярук»та чит сүзләрдән һинд вә кытай телләреннән кергән будда дине истыйляхаты шактый күп. *(Авт. иск.)*

[5] Фәгулән, фәгулән, фәгулән, фәгуль. *(Авт. иск.)*

[6] Кафия – рифма.

[7] Мәүзуг – тема.

киләләр. Әлхасыйль, баштагы унбер фасыл китапның дибаҗәсе[1] урынына торалар. Бу дибаҗәнең мөндәриҗәсе[2], югарыда күрсәтелгәнчә, нәкъ борынгы мөселман китапларындагы шикелле озын вә чуалчык. Бу унбер фасыл арасына хәтта «Җиде кәвакиб[3] вә унике йолдыз» хакында сөйли торган фасыл да керә. Бары уникенче фасылдан башлап кына асыл максатка керешелә.

«Котадгу белег» китабындагы фикер вә фәлсәфәләр гади вәгазь китапларындагы төсле турыдан-туры гына сөйләнми, бәлки шәрык халыкларында кабул ителгән гадәт буенча, вәгазь-нәсыйхәт, хикмәт вә фәлсәфәләрне мөәллиф[4] бер әдәби калыпка салып, берәр кеше авызыннан сөйләтә[5]. Бу китапта шундый фикер сатучы шәхесләр дүртәү: беренчесе патша булып, исеме – Көнтугды, икенчесе вәзир – Айтулды, өченчесе вәзирнең углы – Өгдүлмиш, дүртенчесе вәзирнең кардәше – Узгурмиш.[6] Ләкин бу шәхесләрне бер-бер хикәя яки романдагы шикелле җанлы, тормыштан алынган типлар, әдәби сима-

[1] Дибаҗәсе – кереш сүзе.

[2] Мөндәриҗәсе – эчтәлеге.

[3] Кәвакиб – йолдызлар. Б и р е д ә: «планеталар» мәгънәсендә.

[4] Мөәллиф – автор.

[5] Каюм Насыйри тарафыннан татарчага тәрҗемә кылынган мәшһүр «Кабуснамә»не шундый китаплар өчен үрнәк итеп алырга ярый. Анда чын вәгазьләр Кәйкавес патшаның улына нәсыйхәте формасында сөйләнә. *(Авт. иск.)*

[6] «Котадгу белег» – фәлсәфи эчтәлекле, әхлакый-дидактик поэма. Персонажлар урынында шартлы дүрт зат алынган: Көнтугды (Яңа туган көн) – гаделлек гәүдәләнеше, Айтулды (Тулган ай) – бәхет һәм дәүләт гәүдәләнеше, Үгделмеш (Үгет бирүче) – акыл-зиһен гәүдәләнеше, Узгырмыш (Уяулык) – канәгать булу гәүдәләнеше. Әсәр шушы дүрт затның бер-берсе белән сөйләшүләре, сорау һәм җаваплары, бәхәсләре төсендә язылган. Шундый үзара сөйләшүләр барышында алар бик күп мәсьәләләргә кагылалар: дәүләт һәм аңа карата кешенең бурычы, дәүләт башлыгының үз халкына хуш килерлек сыйфатлары; гыйлем, мәгърифәт, акыл-зиһен һәм аның хорафаттан хөрлеге мәсьәләләре, яшәү мәгънәсе, гаилә, гаделлек, кешеләрнең үзара мөнәсәбәт-мөгамәләләре, хезмәт һәм иҗат, тынычлык һәм сугыш – тагын башка шундый әһәмиятле мәсьәләләр күтәрелә. Шагыйрь бу мәсьәләләргә үзенең мөнәсәбәтен ача бара. Ул актив һәм аек акыл-зиһен ягында, шулай ук фән, мәгърифәт һәм турылык тарафдары, кешенең үз иленә намус белән хезмәт итеп, гомер юлын зур мәгънә белән кичүе ягында.

лар[1] дип уйларга ярамый. Алар һәрберсе берәр символ – мәҗази[2] фигура. Бу дүрт зат дүрт төрле сыйфат-идеяне үзләрендә тәҗәссем иттерәләр:[3] патша – гадәләт, вәзир – дәүләт, вәзирнең углы – гакыл, вәзирнең кардәше – канәгать[4]. Менә шул дүрт шәхес бертуктаусыз төрле-төрле мәсьәләләр хакында сөйләшәләр, бер-берсе белән фикер алышалар, мөбахәсә[5] вә мөназаралар кылалар, хатлар язышалар, киңәшләр бирешәләр, кунакка барышалар, авырыйлар, төш күрәләр, төш юрыйлар, үкенәләр, тәүбә итәләр, әлхасыйль[6], гади тормышта кеше эшли торган һәртөрле эшләрне кылалар. Ләкин ни генә эшләсәләр дә, ни генә сөйләсәләр дә, алар бер гади инсан булып түгел, бәлки үзләре тәҗәссем иттерә торган идея – ноктаи нәзарыннан карап эшлиләр вә сөйлиләр. Аларның бөтен хәрәкәтләреннән вә кылган эшләреннән максат та – хакыйкый тормышны тасвир түгел, бәлки шул эшләр мөнәсәбәте белән фикер сөйләү һәм фәлсәфә сату гына, шуның өстенә тагы фикерләр, шәрык гадәтенчә гаять озын, чуалчык вә эчпошыргыч бер рәвештә бәян ителә.

Мисал өчен, чит мәмләкәтләргә илче итеп җибәрү өчен нинди кеше мәслихәт булуы хакында сөйли торган фасылдан исереклек хакындагы бер кыйтганы алабыз[7]:

Пур ичмәс кәрәк кәт өзин туткучы,
Өзин туткучы әр булур коткучы.
Белеклек пур ичсә, белексез булур,
Белексез пур ичсә, адин нә кылур.
Пур ул бу белеккә укушка ягы,
Пур ади хакыйкать тудуш ул чугы.
Нәчәмә белеклек укушлук кеше,
Башын пурга сукса, бузар өз эше.

---

[1] Сималар – б и р е д ә : шәхесләр.
[2] Мәҗази – символик; уйлап чыгарылган.
[3] Тәҗәссем иттерәләр – гәүдәләндерәләр.
[4] Канәгать – канәгатьләнү.
[5] Мөбахәсә – бәхәс.
[6] Әлхасыйль – җыеп әйткәндә.
[7] О, ӧ авазлары өчен **у, ө** хәрефләре алынды. *(Авт. иск.)*

Нәчәмә увутлык селек кылгый үс,
Пур ичсә удунлык кылур барча өз.
Газизем, өвүтма укуш өк белек,
Арикъсыз бу пурга барур ай селек.
Пур ичмә, пур ичсә, барур әр куды,
Пур ичсә булур тәлбә мундус ады.
Карынга сөчүк керсә, чыкарур сөз үк,
Бу чыкмыш сөз үк яндыру белмәс өз үк.
Нә гүтәр әшәткел бу бәйт айгучы,
Укыгыл, ачылгай тышы да эче.
Калы ичдең әрсә, өсертке сөчүк,
Көңел сере ачды чыкарды ичек.
Белеклек пур ичсә, белексез булур,
Белексез пур ичсә, булур кәчкәчек».

Тәрҗемәсе[1]:

(Илчелек өчен) исерткеч (хәмер) эчми торган, үз-үзен тота белә торган (кеше) кирәк. Үзен тота белә торган ир (генә) үз көче белән бәхет таба ала.

Белекле (галим кеше) исерткеч эчсә, белексез була – белексез (кеше) исерткеч эчсә, ни эшли? (Ни хәлгә тара).

Исерткеч ул – белемгә, аңга дошман ... (Бәйтнең икенче мисрагының мәгънәсе ачык аңлашылмый)[2].

Никадәр белекле, аңлы кеше(ләр) исерткечкә баш салса(лар), үз эшләрен бозалар.

Никадәр оятлы, пакь (гыйффәтле), күркәм фигыльлеләр исерткеч эчсәләр, үзләрен фахиш ясыйлар.

Газизем! Оят исә аң, белем, гакыл (белән бергә). Арусыз (кеше генә) бу исерткечкә (якын) бара, и гыйффәтле!

Исерткеч эчмә! Исерткеч эчкән ирләр түбән (хараплыкка) төшәләр. Исерткеч эчсә (кеше) тиле, ахмак атын таба.

Карынга татлы (исерткеч) керсә, (авыздан кирәксез, артык) сүзләр чыгара.

Бер чыккан сүзне (кеше) үзе үк кире кайтара алмый (белми).

---

[1] Һәрбер ике юллы бәйткә аерым юлдан башлап тәрҗемә бирелде. Мәгънәне тулыландыру өчен өстәлгән сүзләр җәяләр эченә куелды. *(Авт. иск.)*

[2] Автор искәрмәсе.

Ишет, ни әйтә бу бәйтне әйтүче! Укы, (сиңа) тышы да, эче дә ачык булыр.

Татлы исерткечне эчтең исә, (ул синең) күңел сереңне ача, эчеңдәген (тышка) чыгара.

Белекле исерткеч эчсә, белексез була – белексез исерткеч эчсә, тәмам хараплык таба.

Бу тәрҗемә Радлов тәләффызынча[1] түгел, бәлки Каһирәдә табылган гарәп хәрефе белән язылган «Котадгу белег» тәләффызына ияртеп язылды. Дөрес тәләффыз шулай булса кирәк; хәзерге сары уйгурларның да тәләффызлары шуңар якынрак икән. Радлов исә, «Кодатгу белег»нең текстын транскрипция белән нәшер иткәндә, тәләффызны бөтенләй хәзерге шәркый төркләрнекенә ияртеп, күбесенчә яңгыравыклы самитлар[2] урынына – саңгырауларны, бәгъзан[3] киресенчә куйган. Чөнки Радлов таснифы[4] буенча, әгәр уйгур теле шәркый группага керсә, анда тәләффыз, шөбһәсез, шулай булырга тиеш булып чыга[5]. Әмма уйгур язуындагы самитләрне, икенче бабта сөйләгәнчә, һәм яңгыравыклы, һәм саңгырау итеп укырга имкян бар. Радлов укуы буенча, югарыда китерелгән шигырьнең баштагы юллары менә болай укылырга тиеш:

Пелеклек пур ичсә пелексис пулур,
Пелексис пур ичсә атин нә кыйлур.

Соңыннан Радлов үзе бу рәвешчә укудан ваз кичеп, аның ялгыш булуын игътираф иткән[6].

«Котадгу белег»тә сәясәт мәсьәләләренә күп урын бирелгән. Мәсәлән, бикләр (патшалар) ничек булырга тиешлеге, вәзирләрдә

---

[1] Тәләффызынча – әйтелешенчә.

[2] Самитлар – тартыклар.

[3] Бәгъзан – кайвакыт.

[4] Таснифы – классификациясе.

[5] Казанда 1923 елда чыккан «Мәгариф» журналының 5–6 нчы санында Г. Рәхимнең «Төрк телләренең таснифында яңа тәҗрибә» дигән мәкаләсен карагыз. (Төрк телләрен тасниф хакында соңгы тәҗрибә). *(Авт. иск.)*

[6] Игътираф иткән – таныган.

вә башка зур мәнсаб иясе[1] түрәләрдә нинди сыйфатлар табылырга тиешлеге, гаскәр башы итеп куелырга, чит мәмләкәтләргә илче итеп җибәрелергә нинди кешеләр лаек булуы, сарайда хәзинәдарлар[2], кятибләр, капка сакчылары, хәтта аш пешерүчеләр нинди булырга кирәклеге хакында бик тәфсилләп аерым фасылларда сөйләнә. Мәгашәрәт[3] әдәбенә дә зур урын бирелгән. Мәсәлән, гавам белән, хәвас белән катнашканда, үзеңне ничек тотарга тиеш булуы, галимнәр, табиблар вә шагыйрьләр белән, мөнәҗҗимнәр[4] вә төш юраучылар белән, һөнәр ияләре, сатучылар, игенчеләр, әлхасыйль, төрле сыйныфтан булган халык белән ничек мөгамәлә кылырга тиешлеге хакында нәсыйхәтләр ничә фасыллар буенча сузыла; ничек өйләнергә, ничек итеп балаларны тәрбия итәргә, ничек кунак кабул итәргә, үзең кунакка барганда, үз-үзеңне ничек тотарга тиешлеге хакында озын-озын мөляхәзәләр[5] йөртелә. Аннан башка тагы дөньяның фанилыгы, кешенең тормышы белән кирәгенчә файдалана алмыйча, гомеренең ахырында үкенергә мәҗбүр булуы, бәхетнең нидән гыйбарәтлеге, сөбатсызлык[6], дустлык хакында гомуми фәлсәфи фикерләр сөйләгән, кыйсмән суфилык идеологиясенә күчүне күрсәтүче фасыллар да арада бар. «Котадгу белег»нең мөндәриҗәсе нинди характерда вә никадәр чуар булуы шуннан аңлашылса кирәк.

Сарай шагыйрьләре белән нинди мөнәсәбәттә булырга тиешлеген сөйли торган бер кыйтганы[7] китереп узабыз:

Баса кәлде шагыйрь бу сөз кушкучы,
Кишик өккүчеләр йәмә сүккүче.
Кылычда итигрәк буларның теле,
Йәмә кылда әнҗкә бу хәтер юлы.
Батык әнҗкә сөзләр укаин тәсә,

[1] Мәнсаб иясе – дәүләт хезмәтендә торучы.
[2] Хәзинәдарлар – казначылар.
[3] Мәгашәрәт – аралашу.
[4] Мөнәҗҗимнәр – астрономнар.
[5] Мөляхәзәләр – игътибар белән уйлау, фикер йөртүләр.
[6] Сөбатсызлык – ышанычсызлык.
[7] Кыйтганы – өзекне.

Булардин әшит сөз укулга баса.
Дәңизгә кирүр көрсә көңлин түгәл,
Гәүһәр, инҗү-якут чыкарур масал.
Булар өксәләр, өгде әлгә барур,
Калы сүксәләр, аты артаб калур.
Өзә әдгү туткыл буларны кадаш,
Буларның телеңә илинмә адаш.
Калы әдгү өгде тиләсә өзүң,
Буларык сәвендер йадылды сөзүң.
Нәгү кулса бәргел буларга түгәл,
Буларның телендин өзең саткын ал.

Тәрҗемәсе:

Шагыйрьләр – сүзләрне (бер-берсенә) кушып (тезеп), кешене мактаучылар һәм (янә) сүгүчеләр (хакында сөйләргә вакыт) килде.

Боларның теле кылычтан үткенрәк, янә боларның хәтер (хыял) юлы кылдан нечкәрәк.

Тирән, нечкә (мәгънәле) сүзләрне аңлыйм дисәң, болардан ишет, аңлашылыр!

Үзләрен (алар) күңелләре белән тәмам диңгезгә чумган (күк итеп) күрәләр дә (аннан) гәүһәр, энҗе-якут(тай) мәсәл(ләр) чыгара(лар).

Болар мактасалар, ул кешенең шөһрәте илгә бара (тарала), әгәр сүксәләр, аты (исеме) түбән төшә.

Үзеңне болар белән яхшы тот, юлдаш! Боларның теленә эләкмә, кардәш (дус)!

Үзең (турысында) яхшы (изге) дан (чыгарырга) теләсәң, боларны сөендер – аларның синең хактагы сүзләре (дөньяга) таралыр.

Ни сорасалар, төгәл итеп бир боларга, боларның теленнән үзеңне сатып ал. (Радлов тәрҗемәсе: «Боларның теленнән үзеңнең өлешеңне ал»).

Менә бу шигырьдән борынгы шәрыкта сарай тормышы белән әхлаклары бозылган мәддах[1] шагыйрьләрнең нинди булганнары аермачык күренеп тора. Уйларга мөмкин ки, уйгур ханнарының сарайларында оя ясаган, тәлинкә ялаучы шагыйрьләр дә нәкъ шундый булганнардыр, «Котадгу белег»нең мөхәррире

[1] Мәддах – ода язучы.

шуларны күз алдында тотып язгандыр. Бу китапта һәртөрле табәка[1] вә сыйныфтан булган кешеләрнең шундый тәүсыйфләрен[2] табып була. Никадәр коры әхлакчылык белән тулган булмасын, бу әсәр буенча XI гасырдагы уйгурларның иҗтимагый тормышларын тулы рәвештә күз алдына китерергә мөмкин. Шуңар күрә «Котадгу белег»нең тарих өчен дә әһәмияте юк түгелдер.

Бу китапка, әлбәттә, чын сәнаигы нәфисә[3] ноктаи нәзарыннан[4] каралырга тиеш түгел. Нәфис вә шигъри әдәбият әсәре булу йөзеннән аның артык кыйммәте юк. Ләкин шулай булса да, теленең матур вә фәсыйх[5] булуы, моннан 850 еллар элек зыялы бер төрк галиме тарафыннан әдәби бер формада язылып, заманында бер төрк илендә генә түгел, бәлки чит илләрдә дә мәкъбүл[6] бер әсәр булуы аны төрк әдәбияты тарихында бөек вә хөрмәтле урынга куя. Шөбһәсез, «Котадгу белег» борынгы төрк әдәбиятының иң эре энҗеләреннән хисапланырга, иң әһәмиятле әсәрләреннән саналырга тиеш.

Уйгур әлифбасы Чыңгыз вә аның хәләфләре[7] заманында аларда канцелярия язуы булып, уйгур теле дә монгол-татар империясендә рәсми тел булып киткәч, элек уйгурлар каләме белән Чыңгызның «Яса»сы язылды. Шул ук вакытта «Яса» белән бергә Чыңгызның бер «Котадгу белег»е дә булганы мәгълүм. Ләкин бу әсәрнең нөсхәсе безнең заманга кадәр калмаган. Аның барлыгын Мөхәммәд Һиндушаһ[8] исемле бер мөәррихнең[9] монгол

[1] Табәка – катлау.

[2] Тәүсыйфләрен – сыйфатлауларын.

[3] Сәнаигы нәфисә – матур сәнгать.

[4] Ноктаи нәзарыннан – карашыннан.

[5] Фәсыйх – матур һәм килешле; әдәби.

[6] Мәкъбүл – кабул ителгән.

[7] Хәләфләре – дәвамчылары.

[8] Мөхәммәд Һиндушаһ (1293–1376) – дәүләт эшлеклесе, тарихчы. 1361 еллар тирәсендә фарсы телендә «Дәстүр әл-кәтиб фи йакыйн әл-мәратиб» («Дәүләти дәрәҗәләрне билгеләү өчен кулланма») дигән хезмәт яза. Ул сорау-җавап рәвешендә төзелгән, анда Урта гасырларда Иранда җир биләү формалары, налоглар, матди хәл хакында бай мәгълүмат туплап бирелгән.

[9] Мөәррихнең – тарихчының.

хөкүмәтенең фәрманнарын җыйган «Дәстүр әл-кәтиб фи йакыйн әл-мәратиб» исемле әсәрендә табабыз. Шунда «Дәраи март йаргу» (Хөкем әмирлеге хакында) дигән бер ярлык та табабыз. Шунда Баян Бунур дигән бер әмир «Йаргу» түрәсе ясала һәм аның хакында башка сүзләр белән бергә «бер вәҗби кадәр “Котадгу белег” Җенкез хани дидә вә хәвандә» (шул вәҗһе[1] белән кем ул Чыңгызның «Котадгу белег»ен күргән һәм укыган), диелә. Димәк, шундый китап булган. Ләкин бу Чыңгызның «Котадгу белег»е Йосыфныкы белән берме, әллә шул ук китап соңыннан гына Чыңгызга нисбәт бирелгәнме – ачык мәгълүм түгел. Шулай да, тюрколог Мелиоранский[2] фикеренчә, бу әсәр чыңгызиларның хокук мәнбәгы[3] булып, анда хөкем эшләрен тикшерү һәм хөкем йөртүнең тәртипләре күрсәтелгән, һәм бу әсәр Чыңгызның авызыннан яисә аның имла итүеннән язылып алынган булып, уйгурныкына тәкълидән[4] «Котадгу белег» дип аталган булырга кирәк[5].

## VI
## Чыгтай әдәбияты

Чыгтай әдәбияты дип Урта Азия төркләре тарафыннан мәйданга китерелгән, милади XII гасырда башланып та, XIX гасырга кадәр сузылып килә торган, кайчандыр бик бай вә көчле булган бер әдәбиятны әйтәләр.

Тарихи яктан караганда, чыгтай әдәбияты ислам тәэсирендәге уйгур әдәбиятының турыдан-туры варисы һәм дәвамы итеп хисапланырга тиеш. Ләкин күчү дәвереннән сакланып калган мәнбәгъ вә әсәрләрнең азлыгыннан уйгур әдәбиятының

[1] Вәҗһе – сәбәп.

[2] Мелиоранский Платон Михайлович (1868–1906) – күренекле шәрыкшинас, тюрколог. В.В. Радловның укучысы.

[3] Мәнбәгы – чыганагы.

[4] Тәкълидән – охшатып, ияреп.

[5] Мелиоранский П.М. О Кутадгу билике Чингиз-хана. Зап. Вост. Отд. Имп. Рус. Арх. Об-ва, том XIII, вып. 1. *(Авт. иск.)*

чыгтайныкына әйләнеп китү процессының ничек булуын катгый рәвештә тикшерүе читен. Вамбери[1] шикелле галимнәр башта бу ике әдәбиятны бер-берсеннән язылган хәрефләренең уйгур яисә гарәпнеке булуы ноктасыннан карап кына аерсалар да, бу бүлүнең бары механик рәвештә генә икәне ачык беленеп тора. Шуның өчен бу турыда ике юл гына булырга мөмкин: тел ягыннан яки идеология ягыннан карап бүлү. Бу ике әдәбият арасында тел ягыннан да билгеле бер сызык сызуы уңайсызрак, чөнки бер төрле әдәби телнең икенче төрлесенә күчүе – озын бер дәвердә акрынлап була торган бер эш. Мәсәлән, Вамбери уйгур әдәбиятына кертеп хисаплаган «Мигъраҗнамә» һәм «Тәзкирәи әүлия»ларның телендә без, уйгурлык белән бергә, бик күп чыгтай гонсыры[2] табабыз. Хәтта уйгур әдәбиятыннан булуында һичкем шөбһә итмәгән «Котадгу белег»нең дә теле – бөтенләй үк саф уйгурча түгел, бәлки шактый гына гарәби шивәләр (икенче истыйлях[3] белән әйтсәк, «чыгтайча») тәэсире астында ясалган бер тел. Киресенчә, чыгтай әдәбиятының классик әсәрләреннән санала торган Робгузиның телендә дә әле без шактый гына уйгур тәэсирен күрәбез.

Уйгур әдәбияты белән чыгтай әдәбиятын аеру өчен иң уңайлы юл – идеология (даирәи фикрия) буенча аерудыр. Уйгур әдәбиятында без һәртөрле фикер вә идеяләрнең катышуын күрсәк, чыгтай әдәбияты башлану белән, без инде анда ап-ачык аерылып тора торган бер фикер даирәсе белән очрашабыз ки, ул да булса суфилыктыр. Суфилык үзе дә шаманизм, буддизм, христианлык һәм ислам шикелле һәртөрле идеологияләрнең бәрелешеп, бергә катышып синтез ясалуыннан килеп чыкканы шикелле, чыгтай әдәбияты да – Урта Азиядәге төрк халыкларында һәртөрле фикер вә тәгълиматларның бергә катышканы соңында, аларның күпчелеге исламият ягына авышып, суфи-

[1] Арминий Вамбери, яки Герман Бамбергер (1832–1913) – күренекле маҗар галиме, сәяхәтче һәм шәрыкшинас.

[2] Гонсыры – элементы.

[3] Истыйлях – атама, термин.

лыкка килеп туктаган заманнан башланган әдәбияттыр. Шуның өчен дә ул тәмамән суфилык тәэсирендә тора.

Менә бу рәвешчә бүлү тел ягыннан карап бүлүгә дә кире булып төшми, чөнки XI гасырда уйгур телендә язылган «Котадгу белег» ислам тәэсире астында торса да, әле анда чын суфилыктан һичбер төрле әсәр[1] юк. «Котадгу белег» исә – уйгур әдәбиятының безгә мәгълүм булган соңгы әсәредер. Әмма XII гасыр язучылары Ясәви вә Бакырганилар исә, – беренче чыгтай шагыйрьләре булуы белән бергә, инде аермачык тәсаувыф тәэсирендә тора торган кешеләр, суфилыкның нәмаяндәләре[2]. Җәгърафи[3] яктан караганда чыгтай әдәбиятының вөҗүдкә килгән мәйданы – уйгур әдәбияты хөкем сөргән җиргә башка, ләкин күрше булган җирләрдер. Уйгур әдәбияты, башлыча, Уйгурстанның төп җире булган Шәркый Төркестанда яшәгән һәм чәчәк аткан булса, чыгтай әдәбияты Гарби Төркестанда, башлыча Мавәраэннәһердә мәйданга килде.

Мавәраэннәһер дип Амудәрья нәһереннән[4] шәркый шимальгә[5] таба булган (Амудәрья белән Сырдәрья арасында яткан) мөнбит[6] бер өлкәне атыйлар. Бу өлкәнең җәгърафи халәте нәкъ Гыйрак (Месопотамия) һәм Мисырныкы белән бертөсле: асылда, ком сахрасы – чүл. Әмма арыклар васитасы[7] белән сугарылган нәкъ бер җәннәт бакчасына әверелеп, бик күп халыкны туйдырып тота ала. Шулай итеп, Мавәраэннәһер табигать тарафыннан ук матди (димәк, мәгънәви) мәдәниятнең тууына сәляхиятле[8] итеп яратылган. Шуңар күрә дә Амудәрья һәм Сырдәрья хаузалары (бассейннары) элек-электән мәдәният үзәге була килгән.

---

[1] Әсәр – эз.
[2] Нәмаяндәләре – вәкилләре.
[3] Җәгърафи – географик.
[4] Нәһереннән – елгасыннан.
[5] Шәркый шимальгә – төньяк-көнчыгышка.
[6] Мөнбит – уңдырышлы.
[7] Васитасы – арадашлыгы, ярдәме.
[8] Сәляхиятле – сәләтле. Биредә: «ярашлы» мәгънәсендә.

Чыгтай әдәбиятының мәркәзе – менә шул Мавәраэннәһер. Ләкин аның даирәсенә мәдәни һәм беркадәр җәгърафи яктан Мавәраэннәһергә мөнәсәбәтле булган тирә-юньдәге күрше өлкәләр дә керәләр. Бу өлкәләр: Харәзем (Хива, Мәрвә), шимали-шәркый Иран (Мәшһәд), шимали Әфганстан Мавәраэннәһер яки Төркестанны бөҗра рәвешендә әйләндереп алалар.

Мавәраэннәһер, күп заманнардан бирле «Төркестан» дип аталып килсә дә, электә төп төрк җире булмаган. Анда элек-электән иран җенесеннән булган халыклар торганнар. Шималь һәм шәркый шимальдән килгән төркләрнең мондагы фәгалиятләре[1] башта сугыш вә һөҗүмнән генә гыйбарәт булган. Төркләрнең монда ныклап урнашулары VI гасырдан гына башлана. Шуннан башлап инде Амудәрья Иран белән Туран арасында чик ролен үти башлый. Заманнар үтүе белән, Мавәраэннәһергә төркләрнең килүе, аларның иранлыларны кысрыклаулары дәвам итә. Шулай итеп, VII гасырда анда ислам хакимияте урнашкан вакытта, гарәпләр инде бу илне тәмам төркләшкән хәлдә табалар.

Ике гасыр уза. Гарәпләр, милли шовинизм белән иранлыларны кысып тәмсил итәргә[2] тырышулары белән, яңа күтәрелеп килә торган мәдәни гонсыр[3] – төркләргә юл ачалар. Озак заман үтми, шул ук төркләр, паразит шикелле, Хәлифәтнең тәненә кереп, аны зәгыйфьләндерә, һәлакәткә өстери башлыйлар. Хәлифәт, зәгыйфьләнү белән, үзенең табигый кисәкләренә аерыла. Төркестанда төрле сөләләләр[4] бер-берсен алмаштырып, сәясәт мәйданында кылыч уйнатып кичәләр (IX гасырда – саманилар, XI дә – сәлҗуклар вә башкалар). Сарайлар химаясе[5] астында киләчәктә чыгтай әдәбиятына азык бирәчәк Иран әдәбияты күтәрелә һәм үсә: Фирдәүси, Сәгъди, Хафиз, Хәйямнарны бир-

[1] Фәгалиятләре – эшчәнлекләре.

[2] Тәмсил итәргә – үзләренә охшатырга. Б и р е д ә : «ассимиляцияләргә» мәгънәсендә.

[3] Гонсыр – элемент.

[4] Сөләләләр – династияләр.

[5] Химаясе – яклавы.

гән Иран әдәбиятының алтын дәвере башлана. Төрк җәмгыятенең югары сыйныфы Иран мәдәниятенең шәүкәтенә[1] мөкиббән китеп, үзләре дә иранлашалар. Сәлҗук солтаннары Иран шагыйрьләренең бердәнбер арка таянычларына әвереләләр. Әмма бу вакытта әле Төркестанда төрк әдәбиятының исе дә килми. Һәрхәлдә, XII гасырга кадәр гарби Төркестан шивәләрендә язылган бер генә бер әсәр безгә сакланып калмаган. Шәркый Төркестанда уйгур әдәбияты гына бу вакытта үзенең картлык көннәрен уздыра. XII гасыр җитә. Гарби Төркестанның шималь тарафыннан яңа бер рух (суфилык рухы) белән сугарылган, яңа вә моңарчы әдәбиятта истигъмаль кылынмаган[2] яшь бер телдә язучы шагыйрьләр борнап чыга башлый (Ясәви һәм аның мәктәбе). Шулай итеп, соңыннан чыгтай әдәбияты исеме бирелгән яңа бер төрк әдәбиятының беренче сукмаклары салына.

XIII гасыр башы килеп җитә. Азиянең мәркәзеннән чыккан монгол туфаны бөтен Урта Азияне басып, изеп китә. Сугыш һәлакәтләре астында мәдәнияткә беразга торгынлык килсә дә, озак вакыт үтми, Төркестан Чыңгыз балалары кул астында, Чыгтай олысы буларак, яңадан үзенең иске мәдәни хәятын дәвам иттерә башлый. Төрк телендәге әдәбият үсә, киңәя, ахырда, XVI гасырда – Тимер балалары дәверендә – үзенең иң югары ноктасына килеп җитә.

Чыгтай әдәбияты дигән тәгъбир соңгы заманда гына ясалган. «Әдәбият» дигән тәгъбир үзе үк булмаганга, әлбәттә, борынгы заманда бу истыйлях[3] истигъмаль ителмәгән. «Чыгтай теле» аталган әдәби телдә язылганга күрә, ул шулай аталган.

Урта Азия төркләренең әдәби теленә ни өчен монгол ханы Чыгтайның[4] исеме тагылган соң? Чынлыкта Чыңгызның Урта Азиядә хакимият сөргән углы Чыгтайга бу телнең һичбер төрле

[1] Шәүкәтенә – көч-куәтенә, бөеклегенә.
[2] Истигъмаль кылынмаган – файдаланылмаган.
[3] Истыйлях – атама, термин.
[4] Чыгтай, Җыгтай, Чагатай яки Җагатай. *(Авт. иск.)*

мөнәсәбәте юк. Чыгтай хан[1] Мавәраэннәһергә патша булганчы гына түгел, хәтта Чыгтайның атасы Чыңгыз дөньяга килгәнче дә, ул дөньяда булган. Чыгтай әдәбиятының башланган дәвере Чыгтай хан заманында булмаган шикелле, аның тәрәккый итеп иң югары ноктада торган заманы да – Чыгтай һәм аның нәселе хөкем сөргән заман түгел, бәлки Тимер балаларының хакимияте дәверендә. Чыгтай хан һичбер яктан Урта Азиядәге төрк әдәбиятының агымына үзгәреш кертмәгән. Гомумән, бу коры табигатьле, каты куллы сахрави монгол ханы әдәбият шикелле әйберләрдән ерак торган. Аның ана теле монголча, дине дә Будда дине булып, үзе шовинистлык дәрәҗәсендә монгол милләтчесе булганлыгы мәгълүм[2]. Шуның өчен ислам дине тәэсире астында мәйданга килгән төрк телендәге бу әдәбиятның Чыгтай хан белән коры исемнән башка мөнәсәбәте юк.

Чыгтай теленең бу исем белән аталуы бары тик аның истигъмаль ителгән урыны «Чыгтай олысы» дип аталган җир булганга күрә генә. Бу исем Урта Азия төркләренең үзләре тарафыннан түгел, бәлки күршеләре иранлылар тарафыннан бирелгән. Бер халыкның телен шул халыкның тора торган җиренең исеме белән атау гадәте бар. Монголларга чаклы әле Урта Азиядә төрк телендәге әдәбият, яңа гына баш күтәрә башлап, чит халыкларның күзенә чалынырлык булмаган. Әмма аның кәмаләткә[3] ирешеп, фарсы әдәбияты белән ярышуы дәрәҗәсенә килеп җитүе исә XV гасырда. Бу вакытта инде Төркестанга «Чыгтай олысы»

[1] Чыгтай хан, яки Чагатай (Җагатай) хан (1185–1242) – Чыңгыз ханның икенче улы, монгол ханы. Урта Азиядә әле XV гасырда да Чыгтай олысы җирләрендә яшәүче төрки кабиләләрнең бер өлеше (җалаирлар, барласлар, каучиннар, әрләтләр, көнгрәтләр, мангытлар һ.б.) үзләрен чыгтайлар дип атыйлар. XV гасырда бу термин белән монгол яулары вакытында килгән кабиләләрне генә түгел, бәлки Мавәраэннәһердә яшәүче барлык төркиләрне атый башлыйлар. Төрки әдәби телнең тимурилар вакытында формалашкан шәрык тармагы да шушы исем белән йөртелә.

[2] Чынлыкта Чыгтай хан үзенең олысында бик аз торган. Ул үз урынына наиб куеп, күбрәк вакытны Үгедәй янында үткәрә икән. *(Авт. иск.)*

[3] Кәмаләткә – камиллек, тулылык.

дигән ат тагылган була. Шуңар күрә Мавәраэннәһердә мәйданга килгән әдәбият язылган телне иранлылар «чыгтай теле» дип атаганнар. Иранлылардан бу истыйлях[1] госманлыларга кереп, алар аркылы европалыларга күчеп, «чыгтай теле», «чыгтай әдәбияты» дигән тәгъбирләр гомумиләшеп киткән. Урта Азия төркләре исә үзләре телләрен чыгтай теле дип йөртмәгәннәр һәм йөртмиләр, төрки теле дип атыйлар. Борынгы әдипләре дә телләрен чыгтайча дип түгел, бәлки төрки, төркичә, хәтта уйгурча дип исемләгәннәр. Төркләр хәтта ватаннарын да Чыгтай олысы дип атамаганнар. Мөселман булган төркләр тарафыннан үзе буддист, мәҗүс булып, шуның өстенә җирле халыкка һәртөрле кысынкылыклар ясаган монгол ханына ул кадәр мәхәббәтнең булуы, әлбәттә, мөмкин дә түгел. Шулай итеп Урта Азия әдәбиятына «чыгтай» исеменең тагылуы – бары иттифакый[2] булган бер эш[3].

«Чыгтай теле» аталган тел ул – Урта Азиядә яшәгән аерым бер төрк кабиләсенең сөйләшү теле түгел, бәлки язу өчен махсус булган бер әдәби тел. Радлов таснифы[4] буенча, ул Урта Азия төрк телләренә керә[5]. Ул һәм төзелеш, һәм лөгать ягыннан хәзерге гарби Төркестан вә Бохарада яшәүче төркләрнең телләренә бик якын. Ләкин һәрбер әдәби тел шикелле, чыгтай теле дә аларның гади сөйләү телләренә караганда бераз башкарак һәм үз заманында да җирле төркләрнең сөйләү телләренә караганда беркадәр аермалы булгандыр. Ул борынгы әдәби уйгур теле өстенә башка яңа төрк телләренең катлаулануыннан хасил булган. Әдәби чыгтай теленең иң көчле гонсыры[6],

---

[1] Истыйлях – атама, термин.
[2] Иттифакый – очраклы.
[3] Вамбери А. История Бухары. Ч. I. *(Авт. иск.)*
[4] Таснифы – төркемләве, классификациясе.
[5] 1923 елгы «Мәгариф» журналының 15–16 (5–6) номерында Г. Рәхимнең «Төрк телләренең таснифе...» дигән мәкаләсен карагыз. *(Авт. иск.)*
[6] Гонсыры – элементы, состав өлеше.

әлбәттә, хәзерге үзбәкчәгә якын булган, төп Мавәраэннәһер төркләренең теле дип хисапланырга тиеш[1].

Үзенең җиде-сигез гасырлык дәверендә чыгтай теле үзгәрешсез генә калмаган. Бер яктан, ул заманына карап үзгәрсә, икенче яктан, аерым язучыларның торган урыннарына һәм мәнсүб[2] булган кабиләләренә карап үзгәргән. Иң элек, һәрбер әдәби тел шикелле, чыгтай теле дә үзенең ифрат мөхафәзәкярлегенә[3], иске сүз вә формаларны сакларга яратуына карамый, заманының үтүе белән, акрын-акрын халыкның сөйләшә торган теленә якынлаша. Мәсәлән, XII, хәтта XIII гасырларда яралган чыгтай әсәрләре (Робгузи) тел ягыннан уйгур теленә якынрак. Аларда уйгур әдәби теленең, уйгур әдәби ганганәсенең[4] тәэсире күбрәк сизелә. Мәсәлән, Робгузиның шушы сәтрларын[5] алыгыз:

Алчак умул тузун кылыйк,
Билик аригъ хәддин чыка.
Күкдин әдизрәк һиммәте –
Ирдәмләре егламак тәлим.
Үз сүзләйүр сүзне ука
Артуг ераглык сирәте.

Гомумән, чыгтай әдәбиятын бөтенләй аерым рәвештә үзлегеннән генә тәрәккый итеп мәйданга килгән дип уйларга тиеш түгел. Ул борынгы төрк әдәбиятына өзелмәслек җепләр белән бәйләнгән, ул – шуның табигый дәвамы да. Хәтта XV гасыр чыгтай әдипләре дә үзләренең яза торган телләрен «уйгур теле» дип атаудан качмаганнар. Нәваи, үзенең бер әсәрендә XV гасыр

---

[1] XVI гасырга кадәр Мавәраэннәһернең төп халкы «үзбәк» аталмаган, бәлки Шәйбани хан белән килгән үзбәкләр, җиңүчеләр сыйфаты белән үз исемнәрен җиңгән халыкка тагып, үзләре шуларга катышып, эреп киткәннәр булырга кирәк (нәкъ Идел буе төркләренең «татар» аталып китүе төсле). «Сарт» дип Урта Азия төркләре электән үк иранлыларны атаганнар. Иран тәэсиренә бирелеп, фарсыча сөйләшүче шәһәр халкын да «сарт» дип атау шәигъ булып киткән. *(Авт. иск.)*

[2] Мәнсүб – караган.

[3] Мөхафәзәкярлегенә – үз-үзен саклауга омтылуына.

[4] Ганганә – сүзләрнең бер телдән икенчесенә күчеше.

[5] Сәтрларын – шигъри юлларын.

чыгтай шагыйрьләре Сәккакый[1] вә Лотфи[2] хакында сөйләгәндә, аларны «уйгур гыйбарәтенең фәсахәседин вә төрк әлфазының бәләгаседин»[3] дип сыйфатлый[4].

Соңгы гасырларда язылган әсәрләр тел ягыннан борынгы дәвер әсәрләреннән шактый аерылалар. Алар хәзерге үзбәкчәгә тартымрак. Борынгырак чыгтай әдәбиятының теле сафрак, төркчәрәк. XV гасыр әдәбиятының теле исә бөтенләй гарәп-фарсы сүзләре белән тулган, әҗнәбилек тәэсиренә[5] бирелгән.

Аннан соң бер үк заманда язылган әсәрләрнең телләрендә дә бәгъзан[6] аерма табарга мөмкин, чөнки әдәби тел гомуммилләт өчен бер булса да, мөхәррирнең кай җирлек булуы, нинди шивә белән сөйләшүе аның яза торган теленә тәэсирсез калмый. Мәсәлән, бер үк гасырда Мавәраэннәһердә, Фәрганәдә, Харәземдә һәм Кашгарда язылган әсәрләр арасында тел ягыннан беркадәр аермалар табарга мөмкин. Бу – әлбәттә, артык әһәмиятсез кабиләчелек (провинциализм) мәсьәләләре генә. (Бер хивалы тарафыннан язылган әсәрләрдә төрекмән шивәсенең тәэсире булуы шикелле.) Ләкин Мавәраэннәһердән булмаган кайбер язучылар үзләренең чыгтай теленә башка булучылыгын да дәгъва иткәлиләр. Мәсәлән, хивалы мөәррих[7] Әбелгазый үзенең «Шәҗәрәи төрки»сендә[8] теленең «чыгтай теле» түгеллеген,

[1] Сәккакый – XV гасырның беренче яртысында яшәгән үзбәк шагыйре. Сәмәркандта Хәлил-солтан (1405–1409) һәм Улугбәк (1409–1449) идарә иткән елларда таныла.

[2] Лотфи (1366/1367–1465/1466) – үзбәк шагыйре. Безнең көннәргә «Гөл-и Нәүрүз» (1411–1412) поэмасы һәм шигырьләр диваны килеп җиткән.

[3] Уйгур гыйбарәтенең фәсахәседин вә төрк әлфазының бәләгаседин – уйгур сүзенең төзеклеген һәм төрк сүзенең матурлыгын [үзләштергән шагыйрьләр]. *(Авт. иск.)*

[4] Вәлиди Зәки. Лотфи һәм аның диваны. Б. 37. *(Авт. иск.)*

[5] Әҗнәбилек тәэсиренә – чит телләрнең йогынтысына.

[6] Бәгъзан – кайчак.

[7] Мөәррих – тарихчы.

[8] Әбелгазый Баһадир хан, Әбел Гази, Әбү әл-Гази Баһадур хан (1603–1664) – Хива ханы, тарихчы буларак танылу алган. Ике зур тарихи хезмәте бар: «Шәҗәрәи төрекмән» (1661) һәм «Шәҗәрәи төрк» (1852 елда Казанда басыла). Гомеренең ахырында үзбәк телендә Чыңгыз нәселе һәм Шәйбан нәселе тарихы хакында китап яза башлаган була.

бәлки «төрк теле» икәнлеген ачыктан-ачыкка сөйли, ләкин кайбер тикшерүчеләр каршында Әбелгазый теле гомумчыгтай теленнән күзгә бәрелерлек аерылмый. Ихтимал ки, монда мәсьәлә мәхәлли[1] шивә һәм тәләффыз[2] мәсьәләләренә генә кайтып кала торгандыр[3]. Һәрхәлдә, мәсьүлиятле[4] бер эш булса да, без бөтен Урта Азия әдәбиятын, утырган гадәт буенча, «чыгтай әдәбияты», телен дә «чыгтай теле» дип йөртәчәкбез. Гомумән караганда, чыгтай әдәби теле шивә ягыннан хәзергә кадәр кирәгенчә тикшерелмәгән, төпле тәфтишләргә мохтаҗ әле.

Сафлык җәһәтенә килгәндә чыгтай теле, гомумән, XV гасырдагы әдәби тел, хосусан, гарәп-фарсы телләренең тәэсиренә бирелгән. Бу яктан аны Орхон язуларының теле белән генә түгел, хәтта «Котадгу белег» теле белән дә чагыштыру мөмкин түгел. Иң борынгы чыгтай әсәрләрендә дә без гарәпчә тәэсиренең бик зур булганын күрәбез. Фарсы теле исә чыгтай телен XV гасырларга таба баса башлый. Бу заманда чыгтай шагыйрьләре Иран әдәбиятына мөкиббән китеп, бөек Иран шагыйрьләренә тәкълид кылырга[5] тотыналар. Әдәби формалар, фикерләр белән бергә фарсы теле дә истигъмальгә[6] керә. Мавәраэннәһердә иранлык тәэсиренең элеккедән үк куәтле булуы моңар юл ача. «Алтын гасыр»дагы чыгтай әдипләре фарсы телен дә үз ана телләре шикелле яхшы беләләр: ике телдә дә шигырьләр язалар. Шулай итеп, бер яктан, дин тәэсире аркылы төрк теленә гарәп сүзләре кереп тулса, икенче яктан, мәдәни тәэсир аркылы фарсы теле аны баса. Әҗнәби[7] сүзләр белән кирәгеннән артык чуарлануда чыгтай телен госманлы әдәби теле белән генә тиңләштерергә мөмкин. Чыгтай әдипләре каршында, госманлылардагы шикел-

---

[1] Мәхәлли – җирле.

[2] Тәләффыз – сөйләм, сүзнең әйтелеше.

[3] Самойлович аның телен «чыгтайча түгел, бәлки чыгтайлашкан үзбәкчә», ди. [Самойлович А.Н.] Некоторые дополнения к классификации турецких языков. *(Авт. иск.)*

[4] Мәсьүлиятле – җаваплы.

[5] Тәкълид кылырга – иярергә.

[6] Истигъмальгә – кулланылышка.

[7] Әҗнәби – чит, ят.

ле үк, гарәби, фарси сүзләр, гыйбарәләр катыштыру бер төрле фазыйләт[1] хисаплана башлаган. Бу бигрәк тә шигырь бабында шулай булган. Шагыйрьнең теле никадәр аңларга авыр булса, никадәр өслүб чуалчык булса, шигырь шулкадәр шәп исәпләнгән. Халыкның сөйләшә торган теле әдипләр тарафыннан тупас тел, урам теле саналып, әдәби телне аңар якынлаштыру – кимчелек, халык телендә язу – тупаслык, түбәнлек, гомумән, мөмкин түгел бер эш дип игътикад ителгән[2]. Чит лөгатьләр, аерым сүзләр тутыру белән генә дә канәгатьләнмичә, гыйбарәләрне, тәркибләрне[3] дә гарәпчә, фарсыча ясый башлаганнар. Хәтта нәхәви[4] яктан, җөмлә төзелешләре җәһәтеннән дә фарсы теле төрк әдәби телләренә тәэсир ясаган. Менә шуның өчен дә чыгтай әдәбияты, госманлы әдәбияты шикелле, халыктан ерак булып калган. Гади халык аны аңламый, аңласа да бик читенлек белән аңлый, чөнки аны аңлар өчен, үз ана телеңнән башка бик яхшы итеп гарәп һәм фарсы телләрен белү лязим булып төшә.

Сүзебезне исбат өчен Нәваинең бер диванынннан алынган шушы берничә юл шигырьне китерү җитә дип беләбез:

Әшракат мин гакси шәмсел-кәэси әнварел-һади[5]
Йар гаксен мәйдә күр дип җамдин чыкды сада.
Гайр нәкъшидин күңел җамида булса рәнк гам,
Юктыр әй, сакый, вәхдәтә мисле лик гамзәда.

Таки ул мәйдин күңел җамида булгач җәлу кәр,
Чәһрәи максуд маху улгай һәм ул дәм магада.
Вәхдәте булгай мәйсәрме пилә җам эчра кем,
Җамми лафзын дигән бер исем илә кылгай әда.

Әлхасыйль[6], чыгтай әдәбияты үзенең иң югары ашкан дәверендә хәвас (аристократия) әдәбияты булып киткән. Дәрвакыйг[7],

[1] Фазыйләт – яхшы эш.
[2] Игътикад ителгән – ышанылган.
[3] Тәркибләрне – сүз тезмәләрен.
[4] Нәхәви – грамматик.
[5] Бу шигырьнең беренче юлы бөтенләй бер гарәпчә җөмләдән гыйбарәт. *(Авт. иск.)*
[6] Әлхасыйль – җыеп әйткәндә.
[7] Дәрвакыйг – дөрестән дә.

ул – чын-чын сыйнфый характерда булган бер әдәбият. Кирәк тел, кирәк төп фикер-идея ягыннан булсын, чыгтай әдәбиятының классик шагыйрьләре халыктан ерак булганнар. Алар күбесенчә берәр зур дәрәҗәле кешенең (патшаның, әмирнең, бикнең) сараенда, аның химаясендә «сарай шагыйре» булып яшәп, шул югары сыйныфта мәкъбүл булган тарызда[1] һәм шуларга гына аңлашылырдай әдәби телдә язганнар. Халык гаммәсе[2] аларны аңлый алмаган һәм, табигый, укымаган. Бары югары, зыялы, укымышлы сыйныф өчен генә алар аңлашылган, шулар гына аларның әсәрләрен укып ләззәтләнә алганнар. Түбән сыйныф халыклар, ярлылар вә диһканнар[3] өчен нәфис әдәбият капкасы ябык булган. Алар, тик бары бер такым хорафи-дини рисаләләр, догалыклар шикелле чүп-чар гына укып, миләрен агулаганнар. Тәсаувыф әдәбиятыннан да халык арасына бары Ясәвинең «Диване хикмәт» шикелле саф, садә вә җиңел тел белән язылган әйберләре генә керә алган.

Чыгтай әдәбиятының икенче ягына килгәндә, ул – тәмамән ислам Шәркының әдәбиятлары тәэсирендә мәйданга килгән тәкълиди[4] бер әдәбият. Без, аны дикъкатьләп тикшерә башласак, үзенә генә махсус булган аермаларны анда бер дә диярлек таба алмыйбыз. Чыгтай әдәбияты, хосусан, аның XV гасыр дәвере, бөтенләй Иран әдәбияты тәэсирендә тора: бер үк формалар, бер үк гадәтләр, бер үк фикер вә идеяләр анда да, монда да бертөрле хөкем сөрәләр.

Чыгтай әдәбиятындагы әсәрләрне мөндәриҗә[5] ягыннан тарихи, әхлакый, дини вә шигъри дип берничә төргә бүләргә мөмкин.

Тарихи әсәрләр чыгтай әдәбиятында бик күп. Аларның бәгъзылары, мәсәлән, мәшһүр Әбелгазый Баһадур ханның «Шәҗәрәи төрки»се Урта Азия тарихын язучылар өчен иң кыйммәтле

---

[1] Мәкъбүл булган тарызда – кабул ителгән рәвештә.
[2] Гаммәсе – массасы.
[3] Диһканнар – крестьяннар.
[4] Тәкълиди – ияреп язылган.
[5] Мөндәриҗә – эчтәлек.

мәнбәгъләрдән[1] хисаплана. Чыгтай мөәррихләренең[2] тоткан юллары чын шәрыкчә: алар тарихны, гадәттә, дөнья яратылудан, Адәм пәйгамбәрдән башлап китеп, элек Коръән буенча бөтен тарихи мөкаддәсне[3] сөйләп чыгалар. Аннан Мөхәммәд пәйгамбәргә, исламның зоһурына[4], беренче хәлифәләргә, ислам мәмләкәтләренең тарихларына күчәләр. Аннан соң гына нәүбәт төрк халыкларының тарихына килеп җитә. Менә бу – гомумшәрык, мөселман тарихчыларының «тарихе гомуми» язганда тоткан юллары. Тарихе әнбия[5], Коръәндә зикер ителгәнгә күрә, алар тарафыннан хакыйкый тарихи фактлар белән бер рәттә сөйләнә; исламият вә ислам хәлифәләренең тарихларын сөйләгәндә дә, чыгтай мөәррихләре үзләренә кадәр язылган гарәп вә фарсы телендәге тарихлардагы хәбәрләрне тәнкыйтьсез-нисез, үзгәртмичә тәкрар итүдән[6] уза алмыйлар. Яурупа тарихы, шулай ук мөселман булмаган халыкларның тарихы алар әтрафыннан бөтенләй әһәмиятсез нәрсә шикелле читтә калдырыла. Бары төрк-магул тарихына килеп җиткәч кенә, чыгтай тарихларында мөһим, оригинальный мәгълүмат табыла башлый. Гәрчә алар, төрк тарихын Нух пәйгамбәрнең углы Яфәстән башласалар да, әсәрләренең шушы кыйсемендә генә тарих гыйлеме өчен кыйммәтле мәгълүмат бирәләр. Әгәр дә алар инде үз заманнарындагы вакыйгалардан хәбәр бирсәләр, ул хәбәрләр беренче мәнбәгъ булу ягыннан тарихчылар өчен тагын зуррак әһәмияткә малик[7] булалар. Урта Азиядә хөкем сөргән төрк вә монгол хөкемдарларында, гомумшәрыктагы шикелле, хозурларында тарихчы – вәкаганәвец[8] тотып, үзләренең вә салаларының тарихын яздыру гадәте булган. Ханнар вә әмирләр, үзләренең

[1] Мәнбәгъләрдән – чыганаклардан.
[2] Мөәррихләренең – тарихчыларының.
[3] Тарихи мөкаддәсне – иң мөһим тарихи вакыйгаларны.
[4] Зоһурына – килеп чыгуына.
[5] Тарихе әнбия – пәйгамбәрләр тарихы.
[6] Тәкрар итүдән – кабатлаудан.
[7] Малик – ия.
[8] Вәкаганәвец – елъязмачы, тарихи вакыйгаларны язып баручы.

ата-бабаларының эшләгән эшләрен киләчәк буыннарга белдерү өчен, мөмкин кадәр шәп тарих язучыларны сарайларына җәлеп кылып, аларга язган әсәрләре өчен күп акчалар түли торган булганнар. Хива ханы Әбелгазый шикелле үзләре тарих язган хөкемдарлар да булгалаган. Шулай итеп, ханнарның, патшаларның шөһрәт сөюләре аркасында чыгтай әдәбиятында байтак кына тарихи әсәрләр мәйданга килгән. Тарихи әдәбиятны өйрәнү безнең асыл максатыбыздан тыш булганга, без бу мәкаләдә аерым тарих язучыларга вә аерым китапларга тукталмыйбыз. Шулай ук безнең алган даирәбездән тыш та булганга, дини вә әхлакый әсәрләргә дә кагылмыйбыз. Билгеле, ислам дөньясында әхлак дин белән бик нык баглы булып, дини әсәрләр белән әхлакый вә фәлсәфи әсәрләрне бер-берсеннән аеру да читен. Бу нәүгъ[1] әсәрләр һәммәсе гомумислам Шәркына махсус булган калыпта язылганнар.

Чыгтай әдәбиятыннан безнең өчен иң әһәмиятле булганы – аның шигъри кыйсеме. Гәрчә, югарыда әйтелгәнчә, чыгтай әдәбиятының бу кыйсеме дә тәкълиди[2] булса да, нәфис әдәбият бабында Урта Азия дөньяга байтак бөек әдипләр, зур истигъдадлы[3] төрк шагыйрьләре тудырды. Чыгтай әдәбиятында булган шигъри әсәрләрне түбәндәге типларга бүләргә мөмкин: 1) тарихи поэма, яки «Шаһнамә»[4] тибындагы каһарман поэмасы (Шаһзадә Мөхәммәд Салихның «Шәйбанинамә»се күк);

[1] Нәүгъ – төр.

[2] Тәкълиди – ияреп язылган.

[3] Истигъдадлы – сәләтле.

[4] Шаһнамә («Шаһлар китабы») – Иранның мәшһүр шагыйре Әбелкасыйм Фирдәүси (930–1020) әсәре. Анда фарсы телендә Иранның иң борынгы тарихыннан алып, VII гасырда ислам дине урнашуга кадәр вакыйгалар тасвирлана.

«Шаһлар китабы»дигән исем белән төрле дәверләрдә төрле авторлар язган әсәрләрне атау кабул ителгән. Шәриф Амиди тәрҗемә иткән «Төрки Шаһнамә» (1501–1510) китабы төрки халыклар арасында киң таралган була. Бу очракта автор аны каһарман китапларына, ханнар династияләре тарихларына мисал итеп китерә, чыгтай әдәбиятындагы Шәйбаннар династиясе тарихын телгә ала.

2) гыйшкый поэма (Нәваинең «Фәрхад вә Ширин», «Мәҗнүн вә Ләйлә»ләре шикелле[1]; 3) диваннар, ягъни вак хисси шигырьләр (лирика) мәҗмугалары; 4) гыйбрәтле хикәяләр мәҗмугасы (Иран шагыйре Фәридеддин Гаттарның «Бәхтиярнамә»сенең тәрҗемәсе[2], Сөһәйленең «Кәлилә вә Димнә»[3] тәрҗемәсе шикелле); 5) мәснәвиләр, ягъни күбесенчә шигырь белән язылган, һәр кыйссадан хисса чыгарылган гыйбрәтле хикәяләр мәҗмугасы (бәгъзан мәснәвиләрдә көйле кисәкләр көйсезләр белән аралаш була). Шигъри әсәрләр белән нәсери[4] әсәрләр арасындарак тора торган тагын бер нәүгъ китаплар бар ки, аларда бәгъзан бик матур вә шигъри рәвештә пәйгамбәрләрнең вә изгеләрнең тормышлары тасвир ителгән була. Робгузиның «Кыйссас әл-әнбия»се, «Тәзкирәи әүлия», «Мигъраҗнамә» шикелле әсәрләр шул җөмләдән.

Гомумән, шәрыктагы шикелле, чыгтай әдәбиятында да назым белән язу таралган эш булган. Шигъри әсәрләрнең күбесе көй белән язылып кына калмый, һич шигырь белән мөнәсәбәте булмаган, мәсәлән, халис[5] дини китаплар да күп вакыт назым белән язылганнар. Шигырьдә күбесенчә гарәп-фарсы вәзеннәре

---

[1] Биредә автор мәхәббәт дастаннарын аерып чыгара. Мир Низаметдин Гыясетдин Галишир Нәваинең (1441–1501) «Хәмсә»сенә кергән ике поэмасы моңа мисал итеп китерелә. «Ләйлә вә Мәҗнүн» (1484) – традицион сюжетка корылган мәхәббәт тарихы, биредә хатын-кызның үз бәхете өчен көрәше чагылыш таба. «Фәрһад вә Ширин» (1484) мәхәббәтнең дини, милли тыюларны, чикләүләрне белмәвен ассызыклый.

[2] Шәйх Фәридеддин Мөхәммәд бине Ибраһим Гаттар – XII гасыр суфи шагыйре, күпсанлы поэмалар һәм шигырьләр авторы.

[3] «Кәлилә вә Димнә» – урта гасырлар фарсы, гарәп телләрендә язылган һәм борынгы һинд китабы «Панчатантра»дан тәрҗемә, шәрех булган әсәр. VI гасырда төп геройлар ике шакал исеме белән «Кәлилә вә Димнә» буларак фарсы теленә тәрҗемә ителә. VIII гасырда мөселманнар арасында гарәп теленә күпсанлы тәрҗемәләрдә тарала. Автор, «Сөһәйленең» дигәндә, «Панчатантра»дан тәрҗемә рәвешендә төзелгән «Әнваре Сөһәйли» әсәрен (төзүчесе – Хөсәен Вагыйз Кәшифи) күз уңында тота.

[4] Нәсери – чәчмә, проза белән язылган.

[5] Халис – саф.

истигъмаль ителгән[1]. «Тоюг»[2] аталган дүрт юллы шигырьләрнең генә вәзене милли төрк вәзененә туры килә. Шигырьдә истигъмаль ителгән формаларда шәрык әдәбиятлары өчен уртак булган калыплар: касыйдәләр, газәлләр, мәснәвиләр, кыйтгалар, робагыйлар, фәрдләр вә башкалар[3], хисси шигырьләр (лирика) диваннарга[4] җыелган. Шәрык гадәтенчә, диванга кергән шигырьләр бәгъзан кафияләренең[5] ахыргы хәрефләре игътибарынча, әлифба тәртибе белән төзелгәннәр, һәрбер аерым шигырьнең ахырлары мәгълүм бер хәрефкә генә бетә торган булган. Шигырьнең һәрбер мисрагын бер үк сүз, хәтта җөмлә белән тәмам итү – бик шаигъ[6] булган бер гадәт икән. Һәрбер шигырьнең ахыргы юлына шагыйрь үзенең исемен кыстыру да гадәт булган. Бу исә шәрык әдәбиятында имза урынына тора.

Чыгтай лирикасы тәмамән тәсаувыф идеяләренә манчылган. Мәгълүм ки, X гасырдан алып XV гасырга кадәр булган 500 еллык дәвер Иран әдәбиятының иң югары ноктага күтәрелгән «алтын дәвере» хисаплана. Бөек Иран шагыйрьләре шушы 500 ел эчендә килгәннәр. «Алтын дәвер»нең соңгы шагыйрьләреннән Җами[7] – Тимер белән замандаш булган һәм аның химаясендә яшәгән. Мәшһүр тәсаувыф лирикасы шул гасырларда мәйданга килеп тәкәммел иткән[8]. Дөньяга караш вә әдәби гадәт (тради-

[1] Истигъмаль ителгән – файдаланылган.

[2] Тоюг – төрки әдәбиятлардагы лирик жанр, борынгы төрки халык лирикасы формаларына барып тоташа. Бер үк төрле үлчәмдә язылган дүрт юллык шигырь – гарузда, ешрак *ааба*, кайчак *абвб*, *аааа* үлчәмнәрендә. Төп үзенчәлеге – омоним рифмаларда. Төрки шагыйрьләр иҗатында XIV гасырдан очрый. Поэтик күренеш буларак, Нәваи тарафыннан «Мизан әл-әүзан»да, Бабурның «Гарузнамә»сендә тасвирлана.

[3] Касыйдә – җитдирәк мәүзугда озынрак шигырь. Газәл – күбрәк гыйшкый мәүзугда булган кечерәк шигырь. Робагый – һәртөрле мәүзугта дүрт юллы шигырь. Фәрд – ике мисраглы шигырь. *(Авт. иск.)*

[4] Диван – шигъри җыентык.

[5] Кафияләренең – рифмаларының.

[6] Шаигъ – киң билгеле.

[7] Габдрахман Җами – Нуреддин Габдеррахман ибн Әхмәд Җами (1414–1492), фарсы телендә иҗат иткән күренекле шагыйрь, философ.

[8] Тәкәммел иткән – камилләшкән, үскән.

цияләр) мәсьәләсендә дә чыгтай шагыйрьләре үзләренең бөек остазлары артыннан киткәннәр: тәсаувыф юлында күп гүзәл әсәрләр иҗат иткәннәр. Тәсаувыф вә аның әдәбиятта ингыйкясе[1] мәсьәләсенә бу китапта аерым тукталган булганга, бу хакта тәфсилгә керешергә хаҗәт күрмибез.

Чыгтай әдәбиятының борынгы дәвереннән, ягъни XII, XIII, XIV гасырлардан бик аз әсәрләр сакланып калган. Бу гасырларда әле чыгтай әдәбияты үзе шулай зәгыйфь вә ярлы булганмы, әллә бу заманда язылган әйберләрнең күбрәге югалып беткәнме, һәрхәлдә, бу өч гасыр эчендә килгән чыгтай язучыларын бармак белән санарга мөмкин. Тимер дәверенә кадәр Урта Азия төркләрендә мәдәният тә түбәнрәк дәрәҗәдә булган шикелле, төрк телендәге әдәбият та әле балалык дәверен кичергән.

Иң борынгы чыгтай шагыйрьләреннән Хуҗа Әхмәд Ясәви[2] белән аның шәкертләреннән булган бер группа шагыйрьләрне искә алып узарга кирәк. Безнең татарларга бик мәгълүм Сөләйман Бакыргани[3] да шулар арасына керә. Алар XII гасыр кешеләре булып, [иҗатлары] чын тәсаувыф идеяләре белән тулган. Телләре садә, өслүбләре ачык, шуңар күрә әсәрләре халык өчен аңларлык. Шул сәбәптән Ясәвинең «Диване хикмәт» исемле, Бакырганиның «Бакырган», «Ахырзаман», «Хәзрәте Мәрьям» исемле китаплары безнең Идел буена да барып чыгып, татарлар арасында иң таралган китаплардан булып киткәннәр. Шулай ук татар арасында таралган «Кыйссас әл-әнбия»не язучы

---

[1] Ингыйкясе – чагылышы.

[2] Әхмәд Ясәви (Хуҗа Әхмәд, Кол Әхмәд) – XI гасырның икенче яртысы суфи шагыйре. Бохарада бөтен мөселман дөньясының мәшһүр рухание Йосыф Хәмадәнинең шәкерте була. Остазы үлгәч, аның урынына шәех, суфилар башлыгы булып кала. Әдәбиятта үзенең «Диване хикмәт» тупланмасы белән мәшһүр. Казан басмаларында аның күләме 300 биткә якын. Җыентыкта төрле зурлыктагы 135 шигъри әсәр бар.

[3] Сөләйман Бакыргани (Хәким Ата, Кол Сөләйман) – Әхмәд Ясәвинең шәкерте. Гомеренең зур өлешен Харәземдәге Бакырган төбәгендә уздыра һәм 1186 елда шунда ук вафат та була. Шагыйрь әсәрләренең төп өлеше «Бакырган китабы» дип исемләнгән җыентыкта тупланган.

Насреддин Робгузи[1] да – борынгы чыгтай әдипләреннән (XIII гасыр белән XIV гасыр арасында яшәгән). Бу язучылар вә аларның әсәрләре хакында киләчәктә, Идел буе татарларының чыгтай әдәбиятыннан алган әсәрләрен тикшергәндә тәфсыйлән[2] сөйләнәчәк булганга, хәзергә шуның белән канәгатьләнербез.

Чыгтай әдәбиятының чәчәкле, иң парлак дәвере, яурупача әйткәндә, аның «алтын гасыры» XV гасырга, Мавәраэннәһердә Аксак Тимер нәселе хөкем сөргән заманга туры килә. Искергән, какшаган Чыңгыз балаларының хакимиятен җимереп, аның урынына Тимер үзенең фәгалият[3] белән тулган Тимер хакимиятен утырту белән, Төркестанның мәдәни тормышы да өр-яңа бер юл алып күтәрелеп китә. Муаффәкыятьле[4] сугышлар һәм оста йөртелгән империализм сәясәте аркасында Төркестан икътисади байлык ягыннан кинәт алга сикерә. Чит илләрдән көчләп күчерелгән һөнәрмәнд[5] вә осталар, моңар кадәр күрелмәгән рәвештә, техниканың алга китүенә сәбәпче булалар. Сугыш вә җиңү, кул астына алу аркасында чит илләрдән мәркәзгә аккан матди байлык моңар имкян бирә. Бик тиз арада бөтен Төркестан искиткеч нәзакәт белән эшләнгән мигъмар әсәрләре, сарайлар, мәчетләр, мәдрәсәләр, кәрвансарайлар, ханәкалар, мунчалар, күперләр белән тула. Калдыклары хәзердә дә яурупаларны мәфтун иткән[6] искиткеч гүзәл шәрык тарзы мигъмарисе[7], мәшһүр «Төркестан стиле» шушы дәвердә мәйдан алып китә, эшләнә, тәрәккый итә. Ярым гасырлык өзлексез солых вә тынычлык игенче, бакчачы диһканга да рәхәтләнеп эшләргә,

---

[1] Насреддин бине Борһанеддин улы Рабгузи XIII йөздәге Рабат Угызда казый булып тора, аннары Мавәраэннәһернең үзәгенә күчеп китә. Кулъязма күчермәләр рәвешендә татарлар арасында киң таралган «Кыйссас әл-әнбия» («Пәйгамбәрләр турында кыйссалар», 1310–1311) исемле дини әсәр авторы.

[2] Тәфсыйлән – җентекләп.

[3] Фәгалият – эшлеклелек.

[4] Муаффәкыятьле – уңышлы.

[5] Һөнәрмәнд – галим, белемле кеше; оста.

[6] Мәфтун иткән – сокландырган.

[7] Тарзы мигъмарисе – архитектур стиле.

үзенең сугару юлларын рәткә китерергә ирек бирә. Җир эшләү сәнәгате дә көчәя, алга китә. Тимер үлгәннән соң да, балаларының үзара бертуктаусыз сугышып, кан түгеп торуларына карамый, мәдәни дәвер һаман дәвам итә. Мәдәният һаман нечкәрә, нәзекләнә барып, югары сыйныфларның канына сеңеп, алар өчен «ля бүддә минһу»[1] бер нәрсә булып китә. Хасыйле[2], XV гасырда Мавәраэннәһер вә тирәсендә шундый парлак бер мәдәният мәйданга килә ки, бу дәверне халыкларның тормышында вакыт-вакыт кына була торган күтәренкелек дәверләре белән, мәсәлән, Юнанстанның Перикл заманы, Руманың беренче императорлар заманы, Багдадның Һарун вә Мәэмүннәр, Андалусның Габдеррәхман[3] һәм Хәкәмнәр[4] дәвере, Италиянең Ренессанс дәвере белән генә чагыштырырга мөмкин.

Мәгънәви мәдәниятнең гыйлем, фән сәнаигы нәфисә[5] вә әдәбиятның тәрәккые да һәрвакыт матди мәдәниятнең күтәрелүенә баглана. Чыгтай әдәбиятында да без шул ук хәлне күрәбез. Бу дәвердә җитешкән чыгтай шагыйрьләренең ялгыз исемнәрен санап чыгу да шактый урын алачак. Урта Азиянең иң атаклы төрк шагыйрьләре шушы йөз ел эчендә җитешкәннәр. Гомумән, мәдәниятнең күтәренке заманнарында була торганча, бу вакыт Урта Азиядә аерата әдәбият белән шөгыльләнгәннәр, аңа һәвәс иткәннәр. Әдәбият белән шөгыльләнү бу вакытта гомуми бер йогышлы чиргә әверелеп китә. Һәрбер кулына каләм тоткан кеше бу чакта шигырь язу белән шашкан, үзенә «шагыйрь» исеме алырга тырышкан. Халыкның югары табәкасы[6] белән

[1] Ля бүддә минһу – үтә кирәкле; ансыз мөмкин булмаган.

[2] Хасыйле – нәтиҗәдә.

[3] Габдеррәхман – Испаниядәге Кордова әмирлеге хәлифе Габдеррәхман III (891–961), өммәвиләр династиясе вәкиле. Тарихта мөселман Испаниясен мәдәни яктан алгарышка китергән эшләре белән мәгълүм шәхес.

[4] Хәкәм – Кордова әмирлеге хәлифе әл-Хәкәм II (тулы исеме – Әбелгазый әл-Хәкәм бине Габдеррәхман, 915–976), хәлиф Габдеррәхман III нең улы. 961–976 елларда идарә итә, атасы башлаган яңарыш сәясәтен уңышлы дәвам иттерүе белән билгеле.

[5] Сәнаигы нәфисә – нәфис сәнгать.

[6] Табәкасы – катламы.

бергә мирзалар, бикләр, әмирләр үзләре дә әдәбиятка бирелгәннәр. Тимер дә үзенең хөкүмәт төзелешенә, гаскәр вә сугыш эшләренә даир «Түзүкят-е Тимур» һәм «Мәлфузат-е Тимур»[1] аталган кануннамәләрен төрк телендә язган (хәзергә кадәр бу кануннамәләрнең фарсычага тәрҗемәсе генә сакланып калганга, без Тимернең нинди өслүб белән язганлыгын белә алмыйбыз).

Тимернең нәселе үзе, гомумән, шигырьгә, әдәбиятка бик маил[2] булган. Тимер ыругыннан килгән шагыйрьләрне саный башласак, аларның саны дистәдән артачак. Тимерның угылы һәм тәхет варисы Хәлил Мирза[3] шагыйрь кеше булган. Бу кешенең Шади Мөлек исемле матур бер җариясенә тоткан шагыйранә, ялкынлы гыйшкы телләрдә дастан булган. Хикәяләрдә генә була торган бу чиктән тыш гыйшык аңар бик күп зарар да иткән. Өстенә дошман гаскәре килгәндә дә, ул, идарә вә сугыш эшләренә кул селтәп, гүзәл мәгъшукасының итәгендә утырып, аңар багышлап газәлләр язу белән мәшгуль була икән. Дошманнары аны хибескә[4] салганнар. Мәгъшукасыннан шушы мәҗбүри аерылу вакытында ул сагышыннан үлә язган. Ахырда шагыйранә табигате, шул гыйшкы аны тәхеттән аерылырга мәҗбүр иткән. Аның тәдбирсезлеге[5] аркасында Мавәраэннәһердә башланган чуалышларны күреп, ахырда Һират тәхетендә утырган энесе Шаһрух Мирза[6], бабасының төп җирен аның кулыннан алып, үз җиренә кушкан. Гомумән,

[1] Бу урында сүз Аксак Тимернең сугыш сәнгатен тасвирлаган «Түзүкят-е Тимур» һәм аның фарсы телендәге версиясе – «Мәлфузат-е Тимур» трактатлары турында бара.

[2] Маил – һәвәс.

[3] Хәлил Мирза бине Мираншах (1384–1411) – Аксак Тимернең оныгы. 1404 елда җариясе Шади Мөлеккә өйләнә. 1405–1409 елларда Сәмәркандта идарәче. Энесе Шаһрух белән сугышта җиңелә, кулга алына, тәхеттән баш тарта. Сөргендә үлә. Төрки телдә язылган романтик рухлы шигырьләре белән мәшһүр.

[4] Хибескә салганнар – кулга алганнар, зинданга салганнар.

[5] Тәдбирсезлеге – эшне уйлап эшләмәве; чара күрмәве.

[6] Шаһрух Мирза (1377–1447) – Аксак Тимернең кече улы. Атасы үлгәннән соң, хакимлек өчен көрәштә Хәлил солтан белән бәрелешә, аны җиңеп, Хорасан белән Сәмәркандны куша. Мәвараэннәһердә идарәне улы Олугбәккә тапшыра.

бу заман шигърият вә нәзек хисләр заманы булган. Тимер балаларыннан аның улы Шаһрух, туруны Байсынкар Мирза, аның углы Әбелкасыйм Бабур Мирза, Хөсәен Байкара, Солтан Искәндәр Ширази, Сәид Әхмәд Мирза, мәшһүр Бабур Мирза – һәммәсе шагыйрь кешеләр булганнар. Нәваи үзенең «Мәҗалис ән-нәфаис»ендә[1] байтак чыгтай шагыйрьләренең тәрҗемәи хәлләрен сөйли, Солтан Бабур да «Бабурнамә»дә байтак шагыйрьләрне телгә ала. Нәваи, Лотфи, Сәккакый, Һилали, Әһли, Бинаи, Сөһәйли, Мирхәйдәр Харәзми, Бабур Мирза шикелле затлар XV гасыр шагыйрьләренең иң мәшһүрләреннән саналсалар җаиз[2].

XV гасырда килгән чыгтай шагыйрьләренең иң олысы һәм иң атаклысы – һич шөбһәсез, Мир Галишир Нәваидер. Ул, бик хаклы буларак, һәм замандашлары, һәм үзеннән соң килгәннәр тарафыннан иң югары урынга куелып, чыгтай әдәбиятының атасы дип хисапланган. Чынлап та, Нәваи – Урта Азиянең «алтын гасыр» әдәбияты өчен классик бер язучы. Ул үз заманында да, үзеннән соң да бик күп тәкълидчеләрнең[3] мәйданга килүенә сәбәп булган. Галишир үзенең ватанында гына түгел, хәтта госманлыларда да шулай ук шөһрәтле, шулай ук рәгъбәт[4] белән укыла. Госманлыларның үз шагыйрьләре белән бер дәрәҗәдә ихтирам ителә. Нәваинең байтак әсәрләре «Көллият Нәваи» исеме астында бер мәҗмугага җыелган хәлдә йөри.

Нәваи 1440 елда Һират шәһәрендә туган. Аның атасы Солтан Әбүсәгыйднең сараенда зур мәнсаб[5] иясе булган. Ул углы Галиширгә яхшы тәрбия биргән. Галишир үзенең яшьлеген Мәшһәдтә Әбелкасыйм Бабирның сараенда уздырган. Аннан ул кире Һиратка, аннан соң Сәмәркандка күчкән. Тимер нәселеннән килгән мәшһүр хөкемдарлардан Хөсәен Байкара белән

[1] Сүз Галишир Нәваинең «Мәҗалис ән-нәфаис» («Зәвыклылар турында тупланма», 1491–1492) дигән замандаш шагыйрьләргә багышланган җыентыгы турында бара.

[2] Җаиз – дөрес, яраклы.

[3] Тәкълидчеләрнең – үзенә ияреп язучыларның.

[4] Рәгъбәт – теләү, омтылыш.

[5] Мәнсаб – дәүләт хезмәте; эш урыны.

мәктәп иптәшләре булганга, алар арасында дуслык зур булган. 1468 елларда Хөсәен Байкара, аны яңадан Һиратка чакыртып алып, үз янында бөек бер мәнсаб, әмирлек (баш вәзир) мәнсабы бирә. Нәваи, гаять зур истигъдадка малик[1] бер шагыйрь булуы белән бергә, шулай ук мөстәгыйд[2] бер хөкүмәт кешесе дә булган. Мәмләкәт идарәсе эшләрендә ул үзен бик яхшы яктан таныткан. Ләкин табган[3] шагыйрь вә тәсаувыфка маил[4] кеше булганга, ул, хөкүмәт башында торуга караганда, дөнья эшләреннән, һәртөрле сарай интригаларыннан читтә, әдәбият белән генә шөгыльләнеп, тынычлыкта, гозләттә[5] яшәүне артык күргән. Сарайда калырга теләмәгәч, Астрабадка вәли[6] итеп җибәрелсә дә, ул анда да кала алмаган. Шуңар күрә ул, тизлектә хөкүмәт хезмәтеннән ваз кичеп, үзенең сөйгән Сәмәркандына кайтып киткән. Ләкин Байкараның кат-кат үтенеп чакыруы аркасында, аңар әле, үз гомерендә яңадан берничә тапкыр Һират сараена килеп, чуалган идарә эшләрен җайга салып бирергә туры килгән. Нәваи, ахыр гомерен гозләттә үткәреп, 1500 елда алтмыш яшендә вафат булган[7]. Үзенең гомере хакында Нәваи бер шигырендә:

Киһи[8] табдым фәләкдән натәванлык[9], киһи күрдем
заманда кямранлык,[10]
Биси[11] эссик-савык[12] күрдем заманда, биси ачиг чүчүк
татыдым җиһанда, –

ди.

---

[1] Истигъдадка малик – сәләткә, зирәклеккә ия.
[2] Мөстәгыйд – сәләтле, булдыклы.
[3] Табган – табигате белән.
[4] Маил – һәвәс.
[5] Гозләттә – ялгызлыкта.
[6] Вәли – хуҗа, җитәкче.
[7] Никитский М. Мир Али Шир в государственном и литературном его значении. *(Авт. иск.)*
[8] Киһи – бик аз.
[9] Натәванлык – көчсезлек, куәтсезлек.
[10] Кямранлык – теләккә ирешү; рәхәтлек.
[11] Биси – күп, еш.
[12] Эссик-савык – эсселек-суыклык.

Нәваи үз гомерендә бик күп язган язучылар җөмләсенә керә. Ул үзеннән соң утызлап китап калдырган. Аның әдәби мирасы арасында халис[1] әдәби, шигъри әсәрләр булган шикелле, гыйльми, хәтта дини әсәрләр дә юк түгел. Фарсычадан тәрҗемәләре дә бар. Ул – бер риваяче (эпик) булганы күк, көчле бер лирик та. Ул һәм назым, һәм нәсер белән язган. Фарсы телен дә үз ана теле шикелле белеп, һәр ике телдә шигырьләр әйткән. Ләкин без аның үз ана телен һәрвакыт алда тоткан бер милләтче төрк шагыйре икәнен күрәбез. Иранлыларның төрк телен ярлы дип аңар кимсетеп карауларына ачуы килеп, ул үзенең «Мәхакәмәт эл-лөгатәйн» (Ике телне мөхакәмә[2]) намындагы әсәрен язган. Бу китабында ул фарсы һәм чыгтай телләрен фәсахәт-бәлягать[3] ягыннан тәфтиш итеп[4], муаффәкыятьле[5] рәвештә төрк теленең күп яктан (мәсәлән, фигыльләргә байлык ягыннан) фарсы теленнән өстен торганлыгын исбат итә.

Нәваинең никадәр әтрафлы язучы булганын белү өчен, аның әсәрләренең исемнәренә күз йөртеп чыгу да җитсә кирәк. Ул үзенең китапларында ниләргә генә кагылмаган.

Нәваинең шигъри әсәрләреннән мәшһүррәкләре шушылар: биш дастан-поэма: 1) «Мәҗнүн вә Ләйлә», 2) «Фәрһад вә Ширин», 3) Сәдд «Искәндәри»[6], 4) «Сәбгаи сәйярә»[7], 5) «Хәйрәт әл-әбрар»[8]. Бу дастаннарның әүвәлгесе икесе[н]дә Нәваи бөтен шәрык галәме өчен уртак булган гашыйк вә мәгъшук маҗаралары мәүзуг[9] итеп ала. Өченче поэмага Искәндәр Зөлкарнәйннең Яэҗүҗ-Мәэҗүҗне чыгармас өчен ике тау арасына койма кордыруы хакындагы хикәя мәүзуг итеп алынган.

---

[1] Халис – саф, чиста.
[2] Мөхакәмә – тикшерү, хөкем чыгару.
[3] Фәсахәт-бәлягать – әдәбилеге, стиль камиллеге.
[4] Тәфтиш итеп – тикшереп.
[5] Муаффәкыятьле – уңышлы.
[6] «Сәдд Искәндәри» – «Искәндәр дивары».
[7] «Сәбгаи сәйярә»– «Җиде юлдаш» («Җиде планета»).
[8] «Хәйрәт әл-әбрар» – «Изгеләрнең яхшылыклары».
[9] Мәүзуг – тема.

Нәваинең лирикасы, башлыча, дүрт диванга[1] җыелган. Бу дүрт диван инсанның гомерендә кичерә торган дүрт дәверенә, ягъни балалыкка, яшьлеккә, урта яшькә һәм картлыкка багышланган.

Исемнәре: 1) «Гораиб әс-сыйгар»[2], 2) «Нәвадир әш-шәбаб»[3], 3) «Бәдаиг әл-васат»[4], 4) «Фәваид әл-кибар»[5]. Шулай итеп, бу дүрт диван бер-берсенә бер фикер җебе белән бәйләнгәннәр. Бу мәҗмугалардагы шигырьләр чыгтай әдәбиятындагы тәсаувыф шигъриятенең иң гүзәл чәчәкләреннән хисаплана. Моннан башка тагы Нәваинең «Гозлият Нәваи» һәм «Диванча-и Нәваи» аталган ике диваны бар. Нәваинең фарсыча шигырьләре «Сакыйнамә» исемле диванга җыелган. Фарсыча шигырьләрен ул «Нәваи» дип түгел, бәлки «Фани» дип имза итә торган булган.

Нәваинең башка китапларының исемнәре шушылар: «Мөхакәмәт әл-лөгатәйн», «Мәхбүб әл-колуб», «Мәҗалис эн-нәфаис», «Лисан әт-тайр», «Нәвадир эн-ниһая», «Нәсаим әл-мәхәббәт», «Сираҗ әл-мөслимин», «Хәмсәт әл-мөтәхәйирин», «Назым әл-җәваһир», «Китабе тарих», «Рисалә-и мөгаммә», «Китабе вакфият», «Чиһел хәдис», «Мөнаҗәтнамә», «Китаб әл-мөншәат», «Мизан әл-әүзан», «Горузе төрки». Болардан «Мәхбүб әл-колуб» (Йөрәкләрнең сөйгәне) – әхлакый мәүзугта язылган зур гына бер китап; мөндәриҗә ягыннан «Котадгу белег»кә беркадәр охшый. «Лисан әт-тайр» (Кош теле) – Фәриделдин Гаттар исемле Иран шагыйреннән тәрҗемә кылынган тәсаувыфка даир[6] бер әсәр. «Мәҗалис эн-нәфаис» (Гүзәллек мәҗлесләре) дигән китабында Нәваи үз заманындагы һәм үзеннән элекке чыгтай шагыйрьләренең тәрҗемәи хәлләрен сөйли. Бу – чыгтай әдәбиятының тарихы сымаграк бер әйбер. «Китабе тарих» ике кыйсемгә бүленә: беренче бүлеге «Тәварихе

[1] Диванга – җыентыкка.
[2] «Гораиб әс-сыйгар» – «Балачак могҗизалары».
[3] «Нәвадир әш-шәбаб» – «Яшьлекнең сирәк мизгелләре».
[4] «Бәдаиг әл-васат» – «Урта чорның гүзәллеге».
[5] «Фәваид әл-кибар» – «Картлыкның казанышлары».
[6] Тәсаувыфка даир – суфичылыкка караган.

әнбия» – пәйгамбәрләр тарихы, икенче кыйсеме «Тәварихе мөлүк» аталып, бусында Иран шаһларының тарихы сөйләнә. «Рисаләи мөгаммә» – табышмаклар китабы. «Китабе вакфият» – вакыфлар хакында. «Чиһел хәдис» – кырык хәдис, «Мөнәҗәтнамә» – дини шигырьләр, мөнәҗәтләр мәҗмугасы, «Китабе мөншәат» – хат язарга өйрәнә торган китап. «Мизан әл-әүзан» – гыйльме гаруздан, ягъни шигырь вәзеннәре хакында, «Горузе төрки» – төркичә шигырьләрнең үлчәве турысында.

Нәваинең тәсаувыфи лирикасына мисал йөзеннән шигырьләреннән җиңелрәк тел белән язылган берсен күчереп үтәбез:

Күргәле[1] хөснең[2] зар вә мөбтәля[3] булдым сәңа,
Ни балалыг гөл иде кем, ашна[4] булдым сәңа.
Һәр нәчә дидем ки, көн-көндин өзәй[5] сәндин өмид,
Вә ки көн-көндин битәррәк[6] мөбтәля булдым сәңа.
Мин качан дидем: вафа[7] кылгыл мәңа – золым әйләдең,
Син качан дидең: фида булгыл – фида булдым сәңа.
Кай пәри пәйкәр[8] дир син тилбә[9] булдым бу сыйфат[10],
Әй, пәри пәйкәрне кылсаң, кыл миңа – булдым сиңа.
Җам җем[11] берлә Хозыр суы насыйбымдыр мөдам,[12]
Сакыйа[13] тәрке җаһ әйләб,[14] гидай[15] булдым сәңа[16].

---

[1] Күргәле – күргәчтен, күргәннән бирле. *(Авт. иск.)*
[2] Хөснең – матурлыгың.
[3] Мөбтәля – кайгыга төшү.
[4] Ашна – дус, әшнә.
[5] Өзәй – өзәсе иде. *(Авт. иск.)*
[6] Битәррәк – артыграк. *(Авт. иск.)*
[7] Вафа – тугрылык, сүздә тору.
[8] Пәри пәйкәр – фарсы шагыйрьләр гүзәл кызларны шулай диләр. *(Авт. иск.)*
[9] Тилбә – тиле. *(Авт. иск.)*
[10] Сыйфат – образ-сурәт; гүзәл йөз.
[11] Җәм шаһның кадәхе – хорафи мәҗаз. *(Авт. иск.)*
[12] Мөдам – даимән. *(Авт. иск.)*
[13] Сакый (шәраб өләшүче). *(Авт. иск.)*
[14] Тәрке җаһ әйләб – байлыкны ташлап. *(Авт. иск.)*
[15] Гидай – фәкыйрь. *(Авт. иск.)*
[16] Бу газәлнең баштагы дүрт юлы аерым робагый шәкелендә Бабурның диванында бар. Бабур Нәваидән алган булса кирәк. *(Авт. иск.)*

Чыгтай әдәбиятындагы әдипләрнең иң әһәмиятле вә игътибар итәргә тиешле булганнарыннан берсе – Тимер нәселеннән килгән Бабур мирза, яки Солтан Бабурдыр (1482 дә туган, 1530 да вафат). Бабур – Мавәраэннәһердә хөкем сөргән Тимер балаларының иң актыкларыннан. Ул Тимернең торунының торуны[1]. Аның хакында язган мөәррихләр[2]: «Бабасы Тимернең дәһасы[3] йөз елдан соң бу кешедә яңадан заһир булды[4]», – диләр. Чынлап та, бу зат, тәдбирле[5] бер падишаһ, оста бер сәяси һәм гаскәр башы булуы өстенә, истигъдадлы[6] бер әдип – шагыйрь дә булган. Ул сәясәт дөньясына чыккан вакытларда инде Урта Азиядә Тимер ыругының хакимияте какшаган булып, әмирләр, солтаннар, мирзалар бертуктаусыз бер-берсе белән сугышу белән мәшгуль булганнар. Бабур да бу сугышларда катышкан солтан Гали мирза белән иттифакка[7] кереп, Байсынгыр мирза белән сугышкан. Мавәраэннәһерне аның кулыннан алырга теләсә дә, муаффәкъ булмаган[8]. Шул арада Шәйбани хан заһир булып, Тимер нәселен Урта Азия тәхетләреннән сөргән. Монда сәясәт бабында үзен күрсәтергә мөмкин булмаганын күргәч, Бабур мирза, Һиндстанга барып, җирле раҗәләрне[9] җиңеп, шимали[10] Һиндстанны забыт иткән[11] һәм шунда яурупалылар тарафыннан «Бөек Могул империясе» дип атала торган зур дәүләтне төзегән. Аның сөляләсеннән[12] Һиндстан тарихында зур роль уйнаган Шаһиәкбәр, Шаһиҗиһан, Җиһангир шикелле мәшһүр падишаһлар килгән. Тимер сөляләсе белән бергә Мавәраэннәһердәге мәдәният учагы да Һиндстанга

---

[1] Торунының торуны – оныгының оныгы.
[2] Мөәррихләр – тарихчылар.
[3] Дәһасы – даһилыгы, сәләте.
[4] Заһир булды – ачылды, барлыкка килде.
[5] Тәдбирле – эшнең ахырын алдан күреп эшләүче.
[6] Истигъдадлы – сәләтле, булдыклы.
[7] Иттифакка – союзга.
[8] Муаффәкъ булмаган – булдыра алмаган.
[9] Раҗәләрне – һинд патшаларын.
[10] Шимали – төньяк.
[11] Забыт иткән – яулап алган.
[12] Сөляләсеннән – нәселеннән, династиясеннән.

күчкән, Бабур һәм варислары да, бабалары шикелле, мәдәният сөючеләр вә сәнаигы нәфисә химаячеләре[1] булып, алар заманында җәнүбтә[2] көчле һәм парлак яңа бер ислам мәдәнияте мәйданга килгән. Шул вакытта мигъмарчылыкта «һинд-мөселман тарызы мигъмары»[3] аталган гүзәл стиль заһир булган. Бу стильдә салынган гаҗәп зифа вә могаззам[4] биналар хәзерге көндә дә сәйяхларның[5] исләрен китәрүдә дәвам итәләр.

Бабур мирзаның мәшһүр әсәре – аның «Бабурнамә» (яки «Вәкаигы солтан Бабур», «Вакугат Бабури») аталган хатирәләре (басмада зур кулда, 500 биттән артыграк). Монда Бабур үзенең бөтен тормышын, бөтен башыннан кичергән вакыйгаларын сөйли. Чынлап та, аның гомере нәкъ бер роман яки поэма төсле, ул үзенең җилле-давыллы сәяси хәятында башыннан нинди генә гаҗәеп хәлләр, искиткеч вакыйгалар кичермәгән, нинди генә читенлекләргә төшмәгән, бу – бер хатирә (мемуар) яки көнлек дәфтәр шикелле бер әйбер. Ул һәр елда булып узган вакыйгаларны ел тәртибе белән яза барган. Сүз җае килгәндә, арада ул үз илендәге төрле җирләр, шәһәрләр, мәшһүр кешеләр хакында да мәгълүмат биреп китә, һәртөрле мөнәсәбәт белән кыска-кыска шигырьләр дә кыстыра. Шулай итеп, бу әсәрендә Бабур бер шагыйрь, бер эстет, бер тәнкыйтьче, бер философ, бер тарихчы, тәрҗемәи хәлче һәм җәгърафи[6] буларак безнең күз алдыбызга килә. Яурупалылар «Бабурнамә»не Юлий Цезарьның «Комментарий»лары белән бер дәрәҗәгә куялар, Бабурның үзен дә шәрыкның Юлий Цезаре дип атыйлар. «Бабурнамә» саф матур вә тигез чыгтай телендә язылган. Ул чыгтай әдәбиятының иң эре энҗеләреннән, классик әсәрләреннән, чыгтай әдәби теленең иң яхшы нәмунәләреннән[7] санала.

[1] Сәнаигы нәфисә химаячеләре – нәфис әдәбият тарафдарлары.
[2] Җәнүбтә – көньякта.
[3] Һинд-мөселман тарызы мигъмары – һинд-мөселман архитектур стиле.
[4] Могаззам – әһәмиятле.
[5] Сәйяхларның – сәяхәтчеләрнең.
[6] Җәгърафи – географ.
[7] Нәмунәләреннән – үрнәкләреннән.

Мисал өчен, «Бабурнамә»нең берничә юлын да күчереп китәбез: «... киендин[1] һичкем күмәк[2] килмәде вә күмәк килер ихтималы һәм юк ирде, ушандин боларның өстегә йилдам[3] йөреде бир-ике ук атбилар булдыра алмадылар кача бирделәр ялгуз йайдак ат билә күмәксез Синд[4] суыдик[5] дәрьядин уздурыб кичиб ганыймларны[6] качуруб йирләрене алды мөхәккәм мәрданә[7] иш кылды ягыны[8] качургандин соңра... илх[9]».

Бабур истигъдадлы бер шагыйрь дә булган. Аның ике кыска гына диваны сакланып калган. Бу диваннарда аның бик матур, шагыйрьнең нечкә әдәби зәвыклы кеше булганын күрсәтә торган газәлләре, мәснәвиләре, робагый вә тоюглары, фәрдләре җыелган. Аннан башка аның вак-төяк шигъри парчалары «Бабурнамә»дә һәм башка урыннарда чәчелгәннәр[10]. Бу әсәрләреннән башка тагы Бабурның «Мөбәйин» исемле дини мәүзугтагы[11] назым белән язылган бер китабы һәм Гобәйдулла Хуҗа Әхрарның «Вәлидия» дигән тәсаувыфи әсәренең назым белән тәрҗемәсе бар. Болардан башка янә берничә әсәре булганлыгы мәгълүм булса да, хәзергә кадәр табылганы юк.

Бабурның диванындагы гыйшкый газәлләрдән берсен монда күчереп үтәбез:

Ачылыб ике саче йөзигә ябылмышлар,
Ярук җиһанны күрмәгә карангу кылмышлар.

---

[1] Киендин – артыннан. *(Авт. иск.)*
[2] Күмәк – ярдәм. *(Авт. иск.)*
[3] Йилдам – тиз. *(Авт. иск.)*
[4] Синд – Һиндстан.
[5] Суыдик – суы кебек.
[6] Ганыйм – дошман. *(Авт. иск.)*
[7] Мәрданә – егетләрчә. *(Авт. иск.)*
[8] Ганыймларны – җауны – дошманны. *(Авт. иск.)*
[9] Илх – илә ахриһи – һәм башкалар.
[10] Бабурның шигырьләре мөстәшрикъ Самойлович тарафыннан 1917 елда аерым бер китап шәкелендә нәшер ителде. *(Авт. иск.)*
[11] Мәүзугтагы – темадагы.

Чагыр[1] бәгырь[2] канидыр барча гыйшык әһлегә
Зәһиләргә[3] бумы дин дәме әйләмешләр. (?)[4]
Ни кылсам әйләмә, әй, йар гаеб кем миндә
Җөнүн[5] вә гыйшык вә егетлек бары катилмешләр[6].
Сәляхгә[7] фәрд әһле мине явык[8] дирләр,
Күрең ки, ошбу җиҗанлар (?)[9] ерак йәңгелмешләр[10].
Ни сәүд[11] гыйшыкны илдин яшермәк, и Бабур.
Чу халәтең ни бары галәм әһеле белмешләр.

XVI гасырдан башлап, чыгтай әдәбияты кирегә китә, сүнәргә йөз тота. Әдәбиятның тәдәнние[12], мәдәниятнең түбәнләшүе белән мөтәнасиб[13] рәвештә бара. Шәйбаниләр хакимият башына менү белән, Урта Азиянең мәдәни хәятында торгынлык, мөхафәзәкәрлек[14] дәвере башлана. Шәйбаниләр тәэсире астында мәйданга чыккан бер генә игътибар итәрлек шагыйрь-эпик бар, ул да булса, Шәйбани ханның Тимер балаларын җиңүен тасвир итеп, аңа мәдхия йөзеннән язылган «Шәйбанинамә» поэмасының мөхәррире[15] – шаһзадә Мөхәммәд Салихдыр[16]. Мөхәммәд Салихнең «Шәйбанинамә»се, бөтен XV гасыр чыгтай

[1] Чагыр – хәмер, шәраб, аракы. *(Авт. иск.)*
[2] Бәгырь – йөрәк. *(Авт. иск.)*
[3] Зәһиләргә – яхшы кешеләргә.
[4] Төп текстта шул рәвешле куелган.
[5] Җөнүн – мәхәббәттән акылдан шашу; ярсу.
[6] Катилмешләр – катышканнар. *(Авт. иск.)*
[7] Сәляхгә – намуслылыкка, тугрылыкка.
[8] Явык – якын. *(Авт. иск.)*
[9] Чыганакта шулай сорау билгесе куелган.
[10] Йәңгелмешләр – яңгышканнар. *(Авт. иск.)*
[11] Сәүд – файда. *(Авт. иск.)*
[12] Тәдәнние – артта калуы.
[13] Мөтәнасиб – тигез.
[14] Мөхафәзәкәрлек – үз эченә бикләнү, үз-үзен саклауга омтылыш.
[15] Мөхәррире – авторы.
[16] Мөхәммәд Салих (1455–1535) – үзбәк шагыйре, дәүләт эшлеклесе, шәйбанилар дәүләте елъязмачысы. 1499–1506 еллар аралыгында Урта Азиядә барган сәяси-тарихи вакыйгаларны үз эченә алган һәм 9000 гә якын шигъри юлны берләштергән «Шәйбанинамә» исемле әсәре белән данлыклы.

әдипләренә хилаф буларак, бик саф төрк телендә язылган. Аның өслүбе дә яңа даладан килгән садә табигатьле күчмә үзбәкләр шикелле үк садә, сугыш тасвирлары гаҗәп матур вә җанлы.

Урта Азиядә төрк әдәбияты, аксый-аксый, XIX гасырга кадәр дәвам итә. Ләкин ничә йөз еллык шул дәвердә анда һичбер төрле яңару, үзгәрү күрелми, искергән, тузган тәсаувыф аһәңнәреннән башка саф, көчле, яңа бер фикер дә, яңа формалар да юк. Шагыйрьләр XV гасырның бөек шагыйрьләренә зәгыйфь тәкълидләрдән[1] уза алмыйлар. XVII... XVIII гасырлар арасында яшәгән Суфи Аллаяр – сүнү дәвере өчен тип булырлык бер шагыйрь. Ул бер суфи булса да, аның язган әйберләрендә без бөек суфи шагыйрьләрдәге очкынны, алардагы шигърияттне күрмибез. Әхлакый тенденцияле, эчпошыргыч тәкъвалыкка чолганган әсәрләр, «Диване хикмәт»ләр, «Бакырган»нар белән бергә Аллаяр Суфиның «Сөбат әл-гаҗизин» вә «Морад әл-гарифин»нәренең безнең татар арасына килеп керүе дә – игътибарга лаек факттыр.

## VII
## Сәлҗук вә госманлы әдәбияты

Сәлҗук идеологиясенә әсасланган[2] төрк әдәбиятының икенче бер зур тармагы Кечек Азиядә (Анатулы ярыматавында) сәлҗук төркләре арасында тамыр җәя башлап, госманлыларда үзенең иң югары ноктасына ирешеп, XIX гасырның башларына кадәр сузылып барды. Соңгы заманнарда бары яурупачылык белән сугарылган әдәбият кына аны какшатты һәм ахирел әмер[3] үтерде.

XI гасыр башларыннан башлап, ике гасыр кадәр гарби[4] Азиядә сәлҗук төркләре аталган халык зур, көчле бер дәүләт

[1] Тәкълидләрдән – ияреп язулардан.
[2] Әсасланган – нигезләнгән.
[3] Ахирел әмер – ахыр чиктә.
[4] Гарби – көнбатыш.

тәшкил итеп тордылар. Бу дәүләтнең чикләре Әфганстан хөдүденнән[1] Ак диңгез буйларына кадәр җәелгән иде. Чыңгыз тәсәллыты[2] сәлҗук дәүләтен тәмамән бетермәсә дә, аны изеп, вак феодаллыкларга әйләндереп калдырды. Соңыннан кечкенә генә бер урда хәлендә Хорасан эчләреннән килеп чыккан госманлы төркләре, сәлҗукыйларның дәүләт һәм мәдәниятләренә варис булып, сәлҗук империясенең хәрабәләре өстендә яңа бер көчле мәмләкәт торгыздылар.

Сәлҗук төркләре борынгы угыз төркләре нәселеннән булып, төрекмән сахраларыннан килеп чыкканнар иде. Бу халыкның төп гонсыры[3] ислам динендә хисапланса да, шаманизм тәэсирендәге күчмәле һәм бөтен гомерен сугышта үткәрүче профессионал сугышчылардан гыйбарәт булганга, алар арасында язу сәнгате һәм язма әдәбият бик озак заманнарга кадәр тарала алмады. Әмма сәлҗук солтаннары аз заманда зур җирләр ишгаль итеп[4], Урта Азиядән рума-юнан һәм гарәп-иран мәдәнияте сеңгән урыннарга килеп утыргач, аларга бу мәдәниятләр йога башлады. Сәлҗук дәүләте акрынлап сахра монархиясеннән чын-чын утраклы бер дәүләткә әйләнә бару белән, сәлҗукыйларның хөкүмәт сөрүче югары сыйныфларының сарайларына Иран шагыйрь вә галимнәре агылып, алар арасында фарсы телен һәм әдәбиятын тәгъмим итәргә[5] тотындылар. Хәтта солтаннар үзләрен Иран шагыйрьләре (Фирдәүси) тасвир иткән каһарманнарның исемнәре белән атап, бу заманда Кәй Хөсрәү, Кәй Кавас, Кәй Кабад шикелле солтан исемнәре еш очрый иде.

Югарыгы сыйныфны фарсы әдәбияты канәгатьләндерсә дә, түбәнге табәкаларда[6] үз телләрендә язылган әдәбият кирәклеге хисе уянды. Урта Азиядән китерелгән миф, кыйсса, әкият,

[1] Хөдүденнән – чигеннән.
[2] Тәсәллыт – үз биләвенә алып, аның өстеннән хөкем йөртү.
[3] Гонсыры – состав өлеше.
[4] Ишгаль итеп – биләп.
[5] Тәгъмим итәргә – таратырга.
[6] Табәкаларда – сыйныфларда.

дастан вә җырлар гына инде аларны канәгатьләндерми башлады. Шуның өстенә суфилык пропагандачылары, үзләренең фикерләрен халык арасына кертү һәм тарату өчен, халыкның үз телендә язарга кирәклеген сизделәр. Сәлҗук мохитендә вөҗүдкә[1] килеп, Рум туфрагында фарсыча язучы иранлы Җәлаледдин Румиларның газәл вә мәснәвиләре югары табәка өчен аңларлык булса да, түбән сыйныфларга алар аңлашылмый иде. Әмма Иран вә Рум шәһәрләре сәлҗукыйлар кулына керә бару белән, төрекләр арасында акрынлап шәһәр халәте зоһур итә[2], киез өй вә чатырлар таш вә балчык өйләргә әйләнә, шуның белән бергә, язу сәнгате дә тарала, язма әдәбият туа башлый.

Сәлҗукыйларның иң беренче әсәрләре – Җәлаледдин Руминың улы, «Вәләд Солтан» ләкабе белән мәшһүр булган Баһаведдин Мөхәммәд исемле суфиның «Рубабнамә»сендәге 156 данә төркчә шигырьләрдер. Бу әсәр 1301 нче миладида зоһур иткәнлектән, җәнүб төркчәсендә язылган шигырьләрнең иң искеләреннән хисапланырга тиеш[3]. Бу әсәрнең мәүзугы[4] шагыйрьнең атасы тарафыннан төзелгән Мәүләви тарикатен мактау, гомумән, суфилык пропагандасы, тәсаувыф фикерләрен популяризация һәм вәгазь-нәсыйхәттән гыйбарәттер. Әсәрнең иң мөһим ягы – аның теленең садәлеге, соңгы госманлы вә чыгтай шигырьләренең, киресенчә, гарәп-фарсы сүзләренең азлыгы һәм төрк теленә махсус халык үлчәве булган «бармак хисабы» вәзене белән язылуыдыр. Ләкин Вәләд Солтанның күп әсәр вә шигырьләре фарсыча. Хәтта гарәп хәрефләре белән румча (грекча) язылган. Моның сәбәбе исә – иранлы булганлыгыннан, ана теле фарсыча булып, төркчә бик читенлек белән генә язуыдыр. Ул үзе дә, бер шигырендә бу хакта кайгырып:

---

[1] Вөҗүдкә – дөньяга.

[2] Зоһур итә – барлыкка килә, таралыш таба.

[3] Бу әсәр хакында әдәбият: 1. Һаммерның мәкаләсе: Jahrbücher der Litteratur, 1829, 103 s.; 2. Melange Asiatique, Bd. I. Radloff. Über alttürkische Dialekte; 3. Saleman. Noch einmal die Seldschukischen Verse (ibid II Livre); 4. Крымский. История Турции и ее литературы, т. 2. *(Авт. иск.)*

[4] Мәүзугы – темасы.

Төркичә белсәйдем әйдидем сезә:
Серләре Тәңридән дөкди[1] безә.
Белдүрәйдем сүзилә белдүкеме,
Белдүрәйдем бән сезә белдүкеме.
Диләрәм кем күрәләр каму аны,
Җөмлә яхсуллар[2] улә бәндән гани[3].

Сәлҗук телендәге әдәбият XIII гасырда Госманлы дәүләте ясала башлагач та дәвам итеп, сәлҗукыйларның калдыклары һәм госманлыларның феодаллары булган вак әмирлекләрдә тәрәккый итте. Бу әдәбият мәүзуг җәһәтеннән яңа һәм нәү[4] иҗат бер нәрсә түгел иде. Сәлҗук әдипләре, барысы да диярлек Җәлаледдин Руминың мәктәп вә тарикатенә мәнсүб[5] кешеләр булып, шул фикерне тәлкыйн кылалар[6] иде. Вәләд Солтан заманыннан ерак киткән саен, бу дәвер шагыйрьләренең телләренә гарәп-фарсы сүзләре тула башлый, ләкин байтакка кадәр шигырь үзенең халыкка якынлыгын, теленең сафлыгын һәм вәзендә бармак хисабын саклап килә.

Сәлҗук шагыйрьләренең иң искеләреннән берсе – Вәләд Солтанның замандашы Юныс Гомридер[7]. Бу кеше әле «бармак хисабы» белән яза, ят сүзләрне теленә аз катыштыра, Иран шагыйрьләренә дә аз тәкълид кыла[8]. Шуның өчен дә борынгы госманлы тәнкыйтьчеләре («тәзкирә-и шугара»чылар) аны бик үк мактап бетермиләр. Юныс Гомри, Җәлал Руминың тарикатенә мәнсүб булып, аның диванына тәкълидән үзе дә төркчә бер диван язды.

[1] Дөкди – түгелде.
[2] Яхсуллар – юксыллар, ярлылар. *(Авт. иск.)*
[3] Гани – бай. *(Авт. иск.)*
[4] Нәү – яңа.
[5] Мәнсүб – мөнәсәбәтле.
[6] Тәлкыйн кылалар – инандыралар, төшендерәләр.
[7] Юныс Гомри – Юныс Әмре (1240 (?) –1320 (?), урта гасырлар төрек әдәбияты үсешенә зур йогынты ясаган мәшһүр төрек суфи шагыйре.
[8] Тәкълид кыла – ияре.

Шул ук дәвердә 1332 елда вафат булган Гашыйк исемле мәшһүр бер шагыйрь бар иде. Шагыйрьләрнең «солтаны» булганга күрә, Җәлал Руминың улына «Вәләд Солтан» ләкабе бирелгәне шикелле, Гашыйкны да, шигырь бабында «пашалык» дәрәҗәсенә менгереп, Гашыйк Паша дип йөрткәннәр. Бу кеше «Гарибнамә» яки «Диване Гашыйк Паша» исемендә бер төркчә диван вөҗүдкә китерде. Бу әсәр, башлыча, төрк вәзене белән язылса да, Гашыйк Пашада инде Иран вәзененең тәэсире дә юк түгел. Тел вә өслүб ягыннан исә ул әле чын-чын төрк, затән[1], аның бу әсәрен язуның максуды да – төрк телендә фикерләр аңлату, шул телдә сөйләшә торган халыкны агарту, мәгълүмат бирүдер. Шуңар күрә дә ул әсәренең ахырында шундый сүзләр яза:

Гәрчә кем сөйләнде бәндә төрк деле,
Илә мәгълүм улды мәгънә мәнзиле.
Чөн беласин җөмлә юл мәнзилене,
Бәрмәгел син төрк таҗик дилене.
Каму дилдә варыр забыт ысул,
Булара дөшмеш ди җөмлә гакул.
Төрк делинә кемсәнә[2] бакмаз, ди,
Төркләрә һәргиз күңел ачмаз, ди.
Төрк дәхи белмәз ди ул делләри,
Анча юлы ул олы мәнзилләре.
Бу китап анукчен[3] килде делә,
Кем бу дел әһле дәкый[4] мәгънә белә.
Төрк делендә ягъни мәгънә булалар,
Төрк таҗик җөмлә юлдаш улалар.
Юл эчендә бер-берене бәрмәйа,
Диләр бакып мәгънәи хур күрмәйә.
Таки мәхрүм кылмайа төркләр дәкый,
Төрк дилендән аңлайалар[5] ул хаки.

[1] Затән – нигездә.
[2] Кемсәнә – һичкем. *(Авт. иск.)*
[3] Анукчен – аның өчен. *(Авт. иск.)*
[4] Дәкый – дәхи. *(Авт. иск.)*
[5] Аңлайалар – аңласыннар. *(Авт. иск.)*

Дөрес, Гашыйк Пашаның бу диваны да, башкаларныкы шикелле үк, суфилык тарызындагы вәгазь-нәсыйхәт вә дини тәгълиматтан гыйбарәт. Ләкин, шуның белән бергә, аның шигырьләре арасында халык дастаннарын искә төшерә торган Алып (батыр) кешеләрне мактый. Батырлык һәм сугышчанлыкның маһият[1] вә хосусиятен сөйли торган шигырьләр дә юк түгел. Мәсәлән, түбәндәге ике мисрагъ безгә «Сәид Баттал», «Сары Салтык» вә «Коркуд» китапларындагы идеологияне искә төшерәләр:

Кан ауликем эстәр алыплык адыны,
Алмаг эстәр дошманындан дадыны[2].
Дошманын каһәр әйләеб басмак деләр[3],
Башыны ат янына асмак деләр...

Вакыйган, Гашыйк Паша үзенең диваныннан башка тагын нәкъ шул төрк дастаннарындагы шикелле гаять самими, садә мәддахлык[4] һәм вәкаиг нәвасилек[5] өслүбендә нәсер белән, госманлы дәүләтенең килеп чыгу вакыйгасын тасвир итә торган «Тарихе але Госман» исемле бер тарих та язды. Бу әсәрнең рухын белү өчен, аның башыннан шушы ике-өч юлны алу җитә: «Күшәи фирагатьдә[6] Сәлим Риза күнҗендә[7] фәна вә сабыр хиркасын киеп утырмышдым вә дога сафрасилә мөтәнәгъгыйм[8] улмышдым. Нагяһ[9] бераз җәмәгать газизләрдән але Госман[н] ың тәварихендән[10] вә мәнакыйбләрендән[11] зикер итделәр вә бу фәкыйрьдән сөаль итделәр, фәкыйрь дәхи җавап вирдем...» –

[1] Маһият – сыйфат, үзлек.
[2] Дадыны – тугрылыгын, горурлыгын.
[3] Басмак теләр. *(Авт. иск.)*
[4] Мәддахлык – мәдхия уку.
[5] Вәкаиг нәвасилек – нәсел-династиянең тарихы.
[6] Күшәи фирагатьдә – тыныч урында ял иткәндә.
[7] Күнҗ – урын, почмак, мәгарә.
[8] Мөтәнәгъгыйм – иркен яшәүче; ризыкланучы.
[9] Нагяһ – көтелмәгәндә.
[10] Але Госманның тәварихендән – Госман нәселенең тарихларыннан.
[11] Мәнакыйбләрендән – мактаулы эшләреннән.

дип, ул вакыйгаларны бер дә мөһим вә мөһим түгелен сайлап тормыйча сөйләп китә.

Госманлы дәүләте ясалып яткан көннәрдә Кечек Азия туфрагында җәнүб[1] төрк теле белән язучылар, әлбәттә, күп иде. Аларның һәркайсына аерым тукталуның лөзүме[2] юк.

Чын госманлы әдәбияты 1435 елда төрекләр тарафыннан Истанбул алынгач башлана. Бу заманнан башлап инде төрек әдәбияты Иран шагыйрьләренә тәкълидкә мөбтәля[3] булып, теленә гарәп-фарсы сүзләре тула башлый, Иран өслүбе вә тарзы ифадәсе[4] хөкем сөрергә тотына. Шуның өчен әдәбият, халыктан ераклашып, хаким сыйныфларның әдәбиятына әверелеп китә. Шуның нәтиҗәсендә бара-тора бөтенләй халык теленнән аерылган бер госманлы әдәби теле мәйданга килә. Шагыйрьләр үзләре халык телен «каба лисан» (тупас тел) дип яманларга тотыналар. Шагыйрь Яхъя бәй шикелле:

Илең сүзене тәрҗемә итмәдем, ябаның авыруын аңа катмадым,
Делем улмады тәрҗеман гаҗәм[5], гаҗәм үлесенең тәгамен йимәм[6], –

диючеләр булса да, алар бу сүзне тик әйтеп кенә калдылар. Әсәрләре һаман да шул адәм аңламаслык гарәп-фарсы-төрк жаргонынннан гыйбарәт булды.

Тантаналы галәбәләр[7] госманлы хөкүмәт сөрүче сыйныфының кесәсен «ганимәт» белән тутырып, ул сыйныф чын бер феодал сыйныфына әверелде. Алар рус вотчиналары шикелле имтиязлар[8] алып, шундагы җир сөрүче – тарлачыларга эксплуатация ясап яттылар. Сарай тирәләрендә исраф эшлексезлек, гыйшгыйшрәт[9] зоһур итте[10], иске патриархаль, садә төрк тормышы

[1] Җәнүб – көньяк.
[2] Лөзүме – кирәге.
[3] Тәкълидкә мөбтәля – иярүгә дучар.
[4] Тарзы ифадәсе – стиле.
[5] Гаҗәм – иранлы, фарсы; чит халык.
[6] Тәгамен йимәм – ризыгын ашамам.
[7] Галәбәләр – җиңүләр.
[8] Имтиязлар – өстенлекләр.
[9] Гыйш-гыйшрәт – вакытны ашап-эчеп, типтереп уздыру.
[10] Зоһур итте – барлыкка китерде.

бетте. Моның нәтиҗәсе буларак, шул тормышка махсус зәвык һәм назик тойгылар мәйдан алды. Шигырь, әдәбият «чалгы» музыка шикелле зиннәт нәрсәсе булып калды. Солтаннар үзләре дә фарсы вә төрки шигырьләр язарга керештеләр, үзләрен мактату өчен, махсус «сарай шагыйре» мәнсабын[1] ясадылар.

Бу замандагы госманлы әдәбияты, никадәр чынлыкта дөньяви әдәбият булса да, суфилык хиркасын[2] салмады һәм сала алмады, чөнки тәсаувыф идеяләре шулкадәр көчәйгән, тормышка кергән иде, шагыйрьләр ничаклы дөньяви тормышны мактасалар да, ничаклы гыйшык, гыйшрәт, эчемлек вә шәрабка мәдхияләр укысалар да, язып бетергәч, ахырдан һәркайсын тәэвил итеп[3], дөньяны суфилык чадрасы белән капларга мәҗбүр иделәр, заманасының иҗтимагый хәят шәраите[4] алардан шулай икейөзле «ханжа» булуны таләп итә иде.

Гомумән, борынгы госманлы шагыйрьләрен ике горуһка[5] аерырга мөмкин. Аларның берсе – шул сарайлар тирәсенә елышкан, үзләре халис дөньяча фикер йөрткән, бөтен хисләре белән дөнья тормышына бәйләнгән кешеләр булсалар да, мәҗбүрият йөзеннән генә суфиланып азапланучылар; икенчесе – тәкия вә челләханәләрдә утырып, дөньядан ваз кичеп, фәкать сөйгән Аллаларына һәм пәйгамбәргә каратып, чын-самими күңелләреннән чыккан мөнәҗәтләрен язучы, хакыйкатән суфи шагыйрьләрдер. Соңгы тип шагыйрьләрнең иң билгелесе – шөбһәсез, «Язычы углы» ләкабе белән мәшһүр булган Мөхәммәд Чәләбидер. Аның безнең татарларга да бик мәгълүм булган «Мөхәммәдия»се XV гасырның уртасында язылып тәмам булган иде. Бу китап һәм аның мөәллифе[6] хакында киләчәктә аерым тукталып сөйләнәчәк булганга, бу урында тәфсилгә керешмибез.

[1] Мәнсабын – хезмәт урынын.
[2] Хирка – дәрвишләрнең өс киеме.
[3] Тәэвил итеп – аңлатып.
[4] Хәят шәраите – тормыш шартлары.
[5] Горуһка – төркемгә.
[6] Мөәллифе – авторы.

XV гасырның игътибар ителергә тиешле булган шагыйрьләреннән берсе – солтан Мөхәммәд Фатихның углы Җәм солтандыр. Бу зат – атасы үлгәч, яурупалыларның мөшарәкәте[1] белән тәхет даулаучы бер шаһзадә булып, Икенче Баязидның тәгъкыйбеннән[2] Яурупага качкан бер кеше иде. Ул җәнүби Франциядә Ницца шәһәрендә торып, аның матурлыгына, гарәп мәдәниятенең газамәтенә[3] сокланып:

Гаҗәеб шәһәр, имеш, бу шәһре Ницца,
Ки калур янына һәр кеше Ницца, –

дигән бу шагыйрь. Аның Франциядә бер француз кызына гыйшкы, аның белән булган романтик маҗаралары – ничә романнарга мәүзуг[4] булган вакыйгалардандыр. Шәрыкның беренче гарәпчесе булган бу шагыйрь, үзенә иң назик гыйшык бүләк иткән Франциягә хитабән[5], шундый бер мәдхия язды:

Җаме җәм нуш[6] илә, и җәм бу Фәрәнкстандыр,
Һәр колың башына язылан килер дәүрандыр[7].
Кәгъбәтуллаһә варыб бер гиз тәваф итдекем
Бик фәрман, бик гарәп, бик мәмләкәте Госмандыр.
Шәкәрем улдыр, кем, килдем Фәрәнкстанә,
Саг-саглыкында кеше һәфт икълимә[8] һәм солтандыр.
Унсикез бан[9] углы җан каршымызә алтын җам чикәр,
Унсикез сакый[10] бу мәҗлесдә җәван[11] угландыр.
Хан Баязидә сорсалар мәмләкәт Рум иҗрәсен
Солтанат бакый калыр дирләрсә, билләһи, яландыр[12].

---

[1] Мөшарәкәте – катнашуы.
[2] Тәгъкыйбеннән – эзәрлекләвеннән.
[3] Газамәтенә – олылы гына, бөеклегенә.
[4] Мәүзуг – тема, сюжет.
[5] Хитабән – эндәшеп.
[6] Нуш – ләззәт.
[7] Дәүрандыр – чордыр, замандыр.
[8] Җиде икълимгә. *(Авт. иск.)*
[9] Бан – шаһзадә, принц.
[10] Сакый – шәраб коючы.
[11] Яшь. *(Авт. иск.)*
[12] Hammer. Sur le sesour du frère de Bayazed II ou Provense. Journal Asiatique, 1825, т. 11, 137.

Шушы шагыйрьдән башлап, госманлы әдәбиятында «Йосыф – Зөләйха», «Ләйлә – Мәҗнүн» тибындагы «парлы» гыйшкый поэмалар язучы шагыйрьләр тезмәсе башланып китә. Боларның әсәрләре – тәкълидтән[1], идеологияләре суфилыктан гыйбарәт булганга, алар һәммәсе бертөсле.

Менә шул хәлдә госманлы әдәбияты үзенең «алтын гасырына», ягъни XVI гасырга керә. XVI гасыр шагыйрьләре арасында бер оригиналь шәхес булса, ул да – Миһри-хатындыр. Бу – шәрык галәмендә моңарчы сирәк очрый торган, беренче башлап үз хокукларын яклаучы хатыннардандыр. Бер шигырендә ул бу хакта әйтә:

Чөнки нәкыс гакыл улыр дирләр ниса[2],
Һәр сүзен мәгъзүр[3] тотмакдыр рәва[4].
Бер мөәннәс[5] йәкдер ки ул әһел ула
Бең мөзәккәрдән[6] ки ул та әһел әүля[7].

Миһри-хатын да, заманасының башка госманлы шагыйрьләре төсле, суфилык бөркәнчегенә төренеп язса да, аның шигырьләре арасында чын эпикуреизм рухында булып, пессимизм (мәэюсият)тән гари булганнары[8] да юк түгел, мәсәлән, ул бер урында:

Гөлстанында икән ул гончәнең[9] – фөрьяд[10] кыл,
Юкса ярин[11] гөл кидәр, калырсән, и мескин, бизар[12], –

ди. Ләкин ул дөньяны «гөлстан»га охшатса да, анда кайгы-хәсрәтнең күплеген белә.

---

[1] Тәкълидтән – ияреп язудан.
[2] Хатыннар. *(Авт. иск.)*
[3] Мәгъзүр – гозерле; берәр сәбәп белән бер эшне эшли алмаучы.
[4] Рәва – яраклы, ятышлы.
[5] Мөәннәс – хатын кыз.
[6] Мөзәккәрдән – ир-аттан.
[7] Ягъни әһел булмаган мең ирдән әһел булган бер хатын яхшырак. *(Авт. иск.)*
[8] Гари булганнары – катышмаган.
[9] Гончә – ачылырга торган чәчәк, чәчәк бөресе.
[10] Фөрьяд – тәэсирләнү; ярдәм сорап кычкыру; зарлану.
[11] Ярин – иртәгесен.
[12] Калырсән бизар – зарланырга да өлгерми калырсың.

Гөлстан хөсне[не]ң һәр күшәсендә[1], дустым
Былбылы гүя үлеп әфганә[2] килмешләрдәнүз[3], –

дип, яңадан пессимизмга батып китә.

XVI гасыр әдәбиятында бөтенләй эпикуреизм әсасында[4] язылган әсәрләр дә юк түгел. Мәсәлән, 1582[5] елда вафат булган госманлы классикларыннан «Гыйш вә нуш ит, кем, кичәр, калмас әйам бәһар[6]» мисрагъларны язучы Мәсихи[7] – шулар җөмләсеннән. Бу шагыйрь үзенең «Шәһәр әнгиз» исемле поэмасында заһири суфилыкны үзләренә бер һөнәр итеп алган кешеләрне бик каты тешли. Ләкин мондый рухтагы әсәрләр XVI гасыр госманлы әдәбиятында күпчелек тәшкил итмиләр.

Шулай итеп, XVI гасырда госманлы әдәбияты баеса да, галәмгә яңа бер фикер яки форма бирә алмады, бөтен хезмәте госманлы әдәби теленә гарәп-фарсы сүзләрен тутырудан гыйбарәт булды. Бу гасыр – Госманлы империясенең куәт вә шәүкәте иң югары ноктасына менеп җиткән чагы, казнасының да иң баеган дәвере, сарай тирәсендә вә югары сыйныфларда исраф вә зиннәтле тормышның да иң кабарган вакыты иде. Солтаннар, үзләрен мактату өчен, махсус сарай шагыйрьләре мәнсабы[8] ясап, «шаһнамәче»ләр тәгъйин[9] кыла башладылар. Ләкин тышкы яктан ялтыравыклы булган бу дәвер әдәбиятка яңа рух өрә алмады. Шагыйрьләр һаман шул иске мәүзугларны һәртөрле итеп тәкрар кылалар, аларның суфилык битлеге астына яшеренеп җырлаган вә мактаган нәрсәләре һаман да шул Иран шагыйрьләреннән мирас булып килгән шәраб, исереклек, гыйшык, кызлар, матур ир балалар, музыка, бию вә гыйш-гыйшрәттән гыйбарәт иде.

[1] Матурлыгың бакчасының һәр почмагында. *(Авт. иск.)*
[2] Әфганә – зар еларга.
[3] Килгәнләрдән без. *(Авт. иск.)*
[4] Әсасында – нигезендә.
[5] Дөресе: 1512.
[6] Әйам бәһар – яз көннәре.
[7] Мәсихи – Иса Месихи (1470–1512), төрек шагыйре, лирик һәм юмористик шигырьләр авторы. «Бәһар» (Яз), «Ләйлә вә Мәҗнүн», «Йосыф вә Зөләйха», «Шәһәр әнгиз» (Дулкынланган шәһәр) исемле әсәрләре белән мәгълүм.
[8] Мәнсабы – хезмәт, эш урыны.
[9] Тәгъйин – билгеләү.

Фарсы тәэсире бер идея ягына гына мөнхәсыйр[1] булып калмады. Телгә дә аның тәэсире шулай ук зур булды. Фарсы сүзләре төрк теленә бертуктаусыз агып кереп, аны тәмам басып баралар иде. Гасырның башында бу эшкә каршы протест ясаучы бердәнбер шагыйрь Яхъя бәй булды. Ул үзенең «гаҗәм[2] тәрҗеманы булмавы, гаҗәм үлегеннән калган ашны ашамавы» белән мактанды. Әмма гомуми агым кире якка иде. Шагыйрьләр, бер-береннән уздырып, өслүбләрен әҗнәбилекләр[3] белән чуарлыйлар, бер-береннән арттырып, телләреннән «тупас төрк телен» куарга тырышалар, лөгать китапларыннан әллә нинди күгәреп беткән, күз күрмәгән, колак ишетмәгән сүзләрне өстерәп чыгаралар, һич булмаганда төрк сүзләрен азаплап, алардан фарсыча яки гарәпчә җәмгы сыйгалары[4] ясыйлар иде. Чөнки бу үзенә бертөрле «шик»[5] исәпләнә, мөмкин кадәр чуалчык вә авыр тел белән язу госманлы шагыйрьләренең «ма биһи әл-ифтихар»ы[6] булып киткән иде. Эш шул дәрәҗәгә барып җитте ки, кайбер шигырьләрдә төркчә сүзләрнең тәнасебе[7] йөздә[н] унга төште, ул сүзләр дә күбрәк ялгаулар белән алмашлардан гыйбарәт була иде. Моны күрү өчен:

Рухсарә[8] ки хат ганбәр[9] әфшан[10], габд хәбшидер ады рәйхан,
Ул халә сийаһ[11], билал вә ләбләр[12] – якут бере, бересе мәрҗан, –

дигән мисрагны алу җитсә кирәк.

Мәшһүр Явыз Солтан Сәлимнәр, Сөләйман Канунилар дәвере булган XVI гасыр Төркиясенең иң яхшы тасвир вә тәүсыйфын

[1] Мөнхәсыйр – камалган.
[2] Гаҗәм – иранлы, фарсы; чит халык.
[3] Әҗнәбилек – чит телләрдән кергән сүзләр.
[4] Сыйга – сүз формалары.
[5] Шик – бик яхшы эш.
[6] Ма биһи әл-ифтихар – мактаныч.
[7] Тәнасебе– туры килүе.
[8] Рухсарә – йөз, яңак, бит.
[9] Ганбәр – хуш исле сыекча.
[10] Әфшан – сибүче.
[11] Халә сияһ – кара миң.
[12] Билал вә ләбләр – юеш иреннәр.

(характеристикасын) бирүче шагыйрь – Рәванидер. Бу кеше – шагыйрь булуы белән бергә хәйләкәр бер сарай әһеле дә булып, зиннәт вә байлык сөюче адәм иде. Хәтта ул зур мәнсаблар[1] биләп торды. Шулчакта аның шактый әхлаксызлыкка мөбтәля булганлыгы да сизелгән. Шул хакта гаепләүчеләргә каршы ул, һич оялмыйча:

Йә Рәвани, күр, нәләр диделәр, бал тотан бармагын ялар, диделәр,
Кәгъбәйә бөйләчә зиярәт идән, дин вә дөньясыны япар, диделәр, –

дип җавап биргән иде. Рәванинең мәшһүр әсәрләреннән берсе – XVI гасыр Төркиясенең бөтен әхлакый түбәнлеген, аның фикер вә идеяләрен, зәвык, максат вә гаяи[2] хыялларын күрсәтә торган «Гыйшрәтнамә»седер. Бу шагыйрь үзенең әсәрләрендә, суфилык белән капланып, заманасының бөтен кабахәтлекләрен мактады, аристократиягә ярарга тырышып, Иран шагыйре Гомәр Хәйямгә тәкълидән[3], аракы, хатыннар вә уен-көлкене мәдех итте.

Бу классик дәвер госманлы әдәбиятына бик күп шагыйрь вә әдипләр бирсә дә, аларның әсәрләре күбесенчә бер нәрсәдән – урлау вә тәкрардан[4] гыйбарәт булды. Замандашлары бу шагыйрьләрдән «Шигъраи заман кем варе, бер-берендән угырлар әшгаре» дип көләләр иде.

Бу урында госманлы һәм чыгтай әдәбиятларының бер-берсенә мөнәсәбәтләре хакында берничә сүз әйтеп китәргә тиеш. Мәгълүм ки, төрк әдәбиятларының бу ике бөек тармагы, бер үк гасырларда диярлек бер-берсе белән янәшә яшәп, һәр икесе үз башына үсте вә тәрәккый итте. Тел вә мәдәни мохитнең башкалыгы, сәяси яктан да Төркия белән Мавәраэннәһернең рәкабәте[5], хәтта дошманлыгы, арада Иран шикелле зур бер чит халыкның ятуы бу ике әдәбиятка бер-берсе белән берләшеп, бер әдәбиятка әверелеп китәргә имкян[6] бирмәде. Ләкин шул ук Иран

[1] Мәнсаблар – хезмәт урыннары.
[2] Гаяи – чиктән тыш, төп.
[3] Тәкълидән – ияреп.
[4] Тәкрардан – кабатлаудан.
[5] Рәкабәте – көндәшлеге.
[6] Имкян – мөмкинлек.

алар арасында бер галяка[1] да иде. Чөнки һәр ике төрк әдәбияты тигез рәвештә Иран әдәбиятына тәкълид кылалар, андагы суфилык фикерләре белән сугарылалар, әдәби форма-өслүб вә тарзы ифадәне[2] иранлылардан алалар, телләрен фарсы сүзләре белән бертигез чуарлыйлар иде. Дәрвакыйг[3], һәр ике әдәбиятка кергән уртак гарәп-фарсы сүзләре алар арасында тел берлеге мәйданга килүгә сәбәп булды. Бу тел берлеге бер ул яктан гына да түгел иде, чөнки борынгырак дәвердәге госманлы әдәби телендә бик күп чыгтай сүзләре вә формалары истигъмаль ителә[4], шуңар күрә ике әдәби тел арасындагы аерма ул кадәр нык сизелми иде әле. XVI гасыр телендә инде Урта Азия тәэсире күзгә бәрелмәсә дә, элекке сәлҗук шагыйрьләре Вәләд Солтаннар, Гашыйк Пашаларның телендә генә түгел, хәтта XV гасыр язучысы Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия»сендә дә без әле чыгтайча тәэсирнең бик куәтле булганлыгын күрәбез.

Урта Азия төркләре белән гарби төркләр арасында мәдәни мөнәсәбәт һәрвакытта булып тора, гыйлемнәрен төгәлләр өчен госманлылар Мавәраэннәһергә баргалыйлар, шагыйрьләр дә Урта Азияне зиярәт иткәлиләр, шулай ук чыгтай шагыйрьләре дә Төркиягә киләләр, бәгъзылары шунда калып, сарай шагыйрьләре урынын тоталар иде.

Менә шундый мәдәни галяка[5] аркасында бәгъзы бер чыгтай шагыйрьләренең әсәрләре Төркиягә килеп (бигрәк тә Нәваи) госманлы укучылары арасында тәгъмим ителде[6]. Нәваинең госманлылар каршында кадер вә игътибары аларның үзләре арасыннан чыккан бөек шагыйрьләрнекеннән һич ким түгел иде[7]. Хәтта, Нәваинең шигырьләрен аңлар өчен, аның телендәге чыгтай сүзләренә госманлыча мәгънә бирә торган лөгать китаплары да төзелде.

[1] Галяка – бәйләп торучы.
[2] Тарзы ифадәне – аңлатуны, сөйләү стилен.
[3] Дәрвакыйг – чынлап та.
[4] Истигъмаль ителә – кулланыла.
[5] Галяка – бәйләнеш.
[6] Тәгъмим ителде – таралды.
[7] Солтанның Нәваигә матди булышлык күрсәтүе дә мәгълүм. *(Авт. иск.)*

Шулай ук бөтен төрк дөньясы өчен уртак булган икенче бер атаклы зур шагыйрь булса, ул да – Физулидыр. Физули элек – Азәрбайҗан төркисенчә, соңрак таба госманлыча язды. Шуңар күрә госманлылар аны үз шагыйрьләре итеп хисаплаганнары шикелле, азәрбайҗан татарлары да үз әдипләре рәтеннән санныйлар. Башка төрк илләрендә укылганы шикелле, аның диваны безнең ерак шималь иленә дә килеп, татар укымышлысының яратып укый торган китапларыннан булып китте. Физули XVI гасыр кешесе булса да, ул Истанбулның исрафлы вә тантаналы хәятыннан еракта (күбрәк Багдад шәһәрендә) яшәде. Гаять самими бер лирик булуына, өслүбенең нәфасәтенә[1] карамый, бу шагыйрь дә госманлы әдәбиятына яңа бер фикер вә тойгы бирмәде. Аның әсәрләре шул ук тәсаувыф идеологиясе белән тулган иде. Аның иң мәшһүр әсәрләреннән булган «Ләйлә вә Мәҗнүн»е – гарәп хорафатыннан алынып, Иран призмасы аркылы үткәрелгән бер гыйшкый поэмадыр. «Бәнг бадә» (Хәшиш һәм шәраб) исемле әсәре дә суфилык әсасенә бина кылынган кинаяле бер әсәр булып, анда исерткечләрнең падишасы – шәраб – башка төрле кәеф бирә торган нәрсәләр белән бәхәсләшә. Физулиның шигырьләреннән бер кыйтганы монда күчереп үтәбез:

И күңел яры, эстә хандан кич,
Сиркәдин[2] күзәт җиһандан кич.
Ятмаг кәс хәят зәүкындан,
Ялаб ләгыль[3] дилситандан[4] кич.
Мәсләк тәҗриддер[5] фәрагать[6] уй
Тәрке мал[7] илә ханәмандан[8] кич.
Лә мәкянә сирәк газимәтең[9] ит,

[1] Нәфасәтенә – гүзәллегенә.
[2] Сиркәдин – йөз сөрмәсе аша.
[3] Ләгыль – ал, кызыл төстәге кыйммәтле таш.
[4] Дилситан – йөрәкне сагышландыручы; гүзәл.
[5] Тәҗрид – дөньядан ваз кичү, аскетлык.
[6] Фәрагать – эштән бушау, ял итү.
[7] Тәрке мал – байлыкны, малны читкә кагу.
[8] Ханәман – гаилә, өй җәмәгате.
[9] Газимәтең – ниятләп куюың.

Бу хараб улачак мәкяндән[1] кич.
Әһле дөньяның улмаз ахирәте,
Гәр буны эстәр исәң, андан кич.
Мескен безем кян вә хиддәтдер[2],
И Физули, бу хакидандән[3] кич.

Физули никадәр матур өслүбле, самими шагыйрь булмасын, төрк әдәбияты мөәррихләре[4] тарафыннан классик шагыйрь хисапланмый. Шуңар күрә дә әгәр без, Төркиянең XVI гасыр әдәбиятын сөйләгәндә, госманлы әдәбиятының иң зур классикларыннан булган мәшһүр Бакыйны (1600 [елда] вафат) искә алмый китсәк, хата иткән булыр идек.

Бакый – заманасының бер галим рухание һәм Хафиз Ширази тарызында[5] язучы лирик шагыйре иде. Ул үзе гади генә бер мәзиннең гаиләсеннән чыккан. Нәселле, мәгълүм кеше баласы булмаганга, башта озак вакыт төрек җәмгыяте аны танырга теләмәде. Бары тик шул дәвернең башка шагыйрьләре шикелле, солтан Сөләйман Канунига мәдхия касыйдәсе язып биргәч кенә, аны күзгә алдылар, шуннан соң гына ул бераз матди тормышын рәтләп, шөһрәт алып китте. Химаячесе Сөләйман үлгәч тә, ул, 34 ел яшәп, үзе дә шигырь язып маташучы исерек солтан Сәлим II, аның сөяркәсе – шагыйрә Хөбби Хатын һәм суфи шагыйрь Морад III заманнарында, шигырь язуның иң мәкъбүл[6] булган бер дәверендә гомер кичерде.

Бакыйны төрек тәзкирәчеләре генә түгел, хәтта Яурупа мөстәшрикъларлары да мактыйлар. Өслүбенең матурлыгына, тойгысының байлыгына игътибар итәләр. Ләкин һаман да шул бу кешене теле ягыннан, төрек шагыйре дип әйтүдән бигрәк, Иран шагыйре дияргә туры килә. Аның бәгъзы шигырьләрен гади төркчә белүче генә түгел, хәтта фарсы теле вә әдәбияты белән шактый

[1] Мәкяндән – урыннан.
[2] Хиддәт – ачулану, кискенлек.
[3] Хакидан – дөнья; чүплек.
[4] Мөәррихләре – тарихчылары.
[5] Тарызында – стилендә.
[6] Мәкъбүл – кабул күрелгән, яраклы.

таныш кеше дә бик читенлек белән генә аңлар. XV–XVI гасырның кайбер госманлы шагыйрьләрен аңлар өчен, әле гарәп вә фарсы телләренә беркадәр әшна булу җитсә, инде Бакыйны укып аңлар өчен, кулга лөгать китабы тотып утырмый мөмкин түгел. Моны күрсәтү өчен, түбәндә аның бер шигыренең кисәген күчерәбез дә астына татарча тәрҗемәсен дәрҗ итәбез[1]. Бакыйның күбрәк әсәрләре шундый тел белән язылган:

Сакыййа җаммы нәхуш гөл улыр,
Дәстенә кем алырсә, былбыл улыр.
Дир ки, күрен тазәдагы башымда,
Нә гүзәл кырмызи кырынгол улыр.
Гамь зөлфәлеклә дәүд аһ кәбүд
Ля җөрде латыйф сөнбел улыр.
Рөштәи мәви дилбәрә туламыш
Бәстәи бәнд зөлфкә гөл улыр.
Бакый йә аб васаллек ирмәзсә
Атәш һөҗрилә янар гөл улыр.

Мәгънәсе: И шәраб коючы! Шәраб савытың нинди матур гөл, / Кем генә кулына алмасын – былбыл була. / Башымдагы яңа җәрәхәтләрне күргән кеше: нинди матур кызыл канәфер икән, ди. / Синең бөдрәләреңнең кайгысы белән чакырылган аһларның зәңгәр төтене латыйф сөнбелләргә әйләнә. / Гүзәл кызның чәчәкләренә чолганган кеше аның бөдрәләренең чылбырларына богауланып әсир була. / Бакыйга синең кавышу суың ирешмәсә, аерылышу утына янып, көл булыр ул.

Шунысы гаҗәп бер тәсадеф[2] ки, Бакыйның үлгән елларыннан Төркиянең инкыйраз, артка китү дәвере башлана. Шул дәвер башлану белән, әдәбиятта тәкрар, тәкълид вә тойгысыз шигырьләр хасил кылынып кала. XV–XVI гасырлардагы госманлы әдәбияты Иранның тәсаувыф әдәбиятының кире җырлануыннан вә бик оста тәкълиденнән гыйбарәт булды. Бу бабта төркчәләтеп нәрсә әйтергә мөмкин булса, һәммәсе әйтелде.

---

[1] Дәрҗ итәбез – теркибез.
[2] Тәсадеф – туры килү.

XVII гасырда да сансыз күп шагыйрьләр шул ук иске мәүзугларга[1] бихисап шигырьләр яздылар, чәйнәделәр, тәкрарладылар. Ахырда сүз бетте дә, ап-ачык рәвештә бер-берсеннән урлашу башланды. Шулай итеп, госманлыларның икътисад вә сәясәтләре төсле үк, әдәбиятлары да акрын-акрын инкыйразга йөз тотты. Шигырь шигърияттән югалта барды, әмма назымның модасы кабарганнан кабарды. Назымчылык шул дәрәҗәгә барып җитте ки, рәсми канцелярия язуларын көйләп язучылар да табылды. Мәсәлән, мөфти Сәгъдеддин – XVII гасыр башында Кырым ханына язган рәсми кәгазьләрен, 1625 елдагы Иран сәфәренең баш команданы Хафиз Паша үзенең гаскәр сорап солтанга язган хатларын назым белән язганнар иде. Бу түбәнләшүне хәтта XVI гасырның ахрындагы төрк тәнкыйтьчеләре (тәзкирәчеләр) дә аңладылар. Мәсәлән, шулардан берсе (Латыйфи) бу хакта шундый фикерләр бәян итә: «Хәзер сәнгать һәм гыйлем алучысы булмаган мал төсле... Матурлыкны һәм яхшы әсәрләрне аңлау зәвыгы бетте. Бер вакытта яшь булган кеше бара-бара картайган төсле, шигырь галәменең иягенә дә хәзер сакал чыкты. Нәкъ кирәкмәгән бер язулы кәгазь кисәге яки хатыйпларның амбарда күгәреп ята торган кылычы төсле, гыйлем ташланды...»

Без моңар кадәр госманлы әдәбиятындагы шигырь һәм шагыйрьләр хакында гына сөйләп килдек. Ләкин аларда, әлбәттә, нәсери әсәрләр һәм нәсер белән язучы мөхәррирләр дә бар иде. Бары тик, гомумән, шәрык халыкларындагы шикелле аларда да нәсер һәрвакытта әдәбиятта икенче, түбәнрәк урынны тотып килде. «Әдәбилек» мәфһүме[2] госманлы төркләрендә «көйлелек» белән бик нык бәгланган иде. Шуның өчен нәфис әдәбият бабында нәсер шигырь артыннан өстерәлеп кенә барды. Нәсери әдәбият әсәрләре булган, гомумислам Шәркындә таралган кыйсса вә хикәя китаплары шактый иртә госманлы теленә тәрҗемә ителеп, күбрәк даирә укучыларга азык булды. «Әлфе ләйлә вә ләйлә», «Тутыйнамә», «Кабуснамә», «Кәлилә вә Димнә»,

[1] Мәүзугларга – темаларга.
[2] Мәфһүме – төшенчәсе.

«Әл-фараҗ бәгъдә-ш-шиддәт», «Кырык вәзир» шикелле кыйссалар төркчәгә әйләндерелде.

Бер такым исемсез язучылар «Китабе Коркыд», «Сәид Баттал Гази», «Сары Салтык Гази», «Фәттахетдин», «Хәзрәте Гали», «Әбүгалисина» кыйссалары шикелле халык авызында («мәддах»лар тарафыннан) сөйләнеп йөргән хорафи дастаннарны, мәшһүр «Хуҗа Насретдин» ләтыйфаларын[1] язып алып, китапларга теркәделәр. Күбрәк Иран әдәбиятыннан алынган һәртөрле парлы гашыйклар хакындагы романтик поэмаларны халык аңлардай хәлгә китереп садәләштерделәр. Шулай итеп, безнең «Таһир-Зөһрә» вә «Бүз егет»ләр тибындагы текстлары – нәсер белән, диалог вә монологлары назым белән язылган аерым бер тип вак рисалә – кыйссалар мәйданга килде. Югарыда сөйләнгән хорафи дастан вә хикәяләр белән бергә, алар ярым-йорты укымышлы авыл вә шәһәр гаммә укучысы өчен бердәнбер әдәби материал булып хезмәт иттеләр. Югары даирәләр Бакый, Рәвани, Мәсихиләрне укып шашкан вакытта, түбән катлау укучылар шушы исемсез мөхәррирләрнең әсәрләрен укып кәефләнделәр. Әлбәттә, аларның теле дә тегеләрнекенә караганда күп җиңел, гарәп-фарсы белән аз таныш укучыга да аңлашылырлык иде. Ул әсәрләрнең «Коркыд» шикелле бәгъзы бик искеләре бара-тора истигъмальдән[2] чыгып, халык арасыннан югалдылар. Ләкин күбрәге, соңгы елларга кадәр тәкрар-тәкрар ташбасма белән сары кәгазьгә басылып, арзанлы нәшрият рәвешендә госманлы гаммәсе арасында таратылуда дәвам итте. Бу төрле әсәрләрнең бик күбесе, безнең Русиягә дә китерелеп, Идел буе татарлары өчен дә җирле әдәби ярлылыкны каплый торган ямау ролен уйнап килделәр.

Моннан башка тагы госманлылар, Иран шагыйрьләренең әсәрләрен тәрҗемә кылып, аларга озын-озын шәрехләр яздылар. «Тәзкирәт әш-шугараи» исемендәге әсәрләрдә үзләренең шагыйрьләренең тәрҗемәи хәлләрен язарга керештеләр. Бу китаплар госманлыларда әдәбият тарихы урынын тотып килде.

[1] Ләтыйфаларын – анекдотларын.
[2] Истигъмальдән – кулланылыштан.

Башка мөселман халыклары шикелле үк, госманлы төркләре үзләренең милли тарихларына да әһәмият бирделәр. Сәлҗук төркләренең үткәнен сөйләгән тарихи бер әсәр XIV гасырның башларында ук зоһур иткән[1] иде. Соңра тарих гыйлеме аларда сөеп укыла торган әйбергә әверелеп китеп, тарих язу да бер гадәт хөкемен алды. Морад II заманасында тарихчылык өчен сарайда «Вәкаиг нәүвис» аталган аерым бер мәнсаб[2] та төзелде. Шуның нәтиҗәсендә калын-калын, әмма падишаһларга тәлинкә тотып язылганга, күп вакытта тарихи хаталар белән тулган тарих китаплары мәйданга килде.Госманлы телендә башка шәрык халыкларында модада булган җәгърафия гыйлеменә даир[3] әсәрләр дә язылды. XVII гасырның ахырында Әүлия Чәләби дигән кешенең «Тарихе сәйях»ы тасниф кылынды[4], XVI гасырның башында язылган, Пири Рәис дигән кешенең «Бәхрия»сендә Аталар диңгезе тасвир ителде. Сәет Галиәкбәр исемле кеше Кытай (Чин) хакында элек фарсыча бер әсәр язып, соңыннан төрекчәгә тәрҗемә кылды. Ниһаять, 1658 дә вафат булган, Яурупада «Хуҗа Хәлифә» ләкабе белән аталган мәшһүр библиограф Кятиб Чәләби үзенең җәгърафия вә тарихка даир «Җиһаннамә» исемле зур әсәрен вөҗүдкә[5] китерде. Моннан ике гасыр элек Төркиядә басмачылык эше башлангач, иң беренче басылган китаплардан берсе – кятиб Чәләбинең шушы «Җиһаннамә»се иде[6].

Тәмам.

[1] Зоһур иткән – барлыкка килгән.
[2] Мәнсаб – эш, хезмәт урыны.
[3] Даир – караган.
[4] Тасниф кылынды – төзелде.
[5] Вөҗүдкә – дөньяга.
[6] Госманлы әдәбияты хакында язганда файдаланылган әсәрләр:

1. Hammer. Geschichte der Osmanischen Gedichte, Bd. I.
2. Horm P. Die Orienalischen Literaturen. (Die Turkische Literatur).
3. Крымский А.Е. История Турции и ее литературы, тт. I и II.
4. Смирнов В.Д. История всеобщей литературы. Под ред. Корша, т. IV.
5. Его же. Образцовые произведения османской литературы. *(Авт. иск.)*

# ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

## ТАТАР ТЕЛЕ ВӘ ӘДӘБИЯТЫНЫҢ ТАРИХИ ЯЗМЫШЫ

### I

Идел елгасы буенда яшәп, шәрык вә гаребне бер-берсенә тоташтыручы, шәрык вә гареб мәдәниятен бергә кушучы мәдәният ташучы татар милләтенең мәдәнияте, аның кисәге булган фикере, әдәбияты шул фикерне җәюдә васита[1] булган теле тиз генә ясалмады.

Татарның җиреннән ага торган Идел елгасының җитез сулары шикелле Идел буе вә шәркый Яурупада татарларның бабалары төрле төрк халыклары тарихының озын гасырлары буенча мөттасил[2] агып, килеп-китеп тордылар.

Элек, Гайсәдән алда чакларда, төрк халыклары, Хәзәр диңгезе һәм Урал таулары артыннан кереп-чыгып, юнаннар, скиф, соңра румалылар, сармат[3] аталган күчмә халыклар арасында йөрделәр, соңра болар һун исеме белән миладидан соң II–IV гасырларда килеп чыгып үтеп киттеләр. Ләкин үзләренең эзләрен шәркый Яурупаның киң сахраларында калдырдылар: соңра төркләр авар исеме белән үтеп китеп, җәнүб сахраларында Дунай буйларында йөрделәр. VIII һәм IX гасырларда Хәзәр исемендә чын бер утраклы дәүләт ясап, шәрык вә гареб сәүдәсендә васиталык иттеләр. Шул ук чакта җәнүб сахраларыннан V гасырда болгар исемендә килеп, шималь урманнарына, Идел һәм Чулман елгаларының урта бер җиренә утырып, VIII–IX гасырда мәдәни бер дәүләт ясадылар: шул ук вакытта, IX–XI гасырларда, элек – пәчәнәкләр, соңра половец яисә кыпчак (коман)

[1] Васита – арадаш.

[2] Мөттасил – туктаусыз.

[3] Сармат – Тиса һәм Дунай елгасыннан Арал диңгезенә кадәр су аралыгының дала районнарында иртә Тимер гасыр (VI–IV гг.) азагында яшәгән күчмә кабиләләрдән торган халык.

аталган төркләр килеп чыгып, мәгъмүр[1] Хәзәр төркләре илен бетереп, XIII гасырда монголлар яисә татарлар командасында төркләр килеп, Алтын Урда дәүләтен ясаганчыга кадәр тордылар да, соңра бер кыйсеме Алтын Урда яисә кыпчак дәүләтенең эченә кереп, әүвәлге исемнәрен татарга алмаштырдылар, бер кыйсеме булса Мажарстанга мажар кардәшләре арасына кереп, бер-ике гасыр эчендә исемнәрен мажар вәкаигънамәләрендә[2] генә калдырып югалдылар... Шулай итеп, Алтын Урда бер өч гасырга шәркый Яурупадагы бөтен төрк гонсырын[3] җыйды... Ләкин бу интеграция (җыелу) процессы бетәр-бетмәс яңа юллар ачылып, Идел елгасы әүвәлге икътисади әһәмиятен югалту белән[4], яңадан дифференциация (бүленү) процессы башланды. Шуның нәтиҗәсе буларак, тарих сәхнәсенә, бер яктан, яңа төрк сәяси хәмиятләре: Кырым, Казан, Әстерхан, Нугай, Касыйм урдалары туды. Икенче яктан, кайсысы яңадан, кайсысы искедән булып та, Алтын Урда бар чакта күмелеп торган этнографик төрк гонсырлары мәйданга килде: Казан вә әтрафы татарлары, мишәрләр, башкортлар, нугайлар, Кырым татарлары, чувашлар. Әгәр Алтын Урда ясалганчы болгарлар шәркый Яурупаның төркләре арасында иң мәдәни бер гонсырлык, Яурупа империализмына каршы беренче истихкям[5] ролен ифа итеп[6] торсалар, Алтын Урда беткәч тә, шул ук Болгарстан хәрабәсе өстенә салынган Казан ханлыгы ике-өч гасыр бер мөддәттә[7] шул ук вазифаны үтәп торды. XVI гасырда озак вә канлы сугышлар, ничә елларга тартылган ихтиляллардан[8] соң Русиягә кушылгач, бу татар халкы иң авыр хәлдә яшәде. Мәхкүмиятнең иң каты

[1] Мәгъмүр – төзек.
[2] Вакаигънамәләрендә – елъязмаларында.
[3] Гонсырын – токымын.
[4] Бу хакта мофассаллырак мәгълүматны Г. Газизнең «Татар әдәбияты тарихы»нда табарга мөмкин. *(Авт. иск.)*
[5] Истихкям – ныгытма.
[6] Ифа итеп – башкарып, үтәп.
[7] Мөддәттә – вакытта.
[8] Ихтиляллардан – бунтлардан, фетнәләрдән.

зарбәсе[1] аның өстенә төште. Русиянең мөстәбид[2] царьларының, соңра император вә императрицаларның шәрыкны кол итәргә теләү сәясәтләренең иң элекке кизәнүләре Казан татарларына булды. Соңра гына ул сәясәт элек – башкортларга, соңра казакъ, үзбәк, төрекмән халыклары өстенә юнәлде... Ләкин Мәскәү, соңра Петербургның авыр ясаклары, иманаларның (подушная подать)[3] авырлыкларына, колонизаторларның татар җирләрен алуларына, чукынмаган өчен башка халыкка караганда берничә өлеш артык салым, артык рекрут бирү мәҗбүриятләренә, мәктәпләр салырга рөхсәт бирмәүләренә карамыйча, шәрыкның гаребкә ачылган капкасында торучы татарлар бабалары болгарларның вәрасәте[4] булган мәдәният ташучылыкны җуймадылар. Яшереп булса да мәктәп ачтылар, китап укыдылар һәм яздылар... Ниһаять, XIX гасырның соңында, бигрәк тә Русиянең беренче, икенче вә Октябрь революцияләре аркасында, этнографи бер гонсырлыктан чыгып, мәдәни бер милләткә әверелделәр...

Хәзер безгә, татарның үз әдәбиятына яисә аның әдәбиятына тәэсир иткән башка төрк кабиләләренең әсәрләренә күчкәнче, берничә мөһим мәсьәлә белән танышып китәргә кирәк. Ул исә безнең әдәбиятыбызны шактый ишгаль кылган[5], ләкин һаман да хәл кылынмаган «Татар кем?» сөаленә җаваптыр. Бу нәзари мәсьәләгә бертөрле караш ясамыйча торып, татар әдәбиятының тарихы аңлашылачак түгел.

«Татар» дигән сүзне без беренче мәртәбә VIII гасыр төрк мәнбәгъларыннан[6] булган Орхон язуларында очратабыз. Анда әйтелгән: «угыз будун утыз татар бирлә тәрелеп кәлти» (угыз халкы утыз татар кабиләсе белән берләште). Орхон язуларында сөйләнә торган «татарлар»ның угыз будуныннан аерым халык

[1] Зарбә – бәхетсезлек, зыян.
[2] Мөстәбид – изүче.
[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[4] Вәрасәте – нәселгә хас; мирасы.
[5] Ишгаль кылган – биләгән.
[6] Мәнбәгъларыннан – чыганакларыннан.

икәне күренеп тора. Угыз дип борынгы төркләрне атаганнары һәм бу исем төркләрнең «тотәм» (тотем)[1] булуы ихтималы – мәгълүм бер мәсьәләдер. Шуның өчен академик Радлов Орхон язуларындагы татарларны Онон (Онон)[2] буенда торучы монголлар булырга кирәк, ди.[3]

Кытайларның IX гасыр тарихи мәнбәгъларында «татар» исеме очрый. Алар аны «тата» һәм «tha-thaeul» рәвешендә язалар. Чөнки кытайлар «р» хәрефен әйтмиләр. Алар шуның өчен «төрк» дигән сүзне дә «ту-күә» рәвешендә язалар.

1604 елда нәшер ителгән кытайча зур энциклопедиядә шулай әйтелә: «Татарлар Шамо (Гоби) чүлендә торалар, болар юань исемле бәрбәрләрнең балалары; васлалар[4] да моның шимали гарбисендә күчмә тормыш кичерәләр, болар да тата халкына мәнсүб[5]. Мөстәшрикъ Клапрот[6] фикеренчә[7], юаньнар монголлар, әмма васлалар булса, шул ук монголларның бер кабиләсе булган калмыклардыр.

Моннан биш йөз ел элек Пекинда язылган «Кытай-фарсы лөгать китабы»нда «tha-ta» дигән сүзне «монгол» дип тәрҗемә кылынган. Гомумән, кытай мөәррихләренең сүзләренә күрә, борынгы заманда татарлар Кытайның шимали шәркыйсында торып, Mohho яисә монгол халкының аерым бер кабиләсе генә иде[8]. Вакыйган, безнең бу фикеребезне IX гасырда язылган бер кытай мәнбәгындагы шушы сүзләр куәтлиләр: «Алар (монголлар) кайсысы – әкә-монгол, кайсысы су-монгол дип аталып, соңгыларын үзләренең җирләре аркылы үтүче бер елга исеме

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[3] Опыт словаря тюрских наречий, том III, стр. 901. *(Авт. иск.)*

[4] Биредә сүз борынгы монгол кабиләләреннән саналган меркитларның бер этник төркеме – увас (хоас) кабиләсе турында бара. Бүген фәндә увaслар эвенкларның (борынгы атамасы тунгус) этногенезын формалаштырган төп кабиләләрнең берсе исәпләнә.

[5] Мәнсүб – нисбәтле.

[6] Клапрот Юлиус (1783–1835) – немец шәрыкшинасы, полиглот.

[7] Mémoires relatifs à l’Asie, Sur les Tatares, s. 462. *(Авт. иск.)*

[8] Ibd. p. 62. *(Авт. иск.)*

белән «татар» дип атыйлар: бу халыкларның телләре вә төсләре бертөсле, гәрчә аларның аерым падишалары булып, үзләре төрле җирләрдә торсалар да».

Әгәр без мөселман мәнбәгъләрын карасак, анда да шул ук кытай мәнбәгъләрынының фикерләренә мотәбәкать[1] күрәбез. Татарларның ислам галәменә һөҗүмнәре вакытында шул дәкыйкаларны[2] тасвир итүче Ибн әл-Әсир[3] монголларны татар дип йөри. Вакыйган, ислам галәменә һөҗүм итүче Һулагу[4] гаскәрләре эчендә «кара татар» күп иде[5]. Бу кабилә эченнән Чыңгыз хан чыкты[6]. Чыңгызның монголлыгында Леон Кахунның хыяллары белән бозылмаган һичкем шөбһә итмәс, билгеле!

XIII гасырда Яурупадан илче булып татарлар арасына барган монахлардан Рубрук һәм Плано Карпини да монголлар белән татарларны бер халык итеп йөртәләр. Мәсәлән, Карпини сәяхәтнамәсенең 12 нче бабында: «Дөресен әйткәндә, татарлар үзләрен монгал яисә монгол дип йөриләр», – ди. Югарыда сөйләгән сүзләрдән гареб вә шәрык мәнбәгъләрыннан күрдекке[7] «татар» дигән сүз «монгол» дигән сүз белән бер. Ләкин борынгы заман халыкларында, хәзерге шикелле, исемне бер мөгайян[8] бер җенестән булган халыкка әйтү булмаган. Ул заманда этнография фәне

[1] Мотәбәкать – туры килү, охшашлык.

[2] Дәкыйкаларны – минутларны.

[3] Гыйзеддин Әбү-л-Хәсән Гали, Ибн әл-Әсир (1160–1233/1234) – гарәп тарихчысы, 12 томлык «Әл-кәмил фи-т-тарих» («Тулы гомуми тарих») хезмәте авторы.

[4] Һулагу хан (1217–1265) – Чыңгыз ханның оныгы, монгол ханы. 1256 елда монголларның Иранга, Гыйракка һәм тирә-яктагы илләргә яулап алу сугышларын төгәлли.

[5] Кытай вәкаигънәвисе Мән-ра Бәй-лү яза: «Хәзерге император Чыңгыз, аның гаскәр башлыклары, вәзирләре һәм башка мәэмүрләре – барысы да кара татар [харачин] халкыннан». История и древности восточной части Средней Азии, В. Васильев (Труды Вост. Арх. Съезда, ч. 1, с. 217). *(Авт. иск.)*

[6] Радлов В.В. Опыт словаря тюрских наречий, III, 901, Vamberi, Der Ursprung der Magyaren, s. 436. Вамбери бу мәгълүматны Тимерләннең тәрҗемәи хәлен язучы Шәрәфетдиннең «Зафәрнамә»сеннән ала. *(Авт. иск.)*

[7] Күрдекке – без күргән.

[8] Мөгайян – билгеле, анык.

юк. Халыкларны да күп вакытта сәяси берлек ясау, шул берлекнең башында утырган сөляләнең[1] мәнсүб булган кабилә вә ыругы исеме белән атау гадәт иде. Шуның өчен дә, мәсәлән, мәшһүр Рәшид әд-Дин[2] «Җәмигъ әт-тәварих»ендә «төрк» дип бөтен «сахра нишин»[3] халыкларны атый. Шулай булса да татарларның арасында төркләр дә бар. Мәсьәлә шулай: татарлар берничә кисәккә бүленәләр: кара, чаган яисә ак татарлар, буйсынмый торган (вәхши) татарлар[4]. Ак татарлар – төрк җенесеннән. Кытай мәнбәгъларының хәбәрләренә күрә, Чыңгыз заманасында ак татарларны Алагуз исемле кеше идарә кылып торып, бу кеше үзенең нәселенең ту-күә ханнарыннан килгәнен сөйли, имеш[5]. Мәгълүм ки, ту-күәләр – төркләрдер: Орхон язулары шуларныкы, ләкин, һәрхәлдә, Чыңгыз империясен ясаучы гонсырның башында ак татарлар түгел, бәлки кара татарлар, димәк, монголлар торалар.

Ни өчен бер үк халыкка «монгол» һәм «татар» дип исем кушканнар?

«Монгол» сүзе бик борынгы заманнан бирле булса да, хәзерге монголларның бабаларының милли атлары[6] булмаган. Бары тик Тимучин 1206 елда императорлык ләкабен[7] алып, Чыңгыз хан булгач кына, бу исем бөтен монгол халкына гам[8] ат булып киткән. Шул вакытка кадәр монголларны татар дип йөргәннәр[9].

Билгеле, монда кадәр сөйләнгән сүзләр – бер гипотеза гына. Шулай да шактый көчле бер ихтимал. Ләкин безгә татарның

[1] Сөляләнең – ыруның.

[2] Рәшид әд-Дин (1247–1318) – фарсы телендә язган тарихчы, дәүләт эшлеклесе. «Җәмигъ әт-тәварих» («Җыелма тарих») хезмәте авторы. Хезмәттә XII–XIII йөзләрдәге Үзәк Азия белән Урта Көнчыгыш илләре тарихына һәм монгол яуларына караган бай мәгълүмат тупланган.

[3] Сахра нишин – сахра ияләре, сахрада яшәгән.

[4] Васильев В.П. История и древности восточной части Средней Азии..., с. 216. *(Авт. иск.)*

[5] Klaproth. Sur les tatares. 470. *(Авт. иск.)*

[6] Атлары – исемнәре.

[7] Ләкабен – титулын.

[8] Гам – гомуми.

[9] Васильев В.П., с. 159. *(Авт. иск.)*

башта монголмы, төркме булуы мәсьәләсеннән бигрәк, ничек итеп шәркый Русиядә торучы төркләргә «татар» исеме кушылган – шунысы мөһим.

Шәркый Яурупага Җүҗи баласы Бату хан[1] командасында берничә мең татар килгән. Болар килеп, коман (кыпчак) вә болгарларга баш булганнар. Шуларның исеме белән мәхкүм халыкларны да «татар» дип йөри башлаганнар[2]. Ләкин бу монголлар исламият X гасырдан ук нык урынлашкан болгарлар арасына һәм исламият шактый таралган команнар арасына килеп утыргач, боларга халык берничә заман, дошманлык белән, мәҗүсиләр һәм истиля итүчеләр[3] дип караганнар. Килмешәк монголлар да, Чыңгыз кабиләсе «кара татар»лардан килгәнлекләре өчен үзләрен бик зур хисаплап, җирле төп төркләргә өстән торып караганнар: шуның өстенә дә алар чын монгол – мәҗүс «Ясанамә»сенең хөкемнәрен кыпчак вә болгар төркләре арасына җәяргә тырышканнар. Дөрес, «Ясанамә»нең хөкемнәре монголлар шикелле үк күчмәле булган төркләрнең хәятына туры килә торган булса да (чөнки «Ясанамә» гадәт хокукына бинаән итеп ясалган), алар арасында инде мөселман руханилары аркылы шәригать шактый таралган булганга, һәм бу мәсьәләдә монголлар белән җирле төркләр арасында беркадәр дошманлык булган булуы ихтимал. Бәлки, шуның нәтиҗәседер, безнең халык үзен әле дә татар дияргә яратмый. Бәлки телен төрки теле, ди: шулай ук безнең халык мәкальләре арасында татарга каршы булган мәкальләр очрый... Бу мәсьәләне XIX гасырда язучы мөстәшрикъләр дә сизгәннәр[4].

[1] Бату хан (1207 тирәсе – 1256) – Алтын Урданы нигезләүче хан, Чыңгыз ханның оныгы, Җүҗинең улы. Атасы вафатыннан соң олыс идарәчесе (1227). Монгол империясе корылтае кушуы буенча, Идел буе Болгарына, рус кенәзлекләренә һәм Көнбатыш Европа илләренә яулар оештыра.

[2] Рәшид әд-Дин фикеренчә, татарларның шәүкәт вә даннары бик шәп булганга, бик күп җирдәге төрк кавемнәрен дә, фил-җөмлә башкорт вә Дәште Кыпчактагы төркләрне дә «татар» дип атаганнар. *(Авт. иск.)*

[3] Истиля итүчеләр – басып алучылар.

[4] Мәсәлән, Вамбери һәм Клапрут. *(Авт. иск.)*

Шәркый Яурупага килгән монголлар бик аз булганга[1], бигрәк тә 1269 елларда Кублай[2] заманасында Чыңгыз ясаган дәүләттә берлек беткәч, Алтын Урда истикъляллият[3] алгач, Монголиядән яңа монгол гаскәре килмәс булды. Килгән монголлар да акрынлап төркләштеләр. Хөкүмәт ярлыкларын бик иртә төркчә яза башлады. Инде XIV гасырда Ибн Баттута[4] килгәндә, Үзбәк ханның сараенда төркчә сөйләшәләр иде. Шулай итеп, татарлар төркләштеләр. Идел буендагы халыкларны «татар» дип атый башладылар: нәкъ асылда эслау[5] җенесеннән булган Дунай болгарлары – болгар төркләре кул астында торып, болгар исеме; эслау руслар – рус кабиләсеннән норман кенәзләре кулы астына керүләре белән «рус» исеме; галлар франклар истилясы[6] соңында «француз» исеме кабул иткәннәре шикелле, шәркый Яурупа төркләре дә, татар-монголлар кул астына кергәч, «татар» исемен кабул иттеләр.

**II**

Бу кыска мәкаләдә хәл итәргә кирәкле мәсьәләләрнең янә берсе – татар теленең ясалуы мәсьәләседер. Бу мәсьәләгә җавапны мөәррихтән бигрәк тел мөтәхассыйсе бирергә тиеш. Шулай булса да, бу хакта без татар теленең ясалу процессын тикшереп багабыз. XIII гасырда Алтын Урда яисә кыпчак ханлыгы ясалганчы, тәхминән төрк халыклары хәзерге Русия туфрагында

[1] Мәнбәгълар буенча, беренче Яурупага килгән татар гаскәрендә утыз мең монгол булган, чөнки Үгәдәй ханны сайлаган корылтайның кыпчакны алырга шул микъдарда гаскәр бирергә дигән карары мәгълүм. Hammer-Purg stahl, Geschichle der Goldenen Horde, s. 99 *(Авт. иск.)*

[2] Хубилай (1215–1294) – Чыңгыз ханның оныгы, Монгол империясенең ханы (1260–1271), Юань дәүләтенә нигез салучы, Юань династиясеннән Кытайның беренче императоры.

Марко Поло китапларында Кублай хан исеме астында телгә алына.

[3] Истикъляллият – бәйсезлек.

[4] Ибн Баттута Әбү Габдуллаһ Мөхәммәд ибн Габдуллаһ әл-Ләвати әт-Танҗи (1304–1377) – гарәп сәяхәтчесе. 1334 елда Алтын Урдага килә, Болгарны күрә, берникадәр вакыт Үзбәк хан даирәсендә яши. «Төхфәт ән-наззар фи гараиб әл-әмсар вә гаҗаиб әл-әсфар» («Төрле шәһәрләр һәм сәфәрләрдә гаҗәеп хәлләргә шаһит булучыларның бүләге») исемле сәяхәтнамә авторы.

[5] Эслау – славян.

[6] Истилясы – басып алуы.

шулай торалар, хәзерге җәнүби Русиядәге Дон-Днепр арасында вә Малая Русия[1] сахраларында, Иделнең түбәнге агымының уң ягындагы сахраларда төрле исемдә төрк җенесеннән булган халыклар күчеп йөриләр. Аларның исемнәре төрле иде: пәчәнәк, коман (половец яисә кыпчак), гуз (яисә угыз, уз). Төрк (Торки)[2] халыклары, бу халыкларның телләре хакында без аз беләбез. Шулай да мәнбәгълар пәчәнәк теле коман теле төсле булганын сөйлиләр. Мәгълүм ки, коман теле «Кодекс куманикус» мәҗмугасы[3] табылу аркасында безгә мәгълүм шималь төрки теленә, бигрәк тә хәзерге Казан татарчасына бик якын. Аның җәнүб төркисе булмаганлыгын безгә Яурупа сәйяхларыннан Рубруквис та тәэкид кылып[4]: «Уйгур теленең әсасы һәм әмере – төрк һәм коман теледер»[5], – ди. Дөрес, Рубруквис бер тел галиме түгел, шулай булса да, мондый сүзне әйтү өчен, ул коман телен үзе белеп яисә коман телен белүчеләрдән ишетеп әйткән булыр. Һәрхәлдә, коман телен белгән кеше, уйгурлар белән сөйләшкәндә, аларны аңласа гына, бу сүзне әйтергә тиеш. Эш, вакыйган, шулай да. Минорит орденының бер министры яза: «Мин, (дингә өндәргә китәргә) карар кылгач та, элек илнең телен өйрәнергә карар бирдем һәм Алланың гыйнаяте белән коман телен һәм уйгур литературасын өйрәндем ки, бу илләрнең барчасында да шуның белән файдаланалар»[6]. Димәк, соңра татарлар килеп чыгып, Алтын Урда дәүләтен ясагач, уйгур теленә якын телдә ярлыклар чыгара башлауларының

---

[1] Малая Русь, Малая Россия, Малороссия – хәзерге Украина, өлешчә Россия, Белоруссия һәм Польша территорияләренең тарихи атамасы.

[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[3] «Кодекс куманикус» («Codex Cumanicus» – «Коман мәҗмугасы») – XIII йөз ахыры – XIV йөз башы кыпчак телендәге язма ядкәр. Христиан миссионерлары тарафыннан төрки телләрнең көнбатыш һун тармаклары сөйләм теленә нигезләнеп төзелә. Латин-фарсы-коман һәм коман-немец сүзлекләрен, кыпчак грамматикасыннан мәгълүматларны, кыпчак теленә тәрҗемә ителгән Тәүрат хикәятләрен үз эченә алган ике дәфтәрдән гыйбарәт.

[4] Тәэкид кылып – раслап.

[5] Языков Д.И. Собрание путешествий к татарам, с. 27. *(Авт. иск.)*

[6] Голубовский П.В. Печенеги и половцы до нашествия Татар, с. 154. *(Авт. иск.)*

сәбәбе дә, бер яктан, уйгур теленең Чыңгыз канцеляриясендә истигъмаль кылынган булуы булса, икенче яктан, югарыда күренгәнчә, коман-кыпчакларга якын тел булуыдыр.

Калган халыклардан гуз, уз халыклары исә, мөәррих Голубовскийның[1] исбат кылуына күрә, рус летописьларында әйтелә торган Торки[2] дигән халыклар белән бер халыклардыр[3]. Голубовскийның дәлилләрен бу урында китермичә, шуңарга гыйлавә[4] итеп, шуны гына әйтергә кирәк ки, Орхон язуларыннан «угыз будуны»ның «төрк будуны» белән бер халык булганы сизелә: димәк, бу да бер дәлил була ала. Әмма «угыз» белән «гуз» янына «уз» сүзләренең бер үк сүз икәне ачык мәгълүм. Юнанча һәм латинча мәнбәгълар «гъ» авазын яза алмаганга, «уз» яисә «гуз» рәвешендә язганнар. Бу төрк кабиләсе IX һәм X гасырда Урта Азиядә булып, соңра җәнүби Русия сахраларына килеп чыкты. Безнең фикеребезчә, болар җәнүб төркләре шивәсендә сөйләшкән булырлар. Моңарга бер дәлилебез бар: Бизанес мөәррихләреннән Михаил Атталиятның[5] әйтүенә күрә, Рум кайсары сәлҗук солтаны белән сугышкан чакта, Бизанес ягыннан төрк узлар сугышканнар, һәм төрк узлар белән сәлҗук төркләре – бер үк халык: хәтта сугыш вакытында узлар (угыз) исә, үз кардәшләре белән сугышмыйча, сәлҗукыйлар ягына чыкканнар[6]. Шәрык мәнбәгълары дә сәлҗукыйларның «угыз» төркләре җөмләсеннән булганлыкларын бәян итәләр[7]. Сәлҗукыйларның телләре безгә бик мәгълүм. Алар хәзерге госманлы төркләренә кардәш бер халык булганлыкларыннан, җәнүб төрки теле белән сөйләшкәннәр.

---

[1] Голубовский Петр Васильевич (1857–1907) – тарихчы, архив материаллары һәм елъязмаларга нигезләнеп, Россия территориясендә IX–XIII гасырда яшәгән халыклар турында тарихи хезмәтләр яза.

[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[3] Geza Cuun. Codex Cumanicus, p. XLI. *(Авт. иск.)*

[4] Гыйлавә – өстәмә.

[5] Михаил Атталият (якынча 1030–1085) – Византия тарихчысы һәм хокук белгече.

[6] Голубовский П.В.? С. 150. *(Авт. иск.)*

[7] Vamberi. Das Turkenvolk, s. 595. *(Авт. иск.)*

Монда сөйләнгән сүзләрдән безнең мәсьәләгә даир бер кирәкле нәтиҗә чыга: IX гасырдан алып XIII гасырга кадәр җәнүби Русия төркләре арасында ике төрле шивәдә сөйләшүче төркләр булган: җәнүб һәм шималь яисә гареб төркләре. XI гасырда команнар килгәндә, угызлар күренмәсәләр дә, билгеле, аларның шивәләренең тәэсирләре булган булыр: бәлки, алар, команнар тарафыннан җиңелгәч, һаман да шуларның кул асларында торганнардыр. Ләкин команнар сәяси җәһәттән галиб[1] һәм күпчелек тә алар ягында булганга, Алтын Урда дәүләтендә коман телендә сөйләшүче күбрәк булгандыр. Шулай булса да җәнүб төркчәсе белән сөйләшүче кабиләләр булуы да бик ихтимал (Казан ханлыгында татар, мишәр вә чуваш шивәсе белән сөйләшүчеләр булганы шикелле).

Хәзерге Яурупа Пруссиянең шәркында, Иделнең түбәнге агымында, җәнүбтән Кавказ тауларына кадәр, шимальдән Урал тавы яннарына хәтле булган урыннарда Хәзәр дәүләте бар иде. Бу дәүләт, күчмә төркләр һәм норман-русларның талавы аркасында икътисади куәте беткәч, XI гасырда бетәргә йөз тотты. Бу халыкның төрк җенесеннән булганы безгә мәгълүм булса да, шивәләрендә хәзергә кадәр бертөрле дә мәнбәгъ табылмаганга, бер катгый карар чыгарыр хәл юк. Алай да Хәзәр хаканы Йосыфның[2] X гасырда Әндәлес хәлифәсенең сарай табибы, галим яһүд Хасдай ибн Шапрутка[3] язган хатында үзләренең нәселләре хакында сөйләгәндә: «Мин үземнең атамның шәҗәрәсендә таптым ки, Тугарманың ун улы булган, менә аларның исемнәре:

1. Иң олысы – Уйур.
2. Икенчесе – Авырбәз.
3. Өченчесе – Аваз.
4. Дүртенчесе – Угыр.

.................................

[1] Галиб – өстен.

[2] Йосыф каһан (? – 965 тән соң) – Хәзәр дәүләте идарәчесе. Аның Хасдай ибн Шапрут белән алышкан хатлары борынгы болгарлар һ.б. Идел буе халыклары турында мөһим мәгълүмат бирә.

[3] Хасдай ибн Шапрут – Испания хәлифәсенең сарай тарихчысы.

7. Җиденчесе – Хәзәр.

...................................

9. Тугызынчысы – Болгар[1]», –

ди дә «Мин – җиденче улы Хәзәр хәләфе[2]», – ди. Вамбери «уйур», «угур» дигән сүзләрне «уйгур» һәм «угыз» дип ала[3]. Әгәр эш болай булса, хәзәрләр үзләрен уйгур һәм угыз һәм болгарлар белән бер җенестән дип йөргәннәр. Ләкин бу сүз, хәзәрләрнең гомумән төрк булуларына дәлил булса да, аларның төрк теленең нинди шивәсе белән сөйләшүләренә дәлил була алмый. Шулай ук Бизанес мөәррихе Феофилның «шәркый төркләре, ягъни хәзәрләр» дигәне хәзәрләрнең уйгур теленә якын бер тел белән сөйләшү ихтималларын күрсәтсә дә, бертөрле дә катгый мәгълүмат бирмәве өстенә Истахринең[4] «вә лисан әл-болгар....» дигән сүзе тагы мәсьәләне чуалта.

Болгарларның теле мәсьәләсе тагын да чуалчыклырак. Бу хакта без болгар кабер ташлары хакында түбәндә киләчәк мәкаләбездә озаграк туктадык. Фараз итик тә, болгарларның теле хәзерге чуваш шивәсенә якын булсын. Алай булгач, VII гасыр һиҗридә язылган чувашча бер дә катышмаган күп кенә ташларның теле кайдан килгән? Ничек итеп болгар теле, хәзерге истыйлях[5] белән әйтсәк, татарлашкан? Ничек итеп, мәсәлән, шундый язу язарлык чыгтайчага тартым татарча тел килеп чыккан: «Бүләртай ибн Белемшак бик зиярәте торыр Тәңрегә мәсрүр кылып кәүсәр шәрабе берлә кандырсын. Вафаты рәҗәб ахырында тарих йите йөз егерме түрттә»[6].

Монда өч төрле процесс булган булуы ихтимал: 1) татарлар килгәнче үк болгарларның үз телләре шулай булып, бәгъзы ташларда табыла торган «җийат җүр»ле[7] ярым татарча, ярым

[1] Монда барысын да язып тормадык. *(Авт. иск.)*

[2] Хәләфе – киләчәк буыны, нәсел дәвамчысы.

[3] Ursprung der magyaren, 78. *(Авт. иск.)*

[4] Әбү Исхак Ибраһим ибн Мөхәммәд әл-Истахри (908 елга кадәр – 951 елдан соң) – гарәп географы. 930–933 еллар тирәсендә география буенча «Китаб әл-мәсалик вә-л-мәмалик» («Юллар һәм илләр китабы») язган.

[5] Истыйлях – атама.

[6] Березин И.Н.. Булгар на Волге, с. 38. *(Авт. иск.)*

[7] Болгар теленнән «җиде йөз» дип тәрҗемә ителә.

чувашка тартым тел – чын болгарныкы түгел, мөселман булган чувашларның теле, 2) болгарлар, күбрәк чувашчага тартым шивәле булсалар да, җәнүбтән татарлар килгәнче үк, команнар тәэсирендә телләре гареб төркчәсенә әверелә башлаган булыр, 3) безнең кулыбыздагы кабер ташлары һиҗри VII–VIII гасырларныкы, димәк, Болгарстан татарлар кулына кергән булганга, үзбәк кыпчак теле тәэсире астында шундый шивәгә әйләнгән булыр.

Икенче ихтималны бераз тәфсилләп үтәбез. Болгарларның җәнүб кардәшләре команнар белән ихтилятлары[1], шиксез, булган. Безгә аларның бер-берсенә мөнәсәбәтләре мөгайян[2] мәгълүм түгел. Ләкин, һәрхәлдә, рус летописецлары болгарлар белән половецлар (команнар) арасында булган ихтилятка даир бер хәбәр бирәләр: 1117 елда Шәһри Болгарда берничә коман ханнары (кенәзләре) агуландылар, ләкин сәбәбе мәгълүм түгел[3]. Билгеле, инде бу вакыйга болгарлар белән команнар арасында ихтилят булганлыгын күрсәтә. Бәлки, шушы катышу, алыш-биреш, сугышлар аркасында болгарларга коман теле тәэсир иткәндер дә, шәркый Яурупа төркләренең телләрендә берлек ясала башлагандыр.

Болгар иле татарлар кулына кергәч, билгеле, Болгарстанда татар колонизациясе башланды: Азиядән килгән монгол-татар мәэмүре, гаскәр башлыгы «баскак» вә «даруга» булып килде: коман вә башка төрк җенесеннән Алтын Урдада тора торган кешеләр гаскәре булып һәм мал йөртүче сәүдәгәр булып килделәр. Шимали Төркестан да бер заманда Алтын Урда кулында булганга, Урта Азиядән үзбәк телендәрәк сөйләшә торган сәүдәгәрләр, муллалар, фәкыйһләр, мигъмарлар, һөнәрчеләр килә башладылар[4]. Шул рәвешчә, болгар теленә бу халыкларның да теле тәэсир иткән булыр.

---

[1] Ихтилят – аралашу, дуслык.

[2] Мөгайян – анык.

[3] Голубовский, Булгары и хозары, с. 24, (Лаврентьевская летопись, с. 205). *(Авт. иск.)*

[4] Моңарга дәлил – Башкортстанда Кара Ягкуб авылы янындагы кабер ташындагы язулар; «Болгар кабер ташлары» дигән мәкаләгә карагыз. *(Авт. иск.)*

Кабер ташлары арасында чуваш һәм татар шивәсе катыш дип йөртелә торган «Хаҗи зияраты торыр, тарихе җийат җүр»[1] шикелле кабер ташлары, бәлки, шушы болгар теленең чувашсымак бер шивәдән татар теленә күчә башлаган бер заманның сөйләшү телен дә күрсәтә ала торганнардыр.

Алтын Урда дәверендәге сөйләшү теле ничек булганы мәгълүм түгел, ләкин алда сөйләнгән Рубруквис һәм минорит ордены миссионерының сүзеннән мәгълүм ки, Алтын Урданың күпчелегенең теле – коман теле, бу хакта мәгълүмат киләчәктәге «Коман мәҗмугасы» мөнәсәбәте белән язылган мәкаләдә бар. Бу тел – Радлов фикеренчә, хәзерге Казан татары шивәсенә якын бер шивә. Бу телне без, һәрхәлдә, Туктамыш вә Тимер Котлыг ярлыклары буенча тикшерә алмыйбыз. Чөнки бу ярлыклардагы тел – канцелярия теле, Чыңгыз заманасында уйгур галимнәре тарафыннан кертелгән бер тел. Ләкин, һәрхәлдә, бара торгач, җанлы (живой)[2] тел рәсми язуларның теленә дә тәэсир итте. Шуның аркасында, бер яктан, соңгы Алтын Урда вә беренче Кырым ханнарының (госманлы тәэсиренә бирелгәнчегә кадәрге) ярлыкларында без инде, бер яктан, «Кодекс куманикус» теленә, икенче яктан, чыгтайчага тартым татарча булган болгар кабер ташларының теленә һәм Казан татарларының хәзерге телләренә мөшабәһәт[3] табабыз. Мисал өчен 7 нче Кырым ханы – үзен бөтен Алтын Урданың падишасы дип атаучы Мөхәммәдгәрәй[4] ханның

[1] Монда «торыр» һәм «җийат җүр» дигән ике шивә галәмәтенә дикъкать ителергә тиеш. *(Авт. иск.)*

[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[3] Мөшабәһәт – охшашлык.

[4] Мөхәммәдгәрәй (1465–1523) – Миңлегәрәй ханның улы, 1515–1523 елларда Кырым ханы. Бөек Мәскәү кенәзлеге сәясәте яклы этисеннән аермалы буларак, русларга каршы сәясәт алып бара, Мәскәүгә хәрби һәм сәяси яктан басым ясый, Речь Посполита белән хезмәттәшлек итә (1516, 1520). Мөхәммәдгәрәй хан Кырым ханнары идарәчелегендә Алтын Урданың бөтенлеген торгызырга тырыша. 1521 елда Казан ханлыгы тәхетенә үзенең бертуганы Сәхибгәрәйне утыртырга ярдәм итә һәм аның белән бергә Кырым һәм Казаннан Мәскәүгә уңышлы яу оештыра.

(1515–1523)[1] Польшага (Ләх йорты) 926 һиҗридә язган иттифак могаһәдәсенең бер җирен күчереп үтәбез: «...боларның күзенчә безем Коръәнемездән мең ант шарт кылдык, ким син Жигимонт король карендәшем берлә дуст карендәш булгаймыз, дустына дуст, дошманә дошман булгаймыз, бере-беремезгә ничек ким әүвәлгеләремез ирделәр, болай булган соң безем арамызга һичбер дошман кереп булмасдыр».

Тагын бераз соңрак 1038 һиҗридә Җанибәкгәрәй хан[2] II нең (1610–1612) Мәскәү падишасы Алексей Романовка[3] язган бер мәктүбен укысак, Печән базары татары хатын укыган төсле булабыз: «Безем берлә дуст булырдай булсаңыз, халән[4] безгә килә торган олуг илче башыңыздин башка бер яхшы кешегезне Тын[5] казакларыкызга ясак кылып йибәргәйсез... ушлай белгәйсез дип хат бетелде[6]»[7]. Гомумән, бу XVII гасырда Кырым ханнарының Русиягә язган язулары Казан татары теленә якын булган, чөнки бу чакта инде рәсми даирәләрдә госманлы тәэсире көчле булса да, Русиягә язганда, андагы тылмачларның Идел буе татарлары булуын игътибарга алып язганнардыр, әмма шул ук дәвердә Польшага язган язуларда госманлы тәэсирен күрәбез, чөнки анда тылмачлар, Кырым татарлары булганга, җәнүби төрек шивәсе белән язуны мәслихәт күргәннәр булыр[8]. Димәк, Алтын Урдада тел, башта чын команча булып, бара-тора Казан шивәсенә якынлаша бара, һәм, Кырым ханлыгы ясалып, Алтын Урда беткәч тә, Кы-

---

[1] Стенли Лэн Цуль. Мусульманские династии, с. 196. *(Авт. иск.)*

[2] Җанибәкгәрәй хан (1568–1636) – Кырым ханы (1610–1623 һәм 1628–1635 елларда).

[3] Алексей Михайлович Романов (1629–1676) – рус патшасы.

[4] Халән – хәзерге, бу вакытта.

[5] Тын – Дон.

[6] Бетелде – язды.

[7] Бу кыйтгалар алынды: Материалы для истории крымского ханства, изд. Вельяминова-Зернова, 1864. *(Авт. иск.)*

[8] Мөхәммәдгәрәй бине Сәламәтгәрәй Польшага яза (1622–1627): «Хак Тәгалә хәзрәтләре лотыф итеп (киң күңеллелек күрсәтеп) фәтхе мәйсәр улырса, Мәскәү забытында улан Казан вә Әҗдерхан вә төрк вә тура вә ул вилаятьтә һәр нә кадәр татар вә нугай вар исә». (*Авт. иск*)

рымда һаман да шул тел кала; хәтта Мәскәүгә язганда, һич тартылмыйча, Казан татарына иң якын тел белән яза бирәләр, чөнки шул шивә белән сөйли беләләр, бары тик Польшага язганда гына, модага ияреп, төрек солтаны төсле итеп госманлыча язалар.

Казан ханлыгын ясаучылар, XV гасырда Алтын Урдадан сөрелгән але Чыңгыздан[1] Олуг Мөхәммәд белән килгән җәнүб татарлары булганга, соңра да Олуг Мөхәммәднең муәффәкыятеннән соң Алтын Урда бикләре, мирзалары үзләренең кешеләрен алып килеп торганга[2], болай да татарлашкан болгар калдыклары арасына татар телен җәя башладылар. Рәсми тел дә, бер дә шиксез, җәнүбтән килгән татарлар сөйли торган шивә булганга, шул тел тагы да тәгъмим итте[3]. Дөрес, хәзергә бу хакта бертөрле дә Казан ханлыгы заманасыннан калма мәнбәгъ юк, шулай да беренче мисал итеп алынган Мөхәммәдгәрәй ярлыгы белән Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихе Болгария»се һәм Һади Атласиның[4] «Казан тарихы»ндагы Сәхибгәрәй[5] ярлыгының телләре бер-берсенә бик якын, шуның өстенә дә XVIII гасырда язылган, киләчәктә «Вәкаигънамәләр» дигән мәкаләбездә күреләчәк тел белән болар бер-берсенә якын. Әлхасыйль, Казан татарлары, моннан күрелүенә бинаән, хәзерге шәһәр мәдәнияте аз кергән ерактагы татар авылларында карт вә карчыклар сөйләшә торган телгә бик якын бер тел белән сөйләшкән булырлар.

---

[1] Але Чыңгыздан – Чыңгыз династиясеннән, нәселеннән.

[2] «История Казанского царства»да бу хакта шулай әйтелә: «Мнози варвары от различных стран, от Злотые Орды, Осторохони и Азова и Крыма». *(Авт. иск.)*

[3] Тәгъмим итте – таралды.

[4] Һади Атласи (1876–1938) – тарихчы, язучы, педагог, дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Фән һәм әдәбият өлкәләрендә эшчәнлек алып бара. Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (1913). Бер үк вакытта «Йолдыз», «Вакыт», «Шура», «Мәктәп», «Аң» һәм башка вакытлы басмалар белән хезмәттәшлек итә. «Тарих табигый» (Казан, 1902), «Яңа низам вә голәмаларымыз» (Оренбург, 1906), «Себер тарихы» (Казан, 1911), «Казан ханлыгы» (Казан, 1920) һ.б. хезмәтләр авторы.

[5] Сәхибгәрәй (1500–1551) – Казан (1521–1524) һәм Кырым (1532–1551) ханы. Сәхибгәрәй хан ярлыгы 1523 елның 1 гыйнварында (919 һиҗри елның 13 сәфәре) языла, аксөяк Шәех Әхмәт белән аның туганнарына бирелә.

Шулай итеп, без бик борынгы заманнардан алып XIX гасырга кадәр сөйләшә торган телебезнең ясалышы тарихына бер тәҗрибә ясадык. Инде әдәби телнең ясалышы мәсьәләсендә кыска гына бер-ике сүз әйтеп китәбез.

Җәнүби Русия күчмә төркләрендәге әдәби тел хакында бер сүз дә сөйләп булмый, чөнки аларда язма әдәбият туа алмады[1]. Хәзәрләрдә исә әдәбият булса да, ул әдәбият бары югары табәка[2], ибн Фадлан тәгъбире белән әйтсәк, «җәзрел холыс»та гына булган, бу сыйныф исә яһүд динендә булганга күрә, болгарларда – гарәп теле, борынгы русларда иске эслау[3] теле әдәби тел булганы шикелле, хәзәрләрдә әдәби тел яһүд теле булган. Кырымда табыла торган бәгъзы шул заманнан калма кабер ташлары, хәзәр ханы Йосыфның Хасдай ибн Шапрутка язган хаты шуны күрсәтәләр.

Болгар иленә килсәк, X гасырда анда гарәп-ислам тәэсире көчле булганга, әдәби тел X–XII гасырда күбрәк гарәп теле булган, ибн Фадланның сүзләре шуны тәкъвия кылалар[4]. Ләкин XIII гасырдан игътибарән[5] Болгар иле Алтын Урданың бер «өлеш»енә әверелгәч, Урта Азия белән дә мөнәсәбәт куәтләнгәч, анда Урта Азия чыгтай әдәбияты тәэсире белән чыгтай теле әдәби бер тел булып китү ихтималы булса да, шул заманнан бер төрле дә язылган документ сакланып калынмаганга, бер сүз дә әйтеп булмый, кабер ташлары исә – бары XIII һәм XIV гасыр продуктлары гына. Әмма бу заманнан игътибарән чыгтай теленең тәэсире мәсьәләсе кабер ташларыннан ачык күренеп тора.

[1] «Кодекс куманикус»тагы Инҗил һәм догалар, дини җырлар булса, аларның команнар тарафыннан язылган булуы шикелле, я гарәп миссионерлары яисә Кара диңгез буенда күп еллар торып, үзләренең телләрен югалткан христианнар тарафыннан язылган булуы да бик якын ихтимал. Минорит орденының бер монахы истигъмаль кылган «уйгур литературасына» дигән сүз дә ачык бер мәгълүмат бирә алмый. *(Авт. иск.)*

[2] Табәка – сословие.

[3] Эслау – славян.

[4] Тәкъвия кыла – куәтли.

[5] Игътибарән – башлап.

Казан ханлыгындагы әдәби тел хакында шул ук сүзне әйтергә кирәк була. Анда, шиксез, башта Урта Азиядәге әдәби төрки теле таралган булырга кирәк, бигрәк тә югарыдагы фасылда мисал итеп китерелгән Мөхәммәдгәрәйнең Польшага язган ярлыгы теле белән Казан рәсми вә әдәби теле бер булырга кирәк. Ләкин өлкәгә Кырым ханнары Гәрәйләр сөляләсе баш булгач, шуның өстенә госманлы теле тәэсире дә бераз булганы күренә. Без моны Сәхибгәрәй ярлыгындагы «сабах вә шам вә гадү вә рәвах[1] безгә вә безнең ыругымызга дога вә алкыш кылсыннар» дигән сүзгә карап әйтәбез, ләкин шул ук сүзләрне без искерәк сарай ярлыкларында да очратабыз.

Казанлылар Сәхибгәрәйне чакырганда, билгеле, хан үзе белән муллалар, кятибләр (битекчеләр)не алып килгән, шулай ук алар белән бергә госманлы әдәбиятыннан «Мөхәммәдия»[2], «Хакка шөкер»[3], «Пиргули китабы»[4] күк дини әсәрләр, «Сәид Баттал» шикелле хикәяләр килгән булырга кирәк, шуның аркасында Казан татарларының яза торган телләренә госманлы сүзләре, нәхү вә сарфи формаларының керүен XVI гасырдан башланган дип карарга мөмкин.

Безнең XIX гасырга кадәр булган әдәбиятыбызга шушы ике мәркәз әдәбияты: Урта Азия һәм госманлыныкы нык тәэсир итеп килде. Ләкин сизелмичә генә, акрын гына Казан татарларының сөйләшә торган теле дә кызыл җеп шикелле булып, сузылып керә башлады, инде Исхак Хәлфиннең Екатерина заманындагы законнарны тәрҗемәсендә[5], Ибраһим Хәлфиннең

[1] Сабах вә шам вә гадү вә рәвах – иртән-кичен һәм көндезен-төнен.

[2] «Мөхәммәдия» – төрек шагыйре Мөхәммәд Чәләбинең 1449 елда язып тәмамлаган китабы. Казанда 1845 елдан 1917 елга кадәр 24 тапкыр бастырыла. Ул укылу буенча Коръәннән соң икенче урында торган.

[3] Көйләп укыла торган дини эчтәлекле «Хакка шөкер китабы».

[4] «Пиргули китабы» – Мөхәммәд Пиргулиның (1538–1573) ислам һәм аның йолалары хакында сөйләүче трактаты.

[5] Исхак Хәлфин тарафыннан 1792 елда император Екатерина II кушуы буенча тәрҗемә ителгән «Губерналар турында нигезләмәләр» («Учреждения о губерниях») һәм «Җәмәгать тәртибен саклау идарәсе уставы» («Устав Управы благочиния») дигән хокук актлары турында сүз бара.

«Әхвале Чыңгыз хан» мәҗмугасының мөкаддимәсендә тел корама төсле: чыгтай, госманлы һәм саф татар сүзләре вә грамматика формалары белән тулып беткән, аның апофеозын без инде XIX гасырда Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар»ының беренче җилдендә күрәбез. Ниһаять, XIX гасырның ахырында чын татар теле өскә чыга башлап, Насыйри әсәрләрендә инде без аның чын галәбәсенең[1] якын икәнен күрәбез.

## III

Татар теленең ясалу процессы хакында без кыска гына бер мәгълүмат бирергә тырыштык. Безгә хәзер, аның әдәбиятын өйрәнгәндә, татар фикеренең эволюциясен тикшереп карарга кирәк. Бу хакта кыска гына шуны әйтергә мөмкин. Татар халкын этнографик вә милли бер гонсыр итеп ясау процессында иштиракь кылган халыкларның гаммәсенең[2] төп әсаси фикере, дөньяга карашы шаманизм, пантеизм әсасында иде, аларның хокукый, әхлакый фикерләре исә күчмә хәят таләп кыла торган нәрсәләрдән гыйбарәт иде ки, соңра шул фикерләр уйгур галимнәре каләме белән Чыңгыз ханның «Ясанамәсе»ндә кодификация ясадылар. Менә бу фикер әле һаман да бар, аларны нә ислам, нә дә нәсранияят кысып чыгара алмаган. Шушы фикер өстенә күршеләр тәэсире аркасында кергән фикерләр дә булды.

Элек җәнүби Русиядә йөрүче күчмә төркләр (гуз, пәчәнәк, төрк (тар мәгънәсендә команн)ны алабыз. Бу халыкларның фикерләренә берничә тәэсир булды: Бизанестан – православие, гаребтән – миссионерлар аркылы католицизм, шәркый җәнүбидән – элек зәрдәштилек, браһманизм[3], соңра ислам. Бу фикерләрнең иң күп тәэсир иткәне ислам булды. Моны исә безгә «Кодекс куманикус» теленә кергән гарәп, фарсы сүзләре күрсәтәләр[4].

---

[1] Галәбәсенең – җиңүенең.

[2] Гаммәсенең – массасының.

[3] Чөнки бик борынгы чакларда пәчәнәкләрнең Һиндстанга ат илтеп сатулары мәгълүм. *(Авт. иск.)*

[4] Бу хакта «Коман мәҗмугасы» дигән мәкаләбездә мөфассал (*тулы*) мәгълүмат бар. *(Авт. иск.)*

IX гасырда хәзәрләрнең аристократиясе вә хаким сыйныфлары яһүд динен кабул иткәч, хәзәр төркләренә яһүд фикерләре тәэсир итте, бөтен җирдән куылган яһүдиләр хәтта Идел буенда яңа Сион ясау фикеренә дә төштеләр. Моны без Хасдай ибн Шапрутның Йосыф хаканга язган мәктүбендә күрәбез. Хасдай мәктүбендә, назымлы Зәбур өслүбе белән, Хәзәрстанны мактап, шунда бөтен таралган яһүдләрне җыеп, Давыт пәйгамбәр заманындагы шәүкәтне кайтару мөмкин икәнен күз яшьләре түгеп бәян кыла. Йосыф хакан да Хасдайга язган җавабында шундый өметләр бәян кылып яза. Ләкин бу дин, читтән килгән яһүдиләр һәм Исраил динен кабул иткән «җәзрел холыс» арасында гына калып, гаммәгә тарала алмады, исламият җиңде. Шуның өчен Идел шәһәрендә биш казый булып, шуның берәре – христиан, яһүд, мәҗүсиләрдән, икесе мөселманнардан булып, низаглы мәсьәләләрдә мөселман казыйларының фикере катгый карар булган. Болгарлар исә гарәп мәдәнияте тәэсиренә төштекләреннән, аларда иске шаман фикерләре белән бергә ислам фикерләре вә дөньяга карашлары роль уйнады, ниһаять, соңгысы җиңде. XIII гасырда килгән Җүҗи угланнары командасындагы Алтын Урда ясаучы моголлар исә шәркый Яурупага бик куәтле буддизм (ламаизм) буявы белән буялган шаманизм алып килделәр. Ләкин болар, бер яктан, төркләшеп, икенче яктан, икътисади тәэсир аркасында исламлашкач, буддизм фикерләре монгол теле белән бергә очып, югалып бетте.

Казан ханлыгында исә, шәркый Яурупада юлларның алмашуы аркасында бер хакимиятнең булмавы, сәүдә вә сәнәгатьнең тәдәннисе[1] аркасында иске шаманизм яңадан куәт алса да, ислам фикерләре һаман да югалмады, бигрәк тә Гәрәйләр сөлhistoryләсе[2] хакимияте вакытында, Мәскәү белән сугышлар нәтиҗәсендә исламият фанатизмы көчәйде.

Кирәк Алтын Урда, кирәк Казан дәүләтендә булсын, бер табәка халыкта суфилык шактый җәелде. Инде ибн Баттута,

[1] Тәдәннисе – артта калуы.
[2] Сөләләсе – династиясе.

Сарайга килгәндә, анда ишаннар, мәшаих вә талибәләр очратты. Рус мәнбәгъләры да Казанда шул ук суфилык тарафдары мәшаихнең булганлыгын күрсәтә торган сүзләр язалар. Түбән халык – карасөякләр – бу фикергә шактый бирелделәр булырга кирәк. Карасөякләрнең икътисади кысылулары, мирза, хан, ханзадә вә бикләрнең эксплуатациясе халыкны дөньядан биздерде. Организация булмаганга вә мәдәният түбән булганга, сыйнфый көрәшне чын мәгънәсендә алып барып, аксөякләрне җиңә алмадылар. Рума пролетариаты мәэюсиятеннән[1] соң нәсраният кочагына бирелгәне шикелле, безнең мәзлум карасөякләр дә суфилык кочагына бирелделәр. Шуның өчен дә догалыклар, төрле суфилык әсасындагы назымлы китаплар, суфиларның шигъри әсәрләре күп еллар халыкның сөеп укый торган нәрсәләре булдылар. Затән[2], бу суфилык Азиядән монголлар алып килгән буддизм әсаслары белән дә якь[3] аһәң иде. Бәлки, шуның өчен дә суфилык безнең арада тиз тарала алгандыр[4]. Шул сәбәпләргә гыйлавә[5] итеп, XVII–XVIII гасырларда Мәскәү вә Петербург хөкүмәтләренең дини вә икътисади кысуларын да алырга кирәк. Бу кысулар, бер яктан, бездә исламиятнең нык тамыр җәюенә, монотеизмның көчәюенә сәбәпче булса, шул ук икътисади һәм дини кысуларга каршы халык көрәшеп, җиңүдән гаҗиз булганга, тәрке дөньялыкка[6], рәхәтне теге дөньяда эзләүгә мәҗбүр булды. Шуның аркасында бездә көрәшнең әсасын җимерүче, халыкны ялкау вә куркак ясаучы «ишанизм» туды.

Гомумән, бездә XIX гасырга кадәр фикри хәят ярлы булды. Моның сәбәбен дә татарның күбесенең крестьян булганлыгы өчен – сыйнфый яктан, мөселман-татар булганлыгы өчен мәдәни яктан кысылуыннан эзләргә кирәк. Шуның өчен дә, Екатери-

---

[1] Мәэюсиятеннән – өметсезлегеннән.

[2] Затән – нигездә.

[3] Якь – бердәй.

[4] Бу хакта әсәрнең беренче бүлегендә «Суфилык» дигән аерым бер мәкалә булганга, монда кыска гына туктап үтәбез. *(Авт. иск.)*

[5] Гыйлавә – өстәмә.

[6] Тәрке дөньялыкка – дөньялыкны читкә кагуга.

на II дәверендә бераз иркенлек бирелгәч, татарларда фикри хәят бераз терелә төште.

**IV**

Алдагы фасылдан күрелде ки, Идел буе татарларында XVIII гасырның соңына кадәр фикри хәрәкәт юк диярлек, бу хәрәкәтне аңлата торган әдәбият та юк. Казан ханлыгы дәвереннән алып XVIII гасырның ахырына кадәр без татарларда, татарча язылган бер-ике вәкаигъnamә, васыятьнамә, берәр тарихи әсәр, «Җамигъ әт-тәварих» тәрҗемәсе, бер-ике кабер ташы, хәзер генә табылган бер ярлыктан, бер-ике халык җыры төсле тарихи җырдан башка бернәрсә дә белмибез. Булганмы ул әдәбият, әллә булмаганмы мәсьәләсендә катгый бер җавап бирүе читен.

Алай да уйларга мөмкин ки, бераз язма әсәрләр булган булырга кирәк, соңра алар югалганнардыр. Ләкин шулай булса да, ул әсәрләрнең үзләре дә бик аз булгандыр. Бу әдәби ярлылыкның сәбәбен исә татарның Казан алынганнан алып XVIII гасырның икенче ярымына кадәр булган тарихи халәтләре безгә ачып бирә ала. Бу халәтләр шундый читендер ки, ул шәраит эчендә әдәбият, гыйлем вә, гомумән, мәдәни эшләр белән иштигаль[1] мөмкин булырлык түгел.

Казан дәүләте ясалганнан 1552 елга кадәр мөттасил, бер яктан, Мәскәү белән туктаусыз сугышлар булып торды, икенче яктан, Казанның үзенең эчендә тәртипсезлек, мирзаларның бер-берсе белән, ыруг, хан сөляләләре, сәяси ориентацияләр өчен бертуктаусыз низаг дәвам итте. Шул сугышлар аркасында халык мәдәни хезмәткә бирелә алмады. Һәммәсе дә сугышчы, гаскәри булып тордылар. Казан алынды. Мәскәү каре вә аның боярлары үзләренең вәхшәтләрен дин исеме белән буяп ижраэ иттеләр[2].

Бу фикерне исбат кылу өчен, Никон летописеннан шушы урынны күчереп китәбез: «Алланың гыйнаяте белән православный царь Иван Васильевичның зур иманы аркасында Алла аның кулына имансыз татарларны бирде, аларның мөселман

[1] Иштигаль – шөгыльләнү.
[2] Ижраэ иттеләр – эшкә ашырдылар.

динен олуг падишаһ харап итте һәм аларның мәчетләрен ватты вә җимерде һәм аларның караңгы урыннарын үзенең изгелеге белән яктыртты»[1].

Казан өлкәсенә поп, алпавыт һәм аларның крестьянны колонизациясе башланды. Җәбер көчәя, авыр ясаклар күбәя башлады, халыкның чыдамы җитмәде, 1560 елга кадәр ул ихтиляллар күтәрде. Бу кузгалыш, ифрат күп гаскәр белән 7 ел кан коелганнан соң, шиддәтле[2] рәвештә бастырылды. Тагы халыкның истигъдадлы[3] кыйсеме сугышларда кырылды, Башкортстанга качты. Билгеле, Казан алынганда яндырылган шикелле, монда да татарның китаплары авыллар яндырылган чакта көл булдылар, кайсыларын китүчеләр чит илләргә алып китеп югалттылар. Шулай итеп, китап язу белән шөгыльләнергә XVII гасырның башына кадәр мөмкин булмады, чөнки татар халкы яңа мәгълүб булган[4] бер халык булганга, яңа сәяси шәраиткә өйрәнеп җитмәде, һаман да ул истикъляалият[5] алу юлын карады. Кул кушырып кына Мәскәү алдында тормады.

XVII гасыр татарлар өчен бераз уңай булса да, бу гасыр да, Касыйм шәһәрендә язылган бер-ике китаптан башка, безнең заманга бер әсәр дә калдырмады. Бу гасырның башыннан алып, рәсмән 1613 елга, әмма, дөресен әйткәндә, 20 нче, 25 нче елларга кадәр Русиядә «Смута» атала торган ихтилял дәвам кылды.

Бу ихтилял дәверендә татар гонсыры һәм ихтилялчыларга, һәм боярларга кирәк булганга күрә булырга кирәк, татарлар хакында Иван һәм Федор Иванович заманнарындагы вәхши законнар вә мөгамәләләрне күрмибез. Ләкин беренче Романовлар тәхеткә кичү белән, татарлар гаскәри хезмәткә кирәк булганга, алар хакында артык каты карарлар чыгарылмаса да, икенче Романов Алексей тәхеткә кичкәч, Мәскәүнең сәясәт арбасы тагы иске эзенә төште. Шуның өчен без татарлар-

[1] Никонов. Летопись, том седьмой, с. 233. *(Авт. иск.)*
[2] Шиддәтле – катылык, кансызлык белән.
[3] Истигъдадлы – сәләтле, зирәк.
[4] Мәгълүб булган – җиңелгән.
[5] Истикъляалият – бәйсезлек.

ны кыса торган законнарның бер-бер артлы чыгып торганын күрәбез[1]. Бу хәбәр Кырым дәүләтенә дә барып ишетелә, шуның өчен без Кырым татарларының Русиягә биргән берничә ультиматумын очратабыз[2]. Шуларның берсе Морадгәрәй[3] тарафыннан 1093 елда[4] царь Алексейга[5] бирелә. Бу ультиматумда «олуг тәхетгягыңызда[6], такы күп мәмләкәтләреңездә булган, әүвәл-әүвәлдин калган өммәте Мөхәммәд мөселманнарны көч вә кыстау итеп, сәясәтләр белән христиан диненә кайтарыр вә таптырыр ирмешсез, мондак ошаусызлык падишаһлар шанына тормасдыр, бик яман эшдер» дигән соңында, Кырым вә Төркиядә дә бик күп христиан табәкалар булганын, ләкин аларның дингә көчләнмәгәнен аңлаткан. Аннан соң татарларны икътисади яктан да кысканлыклары хакында: «Христиан булмак өчен көч вә кыстау вә сәясәт кылыр булсаңыз, ултырган йирләреннән сөрер булсаңыз», – дип, Кырымда булган христианнарга каршы шундый ук мөгамәләдә булачагын һәм, Төркиягә хәбәр итеп, аның да репрессияләр башлаячагын белдерә[7]. Шундый эшләрдән гаҗиз булган татарлар, чынлап та, Төркиягә барып шикаять кылмалап тордылар. Шуңарга даир без мәнбәгъларда менә шундый вакыйганы очратабыз: 1682 елда

[1] Бу законнарның нидән гыйбарәт булганын монда сөйләп тормыйбыз, ул законнар кыскача гына шулар: 1) 1628 елда бер фәрман нәшер ителеп, монда татар мирзалары кулыннан рус-христиан крестьяннары алына. Шул ук канун «Уложение» исемле закон мәҗмугасының 22 нче бабында тәэкид кылына, 2) шул ук уложениенең 22 нче бабының 24 нче маддәсендә мөселманлык агитациясе өчен ут белән җәза тәгаен ителә, 3) 1681 елда 16 майдагы боерык белән рус крестьяны булган татар алпавытларын чукындырырга яисә җирләрен мөсадәрә кылырга (тартып алырга) әмер ителә. *(Авт. иск.)*

[2] Шуларның берсе 1660 елларда язылган, Кырым ханының вәзире «Сәфәр Гази» тарафыннан бирелгән. *(Авт. иск.)*

[3] Морадгәрәй – 1677–1683 елларда Кырым ханы.

[4] Биредә һиҗри ел исәбе күрсәтелгән.

[5] Алексей Михайлович Тишайший (1629–1676) – Романовлар династиясеннән икенче рус патшасы.

[6] Тәхетгягыңызда – башкалагызда.

[7] Материалы для истории Крымского Ханства, изд. Вельяминова-Зернова, с. 680–681. *(Авт. иск.)*

Русиядән Төркиягә килгән илче олуг вәзир белән мосахәбә[1] арасында вәзир сүзне Русиядә тора торган мөселманнарга бора да: «Алатырь татарлары белән Казан татарлары бер үк халыкмы?» – дип сорый. Илче мәсьәләнең нәрсәгә барып терәлгәнен сизә дә җавабында: «Казан, Әстерхан татарлары әз калдылар, чөнки алар бу чакларда православиене ошаттылар һәм күбесе чукынды. Шулай ук Алатырь татарлары да бик аз, Алатырь шәһәре – үзе дә кечкенә генә бер шәһәр», – ди дә, – «миңа бу кечкенә шәһәр хакын да соравыгыз гаҗәп тоела», – дип куя. Вәзир булса: «Алатырь хакында ишеткәнем бар», – ди. Шул илче царьга язган мәктүбендә: «Мин бу сүзне юри белмәгән булып сорадым», – ди дә шундый сүз куша: «Алатырские татары перед тем были в Царьграде (Истанбулда) с челобитьем (гариза белән), чтобы им из-под державы царского величества свободным быть»[2]. Билгеле, эшләр шулай булгач, татарларның мәдәниятләрен үстерү юлында хезмәт итү ихтималлары юк: мәдрәсә сала алмыйлар, халык качып кына укый, китап язу хакында уйларга мөмкин түгел. XVIII гасырда яңарган Русия хөкүмәте дә татарларга мөнәсәбәтен Мәскәү хөкүмәте шикелле куйды, хәтта алардан арттырып та җибәрде. Моның сәбәбе берничә булырга мөмкин.

Петр вә аның хәләфләренең[3] Яурупа тормышын Русиянең хәятына татбикында рус халкы динсезлек вә бәдмәзһәблек күрде, шуның өстенә Екатерина I, Анна, Антон, Елизавета заманнарында Русияне нимсәләр идарә кылып килделәр. Менә халыкка динле һәм милли күренү өчен, бу падишаларның хөкүмәтләре, әүвәлге православный царьлар күк, мөселман вә мәҗүсләрне дини вә милли яктан кысарга керештеләр.

Ләкин аның иң зур сәбәбе икътисади: XVIII гасырда Русиядә крепостнойлыкның иң куәтле хөкем сөргән чагы, сарай тирәсендә йөрүче алпавытларга күп җир өләшенеп, рус халкы крепостной булып бетте. Хөр крестьяннарны хөкүмәт алпавытларга

---

[1] Мосахәбә – кара-каршы сөйләшү.

[2] Забелин. Посольские путешествия в Турцию в XVII столетии (Рус. Старина 1877 г., сентябрь, с. 27–28). *(Авт. иск.)*

[3] Хәләфләренең – дәвамчыларының.

биреп бетерә язды. Ләкин шәркый Русиядә әле бик күп бирелмәгән крепостной булмаган крестьяннар бар, болар – татарлар. Ләкин борынгыдан килгән закон буенча, христианга христиан булмаган кеше кол була алмый. Бу читенлектән чыгарга бер генә юл бар: татарны вә башка гайре русны чукындыру. Инде чукынгач, аны алпавытлар кулына да бирергә мөмкин.

Ләкин XVII гасырда да падишаһлар эшне татарның аристократиясеннән һәм йомышлы (служилый[1])ларыннан башлады. Чөнки боларны руслаштырган тәкъдирдә, эш уңайланачак: беренче, татарларның шактыйсы – үз алпавытларының коллары, хуҗа чукынгач, ул чукыначак. Кара халык үзенең тел вә гадәтенә күбрәк әһәмият биргәнгә, XVI–XVII гасырларда баш булып, Русиягә каршы халыкны күтәртү эшендә йөргән аксөякләрне халыктан аерачак та, шулай итеп, гайре рус гаугасы хәл кылыначак. Икенче, хөкүмәт алпавытлар сыйныфыныкы булганга, ул заманда руслаштыру дигән сүзне аксөяк, хаким сыйныфларны чукындыру дип аңлаганнар. Чөнки кол хөкемендә булган халык белән соңыннан тиз генә эшне бетерергә мөмкин. Шуның өчен дә Петр Великий, 1713 елда указ чыгарып, ярты ел эчендә кулларында рус крестьяннары булган татар алпавытларын чукынырга яисә крестьян һәм җирләрен хөкүмәт файдасына мөсадәрә кылырга[2] әмер итте[3]. Ике елдан соң бу закон тагы тәкрар ителде. Билгеле, шушы вакытта ифрат күп алпавыт-мирза чукынды.

Димәк, ул чакта бердәнбер гыйлем белән, әдәбият белән шөгыльләнерлек тәэмин ителгән сыйныф яисә руслашты, яисә җир вә крестьяннары мөсадәрә кылынып, крестьян булып, ярлы булып калды.

Инде 1720 елда Петр яңа бер указ чыгарды. Бу указ инде безнең крестьян сыйныфыбызга һөҗүм иде: йорт эче белән чукынучылар өч ел эчендә бөтен имана һәм башка шундый салымнардан котылалар.

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Мөсадәрә кылырга – кулга төшерергә.
[3] Полное собрание Законов, том 5, № 2734. *(Авт. иск.)*

Ләкин хөкүмәтнең бу чаралары уйланганча артык уңышлы булмады булырга кирәк. 1721 елның 11 августында Казан метрополиты Тихон[1] Синод[2] вице-президентына шулай язды: «Әүвәле чукынган мөхәммәдиләрдән кайсысы христиан динендә торалар, әмма кайсы исә бөтенләй ул диннән чыгалар, алар кабәхәтләр һәм итагатьсезләр, аларны төзәтү хакында минем вөҗданым бик авырта...»...

Синод, бу шикаятьнамәне алгач, нинди чаралар күрергә кирәк дип сорагач, Тихон моңар каршы үзенең җавабында татарларны керәшеннәрдән аерырга мәслихәт итеп, чукындыру эшендә торучыларга тулы хакимият кирәклекне белдерде. Петр 1722 елда үз кулы белән Казан вәлиенә хат язып, чукынучыларны солдаттан котылдырырга әмер итте[3]. Әмма шуннан ике ел элек, җинаять эшләүчеләр чукынсалар, кичерергә кушкан иде[4].

1730 елларда татарны кысу тагы да көчәеп китте. Татарларны бетерү өчен яңа бер баш мөәссәсә[5] ясалды. Ул исә Комиссия новокрещенских дел иде. Бу мөәссәсә чукындыру эшен карый. Дини мәктәпләр ача. Ләкин халык күбрәк матди мәнфәгать өчен чукынганга, архимандрит Алексей[6], 1733 елда Синодка хат язып, татарлардан зарланып: «Алар үз гадәтләрендә катып калганнар, чукынырга үз ихтыярлары белән килмиләр. Бары бер-бер нужда мәҗбүр итсә генә чукыналар», – ди. Ләкин бу чаралар һәммәсе дә татарларга начар тәэсир итте: дини реакция куәтләнде, халык алдында голямәнең дәрәҗәсе артты, шуның нәтиҗәсендә мәчет салу күбәеп, хөкүмәт тә яңа мәчетләр салуны мәнгы итте[7].

---

[1] Тихон (1655–1724) – Казан һәм Зөя метрополиты.

[2] Синод – христиан диненә өйрәтү, дини-әхлакый тормыш мәсьәләләре турында фикер алышу һәм аларны хәл итү, христиан җәмгыятьләре эшчәнлеге белән идарә итү максатыннан оештырылган һәм иң күренекле чиркәү әһелләре катнашындагы җыелыш.

[3] Пол. Соб. Законов, том 7, № 4129 и том 2, № 888. *(Авт. иск.)*

[4] П.С.З., том 7, № 4254, том 8, № 5737. *(Авт. иск.)*

[5] Мөәссәсә – оешма.

[6] Митрополит Алексий (Елевферий (Симеон) Фёдорович Бяконт (1292–1305 еллар – 1378) – Киев һәм Русь метрополиты, епископ, дәүләт эшлеклесе, дипломат.

[7] П.С.З., том 9, № 6890. *(Авт. иск.)*

1738 елда Казан өлкәсенә һәм бөтен Русиянең шәркына баш иттереп, Лука Канашевич[1] дигән Болгар хәрабәләрен, кабер ташларын ваттыручы бер мөдһиш[2] поп куелды, иске комиссия бетерелеп, аның урынына чукындыру эшләрен алып бару өчен, Контора новокрещенских дел дигән мөәссәсә ясалды.

Икътисади мәнфәгать белән халыкны чукындыру өчен, хөкүмәтнең әмере белән Лука яңа ысуллар куллана башлады: керәшеннәргә яңа киемнәр, акчалар, иконалар бирелде[3]. Шуның өстенә дә салымнан, рекрут бирүдән, никах акчасы түләүдән котылдылар, хөкем кылганда чукынса – кичерергә[4], шулай ук чукынучыларны рус янына күчереп утыртып, аларга җир бирергә әмер ителде. Ниһаять, 1742 елда указ[5] чыгып, мәчет салу бөтен татар тора торган җирләрдә ясак ителде; билгеле, мәктәпләр дә шуның белән бер хөкемдә иде. Шул ук вакытларда, бер-бер

---

[1] Лука (Лаврентий Канашевич) (?–1758) – дин эшлеклесе, миссионер. Лука (Канашевич) ислам диненә карата гадәттән тыш дошман мөнәсәбәттә булуы белән билгеле. Император Анна Иоанновнаның миссионерлык эшчәнлеген көчәйтүгә юнәлтелгән 1740 ел 11 сентябрь Фәрманы һәм сенатның 1552 елдан соң төзелгән барлык мәчетләрне сүтеп юк итүне күз алдында тоткан «Казан губернасында мәчетләр төзүгә юл куймау һәм губернаторларга һәм воеводаларга Мөхәммәд канунына кайтырга теләгән яңа чукындырылганнарны тикшереп тору турында»гы 1742 ел 19 ноябрь фәрманы чыгуның инициаторы. 1740–1743 елларда Казан төбәгендә Лука җитәкчелегендә 556 мәчетнең 418 е җимертелә. 1749 елгы янгыннан соң, бистәдә берничә гаиләнең чукынуын сәбәп итеп, Лука Казанның Татар бистәсе халкын башка җиргә сөрергә омтыла (мөселманнар һәм яңа чукындырылганнар аерым яшәргә тиеш була). Казан руханилар семинариясен үстерүгә зур игътибар бирә (Лука эшләгән елларда Россиядә иң яхшылардан санала). Татар фольклорында мөселманнарны җәберләүче Лука Каратун яки Аксак Каратун исеме белән билгеле.

[2] Мөдһиш – куркыныч.

[3] П.С.З., том 2, № 8236, пункт 15, п. 7. *(Авт. иск.)*

[4] Шунда ук. П. 7. *(Авт. иск.)*

[5] Сүз сенатның 1742 елның 19 декабреннән «О недопущении в Казанской губернии строить мечети и о разведывании губернаторам и воеводам о обращённых в магометанский закон новокрещёных людей» дип аталган фәрманы турында бара. Рус булмаган халыкларны христианлаштыру буенча 1740–1750 еллар кампаниясе чорының иң әһәмиятле закон актларыннан берсе. Әлеге фәрманны тормышка ашыру нәтиҗәсе буларак, Казан, Себер һәм Әстерхан губерналарында 1744 елга 545 мәчет юкка чыгарыла.

авылда чукынучылар булса, шундагы мөселманнарны, иске авыллардан куып, башка җиргә утыртырга әмер булды[1]. Табигый, бу законны чыгарырга сәбәпче булган Сеченев[2], икътисади уңайсызлык килгәч, чукынырлар, дигән иде. Бу чаралар өстенә дә татар авылларына миссионерлар чыгып, халыкны җыеп сөйлиләр, каршы сөйләүче булса җәза кылалар, бәгъзы вакытта боларга халык һөҗүм кыла, ләкин миссионерлар, үзләре белән гаскәри фиркалар алып йөргәнгә, халыкны корал куәте белән дә куркыталар иде.

Хөкүмәт чукынучылардан бөтен салым, солдат бирү шикелле нәрсәләрне күтәргән булса да, чукынучылар татарлар арасында һаман да күп түгел, шуның өчен хөкүмәт, татарларны тагы да кысып, чукынган авыллар вә кешеләрдән алына торган салым һәм рекрутны чукынмый калган кешеләр, димәк, татарлар өстенә сала башлады. Бәгъзы вакытта татар авыллары елына берничә мәртәбә салым түләргә һәм солдат бирергә мәҗбүр булалар иде. Шуннан гаҗиз булган татарлар 1747 елда хөкүмәткә мөрәҗәгать кылып, бары чукынган татарлар өчен генә салым вә солдат бирергә разыйлыкны белдереп, чукынучы чирмеш, чуваш өчен бирмәскә ясарга сорадылар[3]. Бу эш белән хөкүмәт бер үк сыйныфтан, бер үк милләттән булган татар крестьянын икегә бүлде: күчерү, солдат; һәм, салымны күбрәк түләү өчен, ике арада бераз аңлашылмаулар чыга башлады, хөкүмәтнең кемне яклаячагы мәгълүм иде[4].

Татарлар икътисади вә дини яктан кысуга чыдый алмыйча күтәрелеп карыйлар. Мәсәлән, 1743 елда Воронеж губернасында Верхне-Ломовский өязендә татарлар, җыелып, күсәкләр белән коралланып, баш миссионер вә аның янындагы гаскәргә һөҗүм итте, хөкүмәтнең указын тыңламыйбыз дип игълан кыл-

---

[1] П.С.З., том 2. *(Авт. иск.)*

[2] Димитрий (Даниил Андреевич Сеченов) (1709 – 1767) – Рус православие чиркәве епископы (1742), Санкт-Петербург епископы (1757), Екатерина II не коронацияләүче, Идел буе татарлары арасында миссионер.

[3] П.С.З. том 12, № 9379. *(Авт. иск.)*

[4] Можарский. Изложение хода миссонера деятельности (Чтения в ист. Обществе…) кн. 1, с. 23). *(Авт. иск.)*

дылар (П.С.З., том 12, № 8929). Билгеле, мондый вакыйгалар шиддәтле рәвештә бастырылып, гаепле кешеләрне каты җәза кылдылар, хәтта шундый вакыйгаларны басар өчен, махсус гаскәр тәгаен кылынды. Шул ук чакта Себердә дә ифрат руханилар хакимияте хөкем сөрә: чукындыру эшләренең башында торучы митрополит Сильвестр Главацкий[1] татар балаларын гаиләләреннән көчләп алып чукындыра. Йортларны алып, татар хуҗаларыннан рөхсәтсез чиркәү ясый, халык, моңарга чыдый алмыйча, аны тотып алып кыйный башлап, киемен ерталар[2].

Елизавета хөкүмәт сөргән чакта, 1743 елда (1742 ел 19 ноябрь указы белән), Казан һәм Казан өязендә генә 533 мәчеттән 418 ен ваттыралар[3]. Шундый ук эшләр Себер һәм Әстерхан тирәләрендә дә эшләнә. Шул ук чакта әлеге Лука татарны гаҗиз итүен дә дәвам кыла: балаларны көчләп алып православный дин мәктәпләренә кертә, тәреләр алып чыгып, Иске Татар бистәсендә крестный ход ясап йөртә. Татар арасына китереп, чиркәүләр сала. Эш моның белән генә бетми. 1750 елда указ чыгарып, татарны Иске Бистәдән куып, хәзерге Яңа Бистә урынына көчләп күчерү хакында әмер килә, шул эшне бетерергә 1751 елның язына кадәр миһләт бирелә. Бу закон да руханиларның башлыгы Луканың котырыгы белән ясалган иде. Лука Синодка язган зәһәрле шикаятьнамәсендә шулай ди: «Опыт татар, яко христоненавистных недоброходов, для происходимых от них христианскому благосчетью соблазнов, от общежительства с православными христианы удалить и на том месте, где оные прежде жили строиться не попускать»[4].

Билгеле, бу күчүләр Татарстанның мәркәзе Казан шәһәрендә торучы татарлар өчен ифрат авыр булды, сенатка шикаятьләр,

---

[1] Митропролит Сильвестр (Стефан Гловатский яки Гловацкий, Главацкий) – Рус православие чикркәве епископы, Суздаль һәм Юрьев митрополиты.

[2] Можарский, с. 88. *(Авт. иск.)*

[3] П.С.З., том 2, № 8664, 12, № 8978. *(Авт. иск.)*

[4] Чөнки бу шикаять Казандагы зур янгын соңында бирелгән булган. Бу мәнбәгъ алынды: Описание документов, хранившихся в архиве Св. Синода, № 272/131.*(Авт.иск.)*

гаризалар, вәкилләр җибәрделәр: аларда татарларны Луканың көчләп чукындыруы, татарларның йортларын җимертүе, алар урынына керәшен школасы салдыртуы шикелле вәхши эшләр сөйләнә. Бу гаризаларның нәтиҗәсендә, бигрәк тә бу чакта ихтилял[1] эчендә кайнап торган Башкортстанның ярдәме аркасында, аз-маз гына җиңеллекләр бирелде, ләкин вәхшәт һаман да дәвам кылды.

Мәсәлән, 1762 елда Гостиный рәттә вә башка базарларда татарга маллар белән сату итүче вак сәүдәгәрләрнең 29 данә кибетләре яптырылды. Аларга сәүдә кылырга ясак ителде[2]: хәтта иске-москы һәм ашау-эчү нәрсәләре белән дә сату итмәскә әмер булды, халыкны зинданнарга яба башладылар[3]. Сенатка яңадан шикаятьләр ява башлады.

Табигый, мондый мохиттә нә әдәбият, нә дә мәдәният туа алмады, әүвәлдән дингә салкын караган, рәсмән генә мөселман булып, асылда үзенең гадәт-йолалары белән яшәүче XVI һәм XVII гасырлар татар крестьяны бу дәвердә дин кысынкылыгы аркасында фанатизмга бирелде: аның руханилары игътибар казандылар; гарәп теле фанатизм аркасында баш булды, халык үз теленә аз игътибар итә башлады. Шулай итеп гарби Яурупада бу вакыт рационализм вә хөррият фәлсәфәсенең гасыры булып хисапланса, бу гасырда безнең крестьяныбыз дингә тотынды, мулланың кочагына ыргытылды, шуның нәтиҗәсе буларак, татар арасында ишанлык туды, татар крестьяны белән рус халкы арасында рус алпавытлары вә руханиларының начар сәясәтләре аркасында салкынлык туды. Шуның аркасында Яурупа мәдәниятенә каршылык зоһур итте[4]. Шуның өчен без бу XVIII гасыр дәверебезне әсарәт[5], мәхкүмият һәм караңгылык дәверебез дип атарга тиешле. Шуның өчен бу замандагы әдәбиятыбызның юклыгына ис китәргә ярамый.

[1] Ихтилял – баш күтәрү, фетнә.
[2] П.С.З., том 16, № 11888. *(Авт. иск.)*
[3] П.С.З., том 16, № 11888. *(Авт. иск.)*
[4] Зоһур итде – килеп чыкты.
[5] Әсарәт – әсирлек.

Елизаветаның соңгы көннәрендә татарларда иҗтимагыйсәяси хәрәкәт көчәеп китте, хәтта 1748 елларда Казан өлкәсендә ихтилял хәрәкәте сизелә башлады: бу ихтилял бары хөкүмәтнең шиддәтле тәдбирләре аркасында гына булмый калды[1]. Гомумән, Петербурга татар вәкилләре килеп һәм Татарстаннан сенатка гариза биреп, шикаять бирүләр күбәеп китте. Шуның нәтиҗәсендә татарларга җөзьи[2] генә булса да ирек бирелде. Бу иркенчелек Екатерина тәхеткә кичү белән тагы да артты. Русиянең бу чактагы сәүдәсе артуы, Русия малын үткәрергә шәрыкта базар эзләү мәсьәләсе татарларга карашны үзгәртте. Шуның өчен татарларны бу сәүдә васитачылыгында истигъмаль итү[3] фикере көчәйде. Екатеринаның тәхеткә утырган көннәрендә инде бу мәсьәләгә даир рус зыялылары арасында татарларны дингә кыстау, аларга мәдәни тормышка ирек бирелмәүләр хакында бу мәгълүм фикер ясалган, кенәз Щербаков та үзенең «Рассуждение о России» дигән әсәрендә бу хакта ачык фикер бәян иткән иде[4]. Башта Франциянең XVIII гасыр фәлсәфәсе яклы Екатерина үзе дә, бу хакта, 1770 елда Казанга килгәч, мәшһүр француз философы Вольтерга язганда, шулай әйткән: «Менә мин Азиядә. Минем үз күзем белән күрәсем киләдер иде: бу шәһәрдә егермеләп төрле милләт тора. Бер-берсенә бөтенләй охшамыйлар: аларга һәммәсенә дә бердәй килешерлек кием киертергә кирәк». Табигый, бу кием моңарчы көчләп киертергә теләнгән кием түгел иде.

Менә шуның соңында бездә мәдрәсәләр ачыла башлады. Татар арасында инде Лука Канашевичлар белән бергә хәрәкәт кылган, татарлар:

Ише булды башыбыз,
Эштә булды ашыбыз, –

дип зарланган муллалар бетә башлады. Ниһаять, 1785 елда, именной указ белән[5], мәчетләр янында мәктәп-мәдрәсәләр салу

[1] Бу хакта мөфассал мәгълүмат Ватякскийның «...һәм Оренбург...» дигән китабында җилд 3, сәхифә 745 һәм 746. *(Авт. иск.)*

[2] Җөзьи – кечкенә.

[3] Истигъмаль итү – файдалану.

[4] Чтения в ист. Общ. Ист. и древ. Российских. Кн. 3, отд. 2, с. 61–62. *(Авт. иск.)*

[5] П.С.З., том 22, № 16.256. *(Авт. иск.)*

закон хөкеменә керде. Шулай ук 1788 елда татар-башкортларга Мәхкәмәи шәргыя[1] ачылды[2]. Ниһаять, 1797 елда хөкүмәтнең әмере белән 3600 данә Коръән басылып таралды. Ниһаять, 1799 яисә 1800 елда булырга кирәк, Казан, Оренбург вә башка җирләрдән хөкүмәткә мөрәҗәгать итеп, дин китаплары басарга рөхсәт итүне сорадылар. Моның нәтиҗәсе булып, 1800 елның 15 декабрендә Петербургтагы гарәп хәрефләре булган типография Казанга күчерелеп, гимназия идарәсенә бирелеп, Казан мөселман китаплары баса торган матбагалы булды, беренче нашир дә табылды. Отставной прапорщик Габделгазиз Борнашев гимназия идарәсе белән гарәп вә татар китаплары басарга могаһәдә[3] ясады. 1802 елда матбага эшкә кереште. Беренче басылган китаплар шушы булды: «Иман шарты», «Пиргули китабы», «Фәүз эн-Нәҗат»[4], «Сөбат әл-гаҗизин»[5], «Устувани»[6], Коръән.

Шул рәвешчә, әүвәл заманда язма килеш укылып йөри торган китаплар халык арасына басылып тарала башладылар. Татар халкы, байтак мөселман халыкларыннан алда матбагалы, басылган әдәбиятлы бер халык булып, XIX гасырга керде.

**V**

Менә шундый әхваль[7] безнең татар халкына әдәбият тудырырга юл куймады. XIX гасыр башында башланган беркадәр

---

[1] Мәхкәмәи шәргыя – дәүләт оешмасы буларак Идел-Урал, Себер төбәкләрендә, үзәк губерналарда мөселман руханилары эшчәнлеген, мәхәлләләр тормышын күзәткән, бер үк вакытта татар-башкортларның дини-мәдәни автономиясе башында торган оешма.

[2] П.С.З., том 22, № 16.710. *(Авт. иск.)*

[3] Могаһәдә – килешү.

[4] Әбү Гали Мискавейхның (932/36–1030) гарәп телендә язылган хезмәтенең фарсы, аннан соң татар теленә иректле тәрҗемәсе (тәрҗемәчеләре билгесез).

[5] Суфи Аллаһиярның (1616–1713) «Сөбат әл-гаҗизин» («Гаҗизләргә терәк», 1802) әсәре.

[6] Мөхәммәд Устуванинең «Китаб мөстәтаб вә шәрәф әл-мааб Устувани» китабы.

[7] Әхваль – хәлләр.

җиңеллекләр дә аңар бу юлда ярдәм итмәделәр. XIX гасырның беренче яртысында, татарлар тарафыннан язылып та, татар арасында гамләшкән[1] әсәрләрдән без бары «Рисаләи Газизә»[2] белән «Фәзаил әш-шөһүр»ен[3] генә күрәбез. Чыгтай вә госманлы шагыйрьләренә тәкълид итүче берничә шагыйрь чыккаласа да, алар, гомуми үлчәү белән үлчәгәндә, бик зәгыйфь, бик көчсезләр; шуның өстенә тагы аларның язганнары халык арасында рәваҗ табып[4], гомумиләшеп китә алмады. Әлхасыйль, мәхкүмият[5] дәверендә татар арасында бөек, даһи әдәби әсәрләр түгел, хәтта мәктәптә укыту өчен дәреслек хезмәтен үтәргә яраклы китаплар да җитәрлек дәрәҗәдә язылмадылар. Гүяки әдәбият тудырырга зәмин[6] булырлык иске көчләр йөзләрчә еллык икътисади, сәяси вә рухани изелү аркасында тапталганнар, юкка чыкканнар; татарның иҗади куәтенә көчле бер зарбә орылган[7]; яңа әдәбият тудырырлык яңа көчләр исә әле җитешмәгәннәр һәм аларга мәдәни зәмин дә юк иде.

Ләкин, шуның белән бергә, нинди генә кысулар да безнең халыкта уку-гыйлем дәртен бетерә алмады; киресенчә, дини кысынкылыклар халыкның фанатизмын уятып, аны «дин өйрәнү» шәкелендә тәсаувыр ителгән укуга сәвекъ итте[8]. Иң караңгы дәверләрдә дә бездә уку-укыту эше тәмамән сүнмәгән булырга кирәк. XVIII гасыр рус язучысы Рычковның[9] сөйләвенә күрә, ул чагында да Татарстан вә Башкортстандагы татар авылларының

[1] Гамләшкән – массалашкан.

[2] «Рисаләи Газизә» – Таҗеддин Ялчыгол тарафыннан 1806 елда язылган әсәр, Суфи Аллаһиярның «Сөбат әл-гаҗизин» әсәренә шәрех.

[3] Җамалетдин Бикташиның «Фәзаил әш-шөһүр, яки Саваплы гамәлләр» китабы.

[4] Рәваҗ табып – таралып.

[5] Мәхкүмиять – хөкем астында яшәү.

[6] Зәмин – җирлек.

[7] Зарбә орылган – бәрелгән, сугылган.

[8] Сәвекъ итте – юнәлтте.

[9] Пётр Иванович Рычков (1712–1777) – рус дәүләт эшлеклесе, географ, тарихчы. Көньяк Уралның беренче төбәк тарихчысы буларак мәгълүм. Казакъстан, Урта һәм Түбән Идел тарихын тикшергән.

һәрберсендә мәчет янында мәктәп булган. XIX гасыр ахырларында да (ысулы кадим дәверендә) татар халкының үз телендә укый-яза белү җәһәтеннән гомум рус халкына караганда процент ягыннан күп өстен торганлыгы мәгълүм. Димәк, шулай итеп, татар халкы мәктәпсез тормады. Яшертенме, ачыкмы – ул укыды, укытты. Һәрбер авыл кешесе дә үзенең углын – «мәктәп»кә, кызын «абыстай»га җибәреп, әкалле[1] берничә ел укытуны үзенең өстенә йөкләнгән иң зур фарызлардан берсе дип хисаплап килде.

Менә шул мәктәпләрдә укыту өчен, дәрес китаплары кирәк иде. Мәктәпләрдә укып чыккан халык гаммәсенә дә, үзенең әдәби-рухи ихтыяҗын тутырыр өчен, укырга китаплар кирәк булды. Халыкка караганда зуррак укыган, ләкин гарәпчә моталәгасы чыкмаган[2] муллалар, мәзиннәр, хәлфәләр, остабикәләргә дә, укыр өчен, төркичә китаплар кирәк иде. Әмма татарның үз арасыннан язучылар чыкмады; халыкның ихтыяҗын капларлык әсәрләр тумады. Менә шул кирәген тутыру өчен, татар үзенә кирәкле әсәрләрне үзенең кардәшләре булган башка төрк халыкларының әдәбиятларыннан алырга тотынды. Чыгтай, госманлы әдәбиятларыннан берничә дистә әсәрләр бурычка алынып, ахрысында, «түләнмәс бурыч»ка әйләнеп, татар халкының төп үз малына әверелеп, аның рухани тормышы, дөньяга карашы белән органик рәвештә багландылар. Шулай итеп, читтән килгән байтак гарәпчә, фарсыча китаплар белән бергә бер такым[3] төркичә «килмешәк» әсәрләр дә безнең халык гаммәсе арасына кереп, тәгъмим ителеп, аның өчен үз телендәге әдәбият урынын тотып, әдәби ярлылыгын каплап килделәр. Шуңар күрә дә без бу әсәрләрне татар әдәбияты рәтеннән тикшерергә мәҗбүр булабыз.

Чыгтай әсәрләрен безгә Урта Азиягә укырга барган шәкертләр, димәк, булачак муллалар, үзләренең шунда хасыйл

[1] Әкалле – аз дигәндә.
[2] Моталәгасы чыкмаган – укый, өйрәнә алмаган.
[3] Такым – төркем.

иткән[1] мәгънәви багажлары белән бергә төяп алып кайттылар. Шуның өчен дә алар күбрәк дини әсәрләргә, бигрәк тә киләчәктә үзләре укытачак мәктәпләрдә кулланыр өчен яраклы булган рисаләләргә игътибар иттеләр. Шуңар күрә безгә чыгтай әдәбиятыннан «Бакырган», «Ахырзаман», «Диване хикмәт», «Рәүнәкъ әл-ислам», «Сөбат әл-гаҗизин» шикелле дини вә тәсаувыфи[2] рухтагы әсәрләр күбрәк керде. «Сәйфелмөлек» тибындагы халис әдәби әсәрләр безгә Урта Азиядән берәмтекләп кенә кайтты. Татар өчен бер дә аңлаешлы булмаган XV гасырдагы чыгтай шагыйрьләренең әсәрләре безнең арада бөтенләй оя ясый алмадылар.

«Йосыф китабы», «Кисекбаш китабы» аталган ярым чыгтай, ярым җәнүб шивәсе белән язылган ике әдәби әсәр, шул ук Хәзәр диңгезе артыннан килеп булырга кирәк, безнең халыкның иң сөекле китапларыннан булып киттеләр. Һәм югарыда саналган чыгтай телендәге әсәрләр белән бергә татарның мәктәп програмына керделәр.

Госманлы телендәге әсәрләрне безнең илгә алып кайтучылар исә күбрәк Истанбул аркылы хаҗга барган татар хаҗилары иде. Шуның сәбәпле булырга кирәк, безгә Төркиядән мәктәп өчен кирәкле китаплар түгел, бәлки халис әдәби китаплар кайтты.

Ләкин һаман да бу китаплар госманлы әдәбиятының чәчәкләре түгел, бәлки, «Мөхәммәдия»не истисна белән[3], үз ватаннарында әдәби яктан түбән вә әһәмиятсез саналган әйберләр иде. Классик госманлы шагыйрьләренә, аларның чын теле белән «гали» сюжетларга язылган шигырьләренә безнең садә вә надан татарның теше батмады. Ул бары тик мәддахлар вә кыйссаханнар[4] тарафыннан мәйданга китерелеп, төрк гаммәсенең яратып укый торган китапларын гына үзенә кабул итеп алды. Чын

[1] Хасыйл иткән – тапкан.
[2] Тәсаувыфи – суфилык, ишанлык.
[3] Истисна белән – аерып алганда.
[4] Мәддахлар вә кыйссаханнар – мәдхия һәм кыйсса язучылар, хикәяләүчеләр.

әдәби азыкның иң зур кыйсемен безнең татарга шул Кара диңгез артындагы кардәшләр – госманлылар бирде. Алардан кергән китаплардан «Мөхәммәдия»не көйләп, безнең татар күзләрен яшьләтте[1], «Сәид Баттал», «Сары Салтык», шикелле сугыш китапларын укып ул хиффәтләнде[2], «Тутыйнамә» шикелле кыйссаларны укып гыйбрәтләнде, «Әбүгалисина»ны укып кәефләнде, «Хуҗа Насреддин»ны укып көлде. Менә бу китаплардан татар мәктәбенә бары «Пиргули» белән «Мөхәммәдия» генә кабул ителде. Соңгысы да кызлар мәктәбенең «абыстай» курсының иң югары группаларына гына хәсыр кылынып калды[3].

Чыгтай вә госманлы әдәбиятларыннан бу әсәрләрнең кай чорларда безнең арага килеп таралулары мәгълүм түгел. XIX гасырга кадәр алар халык арасында кульязмаларда йөрделәр. Матбагачылык башланганнан соң алар, бер-бер артлы басылып, халык арасында тагын да ныграк таралдылар. Аларның күбесенең XVIII гасыр эчендә үк укылган булулары – якын ихтималлардан. Ихтимал, кайберләре аннан элегрәк тә таралган булганнардыр. Һәрхәлдә, күчерелү тарихлары мәгълүм булган кульязмалар табылып тикшерелгәнче, бу мәсьәлә ачык калып тора.

## ИДЕЛ БУЕНДА<br>ИҢ БОРЫНГЫ ТЕЛ ЯДКӘРЛӘРЕ

### «Коман мәҗмугасы»<br>(Codex Cumaniecus)

Безнең татар шивәсен ясауда иштиракь кылган халыкларның телләреннән безнең заманыбызга бик аз мәнбәгъләры сакланып калган. Шуларның иң мөһим булганы – «Коман мәҗмугасы» яисә латинча «Кодекс куманикус» исеме белән аталып йөртелә торган мәҗмугадагы коман теленең үрнәкләредер.

[1] Текстта: яшәртте.
[2] Хиффәтләнде – биредә: җиңеллек, рәхәт тапты.
[3] Хәсыр кылынып калды – кулланыла торган булып калды.

Мәсьәләнең үзенә кермәс, әсәрнең үзен тикшерә башламас борын, бу мәҗмуганың теленең хуҗасы булган халыкның тарихыннан бераз мәгълүмат биреп китәргә кирәк.

Урта гасырларда шәркый Яурупаның җәнүб сахраларында күчеп йөргән төрк халыкларыннан берсе һәм татар-монголлар килгәнче иң соң килүчесе – яурупалылар «коман» атаган бер халык иде.

Болар Яурупага 1063 елда килеп чыктылар. Бу халыкны рус летописьлары «половцы»[1] дип атадылар. Мәшһүр немец мөстәшригы Хаммер бу сүз төркләрнең гомуми исемнәре «гуз, угыз» сүзе белән «кыр» мәгънәсендә булган русча «поле»[2] дигән сүздән хасил булган сүз дип дәгъва кыла[3].

Ләкин бу халык үзләрен ничек атаганнардыр – мәгълүм түгел: ләкин шәрык мәнбәгълары боларны «кыпчак» дип атыйлар, ихтимал, үзләре дә шулай атаганнардыр.

Команнар күчмә ыруг тормышы белән торучы, һәрбер ыруг үзенә махсус хан тарафыннан идарә ителүче бер халык булган. Боларның ыруглары үзләренең мәшһүр бер ханнары (ыруг башлыклары) исеме белән аталганнар. Мәсәлән, аларның Бөрҗи углы, Конгыр углы, Антих углы исемле ыруглары булып, шуларның эчендә берсе Кара бүрекле исеме белән мәшһүр булган. Бу халыкны шул замананың мөхәррирләре мактап язалар. XIV гасыр гарәп мөхәррире Ибн Яхъя алар хакында: «Кыпчак төркләре башка халыклардан диндарлык (табигый, бу алар мөселман булгач язылган), батырлык, хәрәкәттә тизлек, камәтләренең[4] матурлыгы, чиһрәләрнең[5] турылыгы[6], галиҗәнаблык белән аерылалар», – ди.

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[3] Hammer, Geseh der Gold. Horde, s. 22. *(Авт. иск.)*

[4] Камәтләренең – буй-сыннарының.

[5] Чиһрәләренең – йөзләренең.

[6] Биредә сүзләрнең урыннары буталган булса кирәк: камәтләрнең турылыгы, чиһрәләрнең матурлыгы булырга тиеш.

Команнар, башка күчмә төркләр шикелле, сугыш кылып торалар, ләкин тыныч чакларда хозур кылырга да сөяләр иде. Зур сугышлардан кайткач, хан батырлар белән мәҗлес ясый. Алларына кымыз килә, батырлар исерешәләр, кыллы музыкада чиертеп уйный башлыйлар, кызлар-кәнизәкләр бииләр, шул вакытта халык җырчылары мәйданга чыгып, саз чиертеп, борынгы батырларны, борынгы заманнарны искә төшерәләр иде[1]. Команнар күчмә булсалар да, аларның җирләрендә шәһәрләр булган: алар һаман сугышып, күршеләренә һөҗүм кылып торсалар да, сәйях һәм сәүдәгәрләргә тими торган булганнар.

Алар ат, кол белән Кара диңгез буйларындагы колонияләрдә торучы Җәнүвә[2]-Венеция һәм юнан-рум сәүдәгәрләре белән алыш-биреш кылганнар.

Команнар, шәркый Яурупага татарлар һөҗүме вакытында руслар белән бергә татарларга каршы сугышып, мәшһүр Калка сугышында 1223 елда җиңелеп качтылар. Боларның бер кисәге Маҗарстанга кереп китте. Әмма бер кисәге татарларга буйсынып калдылар һәм, Алтын Урданың иң күп әһалисен тәшкил кылып, килмешәк монголларны тәмсил иттеләр[3]: ниһаять, Алтын Урдага Кыпчак урдасы дип үз исемнәрен куштылар. Ибн Баттута шикелле XIV гасырда Дәште Кыпчакка килүче сәйяхлар Үзбәк ханның сараенда төрк, ягъни коман телен таптылар.

Менә шушы халыкның теле хәзерге татар телен ясауда бер гонсырлык ролен ифа итте[4]. Шуның өчен дә без бу команнарның тел калдыкларына туктап китәбез.

Венеция шәһәрендә мөкаддәс Маркос исемендәге кәлисәнең көтепханәсендә мәшһүр шагыйрь Франческо Петрарка тарафыннан Венеция җөмһүриятенә һәдия кылган китаплар арасында 1303 елда язылган латинча-фарсыча-команча бер лө-

[1] Бу хакта матур мәгълүмат XII гасыр рус мәнбәгъләрыннан «Слово о полку Игореве»да табарга мөмкин. *(Авт. иск.)*

[2] Җәнүвә – Генуя.

[3] Тәмсил иттеләр – ассимиляцияләделәр.

[4] Ифа итте – башкарды.

гать китабы, шунда ук коман теленең сарыф[1] вә нәхүе[2] хакында бәгъзы мәгълүмат, команчага тәрҗемә кылынган догалар, халык әдәбиятыннан мәкалә вә табышмаклар, Инҗил кисәкләренең тәрҗемәсе булган бер мәҗмуга табылган. Шушы китапны «Кодекс куманикус» дип атаганнар.

Мәҗмуга латин хоруфаты[3] белән язылган. Коман төркисенең авазларына латин хәрефләре җитмәгәнгә, бу хакта бер катгый юл тотылмаган. Төрк авазларына, җиткән кадәр, итальян телендә табылган хәрефләр, анда да җитмәгәннәренә немец телендә шуңарга туры килгән авазларны алганнар.

Бу эш исә тәртип вә тәрҗемә кылучыларның итальяннар яисә германнар булуыннан килгән булып, шушы вакыйга әсәрнең төрле вакытта төрле милләт вә төрле кешеләр тарафыннан язылганлыгын күрсәтә алалар. Нә итальян вә нә дә германнарда табылмаган авазларга исә мөхәррирләр яңа галәмәтләр дә тапканнар. Мәсәлән, «җ» авазына латин хәрефеннән «g» алынып, шуның өстенә әркаме һиндиядән[4] сигезле цифр төсле галәмәт куелган. Бәгъзы урында итальянча да җитешмәгән авазлар шуңарга охшаган хәрефләр васитасы белән ифа ителгән. Мәсәлән, татарча «с» һәм «ш» авазлары латинча «s» хәрефе белән йөртелгән. Татарча «ң» авазына ике хәрефтән мөрәккәб[5] галәмәт куйганнар да «ng» булган[6]. «Кодекс куманикус»ның кем тарафыннан яисә кемнәр тарафыннан язылып та, кем тарафыннан җыелганлыгы мәгълүм түгел. Язылуының максаты хакында шулай уйларга мөмкин: XIII гасырның ярымыннан алып, XV гасырның уртасына кадәр Җәнүвә һәм венециялеләр үзләренең Кара диңгез ярларындагы колонияләре аркылы җәнүби Русиядәге күчмә төркләр белән сәүдә мөнәсәбәтендә булалар

[1] Сарыф – морфология.
[2] Нәхү – синтаксис.
[3] Хоруфаты – хәрефләре.
[4] Әркаме һиндиядән – һинд цифрларыннан.
[5] Мөрәккәб – кушылган.
[6] Бу хакта мөфассал мәгълүмат: Радлов. По поводу куманского словаря. *(Авт. иск.)*

иде: димәк, бу сәүдәгәрләргә команча белергә кирәк булган, шуның өчен бу мәҗмуга ясалган. Бу мәҗмуганы тикшерүче немец Блауның әйтүенә күрә, мондый мәҗмугалар күп булган булып, безнең заманга кадәр калганы гына шушыдыр[1]. Бу – бер ихтимал. Икенче яктан, мәҗмуганың зоһурының сәбәбе шушы булырга мөмкин: мәгълүм ки, Кара диңгез буендагы итальян колонистлары, төркләр арасында тора-тора, үзләренең телләрен онытып бетергәннәр, бу мәҗмуга исә – шуларның төрки теле, латин хоруфаты белән язылган дин китапларыдыр. Өченче һәм иң якын ихтимал булса, команнарны дингә өндәгәндә кирәк булганлыгы өчен, бу мәҗмуга миссионерларга кулланма рәвешендә язылган булуыдыр.

Без «Коман мәҗмугасы»нда ике төрле мәдәни тәэсир күрәбез. Шуның беренчесе – христианлык тәэсире. Рус летописьләре половецларның (команнарның) үзләре арасыннан кәшишләр[2] һәм чукынган кешеләрнең булганлыгын сөйлиләр. Мәсәлән, 1168 елда – Айдар хан, 1332 елда Амсурат[3] хан христиан булганнар. Шуның тәэсирендә команнарга рус мәдәнияте (әгәр болай атарга яраса) тәэсир итте. Үзләрендә булмаган, утрак тормышка махсус булган истыйляхларны[4] команнар рустан алдылар: мәсәлән, без кодекста isba – изба, рес – печь дигән сүзләрне табабыз. Католик дине дә команнар арасында тара-

---

[1] Ueber Volkstum und Sprache dor Cumanen. *(Авт. иск.)*

[2] Кәшиш – христиан рухание.

[3] Биредә елларны билгеләүдә беркадәр төгәлсезлек киткән. Рус елъязмаларында 1132 елда кыпчаклардан Амурат кенәзнең һәм 1168 елда Айдар кенәзнең православие динен кабул итүе турында мәгълүмат бар. (Кара: Полное собрание русских летописей. Том девятый. VIII. Летописный сборник, именуемый Патриаршею или Никоновскою летописью. СПб., 1862. С. 158; 236). Әмма, тикшеренүчеләр билгеләвенчә, елъязманың бу варианты XVI гасырга, христиан диненең башкалардан өстен дин булуы турындагы фикер киң таралган дәвергә карый, һәм шунлыктан әлеге мәгълүматлар шик тудыра (Кара: Голден П. Религия кипчаков средневековой Евразии // Степи Европы в эпоху Средневековья. Т. 6: Золотоордынское время. Донецк, 2008. С. 326).

[4] Истыйлях – атама, термин.

лып, ул мәзһәбнең истыйляхларына команнарда катгый сүзләр дә пәйда булды. Латинча «алла» мәгънәсендәге «Deus»ны – «тәңре», Мәрьям ана яисә латинча «Mater Dei»ны – «Мәрьям хатын» дип, аркылыны – «хаҗ» дип, изге китапны төркчә «түрә» дип тәрҗемә кылалар. «Коман мәҗмуга»сында ислам тәэсире дә күп. Гарәп әл-Бәкринең сөйләвенә күрә, 1009 һәм 1010 миладиларда, бер мөселман фәкыйһе килеп, 12000 кешене ислам диненә керткән. Гомумән, команнарга исламият бик иртә керә башлаганлыктан, аларның телләренә дә бик күп гарәп вә фарсы сүзләре кергәннәр. Көннәрне хәзер татар атаганча фарсыча атап, бары «җомга» гына «айда – Айда[1]», шимбәне «сабат көн»[2] дип йөртеләә. Шулай ук коман теленә *казый, шәригать, солтан, хөкемче, дәллял[3], кассаб[4], җәйш[5], галәмәт, хәммаль[6], җәрихә, савап, вәгъдә, хәләл, гаеп, шәһәр, милек, нигъмәт, нигъмәтле* дигән истыйляхлар да кергән. Шулай ук команчага гарәпләрдән мөҗәррәд мәфһүмнәр (отвлеченные понятия[7])дән: *гомер, гаҗил[8], ләззәт, вакыт, гариб, гашыйк, бөхел[9], гакыл, садака* сүзләре катышкан. Ләкин команнарда ай атлары төркчә булган: март – яз ае, апрель – элек яз ае һәм төбәй (Tobay), май – яз ае, июнь – соң яз ае, июль – көз ае, август – урта көз ае, сентябрь – соң көз ае, октябрь – кыш ае, ноябрь – урта кыш ае, гыйнвар – сәвер ай, февраль – соң ай, декабрьне аресау[10] дип йөргәннәр. Ләкин бу сүзнең нәрсә дигән сүз икәне мәгълүм түгел.

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган..

[2] «Сабат» сүзе яһүд динендәге хәзәрләрдән күчкән булырга кирәк. Бу хакта: Голубовский. Печенеги, торки, половцы, с. 153. *(Авт. иск.)*

[3] Дәллял – арадашчы, маклер.

[4] Кассаб – сугымчы, итче.

[5] Җәйш – гаскәр.

[6] Хәммаль – йөк ташучы.

[7] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[8] Гаҗил – ашыгыч.

[9] Бөхел – саранлык.

[10] Латин хәрефләре белән язылган.

«Коман мәҗмугасы» буенча, халыкның теленең хәзерге кайсы шивәләргә якын торганлыгы мәсьәләсенә киләбез. Элек бу хакта мәнбәгълар сүзен, соңра тюркологларның фикерләрен, аннан соң мәнбәгъның үзен карап карыйк.

Дәште Кыпчакны татарлар алгач, команнар арасыннан Урта Азиягә үтеп киткән Рубруквис: «Уйгурларның телләренең әсаслары һәм тамырлары төрек вә коман теленеке», – ди. Минорит ордены миссионеры: «Мин исә мәслихәтләшеп, элек илнең телен өйрәнергә теләдем һәм Алланың гыйнаяте аркасында коман телен һәм уйгур язуын өйрәндем ки, бу тел һәм язу бөтен илдә истигъмаль кылына», – ди.

Тюрколог Блау да, «Кодекс»ны тикшергән соңында шул ук фикергә килеп, команнарның телләре – чыгтай яисә үзбәк төркисенә якын «шәрык төрки» шивәсе, ди.

Радлов, коман теле хакында «Коман теле лөгате мөнәсәбәте белән» дигән әсәр язып, бу телне тәхкыйк кылган[1] соңында, Иртыш буе татарларының, башкорт, кыргыз, Идел буе төркләренең шивәсенә якын дип таба. Аның фикеренчә, коман шивәсе мишәр шивәсенә бик якын тора. Әмма тавышлы авазлар һәм аларның телдә тоткан урыннары ягыннан коман теле кыргыз шивәсенә бик ошый. Әмма кыргыз шивәсе булса, бу яктан Идел буе татарларының борынгы шивәләренә бик якын. Радловның фикеренчә, коман теле безгә татар теленең биш йөз еллык булган бер халәтен күрсәтеп, шушы биш гасыр эчендә татар теленең алмашу тарихын ачып бирә.

Әгәр без әсәрнең эченә кереп карасак, Радловның бу фикеренең дөрес булуын күрәбез. Моның өчен, сүзне озайтмыйча, бер-ике мисал алу җитә. Менә бер-ике коман табышмагын алыйк:

«Тап-тап тамасыйк тамадирган тамасыйк. Ул күбәләк». «Бити-бити битедем биш агачка битедем күнәсин йөкертдем бәкин чирмәдем. Ул кинадир».

---

[1] Тәхкыйк кылган – дөреслеген тикшергән.

Соңгы мисалны ике галим (Геза Кон[1] һәм Радлов) ике төрле аңлыйлар. Радлов: «Яза-яза яздым, биш агачка яздым, көнә суы белән издем. Таза-таза чормадым: ул кынадыр», – дип укый. Әмма Геза Кон: «Ул киндер», – ди.

«Ултырганы уба (биек) йир, басканы багир (бакыр) чамат (Конча – кечкенә савыт, Радловча – чана), ул өзәңге»[2].

«Бу барди – эзе юг. Көймәдер».

Янә мисал өчен католик иманының кисәген алыйк[3]:

«Инанырмын барчага эрекли бир ата Тәңригә, күкне, йирне күрүнүр-күрүмешни яраты, дагы бир бәйимез Иисус Христос Тәңренең ялгыз торган улы дип, ким барча заманлардан борын аталу аптырур, Тәңре Тәңредән әйтилмәй атага төздәс (ш)[4] туып торур, андан улам бар барча булган турур, ким биз азамлар үчүн дагы бәзим үңгүмиз үчүн, күкдән әниб арытындан улам ирдәң маямдә[5] тәнәлиб киши булуп турур».

Билгеле, бу үрнәкнең дә аңлашыла торган сүзләре безнең шивәгә бик якын, бәгъзы җирдә тавышлы хәрефләрнең татарча «е» урынына «ы» истигъмаль ителүе исә – безнең телебезгә махсус тавышлы хәрефләрнең булмавындадыр.

Русның «Отче наш»[6] дип йөри торган догасының мәҗмугадагы команча тәрҗемәсен алыйк:

«Атамыз кем күктә сән тиешле булсын сәнең ханлыхын булсын сәнең теләмәген нәчик кем [күктә] әлләй йирдә күндәге

---

[1] Comes Geza Kuun, Codex Cumanikus. *(Авт. иск.)* Геза Кон (1838–1905) – «Коман мәҗмугасы»ның тулы текстын искәрмәләр белән эшләп бастырган венгр шәрыкшинасы.

[2] Монда «у» авазы латинча «о» рәвешендә язылган. *(Авт. иск.)*

[3] Бу кисәкләрне гарәп хәрефе белән китерәбез, чөнки матбагада латин хәрефе белән тәмамән туры китереп җыю мөмкин булмады. *(Авт. иск.)*

[4] Бу сүз латинча «шул маһияттә» дигән мәгънәдә «этюдам субстанция» дигән сүздән тәрҗемә. *(Авт. иск.)*

[5] Бу сүз ялгыш язылгандыр дип уйлана: «үземнең башымны тыя алмыйм» мәфһүмендә булырга тиеш икән. *(Авт. иск.)*

[6] Кирилл хәрефләре белән язылган.

үтмәкемезне бизгә бүгүн бәргил әләгә языкларымызны безгә бушаткыл нәчик без бушатырмыз безгә яман эткәнләргә...»

Бу мисал да коман теленең безнең телебезнең эшләнүендә роль уйнаганын күрсәтә. Янә назымлы бер мисал алабыз:

«Авә[1] очмакының калагы
Терелекең агачы
Йимшиң тә ирдең
Авә Мария кем безгә
Тудырдың бу җиһанда
Аны кем Тәңре торыр
Профет[2] ничек әйтеп торыр».

Менә шушы коман теле соңра кыпчак теленең сөйләшә торган теле булып китте, ниһаять, сарайда да шул тел белән сөйләшә башладылар. Ләкин күп заманнар үткәч, бу тел татар теле дип йөртелә башлады.

Табигый, «Коман мәҗмугасы»ндагы фикерләр хакында сөйләп булмый: андагы фикерләр – һәммәсе дә рәсми католик дине фикерләре, чөнки ул тәрҗемәдән гыйбарәт. Эчендәге табышмакларны тикшерү мәсьәләсе халык әдәбиятын тикшерүчеләргә махсус эш булганга, төрк-татар мәкаль-табышмакларын тәфтиш итүчеләргә боларны да онытмауларын тәүсыя итеп[3] үтәбез.

## Болгар кабер ташлары

Х гасырның башыннан бирле шул заманның сәүдәгәр һәм мәдәни гарәп хилафәте[4] белән мөнәсәбәт, 922 елдан алып, рәсмән исламият кабул итеп, габбасиларның протектораты астына керүләре Болгарда ислам мәдәниятен җәйде. Табигый, гарәп сәүдәгәрләре болгарларны мәдәни ясарга, протекторатны саклар өчен дә аларны чын мөселман ясарга тырыштылар.

[1] Латинча «изге кыз» мәгънәсендә. *(Авт. иск.)*
[2] Латинча «пәйгамбәр» дигән сүз. *(Авт. иск.)*
[3] Тәүсыя итеп – васыять итеп.
[4] Хилафәте – хәлифәлеге.

Чөнки гарәпләрнең икътисади мәнфәгатьләре шунда булды: гарәп мәдәниятен болгарларның кабул итүләре гарәп-болгар сәүдәсен арттырасы мәгълүм иде. Шуның өчен Багдад, Басра, Шам факторияләре, шимальнең бозлы урманнарына илтеп, мәчет, мәдрәсәләр салдыра, шул ук урыннарга мөселман фәкыйһләре, галимнәре килеп утырдылар, хәтта анда шәкертләр дә җитештереп, болгарларның үз араларыннан галимнәр дә пәйда булдылар. Ниһаять, болгарның казые (миллияте мәгълүм түгел) Йагкуб бине Ногман[1] исемле кеше болгарның тарихын да язган. Әбү Хәмид әл-Андалуси[2] 529 нчы һиҗридә бу кеше белән күрешкән һәм күп тарихи материал алган. Моннан башка Болгар йортында тыйб әсәрләре язылганы да мәгълүм. Шулай ук Мәрҗани «Мөстәфад»ының беренче җилдендә Болгарга нисбәт бирелгән бик күп галим вә фәкыйһләрнең исемнәрен һәм аларның әсәрләрен зикер кыла. Ләкин бу әсәрләрнең берсе дә болгар төркисе белән язылганы мәгълүм түгел. Шиксез, боларның эчендә төп болгар кешеләре булса да, күбрәге болгар ханы сараенда җылы урын табып килеп сыенып, аларның меценатлыгы белән файдаланып торган кешеләр булыр.

Димәк, чын болгар телендә әсәрләр безнең заманыбызга сакланып калмаган. Ләкин шулай булса да, болгарлардан безгә иске зиярәтләрдә ифрат әгъла[3] язулы, матур эшләнгән кабер ташлары сакланып калган. Боларның төркичә булганнары бары 8 нче һиҗринеке генә. VII гасырныкылар булса да, аларның текстлары гарәпчә генә. Бары тик хәзергә мәгълүм булган

[1] Йакуб бине Ногман – болгар тарихчысы һәм казый. Аның иң мәшһүр әсәре – «Тәварихе Болгария» тарихи язмасы.

[2] Әл-Гарнати Әбү Хәмид Мөхәммәт ибн Габдеррәхим әл-Андалуси (1080–1169/1170) – гарәп сәяхәтчесе. 20 ел чамасы хәзәрләр шәһәре Саксинда яши, шуннан Идел буе Болгарына (1135–1136, 1150 елларда), рус кенәзлекләренә һ.б. дәүләтләргә сәфәр чыга. Аның хезмәтләрендә Көнчыгыш Европа, шул исәптән Идел буе Болгары турында мәгълүматлар бар, Болгар шәһәре һәм анда яшәүчеләр хакында тәфсилләп бәян ителә, Идел буе халыкларының легендалары һәм риваятьләре урнаштырылган, Ягъкуб бине Ногманның «Болгар иле тарихы» («Хәдис Болгари») әсәреннән (XI йөз) өзекләр китерелә.

[3] Әгъла – матур, гүзәл.

ташлар эчендә мөәррих Гайнетдин Әхмәров[1] тапкан вә укыган ташлар арасында бер генә 642 нче һиҗри тарихлы, әмма үзе чын төркчә булганы бар. Бу таш сөлес язуы белән язылган, укылган кадәрлесе шушы: «...алдында 74 яшендә* гадәд тарих алты йөз кырык икедә 642»[2].

Бу кабер ташлары күбесе – сөлес, беразы – күфи хатт белән, кайсысы исә ике төрле хаттның катышуыннан хасил булган язу белән язылганнар. Бу ташлар өч төрле: чат гарәпчә язылганнары бар, без болары хакында сөйләмибез. Икенче төркеме булса, чыгтайчага маил[3] бер шивәдә. Бу төркеме өчен бер-ике мисал алабыз: «Бүләртай ибн Белемшак бик зиярәте торыр. Тәңригә васыл мәсрүр кылып кәүсәр шәрабе белә кандурсун. Вафаты рәҗәб ахырында тарих йите йөз егерме түртдә».

Моның теле чын чыгтайча: «йите, түрт» рәвешләре, тавышларның муәффәкатенең юклыгы («Тәңригә») моны яхшы исбат итәләр[4]. Ләкин кайсысында чыгтай формасының җәнүб төрки формасы белән катышканын да очратабыз. Менә тагы шундый язуны алыйк: «Болгар Муса углы Рәҗәб зиярәте торыр. Тәңригә васыл рәхмәтән эгрык кылсын, әмин, ахыр вафаты бирелмеш тарихка йите йөз егерме тукызында ирде». Монда без, чыгтай формалары белән бергә, «бирелгән» урынына «бирелмеш» очратабыз.

Тагын бер ташны алсак, теленең чыгтай һәм хәзерге Казан татары шивәсе белән катышканын күрәбез:

«Һуа әл-хәййе әлләзи лә йәмүт
Егетләр күрке күңелләр үзке
Галимләрне агырлаган ятим тол
Үксезләрне асраган Муса углы

---

[1] Әхмәров Гайнетдин Нәҗметдин улы (1864– 1911) – тарихчы, этнограф, педагог. Татар халкы тарихына караган этнография һәм археология мирасын туплаучы.

[2] Йолдыз галәмәте яңа юлдан. *(Авт. иск.)*

[3] Маил – тартым.

[4] Бу ташның чыгтайчасы һәм русчага тәрҗемәсе Березинның «Булгар на Волге» дигән әсәренең 38 нче сәхифәсендә. *(Авт. иск.)*

Алтынчы Шаһидулла зиярәте торыр[1].
Һиммәт кылсын шәһре рабигыль-әүвәлнең уртасында
Тарихка 717».

Әгәр бу саф төркичә булган язуларны тикшереп карасак, күрәбез ки, телләре ифрат чыгтайчага якын. Шул ук чакта «Кодекс куманикус» теленә дә бик якын. Моны исбат итү өчен, Кодекстагы Лука Инҗиленнән бер кыйтганы алыйк: «Ары Лукас әйтер әл бәнгәлим (Инҗил) эчендә ничилек бу гөл качан Христус тугды килде фирештә йиздән[2] аяте күчүчегә кем куйлар көтәр».

Моннан күреләки, команнар теле дә чыгтай теленә бик охшаган. Ләкин XIV гасырның башында язылган, халык өчен тәртип ителгән бер әсәрне чыгтай теле яисә шуның әдәби тәэсире белән язылган дип әйтеп булмый. Бу ике халыкның шивәсендә тумыштан якынлык бар, димәк, болгарларның теле дә, половецларныкы төсле, чыгтайчага якын булырга кирәк. Ләкин болгарларга чыгтай тәэсире хакында әйтергә хакыбыз бар. XIII һәм XIV гасырларда Урта Азиянең күп җирләре Җүҗи улусы кулында булганга, Җүҗи угыллары белән Чыгтай угыллары династиясе ясаган патшалыклар арасында солых хөкем сөргәнгә, Урта Азия белән Болгар арасында куәтле сәүдә барды, шулар артыннан шушы гасырларда ук сәүдәгәрләр артыннан үзләренең мәгънәви маллары – гыйлем, дин, тыйб белән акча эшләүчеләр дә килеп тордылар. Моңарга бик яхшы ачык дәлил шушы: Башкортстанда Дим буенда Чишмә һәм Кара Якуб авыллары янында бер кабер ташы бар. Бу таш иске каберстанда бер төрбә эчендә утыра. Төрбә юнылмаган таштан Болгар гыймарәтләре рәвешендә салынган. Шундагы кабер ташы өстенә кабартып, гарәп телендә түбәндәге сүзләр язылган: «Әл-гадел фи әл-әхкям хаҗи Хөсәен бик мән әл-Әмир әл-Кәбир Гомәр бик Төркестани әл-мәрхүм илаһым

[1] Без Березинча укымадык, ул Шаһидулладан соң «басы торыр би» дип укый, без «зиярәте торыр» дип укыйбыз, ташның рәсеме шулай укырга имкян бирә. *(Авт. иск.)*

[2] Йиздән – югарыдан, күктән, чыгтайчада «аез» югары мәгънәсендә. *(Авт. иск.)*

әрхәмә рәхмәтән васига[тән] вә әкрәмә бил-гафу вә-л-мәгъфирәт тәваффа фи әл-әям әт-тасигъ фи шәһри әл-мөбах сәнәт әрбәгыйн вә әснәтин вә сәбигъ мая». Димәк, бу таш шул ук VIII гасыр һиҗринеке, ягъни безгә мәгълүм булган Болгар ташларының күбесе белән гасырдаш. Аның өслүбе дә Болгар ташларының өслүбенә охшашлы, хәтта «майә» сүзенең ялгыш имласы да бу ташта тәкрар ителә. Шөбһәсез, бу кеше асыл төркестанлы булса да, Болгар иленә тәгаллекъле[1] зат булгандыр, ихтимал, ул – Төркестаннан килеп, башкортлар арасына ислам тарату белән мәшгуль булган кешеләрдән берседер. Аның каберенең изге булып хисаплануы да шуңарга дәлил була ала. Шуның шикелле Төркестаннан килгән «әүлиялар»ның Болгар илендә булганлыгын Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихе Болгария»сеннән дә күрәбез. Менә шул ташта без чыгтай шивәсендә бер назым очратабыз. Баштагы төркчә ике юлы вәзен, кафия ягыннан начар тәртип ителгән. Өченче, дүртенче юлы – гарәпчә, соңгы ике юлы тагы төркчә булып, гарәпчә назымнарның тәрҗемәсе булырга ошый:

«Ниләр касд ямлиг та кем качар кавемгә бер үлем сәгате уңар»[2].

«Әрзы дөнья хәрабә бил-игътибари, фәля ябкый мәдамә фил-карари».

«Күрәмен дөньяны вәйранә бары, һәмишә бакый ирмәс юк карары».

Өченче төрле Болгар кабер ташларында тарих, ел исемнәре, ягъни саннар чувашчага маил. Калган сүзләр чыгтай вә Казан татарларыча сүзләрдән гыйбарәт катыш тел белән тәртип ителгәннәр. Чын чыгтайчага маил телле ташлардагы «ибн, бин» сүзләре урынына боларда татарча «ул» («улы») дип язылган, бу нәүгъ[3] ташлардан да берничә мисал алыйк:

«Һуа әл-хәййе лә йәмүт Йосыф ул Мөхәммәд ул Исмәгыйль зиярәте торыр рәхмәтуллаһ галәйһи рәхмәтән васигатән фани

[1] Тәгаллекъле – бәйләнешле.
[2] Бу бәетнең өслүбе «Котадгу белег» шигырьләрен искә төшерә. *(Авт. иск.)*
[3] Нәүгъ – төр.

дөньядин бакый ахирәткә рихләт тынды тарихе җийат җүр ван туату».

«Хәйратле сариҗ юару ул Ягъкуб Юуару ул Хәсән Юару ул Мөхәммәдмир Мәхмүд тарихе җийат җүр».

«Биктимер ул Хуҗа Бәйрам зиярәте торыр рәхмәтуллаһи Тәгалә рәхмәтән васигатән вә каты билкүс җийат җүр».

«Әл-хөкем лилләһ әл-гали әл-кәбир – мирза Ибраһим әнә ул шәһид – хаҗ белеп[1] (...) рәхмәтән – Аллаһы галәйһә рәхмәтән васигатән вафат ятуы тарихе җийат җүр җийар мәнеш җал мәхрүм 1 нче икенҗ көн ати (иде)»[2].

Менә шушы саннарның вә бәгъзы сүзләрнең нә чыгтайча вә нә дә татарча булмавы галимнәрне тәмам шаштырган. Элек «җийат җүр»не «җиат җәүр» (пришествие угнетения)[3] дип укыганнар. Имеш, без «җийат җүр»нең хәрефләрен әбҗәд хисабы белән санга алмаштырып җыйсак, 623 ел һижри яисә 1226 миладыи килеп чыга. Бу ел исә татар-монголларның Болгарга һөҗүм кылып җимергән елы. Шуның өчен болгарлар моны гарәпчә (!) «җийат җүр» дип атаганнар. Ләкин Хөсәен Фәезханов үзенең русча бер мәкаләсендә бу саннарның чувашча булуы ихтималын белдергән. Шуның соңында мөстәшрикъләр арасында болгарларның теленең чуваш теленә якын бер тел булганлыгы фикере көчәеп киткән. Бу дәгъваларын исбатлау өчен, алар башка дәлилләр дә эзли башлаганнар[4].

Ләкин мөстәшрикъләр никадәр бу мәсьәлә белән шөгыльләнеп, кызып китеп, бик кызык вә гаҗәеп дәлилләр китерергә азапланмасыннар, бу ташларга карап, бөтен болгарларның чуваш булуы чыкмый. Чөнки ташлар эчендә бары чувашча гына булганнары булса, бу дәгъваны дөрес дип әйтергә мөмкин дә булыр иде. Ләкин табылган ташлар эчендә чыгтай теленә маил

[1] Ашмарин «Белек» дип укый. 90 стр., «Болгары и чуваши». *(Авт. иск.)*

[2] Без Хөсәен Фәезхановча күчердек. *(Авт. иск.)*

[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[4] Бу хактагы фикерләрне Смолинның «Болгарларның чуашлыгы мәсьәләсе» дигән әсәрендә табарга мөмкин. *(Авт. иск.)*

булганнары да күп. Шуның өстенә дә чувашча дип йөртелә торган «җийат җүр»ле ташларның үзләрендә «торыр», «билгесе», «фани дөньядин бакый ахирәткә рихләт тынды» шикелле чыгтай сүзлеләре бар.

Һәрхәлдә, ташларның кайсысы – чын болгарларныкы, кайсысы «килмешәк татарлар»ныкы икәнен дә белеп булмый. Татарлар исә бер дә Җүҗи углы Бату белән алай күп булып килмәделәр. Аларның Чыңгыз тарафыннан тәгъйин кылынган урдалары ике төмән (егерме мең) икәне мәгълүм[1]. Шуның өстенә дә, рус летописеның хәбәренә күрә, Болгарстан татарлар тарафыннан 1231 елда, әмма икенчесе буенча бары 1241 елда алынды[2]. Ләкин рус мәнбәгъләрының әйтүенә күрә, болгарларның Алтын Урда дәверендә сәяси мохтариятләре һаман да калды: рус кенәзләре белән бергә болгар ханнары да, Сарай шәһәренә барып, ханлыкка ярлык алып кайталар иде[3]. Болгар, Алтын Урда дәүләте ясалгач та, мәдәни бер мәмләкәт булып торды, хәтта Сарай ханнарының акчалары да күп заманнар Болгарда сугылып килде. Шуның өчен мәдәни болгар теленә алардан түбәнрәк монголларның телләренең тәэсире хакында уйлап булмый: үзләре төрк тә булмаган монголларның чыгтай әдәби телендә сөйләшүләре тагы да акылга сыймаслырак бер эш булуы бәдиһи[4].

Аннан соң хәзер дә шимали Кавказ таулары арасында яшәп, үзләрен «балкар» (болгар?) дип атый торган кечкенә генә бер кабиләнең барлыгы мәгълүм. Алар, электәрәк Кавказның шималендәге далаларда торып, соңыннан тау араларына күчеп килеп утырганнар. Менә шул халыкның теле форма һәм лөгать ягыннан хәзерге татар теленә бик охшый. Бу, ихтимал, Азиядән килешли, болгар төркләренең гомуми массасыннан аерылып калган бер тармак булып, аларның телләре Идел буе болгарла-

---

[1] Vamberi. «Das Iurkenvolk», с. 180. *(Авт. иск.)*

[2] Шпилевский. «Древние города», с. 160, 162. Соңгы фикерне Рәшид эт-Дин дә куәтли. *(Авт. иск.)*

[3] Шпилевский, 162. *(Авт. иск.)*

[4] Бәдиһи – ачык.

рының теленең тәхминән[1] нинди булганын күрсәтә торган дәлилләрдән берсе булып хисапланырга мөмкин[2].

Ихтимал, чувашча сүзле дип йөртелә торган ташлар мөселман булган чувашларның ташлары булгандыр. Һәрхәлдә, бәгъзы рус мөстәшрикълары уйлаганча, мәсьәләне тәмам хәл ителгән дип әйтеп булмый, мәсьәлә һаман да ачык кала. Бигрәк тә казанлы яшь мөәррих һәм археолог Худяковның[3] 1922 ел язында Шәрык академиясе хозурындагы «Шәрыкны өйрәнү» җәмгыятендә болгарларның чуваш булулары мәсьәләсенә даир китерелгән дәлилләрне тәнкыйть иткәненнән соң, бу мәсьәләне яңадан карап чыгу мәсьәләсе телчеләр һәм мөстәшрикъләр өстенә фарыз булып кала.

## Ярлыклар

Сугышта туган, гомерен сугышта үткәргән, халкы, патшалыгы күчмәлектән үтә алмаган, бөтен икътисади тормышын Кара диңгез буендагы Италия колонияләреннән килә торган көрәшкә баглаган Алтын Урда бай әдәбият тудыра алмады. Булган кадәрлесе дә хәзергә мәгълүм түгел. Бары безнең заманга Алтын Урда дәвереннән берничә пайза[4], акча-тәңкәләр, ханнарның ярлык аталган язулары яисә, Яурупа истыйляхы[5] белән әйтсәк, дипломнар калган.

Хәзергә кадәр табылган пайзалар монголча: бу хакта башка мөнәсәбәт белән сөйләячәгебезгә күрә, хәзер ул мәсьәләне калдырып китәбез. Акчаларның булса, һәммәсенең дә сугылган

---

[1] Тәхминән – якынча.

[2] Караулов. Балкары на Кавказе. (Изв. Общ, Арх. Ист. И Этн., т. XXIII, вып. 2). *(Авт. иск.)*

[3] Худяков Михаил Григорьевич (1894–1936) – тарихчы, археолог, этнограф. Хезмәтләре Ананьино культурасына, Казан ханлыгы, Урта Идел буендагы мөселман мәдәнияте тарихына карый. Аның «Очерки по истории Казанского ханства» китабы аеруча киң таныла. Әлеге хезмәтендә М.Г. Худяков, рус тарихчыларыннан беренчеләрдән булып, Казан ханлыгының объектив тарихын яза, аның югары дәрәҗәдәге икътисади, хәрби, мәдәни һәм рухи үсешен ачып бирә.

[4] Төрле чиновникларга бирелә торган язулы мәгъдән тактадан гыйбарәт таныклык. *(Авт. иск.)*

[5] Истыйляхы – атамасы.

кала һәм хан исемнәреннән башка сүзләре гарәпчә. Мисал өчен, бер-ике акчаның ике ягына да язылган язуын алыйк:

I. а) «Әс-солтан әл-могаззам Үзбәк»; б) «Lә-иляһа иллә Аллаһ Мөхәммәд рәсүл Аллаһ 717».

II. а) «Әс-солтан әл-гадел Бирдебик хан»; б) 58 зарб әл-акер сәнәт 7»[1].

III. а) «Әс-солтан әл-гадел Бирдебик хан»; б) «Фи зарб бибәләд Гөлестан 760 сәнә 6»[2].

Бу мисаллардан күрелгәнчә, бу акчалардагы язулар бертөрле дә тел, имла вә әдәбият өчен материал бирмиләр. Ләкин ярлыкларның эш башка. Аларның мөндәриҗәсе безгә Алтын Урданың эчке тормышын, мәдәни дәрәҗәсен, икътисади хәятын ачып бирә. Төрки телендә сакланып калганнары исә ул чактагы татарның теле хакында яхшы гына мәгълүмат бирәләр.

Ярлык татар вә башка шәрык халыклары әсәрләрендә «ярлык, ярлик, йырлик, ерлык, ерлигъ, ярлигъ, ерлыг» рәвешендә языла. Бу сүз – асылда, монгол вә төрккә уртак сүз, ләкин төркләр эченә кереп китеп тәмам үзләшкән. Ул монголча «дзарлик» рәвешендә тәләффыз ителеп[3], «дзарликлаху» масдарыннан алынган. «Дзарликлаху» – ярлыкамак, әмер итмәк мәгънәсендә. Ярлык дип татарлар ханнарының фәрманнарын атыйлар иде. Мәгълүм ки, Алтын Урда ханнары бөек монгол ханлыгыннан XII йөздә аерылган булсалар да, алар Чыңгыз ганганәсе[4] белән гамәл иткәннәр. Чыңгыз вә аннан соң булган дүрт хан булса, җиһангирлек идеясен тәгъкыйб кылалар[5], бөтен дөньяны – милекләре, барча халыкларны коллары дип хисаплыйлар иде. Плано Карпини: «Аларның теләкләре – бөтен дөньяны алу, аларга Чыңгыз хан шулай фәрман биргән» һәм «алар ханнарын

[1] «Чекан Алагирский года 7». *(Авт. иск.)*

[2] «В 70 бито в городе Гюлистане 760 лета». «Монеты Джугидов, Джагатаидов, Джалаиридов», Савельев. *(Авт. иск.)*

[3] Тәләффыз ителеп – әйтелеп.

[4] Ганганәсе – сүзе.

[5] Тәгъкыйб кылалар – эзәрлеклиләр.

Алланың углы диләр һәм аңарга Аллага табынган күк табыналар», – ди.[1] Шуның өчен Гүюг хан[2] ярлыкларын «Алланың көче белән бөтен кешеләрнең хуҗасы» диеп башлый һәм мөһерендә: «Тәңре күкләрдә, әмма җирдә Гүюг хан – Алланың көче белән бөтен кешеләрнең хуҗасы»[3], – дип язган, имеш. Менә шуның өчен үзләре белән бер күчтә булган патшаларны да вассаллары дип фараз итәләр: шул сәбәпле, алар белән мөнәсәбәтләрендә язган хатларын «ярлык» – «әмер, фәрман» дип атыйлар иде. Шуның өчен Алтын Урдада һәм, ул җимерелгәч, аның кисәкләре булган Кырым һәм Казан ханнары да аларны (мәсәлән, Мөхәммәдәмин хан[4] Русиягә һәм Польша короле Сигизмундка язган хатын) ярлык дип атаганнар. Бирдебәк хан[5] 1347 елда Венеция җөмһүрияте белән могаһәдәсен[6] дә шул ук итальянча «ярлык» дигән сүзнең тәрҗемәсе булган «Commen domento» (әмер) дип атый[7].

Һәртөрле ярлыклар, әлбәттә, бик күп булганнар. Алардан рус вә чит мәмләкәт хөкүмәтләренә, рухани вә монастырьларга бирелгәннәре – хөкүмәт вә монастырь архивларында, хосусый кешеләргә бирелгәннәре халык арасында булынырга тиеш иде. Ләкин заманның озынлыгы белән һәртөрле сугыш вә янгыннар аркасында аларның күбесе югалып, бик аз бер кыйсеме генә тарих өчен сакланып калган. Аларның да байтагы рус вә гарби Яурупа архивларында чит телләргә тәрҗемә ителгән хәлдә генә сакланганнар. Русча тәрҗемәләре генә сакланганнарыннан Алтын Урда дәверенә махсус җиде данә ярлык мәгълүм:

[1] Языков. Путешествие к татарам, с. 44 и 104. *(Авт. иск.)*

[2] Гүюг хан (1206–1248) – Чыңгыз ханның оныгы, Үгәдәйнең улы, 1246 – 1248 елларда Монгол империясе ханы.

[3] Языков. Путешествие к татарам, с. 44 и 104. *(Авт. иск.)*

[4] Мөхәммәдәмин (1469–1518) – Ибраһим хан белән Нурсолтан ханбикәнең улы. Казан ханы (1479, 1484, 1487–1495, 1502–1518) елларда Казан ханы. Мәскәү кенәзлеге белән якынаю тарафдары була.

[5] Бирдебәк хан (1310 тирәсе – 1359) – Җанибәк ханның улы, 1357 елдан Алтын Урда ханы.

[6] Могаһәдәсен – килешүен.

[7] Hammer. Gesch. Der Gold.: бу могаһәдәнең итальянчасы басылган. *(Авт. иск.)*

1) Мәнгу Тимернең[1] – рус митрополитларына вә руханиларына; 2) Үзбәк ханның[2] – митрополит Петрга; 3) Хан хатыны Тайдуланың[3] – митрополит Феогностка; 4) Шул ук Тайдуланың – митрополит Алексейга; 5) Бирдебәк ханның – шул ук Алексейга; 6) Тайдуланың – митрополит Иванга һәм 7) янә бер ханнан митрополит Михаилга бирелгән ярлыклар. Болардан башка тагы төрле гарәп хөкемдарларына, татарча язылып та, латин вә итальян телләренә тәрҗемә кылынган хәлдә сакланган берничә ярлык бар.

Татарча оригинальләре сакланганнары исә ул кадәр күп түгел. Аларның күбрәге – Кырым ханнарының Мәскәү хөкүмәте белән мөнәсәбәтләренә даир документлар. Алтын Урданың борынгы дәвереннән оригиналь документлар сакланмаган. XIV гасырның ахырларында Алтын Урда хөкүмәте тарафыннан бирелгән өч данә ярлык фән әһеленә мәгълүм. Болардан берсе 1397 миладида Тимер Котлыг хан тарафыннан, икенчесе Туктамыш хан (1376–1391) тарафыннан бирелгән тарханлык ярлыклары булып, өченчесе – шул ук Туктамышның милади 1393 тә Литва короле Ягайлога[4] язган ярлыгы.

Алда сөйләнгән рус телендә сакланып калган ярлыкларның тәрҗемә булуы мәгълүм. Ләкин монгол теленнәнме, әллә төрк теленнәнме – бу мәсьәләгә җавап бирү, Алтын Урдада рәсми тел мәсьәләсен хәл кылу булганга, бик мөһим. Ләкин бер факт шуларның бәгъзысының монгол телендә язылган булуын күрсәтә.

Монголча ярлыклар шундый сүз белән башланалар иде: «Мүнгү Тәкрүнин күчиндүр». Татарча тәрҗемәсе шулай: «Мәң-

[1] Мәнгу Тимер хан (? –1282) – Батый ханның оныгы, 1266–1282 елларда Алтын Урда ханы. Алтын Урданың Монгол империясеннән аерылып, мөстәкыйль яшәвен ныгыта.

[2] Үзбәк хан (Мөхәммәд Солтан) (? –1342) – Мәнгу Тимер ханның оныгы, 1312 елдан Алтын Урда ханы. Мәмләкәтне ныгыту, үзәкләштерү сәясәтен үткәрә, исламны дәүләт дине буларак кабул итә.Үзбәк хан идарә иткән утыз ел дәверендә Алтын Урда иң югары үсеш чорын кичерә.

[3] Тайдула бикә (? –1360 тирәсе) – Алтын Урда ханбикәсе, Җанибәк, соңрак Нәүруз ханнарның хатыны. Рус руханиларына карата хәерхаһ булганлыгы, аларга өч яклау ярлыгы биргәнлеге мәгълүм.

[4] Ягайло (Ягелло Владислав) (1350 тирәсе – 1434) – 1377–1392 елларда Литва кенәзе, 1386 елдан Польша короле.

ге Тәңре көче белән». Үзбәк ханның (1313–1342) митрополит Петрга биргән ярлыгында шул ук сүзнең борынгы рус теле белән булган шундый тәрҗемәсен укыйбыз:

«Всевышняго и бессмертного Бога силою»[1].

Екатеринбург вилаятендә 1848 елда, монголча язылган, 1362 (63)–1368 (69) елларда Алтын Урдада хөкүмәт сөргән Габдулла хан тарафыннан бирелгән бер пайза (көмеш такта) табылган. Анда да шул ук митрополитка Үзбәк тарафыннан язылган ярлыктагы сүзләр тагы да тәфсыйле белән язылган[2]. Димәк, XIV гасырда да монгол телендә рәсми язулар язылган. Ләкин Алтын Урданың күпчелеге төркчә сөйләшкәнгә, ярлыкларның күбесе төркчә языла торган булган.

Югарыда мәзкүр[3] пайза һәм Туктамышның Ягайлога язган ярлыгы уйгур хәрефләре белән язылганнар. Әмма Тимер Котлыгныкы булса, ике төрле: өстән – уйгур, астыннан гарәп хоруфаты белән язылган, әмма Туктамышның икенче ярлыгы бары гарәп хәрефләре белән генә язылган. Шуннан академик Радлов шундый нәтиҗә чыгара: бәйнәлмиләл[4] мөнәсәбәтләр өчен татар хөкүмәте – борынгыча уйгур, әмма эчке эшләр өчен гарәп хоруфаты истигъмаль кылган[5], ди[6].

Тимер Котлыгның һәм Туктамышның берәр ярлыгы – тархан ярлыклары җөмләсеннән. Мондый тип ярлыклар белән ханнар бер мәгълүм кешене яисә мөәссәсәне (чиркәү, монастырь) тархан ясаганнар. Ягъни дәүләт хезмәтләре һәм салымнардан мәгаф[7] ясаганнар. Әмма Туктамышның икенче ярлыгы исә – дипломатия язуы.

---

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[2] Банзаров, пайзы (Зап. Арх. Общ., т. 2, стр. 72). *(Авт. иск.)*

[3] Мәскүр – әйтелгән.

[4] Бәйнәлмиләл – халыкара.

[5] Истигъмаль кылган – файдаланган.

[6] Ярлыки Тохтамыша и Темир-Кутлука, стр.3. Банзаров исә эчке эшләрнең дә мөһимнәрен уйгур хәрефе белән язганнар, ди. «Замечание о монголизмах в ярлыке Тохтамыш хана». *(Авт. иск.)*

[7] Мәгаф – коткарылган.

Хәзер ярлыкларның телләре мәсьәләсенә киләбез. Аларны тикшерүчеләр төрле фикерләр сөйләгәннәр. Кайсылары (Березин) туп-туры аларны уйгур телендә, дигәннәр, Вамбери яңа уйгур телендә, дигән, Банзаров Туктамыш ярлыкларында монгол сүзләре дә табарга тырышкан. Радловның фикеренчә, бу ярлыкларның бары хәрефләре генә уйгурча. Теленең әсасына уйгур теле салынган булса да, уйгур гонсыры чыгтай телендә күпме булса, аларда да шулкадәр генәдер. Аның фикеренчә, чыгтай теле сонгый[1] тел булып, аның асылына уйгур теле салынган, ләкин, язучының сөйләшә торган шивәсенә карап, җирле сүзләр дә кергәннәр.

Ләкин ярлыкларның һәммәсе дә бертөсле телле түгел. Алыйк Туктамышның Ягайлога язган ярлыгын. Әгәр бу ярлыкның сарыф-нәхү формаларын һәм телен тикшереп карасак күрәбез: шундагы сүзләрнең 43 е – бөтен төрк шивәләренә гам сүзләр, 24 е – шимали төрек сүзләре, 22 се – гарби төрк сүзләре, 15 е – чыгтай-уйгур сүзләре. Радлов бу ярлыкның битекче – язучысы хакында шулай уйлый: бу зат монгол ханнары канцеляриясендәге рәсми тел булган уйгур-чыгтай шивәсен яхшы белүче кеше булса да, үзе гареб төрке (коман яки караим) булганга, рәсми телне үз шивәсенә тартып язгандыр. Әгәр бу ярлыкның сарыф-нәхү рәвешләренә карасак, шундый нәтиҗәгә киләбез:

Гомумтөрк рәвешләре – 41 процент
Шимал төркисе..............31
Гарәби төрк....................21
Уйгур-чыгтай...................7

Бу ярлыкның шунысы кызык: «тарих», «нишан» һәм бер-ике кеше исеменнән башка гарәп-фарсы сүзләре юк.

Тимер Котлыгның уйгур-гарәп хәрефләре белән язылган ярлыгына килсәк, аның теле дә башкарак, гарәп сүзләре дә күбрәк.

Андагы 166 сүздән:

Гомумтөрк сүзләре – 50
Шималь төркисе – 38
Гареб төркисе – 13

[1] Сонгый – махсус, ясалма.

Уйгур төркисе – 44
Гарәп – 14
Язучы-нугай – 7
Сарыф-нәхү җәһәтеннән:
Барысы 70 нәхәви игърааблардан[1]:
Гомумтөркнеке – 22
Шималь төркисенеке – 24
Уйгур-чыгтайныкы – 21
Нугай шивәсенеке – 3

Мисал өчен, бу урында Туктамышның Ягайлога язган ярлыгын һәм Тимер Котлыг ярлыгын күчерәбез. Беренче ярлык уйгур язуы белән язылган булганга, без аны Радлов транскрипциясе буенча күчерәбез[2]:

«Туктамыш сүзем

Ягайлога»

«Олукъ урынга ултырган яркесен аңлату Котлыбуга Асан башлы илчилә идүк әрде сән тагы кәләчигене безгә идең әрде борынгы ел Бәкбулат Күҗәмәдин башлы бирнәчә угланнар Бәкиш Турдуҗан бәрде Давыд башлы бәкләр Әдүкәй атлы кешене Тәмиргә алдыртын чакырып имеш, ул тел билә кәлде әрде аларның ала күңел билә итеп әл кыруганга йитә килгәндә аңлап еглып санечмәгә торганда ул яман кешеләр борын тәбәрәкәндин әл тарбәб ул эш тагы ул чаклы булган яркәсе ул әрде Тәңре безне ярлыгаб тушманлык кылган Бикбулат Күҗәмәдин якеш Турдуҗан бәрде Давыд башлы угланлар бәкләрне мүккаләнте әмде бу ягуны аңлату асан тулу хуҗа башлы әлчеләрне идүк әмде тагы булса, безгә бакар әлләрнең чыгышларын чыгарып барган әлчиләргә бәргил хазинәгә тәгәсүнләр, база борынга йусунча бәзәргән уртатларың тагы йөрешсенләр олук улусынүк тору шуңа тагы якшысы ул булгай тип алтын нәншанлык ярлык

[1] Игъраб – сүзләрнең төрләнүе.

[2] Чөнки Радловның әсәре Вамбери, Березин, Хәлфин әсәрләренә һәм укуларына караганда иң соңгы. 1918 елда басылган «Азиатский сборник» та бу хакта Самойловичның бәгъзы яңа фикерләре булса да, без Радлов буенча алдык. *(Авт. иск.)*

тоттык тагагу, ел тарих йиде йөз туксан бәштә рәҗәб аеның сәкиз ягыда орду данда әрүрдә бителмиш»[1].

Хәзерге татар телендә бу ярлык шулай була:

«Туктамыш сүзем

Ягайлога

Олуг Урда утырган хәбәрен аңлату өчен, Котлыбуга һәм Асан башлыгында илчеләр җибәргән идек. Син дәхи келәнчеңне (челобитчика)[2] безгә җибәргән идең. Өченче ел Бикбулат хан, Күҗәмәдин баш булып торган берничә угланнар һәм Бәкиш Турдуҗан бирде һәм Давыд баш булып торган бикләр Әдүкәй атлы кешене астыртын Тимерне чакыртып җибәргәннәр иде. Бу чакыруга ул килде һәм аларның ала (кара) күңелләренә муафәкать итеп хәбәр җибәрде. Ил кырыена җитеп килгәндә белеп, җыелып сугышырга торганда, ул яман кешеләр баш тартканга, илдә тынычсызлык булып, ул эш тагы шулай булды: Тәңре безгә мәрхәмәт итеп, дошманлык кылган Бикбулат, Күҗәмәдин, Турдуҗан бирде, Давыд башында торган угланнар, бикләрне җәза кылды. Бу эшләрне аңлату өчен, Тулы хуҗаны баш итеп, илчеләр җибәрдек. Тагы исә безгә караган илләрнең чыгыш (хираҗ – дань[3])ларын чыгартып барган илчеләргә бир хәзинәгә тапшырсыннар, борынгы гадәтчә, сәүдәгәр әртилләрең йөрсеннәр, Олуг олысның тормышына тагы яхшысы ул булыр дип, алтын нишанлы ярлык нәшер иттек. Тавык елы тарих җиде йөз туксан биштә рәҗәб аеның сигезенче көнендә арду Танда[4] булган чакта язылды».

Тимер Котлыг ярлыгы берничә җәһәттән әһәмиятлерәк: анда сүз күп, хәзер истигъмальдән чыккан истыйляхат[5] бар, шуның өстенә дә ул, уйгур хәрефе белән язылып, астына тәгъликъ язуы кызыл кара белән матур иттереп гарәп хәрефе белән дә языл-

[1] «у» һәм «о» хәрефләре аерылмады: башка авазларда хәзерге яңа татар имласыннан чыгып, һәммә тавышлы хәрефне язып күчерелде. Һәммә сүзләренә шәрех баглап тормыйча, Радловча тәрҗемәсен генә бирдек. *(Авт. иск.)*

[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[3] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[4] Азак диңгезе буендагы сәүдә шәһәре. *(Авт. иск.)*

[5] Истыйляхат – атама-терминнар.

ган булганга, шул заманның имласын дә күрергә мөмкин. Без бу ярлыкны гарәп хәрефе белән язылган имласы белән күчерәбез:

«Тимер Котлыг сүзем

Унық кул сул кул нинең угланларына томан укубашлыг мең йөз ун бикләрегә эчке кәндләренең казый мөфтиләрегә мәшаих суфиларыга диван йитикчеләргә тамгачы тәрт накҗиларыга йөртәр эшләнче юлаучыларга букәвел тоткавылларга ямче сүсүнчеләр кошчы бәрәсчеләргә кимәнче күбрүкчеләргә базарда торганларга бу ярлыгны тота торган Мөхәммәднең убака аталары борынгы кичкән Саин хан чагы дик бере берә йарлыг раст тарханлык йусуныча атасы хаҗи Бәйрәмхуҗаны безнең хан агаларымыз сийертап тархан кылган чәрәксен аныклата үтенде әрсә у кулын юып кереп Мөхәммәд безнең суюргал булып тархан булып торсын тидемиз бүгендин илкәр вә Кырым белә Кырым йиренең томаны да Судак атлиг кәнтнең җәварендә борынгы замандин бире мөтәгадәт тархан булган индерҗе сөлясе белә мәшһүр булган каласыдин шәргый кабалә йусунча йир сулары белә Мөхәммәднең угланнары илке хаҗи Мөхәммәд вә Мәхмүд азад тархан булсын булырның йир-суларына баг-багчаларыга хәмам тегермәнләрегә тәсрыйф кыла торган йирләрегә борындин калган азадларга басасларыга сабаҗи уртакчыларга кем-кем ирсә көч уга тикүрмәсен юлсын ярдәнмәләрене тәртип алмасынлар болар тамгасы ибне кинҗе ускубул корты әнбар малы индер хакы табанлык кыйсмәт кобур ясагы кылан мәсмасалык бурыч хариҗ алмасынлар барыр килүре дә кирер чыкары да Кырымда Күфәдә кабумә төрлек нәрсә алыридә ... тамга тартынак алмасын тарханлык табанлык юл хакы караванлык тиләмәсенләр товар коралларын арлак тотмасын кунак төшел төшермәсенләр сүсүн голүфә тиләмәсенләр кайума төрлек зәхмәт вә мавинәт... масун вә мәхрус булсынлар тыныч торып тынычлык билә шам вә сабах әүкат шәрифләре дә безгә дагы безнең ыруг-ыругымызга дога алкыш итә торсын дип тота торырга алтын нәшанлык ал тамгалык ярлык бирелде. Тарих сикез йөздә барс елы шәгъбан аеның алтынчы көнедә авыз ....нең кәнаредә ... ирердә бетелде».

Хәзергә татарчасы:

«Тимер Котлыг сүзем

Уң кул, сул кул угланнарына, хисапсыз изге (добрый)[1] башлыкларга: мең, йөз, ун бикләренә эчке шәһәрләрнең казый, мөфтиләренә, мәшаих суфиларына, диван язучыларына, салым җыючыларга һәм тамгачы (таможнячы)ларга, йөрүчеләргә һәм юлаучыларга (юлчыларга), бикавылларга һәм тотавылларга һәм стансачыларга, кошчы, барсчы, көймәче, күперче һәм базарда торганнарга[2] бу ярлыкны тота торган Мөхәммәднең баба-аталары борынгы үлгән Саин ханнан[3] бирле берсе артыннан берсе ярлыкка әсасланган рас тарханлык хокукында тордылар; атасы хаҗи Бәйрәмхуҗаны безнең хан агаларыбыз мәрхәмәт итеп тархан кылганнарын белдерергә үтенгәнлектән, аның үтенечен кабул итеп: «Мөхәммәд безнең мәрхәмәтебездә булып, тархан булып торсын», – дидек. Бу көннән алып Кырым белән Кырык җирнең төмәнендә (область)[4] Судак атлы ныгытманың җәварендә[5] борынгы заманнан бирле мөтәгаддид[6] тарханнар белән мәшһүр булган Ындырчы саласы белән каласыннан шәргый кабала (обязательство)[7] гадәте буенча җирләре, сулары белән Мөхәммәднең угыллары олуг Хаҗи Мөхәммәд һәм Мәхмүд Азат тархан булсыннар. Боларның җир-суларына, баг-бакчаларына, мунча-тегермәннәренә, тәсаррыф кыла[8] торган җирләренә, борынгы заманнан калган азатларына һәм аларның бөтен салаларына, сабанчы, уртакчыларына беркем дә тимәсен, юлсыз урында (сәбәпсез) нәрсәләрен тартып алмасыннар, йөземлекләреннән алына торган тамга (пошлина)...[9]. Амбар малы,

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[2] Болар һәммәсе дә мәэмүрләр исеме. *(Авт. иск.)*

[3] Саин – Бату ханның кушаматы.

[4] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[5] Җәварендә – тирәсендә.

[6] Мөтәгаддид – күпсанлы.

[7] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[8] Тәсаррыф кылу – кулда тоту.

[9] Бу урынны Радлов тәрҗемә кылмаганга, без дә, Березинча тәрҗемәгә ышанмаганыбызга күрә, тәрҗемә кылмадык. *(Авт. иск).*

ындыр хакы, арыклардан алына торган ясак, «калан» атала торган салым, бурыч, хәрәҗ алмасыннар, әгәр ул китсә-килсә һәм керсә-чыкса, Кырымда, Күфәдә нинди генә нәрсә алмасын, сатмасын, тамга һәм үлчәү салымы алмасыннар, тархан һәм хезмәтчеләрдән (служители)[1] алына торган юл хакы да, караыллык та алмасыннар, туар-караларыннан түләү алмасыннар, кунак-төшем төшермәсеннәр[2], эчәргә-ашарга сорамасыннар, авырлыклардан, салымнардан һәм фәүкыльгадә[3] салымнардан котылдырылсыннар, тыныч торып, тынычлык белән торып кич вә иртә, шәриф вакытларында безгә дәхи безнең ыругыбызга дога кылсыннар дип, (тиешле урында) тоттырырга алтын нишанлы[4] ярлык бирелде. Тарих сигез йөздә барс елы шәгъбан аеның алтынчы көнендә Үзи[5] суының буенда мөҗавиранда[6] булганда язылды».

Бу Алтын Урда ярлыкларыннан башка Кырым ханнарының ярлыклары да сакланып калган. Болар инде һәммәсе дә гарәп хоруфаты белән язылганнар. Кырым ярлыкларының безгә мәгълүм булган тархан ярлыкларыннан бары берсе генә мәгълүм[7]. Бу ярлык – Сәгадәтгәрәй хан (1523)[8] тарафыннан берничә кешене тархан ясау хакында бирелгән ярлык. Аның язылу рәвеше шул Котлыг Тимернеке төсле, шулай ук бөтен мәэмүрләр, салымнар саналган. Теле мәсьәләсенә килсәк, моның да шул ук рәсми чыгтай-уйгур теле белән язылганын күрәбез. Имласы да шулай ук. Ләкин монда инде «төннекче» күк яңа сүзләр очрыйлар. Ләкин бу ярлыкның башыннан бер-ике юлы ертылган. Бик күп җире танылмый. Мисал өчен, шушы бер-ике җөмләсен алыйк:

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] «Пусть не назначают постоя». *(Авт. иск.)*
[3] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.
[4] Нишанлы – тамгалы.
[5] Днепр. *(Авт. иск).*
[6] Мөҗавиранда – дәрвишлектә.
[7] Березин. Ханские ярлыки, 2. *(Авт. иск).*
[8] Бер генә ел патшалык сөргән. *(Авт. иск).*

«Бу тарханларга күч-бәсиҗ тикергән[1] кешеләрнең үзләренә яхшысы булгай».

Кырым ханнарының Русия һәм Польша белән дипломатия мөнәсәбәтләренә даир язылган ярлыклары да безнең заманга кадәр сакланып калган. Бу язуларны мулла Хөсәен Фәезханов[2], 1808 елда Академия наук тарафыннан Мәскәүгә җибәрелеп, шунда хариҗия нәзаратының[3] баш архивыннан күчереп алып кайткан. Шул язулар Вельяминов-Зернов[4] карамаклыгы астында 942 сәхифәлек калын һәм зур кулдагы бер китап рәвешендә басылган[5]. Монда иң иске ярлык – Мөхәммәдгәрәй хан (1478–1515) тарафыннан 926 һиҗридә Польша короленә язылган (ярлыкның үзендә аталганча) шартнамә. Моның теле дә чыгтайча.

---

[1] Күч-бәсиҗ – көч-явызлык.

[2] Хөсәенов Фәезхан Хөсәен улы (1823/1828–1866) – тарихчы, филолог, Ш. Мәрҗанинең укучысы. 1840 еллар ахырыннан Казан университетының шәркыятьче галимнәре И.Н. Березин, А.К. Казимбәк, 1854 елдан – академик Б.А. Дорн, В.В. Вельяминов-Зернов, М.И. Броссе, А.А. Куник (С.-Петербург) белән хезмәттәшлек итә. 1854 елдан С.-Петербург университетының шәрык телләре факультеты укучыларына лекцияләр укый. Мәскәүдә Тышкы эшләр министрлыгы архивында сакланган Урта гасырларда төрки телдә язылган документлар текстларының тасвирламасын төзи: 378 текст ачыклана. Касыйм шәһәре татар зиратындагы кабер ташлары язмаларын күчереп ала. Х. Фәезханов тарафыннан табылган 29 эпиграфик текст Касыйм ханлыгы тарихының чыганак базасын нык баета. Тархан һәм Урюм (Ырым) авылларында яңа болгар эпитафияләрен ача, беренчеләрдән булып болгар эпитафияләрендәге чуваш теле элементлары булган «серле» компонентларны укый һәм аңлата, бу мөһим фәнни ачыш санала. Бер үк вакытта гарәп кульязмаларын, татар халкы, Казан һәм Кырым ханлыклары тарихы буенча материаллар җыю һәм тасвирлау белән шөгыльләнә, беренчеләрдән булып татарларның килеп чыгышы мәсьәләсе буенча тикшеренүләргә керешә. Х. Фәезхановның фәнни тикшеренү нәтиҗәләре В.В. Вельяминов-Зернов һәм Ш. Мәрҗанинең күптомлы фундаменталь хезмәтләрендә урын ала.

[3] Хариҗия нәзаратының – Тышкы эшләр министрлыгының.

[4] Вельяминов-Зернов Владимир Владимирович (1830–1904) – шәрыкшинас, тарихчы-нумизмат, археолог. Хезмәтләре Россиядә яшәүче шәрык халыклары тарихына һәм мәдәниятенә карый. Дүрт китаптан торган «Касыйм ханнары һәм ханзадәләре турында тикшерү» («Исследование о Касимовских царях и царевичах», 1863–1887) исемле хезмәт һәм төрки лексика сүзлекләре авторы.

[5] Материалы для истории Крымского Ханства. *(Авт. иск.)*

Димәк, XVI гасырда сонгый[1] рәсми чыгтай теле һаман да рәсми тел булып йөри. Бу һәм моннан соңгы паташалар заманында язылган бәгъзы ярлыкларда Кырым, үзен Алтын Урданың варисы дип белеп, «Олы Урданың олы ханы Дәште Кыпчак барча могол патшасы» дип атый, бу соңгы сүзне без Алтын Урда исән чакта Җанибәк ханның[2] итальяннар белән ясаган могаһәдәсендә[3] дә «Mogalbei» (Магул бәй)[4] дигән рәвештә очратабыз. Ләкин заман үтүе белән, тел алмаша башлады. Мәсәлән, инде без 1594 һәм 1608 еллар арасында хөкүмәт сөргән Газигәрәйнең[5] калгасы[6] Сәламәтгәрәйнең «Ләкралнә» (Литва падишасына) язган хатында тел башкарак: «Олы Урданың олы ханы Газигәрәй хан Адәм Аллаһы Тәгалә мәгалийә хәзрәтләренең кагылгасы улан Сәламәтгәрәй солтандин карендәшем Ләкралнә күпдин күп сәлам дигәч, әгълям ярлиг белиг мәхәббәт әнҗам будыр ки бондан икъдәм мәктүб шәрифеңез килеп, һәр нә язылмыш исә бил-тәмам мәгълүм...»

Моның телендә инде без чыгтай әдәби мәктәбенең телен түгел, бәлки төрк галәмендә аның урынын алып килүче госманлы әдәби телен күрәбез. Бу госманлы шивәсе акрынлап чыгтай тәэсирен чыгарып бетерә язды. Ләкин Кырым татар ханнарының Русиягә язган мәктүбләрендә без Казан татары шивәсенә якын бер тел очратабыз. Бәлки, Мәскәүдә тылмачлар Казан татарлары булганга шулай язганнардыр. Менә мисал өчен, шушы XVII йөзнең башында хөкүмәт сөргән Җанбикгәрәй ханның[7] Михаил Федоровичка[8] язган ярлыгын алыйк:

---

[1] Сонгый – махсус.

[2] 1340–1357. *(Авт. иск.)*

[3] Могаһәдәсендә – килешүендә.

[4] Hammer, Geschichie der Gol. Horde, s. 517. *(Авт. иск.)*

[5] Газигәрәй II – 1588–1597, 1597–1608 елларда Кырым ханы.

[6] Калга (калгай, кагылга, кагылгай) – Кырым ханлыгында дәрәҗәсе буенча ханнан соң икенче урында торган шәхесне атаучы титул.

[7] Җанибәкгәрәй II – 1610–1622, 1627–1635 елларда Кырым ханы.

[8] Михаил Фёдорович Романов (1596–1645) – Романовлар династиясеннән Русия патшалыгының беренче патшасы.

«Җанбик хан сүземез

Олуг Урда олуг йортның вә тәхте Кырымның вә Дәште Кыпчакның вә сагышсыз Нугайның вә Тат белә Тукачның вә таг ара Чиркәчнең олуг падишаһы вә һәм олуг ханы сәгадәтле вә рәфгатьле[1] вә шәүкәтле вә хушамәдле[2] вә гыйзамәтле[3] Җанбикгәрәй хан ... хәзрәтләрендин олуг русның вә пруссның вә күп христианның падишаһы хан һәм олуг бәк Михайла Федорович җөмлә русның вә күп мәмләкәтләрнең дә булса падишаһы вә хөкемдарындин күп сәлам кылып, нәдер хәлегез вә хатирыңыз яхшымы-хушмы дип сораганымыздан соңра...».

Казан ханлыгы заманасыннан калган ярлыклар бу көнгә кадәр мәгълүм түгел иде. Бары Кырымнан килеп Казанда ханлык сөргән Сәхибгәрәй ханның бер тархан ярлыгын гына Һади Атласи[4] үзенең «Казан ханлыгы» исемендәге әсәрендә китергән, ләкин бу ярлыкның бик күп сүзләре мәгълүм түгел, төшеп калган иде. Менә бу ел тарих мөгаллиме Сәет Вахидов[5] тарафыннан шул ярлыкның асыл нөсхәсе табылды. Хәзергә кадәр әле бу ярлык тел, өслүб ягыннан тикшерелмәгән. Бу ярлык – җиде кеше исеменә бирелгән тарханлык ярлыгы. Бу ярлык хакында зур тәфтишләр ясалырга тиеш. Билгеле, дөрес укырга кирәк.

Безнең кулда бары Сәет Вахидов укыганча копиясе генә бар. Ярлык «әл-гази Сәхибгәрәй» дип башлана. «Сүзем» дигәне ертылган булырга кирәк. Ярлыкның тарихы «тукыз йөз егерме тукызда мөбарәк сәфәр аеның ун өченче көн», димәк, милади 1522–1523 елларга туры килә. Язуы тәгъликъ, рокга һәм ди-

[1] Рәфгатьле – югары дәрәҗәле, бөек.

[2] Хушамәдле – мактаулы.

[3] Гыйзамәтле – бөек.

[4] Һади Атласи (Атласов Әхмәтһади Мифтахетдин улы (1876–1938) – тарихчы, дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (1913). Икенче Дәүләт Думасы (1907) һәм Милләт Мәҗлесе (1917–1918) депутаты. Февраль революциясеннән соң милли демократик хәрәкәтнең актив әйдәүчесенә әверелә. Репрессия корбаны.

[5] Сәет Вахиди (1887–1938) – тарихчы, педагог, Көнчыгышны өйрәнүче, археограф, кульязмалар җыючы.

вани[1] арасындарак бер язу: мәшкый[2] түгел. Өслүбе чыгтайчасыман. Без анда Казан татарчасы тәэсирен күрмәдек. Ярлык «ал нәшанлыг»: астында ал тамгасы да бар. Ярлыкның теле ифрат Сәгадәтгәрәйнекенә охшаган. Затән, аларның тарихлары да бер дип әйтерлек, Сәгадәтгәрәйнеке 930 һиҗридә язылган булса, Сәхибгәрәйнеке – 929 һиҗридә. Хәтта башка ярлыкларда очрамый торган «псих зәхмәт янҗуг тикүрмәсенләр» дигән сүзе дә бар[3]. Сәхибгәрәй ярлыгында гарәп-фарсы әсәренең бик куәтле булуы күзгә бәрелә. Хәтта, төрле мәэмүрләрне санаганда, «илҗиан» (илчеләр) дигән шикелле төркчә сүзләрне фарсыга ияртеп, җәмгы ясау шикелле ифратлар да бар. Гомумән, сафлык ягыннан аның телен шул ук мәүзугда[4], шул ук тарызда[5] диярлек язылган Тимер Котлыг ярлыгы белән чагыштырып булмый. Ихтимал, соңгырак гасырларда татарның язу теленә гарәп-фарсы теленең тәэсире куәтләнгәнен күрсәтә торган факттыр. Ләкин бу ярлыкның Татарстанда табылуына карамыйча, Казан ханлыгына гаид булуы хакында шөбһәләнергә урын күп: чөнки Казан улусы хакында анда бер сүз дә юк. Шулай да әсәр тарих вә телгә даир материал бирә ала. Монда башка ярлыкларда очрамаган сүзләр, салым исемнәре бар. Мәсәлән, «салә[6] хәрәҗе», «ир хөбләсе», «төтен саны», «җарвалар» шикелле. Боларның һәммәсе дә тикшерүчеләр тарафыннан игътибарга алынырга тиеш.

---

[1] Тәгъликъ, рокга, дивани – гарәп язуы төрләре.

[2] Мәшкый – каллиграфик.

[3] Березин, «псих» дигән сүз «басмак» дигән сүздән алынып, «притеснение» дип тәрҗемә кылырга кирәк, ди. Ләкин болай уку хата булырга кирәк. Чөнки бу сүзне Сәхибгәрәй ярлыгында «сих, сиҗ» дип укырга бик мөмкин. Элек бездә тешсез «с»нең астына һәрвакыт өч нокта төртеп язганнар. Ихтимал, Березинны шул ялгыштыргандыр. *(Авт. иск.)*

[4] Мәүзугда – эчтәлектә.

[5] Тарызда – үрнәктә.

[6] «Салә» – «сала»ны Радлов авыл дип тәрҗемә кыла. Тимер Котлыгның ярлыгында «Ындырчы саласы», «салалары» дигән сүзләр бар. Бу «сала» сүзе хәзерге җәнүби Русиядәге күчмә төркиләргә руслардан кергән булырга кирәк, ди. Ярлыки Тохтамыша и Темир Кутлуга, с. 31. *(Авт. иск.)*.

# ИДЕЛ БУЕНДА ЧЫГТАЙ ӘСӘРЛӘРЕ

## «Кыйссас әл-әнбия» Робгузи[1]

Робгузиның (бәгъзылар тәләффызынча[2] Рабгузи) «Кыйссас әл-әнбия»се чыгтай әдәбиятының Тимергә кадәрге дәверенең әһәмиятле әсәрләреннән санала. Бу китапның мөхәррире – Урта Азиядә «Рабат Угуз шәһәренең казые Насреддин бине Борһанеддин исемле кеше, Робгузи – аның кушаматы. Бу ләкаб[3] «Рабат Угызы» дигән сүздән үзгәргелгән. Робгузи үзенең бу китабын шул шәһәрнең биге Насреддин Тукбугага багышлап, аңар тәкъдим итәр өчен язган. Мөкаддимәсендә[4] сөйләвенә күрә, бу бик пәйгамбәрләр хакында язылган кыйссаларны укырга рәгъбәтле булган[5]. Ләкин шул замандагы китаплар берсе дә аны канәгатьләндермәгәннәр; шуның өчен ул Робгузидан шушы бабта яңа бер китап тасниф итәргә[6] үтенгән. Мөхәррир әсәрнең ахырында шигырь белән үзенең аны ничек язганын бик матур, фәсыйх[7] тел белән тәфсир итә: «Бу китапны төне-көне яздым, бер ел эчендә тәмам иттем», – ди. Мөкаддимәдә Насреддин Тукбуганы, шәрык гадәтенчә, мөбаләгаларны[8] кызганмыйча мактый. Аңар мәдхия итеп, бөтен бер касыйдә дәрҗ итә[9]; китапның ахырындагы шигырендә дә аны телгә алмый калмый. Мөкаддимәдә без шушы сүзләрне укыйбыз: «(Әмма бәгъдә[10])

---

[1] Гали Рәхим «Кыйссас әл-әнбия» авторын Робгузи дип бирә. Әдәбият буенча хәзерге хезмәтләрдә Рабгузи варианты кабул ителгән.

[2] Тәләффызынча – әйтүенчә.

[3] Ләкаб – кушамат.

[4] Мөкаддимәсендә – керешендә.

[5] Рәгъбәтле булган – яраткан.

[6] Тасниф итәргә – төзергә.

[7] Фәсыйх – матур, әдәби.

[8] Мөбаләгаларны – арттыруларны.

[9] Дәрҗ итә – багышлый.

[10] Әмма бәгъдә – шуннан соң.

бу китапны төзегән тагать[1] юлында тизгән[2] нәсыйбәт йабанин гизгән[3] аз азуклуг, күб язуклуг Рабат Угузының казыйсы Борһанеддин угылы Насреддин сәтер Аллаһ гойубиһи андаг әйтүр бикмез әҗәл таҗ әл-әмраи вә мөхиб әл-голәмаи бикләр ыругы екетләр аригы олуг атлыг арыг[4] затлыйг – яхшы кылыйглыйг[5] магул сынлыйг[6] мөселман динлигъ адәмиләр инанчи мөэминләр күанчи[7] һимммәти әдиз[8] гаклы тингиз[9] бикмиз Насреддин Тукбуга сәбәтәһу Аллаһ галә дин әл-ислам[10]». Магул сынлы, мөселман динле дип мактаудан күренә ки, бу Тукбуга, күптән түгел генә мөселманлык кабул итә башлаган монгол түрәләреннән, ярым мөстәкыйль бер бәк булырга кирәк. Ул Робгузига бу әсәрне язган өчен нинди мөкяфәтләр[11] биргәндер – бу безгә мәгълүм түгел, ләкин чыгтай әдәбиятында тоткан хөрмәтле урыны, онытылмас исеме аңар мәңгелек мөкяфәт булачак.

«Кыйссас әл-әнбия»нең язылу тарихы хакында беркадәр шөбһә бар. Мөкаддимәдә «тарихка сикез йөз тәкузында ит йыл[12] касд (?) бетелде[13]», диелгән. Бу сүзгә караганда, ул милади XV гасыр башында язылган булып чыга. Әмма китапның ахырындагы шигырьдә «йите йөз ун ирди йылга ким бителди бу китап», дип әйтелгән. Моңар караганда, ул XIV гасыр башында (милади 1310–[13]11 елларда) язылып беткән булырга тиеш. Димәк, арада

[1] Тагать – Аллага гыйбадәт кылу.
[2] Төзегән. *(Авт. иск.)*
[3] Хәсрәт сахраларын гизгән. *(Авт. иск.)*
[4] Ару, пакь, яхшы. *(Авт. иск.)*
[5] Колыклы (*холыклы*), гамәлле. *(Авт. иск.)*
[6] Монгол кыяфәтле. *(Авт. иск.)*
[7] Куанычы. *(Авт. иск.)*
[8] Гали, югары. *(Авт. иск.)*
[9] Диңгез. *(Авт. иск.)*
[10] Сәбәтәһу Аллаһ галә дин әл-ислам – Аллаһы Тәгалә аны ислам динендә нык тотсын.
[11] Мөкяфәтләр – бүләкләр.
[12] Эт елында. *(Авт. иск.)*
[13] Язылды. *(Авт. иск.)*

бөтен бер гасыр бар. Инде бу ике тарихның кайсы хакыйкатькә якын булуын тикшерергә кала. Моның өчен әсәрнең теленә кайтып карарга кирәк. «Кыйссас»ның теле исә – борынгы чыгтай теле. XV гасырдагы чыгтай әдәбиятының кәмаләт[1] дәверендәге әдәби чыгтай теле белән Робгузи теле арасында аерма бик зур. Робгузиның телендә (хосусан шигырьләрендә) уйгурча тәэсире шактый күренә; анда XV гасыр чыгтай әдәбиятында очрамый торган борынгы чыгтай вә уйгур сүзләренә туры киленә.

Мөкаддимәнең кайбер урыннарының өслүбе[2] бөтенләй «Котадгу белег»нең мөкаддимәсен искә төшерә. Гомумән, бу китап тел ягыннан чыгтай әдәбиятының әүвәлгерәк гасырларында язылган «Мигъраҗнамә»[3] вә «Тәзкирәи әүлия»ларга[4] якын килә. Шулай ук без Робгузида, бигрәк тә шигырьләрдә, гарәп-фарсы тәэсиренең, XV гасыр теленә чагыштырганда, кыяс ителмәслек[5] дәрәҗәдә аз булганын күрәбез. Гарәп сүзләрен Робгузи кирәк урында гына куллана, сүи истигъмаль итми[6], алар белән уйнамый. Хосусан, фарсыча тәэсиренең зәгыйфьлеге күзгә бәрелә. Аның шигырь өслүбен XV гасырдагы фарсыча сүзләр вә гыйбарәләр басып бетергән шигырь өслүбе белән чагыштыру да мөмкин түгел. Менә шушы дәлилгә истинадән[7], «Кыйссас»ның язылу тарихын XV гасыр башында түгел, бәлки XIV гасыр башында дип карар бирергә мәҗбүр булабыз. Мөкаддимәдәге «сигез йөз» дигән сүз, ихтимал, күчерүчеләр хатасы булгандыр.

«Кыйссас әл-әнбия»нең безнең татарлар арасына кайчан килеп керүе турысында без тәгаенләп бер сүз дә әйтә алмыйбыз. Ләкин Урта Азиядә бик мәшһүр китап булуын, теленең дә та-

---

[1] Кәмаләт – үскән, җитешкән.

[2] Өслүбе – стиле.

[3] Мигъраҗнамә – Мөхәммәд пәйгамбәрнең мигъраҗы хакында сөйләүче яки шуның белән мөнәсәбәттә язылган әсәргә яки әдәби парчага бирелгән исем.

[4] Тәзкирәи әүлия – әүлиялар турында истәлекләр.

[5] Кыяс ителмәслек – чагыштырмаслык.

[6] Сүи истигъмаль итми – урынсыз кулланмый.

[7] Истинадән – таянып.

тар өчен аңларга ансат булуын игътибарга алганда, бу китапның безнең Идел буена бик күптәннән килгән булуына һич истихалә[1] күрелми. Шуның белән бергә үк аның Әбелгазыйның[2] «Шәҗәрә-и төрк»есе күк, XVIII гасырда гына Төркестаннан алып кайтылган булу ихтималы да юк түгел. Һәрхәлдә, 32 ел арасында (1859–1891) алты мәртәбә басылуны күтәрә алуы аның бездә ифрат[3] күп укылган, халык тарафыннан яратылган әсәр булуын күрсәтә. Ул беренче мәртәбә 1859 елда Казанда уртачадан зуррак кулда 550 битләр чамалы бер китап булып басылган. Беренче басмасының ахырында шушы сүзләр язылган: «Ошбу «Кыйссас әл-әнбия» китабыны басдырмак ирадәмез улгач[4], ничә кадими иске китаплардан мөмкин улганча Татарстан кадими теленчә дөрестләмәккә ничә мөддәт сәгый[5] белигъ кылып, әүвәл мәртәбә Кишет Рәхмәтулла Әмирхан углы[6] үз хәраҗатым[7] илән укыяннардан хәер-дога үтенеп, Казан университетының басмаханәсендә табигъ кылдырдым[8]». Күренә ки, бу кешенең кулында

[1] Истихалә – мөмкин булмавы.

[2] Әбелгазый Баһадур хан (1603–1664) – Хива дәүләте ханы (1643–1663), тарихчы. Ике тарихи хезмәт авторы: «Шәҗәрә-и гузия» («Угызлар шәҗәрәсе», 1659–1661) һәм «Шәҗәрә-и төрк» («Төркиләр шәҗәрәсе», 1663–1664). Бу хезмәтләрдә Евразия кыйтгасында XIII–XVII йөзләрдә яшәгән төрки халыкларның тарихы, кайбер кабиләләрнең килеп чыгышы, риваятьләре, яшәү урыны тасвирлана.

[3] Ифрат – бик.

[4] Ирадәмез улгач – теләгебез булгач.

[5] Ничә мөддәт сәгый – күпме вакыт тырышлык.

[6] Рәхмәтулла бине Әмирхан (1805–1876) Яңа Кишет авылында крестьян гаиләсендә туа, Казан мәдрәсәләрендә белем ала, гарәп һәм фарсы телләрен яхшы үзләштерү өстенә, үзлегеннән русча оста сөйләшергә һәм укырга-язарга өйрәнә. Казан ратушасында тәрҗемәче булып эшли. «Кыйссаи Йосыф» китабын беренче булып ул бастырып чыгара (1839). Борынгы әдәби ядкәрләрдән «Кыйссаи Робгузи» (1311) китабын барлап, әзерләп матбугатта чыгару да Р. Әмирханов исеменә бәйле. Ул – татарча календарьлар чыгару эшен башлап җибәрүче (1841). Төрек шагыйре Ибраһим Хаккыйның (1703–1783) «Мәгърифәтнамә» әсәренең керешен һәм ахыргы бүлеген зур китап итеп татарчалаштырып чыгара (1845).

[7] Хәраҗатым – чыгымнарым.

[8] Табигъ кылдырдым – бастырдым.

берничә кулъязма булып, ул аларны чагыштырып, үзе белгәнчә «дөресләгән». Хәзерге көндә кулыбызда бу китапның кулъязмалары булмаганга, бу «дөресләү» аның тел вә мөндәриҗәсен[1] никадәр үзгәрткәндер – без моны белә алмыйбыз. Ләкин өмет итеп була ки, ул – китапның телен үзгәртмәгәндер, «Татарстан кадими теленчә» дигәндә, ул борынгы татар теле дип чыгтайчаны әйтә торгандыр. Һәрхәлдә, үз өслүбендәге госманлычалыкларны ул Робгузиның теленә катыштырмаган. Шуңар күрә ул, тел ягына артык кагылмыйча, мөндәриҗә ягыннан төрлечә булган урыннарын, танылмый һәм аңлашылмый торган җирләрен генә бер-берсе белән чагыштырып, үзенчә дөресрәк күренгәнен алган булырга кирәк дип уйлыйбыз. Шулай булган вакытта Рәхмәтулла Әмирхан углы, бу кулъязманы бастырганда, фән әһелләре тота торган юлны тоткан булып чыга. Шуның өчен дә ул бу турыда бер-бер рус мөстәшригының[2] (мәсәлән, Казембекның[3]) күрсәтүе буенча эшләмәдеме икән дип уйлана. Чөнки китапта чыгтай теленең сафлыгы бер дә югалмаган.

Исеменнән үк күренгәнчә, «Кыйссас әл-әнбия»нең мөндәриҗәсе, башлыча, исламият каршында пәйгамбәр дип танылган кешеләр хакындагы хикәяләрдән гыйбарәт. Хозыр, Локман, Җәрҗис, Зөлкәрнәйн, Гозәер, Даниял шикелле пәйгамбәр булулары ихтиляфлы[4] булган затларның да кыйссалары шул рәттән сөйләнә. Ахырда Мөхәммәд пәйгамбәрнең дә сәиренә[5] зур урын бирелеп, чәһарьяр[6], Хәсән, Хөсәен хакында да кыскача язылган. Шулай ук бер-бер пәйгамбәр исеме белән багланып та,

[1] Мөндәриҗәсен – эчтәлеген.

[2] Мөстәшригының – көнчыгышны өйрәнүченең, ориенталистның.

[3] Казимбәк Мөхәммәтгали Касыйм улы (Александр Касимович Казем-Бек) (1802–1870) – филолог, шәрыкшинас. 1826–1849 елларда Казан университетында эшли (1828 елдан – төрек-татар теле кафедрасы мөдире), 1849 елдан Санкт-Петербург университетында эшли, анда шәрык телләре факультетының беренче деканы була.

[4] Ихтиляфлы – каршылыклы.

[5] Сәиренә – тормыш итү рәвешенә.

[6] Чәһарьяр – Мөхәммәд пәйгамбәрдән соң килгән дүрт хәлифә: Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Гали.

турыдан-туры «тарихе мөккаддәс»кә[1] бик аз мөнәсәбәте булган хорафи кыйссаларга да китапта урын бирелгән; мәсәлән, Гуҗ бине Гонык[2], Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ, Һарут-Марут, әһле Сәба, Әсхабе кәһәф[3], «Бир әл-мөгаләтә» хикәяләре шул җөмләдән. Хәтта арада берәүнең хайваннар телен өйрәнеп, шуның аркасында кызык хәлләргә төшүе хакындагы хикәя шикелле, «Мең дә бер кичә»дә[4] дә булган, гомум шәрык әдәбиятларында таурана торган мәүзуглар[5] да юк түгел. Шулай ук урыны белән иген игү, икмәк пешерү, комаш[6] тугу, кием тегү, үлекне җиргә күмү, йорт хайваннарын ияләндерү шикелле эшләрнең башта кайдан килеп чыгуы, кем тарафыннан башлап эшләнүе хакында да мәгълүмат биреп узыла. Бу исә ислам шәркының тарихе мөкаддәс ноктаи назарыннан[7] мәдәният тарихына карашыдыр[8].

Робгузи үзенең кыйссаларына нигез итеп Коръәнне ала. Сүзенең дөреслеген исбат өчен, һәрвакыт сүз арасында Коръән аятьләрен китерә. Коръәндә булмаган тәфсилатны ул төрле тәфсирләрдән чүпләгән[9]. Шулай ук Кәгаб әл-Әхбар риваятьләре[10],

[1] «Тарихе мөкаддәс» – ислам дине тарихы, изге тарих.

[2] Гуҗ бине Гонык – дини мифология буенча, гадәттән тыш зур гәүдәле кеше.

[3] Әсхабе кәһәф – мәгарә хуҗалары.

[4] Текстта: «Мең бер кичә».

[5] Мәүзуглар – сюжетлар.

[6] Комаш – ефәк.

[7] Ноктаи назарыннан – карашыннан.

[8] Этнең кешегә ияләнүе турысындагы легенда дикъкатьне җәлеп итәрлек: Адәм җәннәттән сөрелеп җиргә төшкәч, шайтан җир йөзендәге җанварларны котырта: «Кешеләр сезне үтерәчәкләр, шуның өчен сез, җыелып барып, аны үтерегез», – ди. Һәммә хайваннар, җыелышып килеп, Адәмгә һөҗүм итмәкче булалар. Адәм, бик куркып, Аллага ялвара. Алла аңар әйтә: «Шуларның арасыннан берсен чакырып, башыннан сыйпа», – ди. Адәм, этне чакырып, башыннан сыйпый. Шуннан соң эт Адәм ягыннан булып, башка хайваннарны куалый. Шул көннән бирле эт – кешеләргә ягымлы, башка җанварларга дошман булып кала. *(Авт. иск.)*

[9] Тәфсирчеләр үзләре исә ул мәгълүматны христиан вә яһүдләрнең хорафатыннан алганнардыр. *(Авт. иск.)*.

[10] Кәгаб әл-Әхбар – ислам динен кабул иткән бер яһүд галиме булып, бәни Исраил хорафатының ислам дөньясына кереп таралуына зур сәбәпчеләрдән берсе булган (Шура, 1915, 4 сан). *(Авт. иск.)*

Әбү Исхак Нишабуриның «Кыйссас әл-әнбия»се һәм башка кешеләрнең әсәрләре белән файдаланганын ул китапның бәгъзы урыннарында әйтеп китә. Әлхасыйль, Робгузи гомерендә күп нәрсә укыган галим кеше булган һәм үз заманасында ислам дөньясында бу бабта язылган бар китапларны күреп чыккан булырга кирәк. Аның китабы заманының укучылары өчен һәм кызыклы, һәм гыйбрәтле бик күп материалны эченә алган булып, үз вакытының нәфис әдәбияты, роман вә хикәяләре урынына торган. Шуңар күрә дә без бу әсәргә сәрәф[1] бер дини максат белән генә язылган нәсри[2] әсәргә караган күк түгел, бәлки бер әдәби, шигъри әсәр булу ягыннан да карыйбыз.

Робгузиның һәрбер пәйгамбәр хакындагы хикәясе, түбәндәге шикелле, кыскача шул пәйгамбәрнең сыйфатларын, хассасларын[3] санап чыгу белән башлана: «Ул гамәли укуш[4], дидари гүнүш, Газраил бирлә табишкан[5], Ризван бирлә яндашкан[6], дөньядин куш тик учкан, тәмугга кереп чыккан, сыйрат күбрүкин[7] кичкән, оҗмах ишекин ачкан, үзи газиз, урыны әйиз[8], әригъ затлигъ, яхшы атлигъ Идрис пәйгамбәр салаватуллаһи галәйһи вәссәлам». Аннан соң шул пәйгамбәрнең башыннан кичкән хәлләрне кыскача сөйләгән бер шигырь – касыйдә килә. Шигырьдән соң нәсер белән язылган асыл кыйсса башлана. Сирәк-сирәк кенә арага көйле кисәкләр дә катышып китәләр. Шулай ук, иститрад[9] йөзеннән, төрле мөхакәмә вә мөляхәзәләрдә[10] хикәяләрнең тигез агышын бүлгәлиләр. Мәсәлән, Тия сахрасында адашып йөргәндә, Алла бәни Исраилгә күктән әзер киемнәр, азыклар иңдергәнен сөйлә-

[1] Сәрәф – исраф.
[2] Нәсри – чәчмә.
[3] Хассасларын – сыйфатларын.
[4] Гамәли укуш – мактаулы. *(Авт. иск.)*
[5] Табишкан – килешкән. (*Авт. иск*)
[6] Яндашкан – якынлашкан, дуслашкан. *(Авт. иск.)*
[7] Күперен. *(Авт. иск.)*
[8] Югары. *(Авт. иск.)*
[9] Иститрад – читкә китү, сүз уңаеннан әйтелгән сүз.
[10] Мөхакәмә вә мөляхәзәләрдә – хөкем чыгару, хөкем итү һәм фикер йөртүләрдә.

гәндә, мөәллиф[1] түбәндәге мөляхәзәсен кыстырып китә: «Файдәи мөэминләр Муса пәйгамбәр догасы берлә ул гасыйлар[2] таяр тун[3] киделәр, анук тәгам йидиләр, без гасыйлара тәкый Мөхәммәд Рәсүлуллаһ догасы бирлә оҗмахта таяр тун киеп, анук тәгамнар йийеб, янә Хак Тәгаләнең фазылы булса, дидарын күрсәк, һич гаҗиб вә гариб булмагай иншаллаһы Тәгалә». Күбрәк бу мөляхәзәләр сөаль-җавап шәкелендә[4] язылганнар. Мәсәлән, Ибраһим пәйгамбәр Исмәгыйльне корбан кылганны сөйләгәндә яза: «Сөаль Ибраһим гам ничук[5] йыглар ирди, Исмәгыйль гам ничүк йыгламас ирди, җаваб Исмәгыйль фани дустдин бакыйга уланур[6] ирди Ибраһим гам һәм фанидин, һәм бакыйдин икесенең дидаридин[7] мәхрүм калганыга йыглар ирди». Бәгъзан шушындый сөаль-җаваплар бик озынга китеп, берәр биткә тартылалар.

Шәрык әдәбиятына махсус мөбаләгалар[8] Робгузида да бик күп очрый. Гуҗ бине Гоныкның зурлыгы, Сөләйман пәйгамбәрнең бөтен дөньядагы җан иясен сыйлыйм дип әзерләгән ашларын бер кабып йоткан балыкның олылыгы, төрле патшаларның тәхетләренең, байлыкларының, хәзинәләрнең тасвирлары – һәркайсы шәрыкка хас арттырулар белән сөйләнә: хәзинәләр булса – һич адәм хисабына чыга алмаслык, тәхетләр булса – иңе, буе әллә ничәшәр «йыгаҗ»лык. Йосыфның кардәшләре, мәсәлән, шундый көчле булалар: Бинияминне алып калганга ачу итеп Йәһүдә бер нәгърә оргач[9], бөтен Мисыр халкы һушсыз булып егыла, Лавия бер таш алып ыргыта да Йосыфның тора торган сараен җимерә.

Робгузиның «Кыйссас»ы, борынгы чыгтай әдәбиятының классик әсәрләреннән саналып, чыгтай телен өйрәнү өчен иң

[1] Мөәллиф – язучы.
[2] Гөнаһлылар. *(Авт. иск.)*
[3] Әзер кием. *(Авт. иск.)*
[4] Шәкелендә – формасында.
[5] Ни өчен? *(Авт. иск.)*
[6] Уланмак – юллану, юлыгу. *(Авт. иск.)*
[7] Йөзеннән. *(Авт. иск.)*
[8] Мөбаләгалар – арттырулар, күпертүләр.
[9] Нәгърә оргач – каты кычкырып аваз салгач. *(Авт. иск.)*

яхшы нәмунәләрдән[1] хисаплана. Аның теле төзек һәм саф, чит сүзләр белән артык чуарланмаган. Робгузиның өслүбе урыны-урыны белән фәсахәт-бәлягатьнең[2] югары катлауларына күтәрелә. Хосусан, Йосыф пәйгамбәр кыйссасын мөхәррир бик яратып язган булырга кирәк; монда аның өслүбе парлак[3] бер тасвири өслүбкә үрелеп киткәли. Әсәр башлыча нәсер белән язылса да, аның һәрбер кыйссасы аерым бер поэма шикелле тоела. Насир[4] Робгузи, шөбһәсез, шагыйрь кеше булган. Хикәя, дастан язарга, ихтимал, аның тәрбиясе, тоткан мәүкыйгы манигъ[5] булгандыр. Менә ул, үзенең шагыйрь рухын канәгатьләндерер өчен, дини мәүзуглардан хыялга иң күп азык бирердәен, ягъни тарихы мөкаддәсне алган. Шулай итеп, аның «Кыйссас»ы Тәүрат[6] шигъриятен төрк телендә тәҗәссем иттергән[7]. Үзенең Коръән, тәфсир киртәләреннән чыга алмавына карамый, Робгузи бу кыйссаларга үз рухын бирә алган. Аның хикәяләре күбесенчә ривая формасында тыныч кына агып килсә дә, бәгъзан ул – шигъриятнең күкләренә күтәрелә: хисси иститрадлары[8] аның чын шагыйрь рухын ачып бирәләр. Бәгъзан ул язып-язып килә дә, гади нәсер аны канәгатьләндерми башлый. Шул вакытта аны илһамы шигырьгә күчәргә мәҗбүр итә. Шулай итеп, арага асыл хикәя белән мөнәсәбәте аз булган шигъри кисәкләр кереп китәләр. Мәсәлән, Йосыф кыйссасындагы «Яз» газәле белән «Корткалар» хакындагы шигырь шул җөмләдән. Робгузида яхшы гына шигырь куәте дә бар. Аның шигырьләре күбрәк бәхре рәмел (фагыйлатен фагыйлатен фагыйлатен фагыйлат) вәзенендә язылганнар. Бәгъзан ул, гарәп шигырьләре

[1] Нәмунәләрдән – үрнәкләрдән.
[2] Фәсахәт-бәлягатьнең – матур-төзеклекнең.
[3] Парлак – билгеле, танылган.
[4] Насир – чәчмә стильдә язучы.
[5] Мәүкыйгы манигъ – урыны киртә.
[6] Тәүрат – Аллаһы Тәгалә тарафыннан Муса пәйгамбәргә иңдерелгән китап.
[7] Тәҗәссем иттергән – сурәтләгән.
[8] Иститрадлары – чигенешләре.

китереп, аларны шигырь белән үк төркичәгә тәрҗемә кылып китә. Ул хәтта гарәпчә дә шигырь яза алган; шәрыкка махсус әдәби гадәт буенча, ике юлы – гарәпчә, ике юлы төрекчә кара катыш шигырьләр язып та уйнаган.

## «Диване хикмәт»

Чыгтай әдәбиятыннан безнең татар арасына күбрәк дини һәм тәсаувыфи әсәрләр кергән. Тәсаувыфи әсәрләрнең дә иң әһәмиятлеләреннән берсе – «Диване хикмәт» исемле шигырь мәҗмугасыдыр.

«Диване хикмәт»нең язучысы – Хуҗа Әхмәд Ясәви[1]. Бу – безгә бик таныш булган бер исем; чөнки бу зат – Хуҗа Баһаведдин Нәкышбәнди[2] белән берлектә безнең татар халкының иң ихтирам итә торган әүлияларыннан. Тәсаувыф идеяләре, ишанлык, шәехләргә, изгеләргә ышану, әүлиялардан мәдәд[3] өстәү безнең Идел буе татарлары арасына Урта Азиядән, Төркестаннан килгән; аларны дин гыйлеме белән бергә безнең Бохарада укыган муллаларыбыз алып кайтканнар; сәяси мәхкүмиять[4] аркасында пәйда булган икътисади кысынкылык, дөньядан бизәргә, ахирәткә генә юнәлергә өнди торган тәкъвалык[5] вә суфилык идеологиясенең таралуы, халык аңына керүе өчен нык бер зәмин[6] булган. Менә шуңар күрә безнең татарның «изгеләре» дә – Төркестан изгеләре, Төркестанда чыккан шәехләр, тарикать әһелләре. Болардан иң атаклылары – тәсаувыфта Нәкышбәнди

[1] Хуҗа Әхмәд Ясәви – Йәсәвия тарикатенә нигез салучы.

[2] Баһаведдин Мөхәммәд бине Борһанеддин Мөхәммәд ән-Нәкышбәнди (1318–1389) – суфичылыкның Нәкышбәнди мәзһәбенә нигез салучы. Бу мәзһәб башка кайбер суфи тарикатьләрдән үзенең тормышчанлыгы белән аерылып тора. Нәкышбәндийә кеше табигатенә хас гамәлләрдән, ихтыяҗлардан, дөньявилыктан ваз кичмичә яшәүне, ләкин шул ук вакытта күңел белән Аллаһы Тәгаләгә баглануны, аңа табынуны алга сөрә.

[3] Мәдәд – ярдәм, булышлык.

[4] Мәхкүмиять – хөкем.

[5] Тәкъвалык – диндарлык.

[6] Зәмин – җирлек.

тарикатен төзегән Хуҗа Баһаведдин белән җаһрия тарикатенә нигез салган Хуҗа Әхмәд Ясәви. Болар, Мавәраэннәһер халкының «милли» изгеләре булган шикелле, безнең Идел буе татарларының да «милли» әүлияларына әверелеп киткәннәр. Безнең татар, тормышта үзенә авырлык килгән чакларда, Алласыннан да элегрәк, шушы ике шәехтән мәдәд сорый, алардан ярдәм таләп кыла. Һичбер татар авылында бу ике затны белмәгән азмы-күпме диянәтле[1] карчык таба алмассың. Алар бу ике әүлияны пәйгамбәрләрдән дә якынрак күрәләр, читен вакытларда шуларга ялваралар, нәзер садакаларын аларга адарыналар.

Хуҗа Әхмәд Ясәвинең безнең өчен әһәмияте, әлбәттә, аның әүлиялыгы ягыннан түгел, бәлки әдиплеге, шагыйрьлеге җәһәтеннән. Мәшһүр тәсаувыф әһелләре, күбесенчә дәрвиш-суфи булу белән бергә, шагыйрь дә булганнар. Әдәбиятта суфилык тәэсире бөтен ислам шәркының әдәбияты өстенә гарыз булган бер чир шикелле. Иранның, аларга тәкълидән тереклек галәменең бөтен шагыйрьләре тәсаувыф тәэсиренә бирелгәннәр. Дөрес, тәсаувыф безгә бик күп яхшы шагыйрьләр, байтак гали әдәби әсәрләр багышлаган, ләкин, шуның белән бергә, әлбәттә, суфилыкның начар тәэсире ислам шәркының бөтен тормышында күренгән күк, аның әдәбиятында да заһир була[2]. Ул ничек шәрык мөселманының фикерен кысып, мәдәнияттә алга барудан, заман белән бергә тәрәккый итүдән тыйган булса, шулай ук шәрыкның әдәбиятын да җансыз калыпларга тыгып, аның үзгәрүенә, төрләнүенә манигъ[3] булган. Хуҗа Әхмәд Ясәвинең ялкынлы иман, чын илһам белән язылган шигырьләре, шөбһәсез, соңгырак заманның шәрык әдәбиятындагы, модага бирелеп кенә суфиланып азапланган бик күп шагыйрьләрнең сонгый[4] әсәрләренә караганда, әдәби яктан күп алда торалар. Мөәллифе-

[1] Диянәтле – динле.
[2] Заһир була – ярдәмче була. (ачык күренеп тора дөресрәк булмыймы)
[3] Манигъ – киртә.
[4] Сонгый – ясалма.

нең[1] дә тәсаувыф әһеленең зурларыннан булып, шуның өстенә көчле бер шагыйрь булуы җәһәтеннән, «Диване хикмәт» – чын, самими тәсаувыф лирикасы өчен нәмунә[2] булырлык (характерный) бер әсәрдер.

Хуҗа Әхмәд миладиXI һәм XII гасырлар арасында Ташкенттан аз гына шимальдәрәк, хәзерге Төркестан аталган шәһәр янында булган Ясса исемле кечкенә калада дөньяга килгән. Шуның өчен аны Ясәви дип атаганнар. Яшь вакытында төрк шәехләренең зурларыннан Шәех баб Арыслан (Арыслан баба) хозурында тәрбияләнгән; вафатына кадәр аның хезмәтендә калып, «тәрәккыяте көллия»гә ирешкән. Баб Арыслан үлгәннән соң, аның күрсәтүе буенча Бохарага барып, Хуҗа Йосыф Һәмәдани исемле шәех хозурында, ишан булырга теләгән мөридләр үтәргә тиешле булган хезмәтне тутырып, сахибе тәкмил[3] булып иршад (ягъни ишанлыкка иҗазәт[4]) һәм хилафәт хиркасы алган. Ясәвинең тәрҗемәи хәлен язучы аның хакында: «Заһири вә батыйни[5] гыйлемнәрне үзенә җыйган, зөһед вә тәкъвалыкта, шәригать вә тарикатьтә иң югары дәрәҗәләргә ирешкән иде», – ди. Ул, аныңча, төрк мәшаихе[6] хилкасының башы хисаплана. Төрк ишаннарының күбрәге тарикатьтә аңар интисаб итәләр[7]. Бик күп кешеләр, аңар тәвәҗҗеһ итеп (ияреп), иршад сахибе булганнар. Вафаты милади 1166 (һиҗри 562) елда булып, кабере Ясса касабәсендә[8]. Хуҗа Әхмәд Ясәвинең тәрҗемәи хәле хакындагы бу мәгълүмат «Диване хикмәт»нең башында, фарсыча «Хәзинәт әл-әсфия» исемле китаптан күчерелеп дәрҗ ителгән[9]. Хәзердә дә Ясәвинең кабере төркестанлылар тарафыннан ифрат ихтирам ителә; халык, аны

[1] Мөәллифенең – язучысының.
[2] Нәмунә – үрнәк.
[3] Сахибе тәкмил – җитлеккән.
[4] Иҗазәт – рөхсәт.
[5] Заһири вә батыйни – ачык вә яшерен.
[6] Мәшаихе – шәехләре.
[7] Интисаб итәләр – бәйләнешле булалар.
[8] Касабәсендә – районында.
[9] Дәрҗ ителгән – теркәлгән.

зиярәт кылыр өчен, нәкъ хаҗга барган шикелле килә. Аксак Тимер аның кабере өстенә бик шәп төрбә салдырган. Хуҗа Әхмәд Ясәви казакъ вә үзбәкләрнең иң сөекле әүлияларыннан булып, аның шигырьләрен халык Коръән белән бер дәрәҗәдә тәкъдис итә[1] икән. Гомумән, элек-электән Ясәви Төркестанның шималендә яшәүче күчмәле төрк халыкларының хамия (патроны[2]) саналып килгән[3]. Аның күчмәле төркләр каршында шулкадәр игътибар казануының төп сәбәбе, шөбһәсез, аларның ватаннарына якын бер җирдә яшәве булгандыр.

«Диване хикмәт»не дикъкатьләп моталәга кылган[4] кеше андагы шигырьләрдән мөәллифнең тәрҗемәи хәленә гаид[5] беразмәгълүмат таба ала. Берничә шигырьдә (2, 3, 4, 5, 34 һәм 124 нче хикмәтләрдә) Ясәви бер яшеннән башлап алтмыш өч яшенә хәтле, һәрбер яшькә аерым-аерым тукталып, үзенең тормышын сөйли. Ләкин бу мәгълүмат, күбесенчә, аның тышкы хәятына гаид түгел, бәлки ул күбрәк киная тарикы белән, үзенең эчке рухи тормышыннан тәсаувыф бабында тәкәммеленнән[6] бәхәс итә. Берничә мисал китерәбез:

«Бер яшемдә әрвах[7] миңа өлеш бирде,
Ике яшьтә пәйгамбәрләр килеп күрде».

«Түрт яшемдә хак Мостафа бирде хөрмә...»

«Алты яшьтә тормай качтым халаикъдин,
Күккә чыкып, дәрес үргәндем[8] мәләикдин».

«Йите яшьдә Арыслан бабам эзләп тапты.
Һәр сер күреп, пәрдә берлә бөркеп япты.
Бихәмдуллаһ, күрдем, – диде эзем үпте...»

[1] Тәкъдис итә – изге дип ышана.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Вамбери. «История Бохары». *(Авт. иск.)*
[4] Моталәга кылган – өйрәнгән, укыган.
[5] Гаид – караган.
[6] Тәкәммеленнән – камилләшү, үсеп җитү.
[7] Әрвах – рухлар.
[8] Үгрәндем, өйрәндем. *(Авт. иск.)*

«Унбишемдә хур вә гыйльман каршы килде
Башин орып кул каушурып тәгъзим кылды
Фирдәүс атлиг җәннәтидин мәхзур[1] килде.
Дидар өчен[2] барчасыны куйдым мәна[3]».

«Йәшим йитте йекермегә үтдим мәкам
Бихәмдуллаһ бир[4] хедмәтин кылдым тәмам
Дөньядагы корт-кошлар кылды сәлам
Ул сәбәбдин хакка яук[5] булдым менә».

«Мин йекерме сикез яшьдә гашыйк булдым[6].
Кичә ятмай михнәт тартып садыйк булдым
Андин соңра дәр кәһикә лаек булдым...»

Менә шушы өзек-өзек кыйтгалардан[7] Ясәвинең үз тәрҗемәи хәлен ничек язганлыгы ачык күренсә кирәк. Чын тәрҗемәи хәл өчен монда материал, әлбәттә, бик аз табыла.

Ясәви, 63 яшенә җиткәннән соң, үзенең җир астына кергәнлеген, ягъни мәгарәгә кереп, дөньядан гозләт иткәнлеген[8] сөйли. Бу хакта ул бер шигырендә әйтә:

«Йир өстидә үлмәс борын тәрик улдым[9],
Алтмыш өчтә сөннәт, диде, иштеп белдем.
Йир астыда җаным коллык кылдым...»

---

[1] Мәхзур – табын, әзерләнгән нигъмәт. *(Авт. иск.)*

[2] Дидар өчен – Алланың йөзен күрер өчен. *(Авт. иск.)*

[3] Мән – мин; кафияне «әлиф»кә тәмам итү һәм вәзенгә туры китерү өчен, төрк шагыйрьләре, бәгъзан төрк сүзләрен үзгәртеп, ахырына һич кирәк булмаган хәрефләр кушалар; мәсәлән, «мәм»не – «мена», «тиде»не «тидия» дип әйтү шикелле. Бу гадәт гарәп-фарсы шигырендә дә бар. *(Авт. иск.)*

[4] Бихәмдуллаһ бир – шәех, ишан. *(Авт. иск.)*

[5] Яук – якын *(Авт. иск.)*.

[6] Әлбәттә. Аллага гашыйк булган. *(Авт. иск.)*

[7] Кыйтгалардан – кисәкләрдән.

[8] Гозләт иткәнлеген – читләшкәнлеген.

[9] Тәрик улдым – терек хәлдә үлдем. *(Авт. иск.)*

Ягъни, Мөхәммәд пәйгамбәр 63 яшендә вафат булганга күрә, шул яшьтә җиргә керү сөннәт дип, 63 тән артык торуны рәва[1] күрмичә, ул тереләтә җир астына керә. Бу эшнең сәбәпләре турысында озын-озын итеп әллә ничә шигырендә сөйли. Менә шуңар караганда, Ясәвинең «Диван»ы XII гасырның икенче яртысында тәртип ителгән булырга тиеш.

«Диване хикмәт» – басмада урта кул 262 битле бер китап. Ул 150 кадәр, күбрәк уртача зурлыктагы шигырьләрдән гыйбарәт. Һәрбер шигырь «хикмәт» дип атала. Тәсаувыфи шигырьләрне шулай атау ул заманның суфи шагыйрьләре арасында гадәт булган. «Диване хикмәт», безнең халык арасында артык таралган китаплардан булмаенча, күбрәк хәвас[2] тарафыннан укылган булырга кирәк.

Ясәвинең хикмәтләре күбесе мөндәриҗә[3] ягыннан тәсаувыфи лирикага керәләр; кыйсса-хикәя формасында язылганнары аз. Шагыйрь шигырьләрендә күбрәк үзенең фикерләрен яки халәте рухиясен сөйли. Киная-аллегориягә аларда зур урын бирелә. Ясәвинең иң яраткан кинаяләре – вәхданиять[4] дәрьясына гаувас[5] булып чумып, хакыйкать энҗеләре чыгару, мәхәббәт яки шәүкъ[6] шәрабын эчү, аләст хәмерен нуш[7] итү, халык арасына диңгез булып ташу, дәрья булып аккан күз яше белән игенлекләрне, бакчаларны сугару, ля мәкянга[8] ашу, күкләрдә сәйяр итү шикелле әйберләр. Ясәвинең кинаяләре астында һәрвакыт дини тойгыларны аермачык күрергә мөмкин. Ул үзенең шигырьләрендә бәгъзан тагать-гыйбадәткә дә өнди, ләкин, гомумән караганда, мондый мәүзуг аларда бик аз роль уйный. Ул үләчәкне, җена-

[1] Рәва – яраклы, кирәкле.
[2] Хәвас – югары сыйныф.
[3] Мөндәриҗә – эчтәлек.
[4] Вәхданиять – бердәмлек.
[5] Гаувас – чумучы.
[6] Шәүкъ – дәрт, теләк.
[7] Нуш – ләззәт.
[8] «Ля мәкян»га – урыны юк, урыны билгеле булмаган (Аллаһы Тәгаләгә карата әйтелә).

за булып күтәрелүне, сөаль фәрештәләре килүне, кабер куркынычларын, кыямәт көннәрен искә төшерергә ярата; үзенең гөнаһы күплегенә пошына. Хәтта урыны-урыны белән үзен кимсетүдә артык дәрәҗәгә барып җитеп:

> «Кол Хуҗа Әхмәд, яманларны[1] яманы син,
> Юлдин азган гөмраһларны[2] наданы син», –

шикелле сүзләр белән үзен шелтәли. Ләкин, туры килгәндә, ул үзенең кәмаләте[3] белән мактанудан да кире тормый.

Сүз арасында шуны да әйтеп үтәргә кирәк ки, никадәр суфи-дәрвиш булган кешегә кече күңелле булып, үзе хакында аз уйлау рәва[4] шикелле күренсә дә, без Ясәвинең һаман үзе белән генә мәшгуль булуын, ике сүзнең берендә үзенең изгелеге, Аллага якынлыгы белән, тәсаувыф юлында нинди югары дәрәҗәләргә ирешүе белән мактануын күрәбез. Шушы ифтихар[5], үзен борынгы замандагы иң атаклы суфилар, шәехләр белән бер тактага тезеп йөртү аның бөтен «Диван»ы буенча кызыл җеп булып сузылып бара. Ихтимал, тәсаувыф әһелләре моны үзләренчә юрый торганнардыр, ләкин бу, битараф укучының күзенә бәрелеп, «инсанның ноксанаттан хали булмавын» искә төшерергә мәҗбүр итә.

Шагыйрьнең бөтен теләгәне, бөтен гаяи хыялиясы[6] – Аллага васләт (кавышу). Ул бу юлда Җүнәйд Шибли, Хәсән Басри, Зөннун Мысри шикелле мәшһүр суфиларны үзенә идеал итеп тота; Мансур Хәллаҗ шикелле дарга асыласы, Баязид Бөстами күк үтереләсе килә. Аның бар теләгәне – Алланың дидарын[7] күрү. Аның бөтен уе-сагышы шул, суфиларның гаяи хыялиясе булган

---

[1] -ны – чыгтайчада -ның мәгънәсендә. *(Авт. иск.)*
[2] Гөмраһ – юлдан язган кеше. *(Авт. иск.)*
[3] Кәмаләте – житешкәнлеге.
[4] Рәва – яраклы.
[5] Ифтихар – мактану.
[6] Гаяи хыялиясы – хыялдагы теләге.
[7] Дидарын – йөз сурәтен.

Алланы йөзгә-йөз күрергә юнәлгән. «Әна әл-хакк»[1] диюче шәех Мансурның[2] сурәте аңар тынычлык бирми; чөнки аны шул сүзе өчен, кяфер дип, дарга асканнар, асылгач, ул «дидар» күрергә муаффәкъ булган[3]. Шул мөнәсәбәт белән һәм болай да урыны туры килгәндә, Ясәви үзенең шигырьләрендә рәсми ислам руханиларын, муллаларны, хуҗаларны сүгүдән, аларны хурлаудан кире тормый. Анынча, алар наданнар; надан булганга күрә аларга «Әна әл-хакк»ның мәгънәсен аңлау да насыйп булмаган. Шул «наданнар» аңар тынычлык бирмиләр. Бер җирдә ул: «Йир астыга качып кердем наданнардин», – ди.

Аллага гыйшык Ясәвинең бөтен лирикасына тон[4] бирә.

«Хак васлыны эзләп табмай хәйранамен
Тынмаи йыглаб күңеле бозык диванамен
Хәлем сорсаң мән талиб җанәнәмен
Җанан эзләп фани булып килдем менә», –

ди ул. «Җанан», ягъни мәгъшукка ирешер өчен, аны җаныңнан ваз кичеп сөяргә кирәк:

«Әйя дустлар, гыйшык гаувасы булмагынча[5]
Вәхданият дәрьясыга керсә булмас.
Ул дәрьяны гәүһәредер Хак висалы
Җандин кичеп кермәкенчә күрсә булмас».

Гашыйк булган бәндә өчен дөнья вә ахирәттә Алладан башка һичнәрсә кирәк түгел:

«Синсез миңа тәгам йимәк кып-кызыл кан,
Синсез миңа нигә кирәк бу тәндә җан
Синсез миңа караңгыдыр ошбу җиһан».

---

[1] «Әнәл-хак» – «Мин – Аллаһ!»

[2] Әбү Габдулла әл-Хөсәен ибн Мансур әл-Хәллаҗ (858–922) – суфи дин әһеле һәм шагыйрь, «Әна әл-хакк», ягъни «Мин – хакыйкать» яки «Мин – Алла» дип белдергән өчен җәзалап үтерелә.

[3] Муаффәкъ булган – ирешкән.

[4] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[5] Булмыйча торып. *(Авт. иск.)*

Гашыйклар аны һичбер нәрсәгә алыштырмыйлар:

«Солых әйләсә гашыйклары кабул кылмас,
Хуры гыйльман җәннәт бирсә – күзгә илмас,
Дидар теләп башларыны йирдин алмас».

Гашыйклар хакында сөйләгәндә, безнең шагыйрь әллә нинди мөбаләгаларны[1] да кызганмый:

«Утка янмас, салса утдин гашыйк кеше
Йир вә күкне бөстан кылгай акган яше», –

ди. Аннан соң күкләргә, җирләргә хитаб кылып[2] әйтә:

«Әй, йир вә күк гашыйклардин хәзер кылының
Утлуг аһы чикар булса, хазир булының.
Күккә бакыйб нәгъръә тартса, куркып торының
Бир аһ урса, галәм иксан булыр[3] ирмиш».

Гашыйкларның аһлары шундый кызу ки, аларга хәтта җәһәннәм дә тәкать тота алмый[4]:

«Дузах[5] йыглаб, зар әйләгәй Ходаега
Тәкатем юк гашыйкларны йир аһыга
Качыб баргай Хак Тәгалә пәнаһыга»[6].

Гомумән, «Диване хикмәт»не укыганда, күз алдына безнең татар арасында бик таралган бер шәмаил килә. Бу рәсемдә аллегория формасында тәсаувыф тасвир ителгән. Бу рәсемне ясаучы кем булгандыр, аның асылы каян килә торгандыр – бу безгә мәгълүм булмады. Рәсемдә җир өсте тасвир ителә; урталыкта бер күз, битсез-нисез бары ялгыз күз генә. Бу күз – Аллага гыйшкыннан җылаучы суфиның күзе. Аннан агып чыккан күз яше, елга булып ага-ага, дәрьяга әверелеп, җир йөзенә җәелгән. Дәрьяның тирәсендә шәһәрләр, агачлыклар, су өстендә

[1] Мөбаләгаларны – арттыруларны.
[2] Хитаб кылып – эндәшеп.
[3] Тип-тигез булыр, ягъни хәраб булыр. *(Авт. иск.)*
[4] Тәкать тота алмый – чыдый алмый.
[5] Дузәх – фарсыча: җәһәннәм. *(Авт. иск.)*
[6] Хозурына, каршына. *(Авт. иск.)*

көймәләр-кораблар йөриләр. Югары планда гашыйкның аһлары җирне тишеп чыгып, ут һәм төтен атып тора торган вулканнар пәйда булган. Белмим, рәсемне ясаучы аңлапмы, әллә аңламыймы ясагандыр, әмма ул тәсаувыфның төп идеясен, пантеизмны, ягъни суфиның бөтен галәм белән, бинаән галәйһи[1] Алла белән берлеген, бик вөҗүд булуын аерымачык күрсәтә. Ясәвинең шигырьләре дә безгә нәкъ шул шәмаил биргән тәэсирне бирәләр. Гүяки ул аның шигырьләренә атап ясалган рәсем шикелле[2].

Ясәви бик җиңел, безнең татар өчен дә аңларга асат булган чыгтай телендә язган. XII гасырда, «Котадгу белег»тән йөз генә ел соң язылуына карамый, аның телендә уйгур тәэсире бер дә күренми. Ихтимал, шагыйрьнең уйгурлардан ерак бер җирдә торуы моңар сәбәп булгандыр. Гомумән, аның теле бик садә, өслүбе матур, урыны-урыны белән ифрат көчле ифадәгә малик[3]. Кирәк телне, кирәк форманы булсын, Ясәви үзенең кулында бик нык тота; ул – үз өслүбенең камил хуҗасы. Бәгъзы вакытта шигырьләре чит сүзләр белән кирәгеннән артык чуарланган булса, бәгъзан ул саф төркчәгә якынлаша, никадәр төркчәрәк булса, Ясәвинең шигырьләре шулкадәр матур һәм куәтле чыгалар. Гарәп-фарсы сүзләре белән ул сүи истигъмаль итми[4].

[1] Бинаән галәйһи – шуңа күрә, шуның өчен.

[2] «Диване хикмәт»нең башында шактый озын гына (10 битле) бер мөкаддимә дәрҗ ителгән. Бу мөкаддимә җиңел чыгтайча тел, хәтта бәгъзан тәкәллефле *(ясалмалы)* өслүб белән язылган; урыны-урыны белән аның өслүбе мөсәҗҗәгъ *(рифмалы)* нәсергә әверелеп киткәли. Мөкаддимәнең кем тарафыннан һәм кайчан язылганы билгеле түгел. Һәрхәлдә, «Диван»ның үзеннән байтак соң язылган булырга кирәк. Аны язучы, башта бик озын итеп Ясәвине мәдехләп *(мактап),* бик күп шалтыравыклы титулларны тезгәннән соң, «Хәзрәте солтан Хуҗа Әхмәд Ясәви андаг итеб дурлар кем…» дип сүзен башлый. Монда тәсаувыфның бөтен нәзариясе (*теориясе*) бәян кылына; суфиларның үз аңлауларынча, тәсаувыфның нидән гыйбәрәт булуы, суфи булган кешенең нинди булырга тиешлеге, чын «мәшаих»лар белән ялган суфиларның аермасы, тәсаувыфта ирешү мөмкин булган дәрәҗәләр, аларның бүленүе, хосусиятләре сөйләнә, бу нәзария, әлбәттә, Хуҗа Әхмәд Ясәвинең үз тарикатенә карап ясалгандыр. *(Авт. иск.)*

[3] Ифрат көчле ифадәгә малик – бик көчле аңлатуга ия.

[4] Сүи истигъмаль итми – урынсыз кулланмый.

Ясәви берничә төрле вәзен[1] истигъмаль итә. Аның иң яраткан вәзене – бәхре һәзәҗ (мөфагыйлен, мөфагыйлен, мөфагыйлен). «Диване хикмәт»тәге күбрәк шигырьләр шул вәзен белән язылганнар. Аннан башка шушы вәзеннәр дә очрый: «мөфагыйлен фәгулен, мөфагыйлен фәгулен», «мөфагыйлен, мөфагыйлен фәгулен», «фагыйлатен, фагыйлатен, фагыйләт» дүрт мәртәбә «мөфагыйлен» һәм башкалар. Шигырьләрнең һәрбер дүрт юлы күбесенчә шәрык әдәбиятындагы гадәт буенча нократ (припев)[2] шикелле бер үк җөмлә белән, һич булмаганда «дуслар» дигән шикелле бер үк сүз белән тәмамланалар; кафия[3] исә һәрбер дүртьюллы бәйтнең әүвәлге өч мисрагында[4] була.

## Сөләйман Бакыргани вә аның әсәрләре

### I
### *«Хәким ата китабы»*

XII гасырның соңгы яртысында Урта Азиядә Сөләйман Бакыргани атлы бер суфи шагыйрь яшәгән. Бәгъзан «Хәким ата» ләкабе[5] белән өйрәнелә торган бу затка, «Бакырган», «Ахырзаман» һәм «Мәрьям» исемнәрендә татар арасында бик күп укылган өч китап нисбәт бирелә. Бу китаплар хакында сүзгә керешкәнче, Сөләйман Бакырганиның тәрҗемәи хәле белән танышып үтелергә тиешле. Безнең кулыбызда бу зат турысында төпле вә ышанычлы мәгълүмат юк. Бу хакта бары тик аның тәрҗемәи хәленә багышланган «Хәким ата китабы» дигән рисаләләрдән генә мәгълүмат алып була. Ләкин анда хакыйки фактлар урынына хорафи мәгълүмат тулган. Ихтимал, аның эчендә хакыйкать орлыклары юк түгелдер (һәм без шулай дип өмет итәбез дә), тик алар һәммәсе әфсанә (легенда) пәрдәсе белән өртелгәннәр.

---

[1] Вәзен – форма, ритм.
[2] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[3] Кафия – рифма.
[4] Мисрагында – шигъри юлында.
[5] Ләкабе – кушаматы.

«Хикәяте Хәким ата» исемле кечкенә кулда 47 битле бу рисалә беренче мәртәбә Казанда 1846 елда басылган. Бу китап – татар арасында иң укыла торган китаплардан берсе; теле – татарчага якын җиңел чыгтайча, мөәллифе[1] мәгълүм түгел. Бу китап Төркестанда язылганмы, Идел буендамы, ничек вә кайчан татар арасына кергән – бу турыда без бернәрсә дә белмибез. Ләкин, шөбһәсез, бу китапта язылган хикәя Төркестанда туган. Ихтимал, бу китапны, башка чыгтай әсәрләре шикелле, Мавәраэннәһергә барган татарлар алып кайтканнардыр; ихтимал, аны, Урта Азиядә язылган бер-бер китаптан күчереп, бер Идел буе татары язгандыр. Бу әсәрнең мөндәриҗәсе кызыклы вә Сөләйман Бакырганиның кем булганлыгын ачу юлында бердәнбер китап булганга, без монда аның кыскача мөндәриҗәсен сөйләп, бәгъзы урыннардан кыйтгалар да алабыз.

«Хәким ата» китабында Бакырганиның балалык вакыты хакында түбәндәге хикәяләр сөйләнә:

Сөләйман кечкенә чагында, мәктәптә укыганда, һәммә балалар Коръәнне муеннарына асып баралар, тик бу гына баш түбәсенә күтәреп йөри икән; аннан соң мәктәптән кайтышлый, йөзен остазына борып, арты белән чигә-чигә кайта икән. Көннәрдән бер көнне Хуҗа Әхмәд Ясәви, мәчет алдында утырганда, һәммә балалар арасында Сөләйманның гына Коръәнне түбәсенә күтәреп барганын күрә дә, балага мәхәббәт баглап, аны янына чакырып алып әйтә: «Бар, остазыңнан рөхсәт сора, җибәрсә, миңа кил, мин сиңа Коръән өйрәтермен», – ди. Остазы риза була, ата-аналары да ризалык күрсәтеп, үзләре китереп, баланы Ясәвигә тапшыралар. Сөләйман, 15 яшенә хәтле Ясәви хозурында сабак укыганнан соң, аңар мөрид булып хезмәтендә кала. Көннәрдән бер көнне Хозыр пәйгамбәр Ясәвигә кунакка килә. Ясәви үзенең шәкертләрен кырга утын җыярга җибәрә. Шул вакытта бик каты яңгыр явып, балаларның утыннары юешләнә. Бары тик Сөләйман гына, үзенең киемен салып, уты-

[1] Мөәллифе – авторы, язучысы.

нын киеменә төреп алып кайта. Кайткач, утыннарны ягып карыйлар – берсенең дә утыны янмый; бары тик Сөләйман алып кайткан утын гына янып, шуның аркасында башка утыннарга да ут кабына. Хозыр ата Сөләйманның бу эшенә тәхсин итеп[1], хәкимәнә эш кылганга күрә, аны «Хәким» дип атый. Шуннан соң аның аты Хәким Сөләйман булып китә. Хозыр, Сөләйманны мөбарәкләп, авызына төкереген сала. Шуннан аның эче «фәез[2] нуры» белән тула да, ул, илһамланып, бер хикмәт әйтә. Бу урында Бакырганиның беренче әйткән шигыре дип китерелгән шигырь «Бакырган китабы»нда да бар, ләкин анда бераз башкачарак.

Тиз арада Сөләйман Хуҗа Әхмәд Ясәвинең һәммә мөридләреннән өскә чыгып, кәмаләт[3] дәрәҗәсенә ирешә. Ясәвинең аны сынавы, үзенә ихласы там[4] булуын нинди хәйлә аркасында белүе хакында китапта изгеләргә бик үк килешеп бетмәсди булган бер көлкеле вакыйга риваять кылына. Шуннан соң ишаны Сөләйманны читкә җибәрә:

«Хуҗа Әхмәд Ясәви рәхмәтулла галәйһи Хәким Хуҗага әйдиләр имди: синең эшең тәмам булуп торур. Таң берлә ишекдә бер тивә[5] чыкар, ул тивәни менгел, тәкый башын буш куйгыл, барып ул тивә каю йирдә чүкә куймаса (куйса), сәнең мәгъзул мәкамең ул йир булур тиб рөхсәт бирдиләр. Хәким ата видаг[6] кылышу таңдасы[7] ул тивәгә менди, башын буш куйди ирсә, ул тивә Төркестандин көн тарафига йүрде вә тәкый Хорасан шәһәренең кояш инеше сары би нәва аркаси дигән йирдә барыб чүкти, купмади, кулладилар янә купмади. Тивә бакырди, ул йиргә Бакырган ат андин калди».

---

[1] Тәхсин итеп – мактап.
[2] Фәез – белем.
[3] Кәмаләт – камиллек.
[4] Там – тулы.
[5] Тивә – дөя.
[6] Видаг – озату, саубуллашу.
[7] Иртә белән. *(Авт. иск.)*

Хәким ата шул урында урнашып калмакчы була, ләкин анда Бугра ханның елкылары утлыйлар икән; көтүчеләр Хәким атаны куалыйлар. Шулвакыт аның беренче кәрамәте заһир була[1]. Моны кыйнарга килгәндә, көтүчеләрне агач ботаклары тотып калалар. Ике көтүче качып котылып, бу хәбәрне ханга барып сөйлиләр. Хан бик гаҗәпләнә, вәзирләреннән берсен бу эшне тикшерергә җибәрә. Аның Хуҗа Әхмәд Ясәвинең мөриде икәнен белгәч, Богра хан, изге кеше икән дип, аңар үзенең Ганбәр атлы кызын хатынлыкка бирә, бик күп мал-туарлар бүләк итә, үзе һәммә бәкләре белән килеп, аңар мөрид була. Акрын-акрын ул утырган җиргә халык җыела башлап, бер шәһәр пәйда булып, бу шәһәрне «Бакырган» дип атыйлар. Торган шәһәренә нисбәтән, Хәким ата үзе дә Сөләйман Бакыргани дип атала башлый.

Димәк, Хәким ата китабы буенча, Бакырган шәһәре Хуҗа Әхмәд Ясәви торган Төркестан яки Ясса шәһәреннән җәнүбтә Хорасан шәһәренең кояш баешы ягында булып чыга. Хорасан исә – чынлыкта бер шәһәр исеме түгел, бәлки шәркый Иранның бер вилаяте. Һәрхәлдә, Хәким ата китабының җәгърафиясе яхшы ук чуалчык. Бакырган исемле шәһәрнең хәзерге көндә дөньяда барлыгы мәгълүм түгел. Гарәб җәгърафиясеннән мөкаддәс Бакырган шәһәре Харәземдә Маш һәм Кас шәһәрләре арасында дип хәбәр бирә. Хәким ата китабында Бакырганны Гомуд дәрьясының басып узуы сөйләнә. Бу, шиксез, Гомуд дәрья, ягъни Амудәрья булырга кирәк. Бу сүз Бакырганның Хивада булуын куәтли генә. Ихтимал, чынлап та, нәһернең[2] күчүе аркасында, бу шәһәргә һәлакәт килеп, шуннан соң ул төзелә алмагандыр. Бары тик хикәядә Богра хан булып, аның Хәким атага якын мөнәсәбәте генә бераз уйга калдыра. Билгеле, Богра хан дип гарби уйгур ханнарын атаганнар. Шуңар караганда, Бакырган шәркый Төркестанда, яки аңар якын бер урында булырга тиеш

[1] Кәрамәте заһир була – могҗизасы билгеле була.
[2] Нәһернең – елганың.

иде. Мөтәвәффа[1] профессор Катанов[2] Бакырганның Төркестандагы Бака курган исемле бер шәһәр булуын, «Бакырган» дигән сүзнең шул «Бака курган»нан үзгәртелгәнлеген дәгъва итә иде.

Хәким атаның Ганбәр анадан өч углы була. Алар да изгеләрдән булып, яшь чакларыннан ук кәрамәтләр[3] күрсәтә башлыйлар. Кече углы Хөбби Хуҗа атка атланып йөрергә, ау ауларга бик һәвәсле була. Атасы инде аны, бу дәрвиш булмас, гаскәри булыр дип юрап куйган була. Ләкин, көткәннең киресенчә, кәрамәтләрнең иң шәпләре Хөбби Хуҗада күренә башлый: мәсәлән, ул диңгездә бата торган кешеләрне коткара, атасы иртән намазны Кәгъбәгә барып укып кайта икән, бу Кәгъбәнең үзен Бакырганга китерә, суйган үгезләрне тергезә. Бу кәрамәтләрне күргәч, атасы Сөләйман углыннан көнләшә башлый; ахрысында чыдый алмый, әйтә: «Углым, ике тәкә башы бер казанга сыймас», – ди. Бу сүзгә Хөбби Хуҗаның ифрат кәефе китә; әйтә: «И эти, мөгезле булсалар гына сыймыйлар алар, әгәр мөгезләрен сындырсаң, өч тәкә башы да бер казанга сыяр», – ди. Ләкин атасыннан мондый сүзләр ишеткәннән соң, ул Бакырганда калырга уйламый: «Хуш калның, без баралның», – ди. Анасы белән елашып күрешеп, өстенә бер нәрсә ябынып, идән уртасына ята да шуннан юкка чыга. Аталары бу хәлгә бик кайгыралар, елашалар, Хәким ата хәсрәтеннән бер шигырь әйтә. Бу шигырь Бакырган китабында юк, бары шушында гына. Аллаһы Тәгалә, болай итеп углын югалткан өчен, Хәким атага бик ачулана: «Бу Хөбби Хуҗа нәселеннән алтмыш әүлия килер иде, шулар һәммәсе хәзер дөньядан киселделәр», – ди. «Шушы эшең өчен синең өстеңнән кырык ел су агар, шуннан соң гына бу гөнаһыңнан арынырсың», – ди.

Хәким ата кара тәнле, чандыр, ямьсез бәдәнле кеше икән. Көннәрдән бер көнне хатыны Ганбәр: «Ай-һай, мин Богра

[1] Мөтәвәффа – вафат булган.

[2] Катанов Николай Федорович (1862–1922) – тюрколог, этнограф, фольклорчы.

[3] Кәрамәтләр – могҗизалар.

ханның шундый матур кызы идем, нинди ямьсез, кара тутлы кешегә насыйп булдым», – дип фикереннән кичерә. Аның бу уен ире кәрамәт белән сизә дә, кәефе китеп әйтә: «Кара дип мине хурлыйсың, ак дип үзеңне олуглыйсың, минем белән озак тормассың, миннән калырсың; миннән соң сине шундый бер кеше алыр – тәнендә тешеннән башка ак җире булмас», – ди. Үләр алдыннан угылларына, үзе үлгәч, аналарын кап-кара тәнле, аксак, бер күзе зәгыйфь бер кешегә бирергә васыять итеп калдыра. Аталарыннан соң угыллары Ганбәр ананы шундый чиркен[1] кыяфәтле Зәнки баба атлы бер дәрвишкә иргә бирәләр. Бераздан Гомуд дәрьясы ташып, Бакырганны басып харап итә. Хәким атаның да кабере су астында кала. Шулай итеп, Алла әйткәнчә, аның өстеннән кырык ел су акканнан соң гына, дәрья үз урынына кире кайта.

Менә Хәким ата китабының мөндәриҗәсеннән иң әһәмиятле кыйсеме шушы. Әсәрнең шул ягына игътибар итәргә кирәк ки, анда сөйләнгән әүлиялар безнең күз алдыбызга коры, хәятсыз, мөҗәссәм (схематический) «изге»ләр булып кына килмиләр. Алар – җанлы, тәнле инсаннар. Көнләшү, үпкәләү, кинә тоту[2], үч алу, аталык шәфкате шикелле һәрбер гади кешедә булырга мөмкин булган тойгыларны без аларның кылган эшләрендә дә күрәбез; хәтта Хәким атаның угыллары, үзләренең әүлия баласы, әүлия булуларына карамастан, шәкерт вакытларында, яшеренеп, шәраб мәҗлесләре дә ясыйлар.

Хәким ата үзе безнең татар халкы арасында хәлфәсе Хуҗа Әхмәд Ясәви күк «популярный» изге түгел. Аның углы Хөбби Хуҗа безнең карчыклар арасында артыграк игътибар казанган; ялварганда, аңар ялваралар; адарынганда, аңа адарыналар. Безнең халык кулында аның хакында язылган «Хикәяи Хөбби Хуҗа» аталган, «Хәким ата китабы» тибындагы һәм шундый ук тел белән язылган кечкенә бер рисалә йөри. Аның мөндәриҗәсе

[1] Чиркен – чирканыч.
[2] Кинә тоту – үпкә тоту.

Хәким ата китабыннан алынган булырга кирәк. Чөнки анда яңа бернәрсә юк, бары шул китаптагы Хөбби Хуҗага тәгаллекъл[1] хикәяләр генә сөйләнә.

Без югарыда сөйләнгән хорафи тәрҗемәи хәл эченнән хакыйкатьне сөзеп ала башласак, нәрсә табабыз? Сөйләйман Бакыргани – милади XII гасырның икенче яртысында яшәгән, Урта Азиядәге Җәһрия тарикатендә булган бер шәех, бер ишан. Ул – Хуҗа Әхмәд Ясәви хозурында тәрбияләнеп, аннан иҗазәт[2] алган күп мөридләрдән берсе һәм шулардан алгарак чыгып шөһрәт казанганрагы. Аның шәехлек гомере кайда икәнлеге мәгълүм булмаган «Бакырган» исемле бер урында (шәһәрдә) узып, шунда ул вафат булган. Әгәр дөрес булса, Хәким ата китабы буенча без аның тышкы кыяфәтен дә беркадәр күз алдыбызга китерә алабыз. Ләкин анда аның туу-үлү тарихлары, еллар күрсәтелмәгән. Сөләйман Бакыргани, шөбһәсез, гади бер кеше булмаган; анда булган ялкынлы шигъри куәт безгә шуны күрсәтә.

## II
## *«Бакырган китабы»*

«Бакырган китабы» – безнең татар арасында иң таралган китаплардан берсе. Һәрбер мәктәпнең, һәрбер «сабак абыстае»ның дәрес программасына кергәнгә күрә, азмы-күпме укыган татар баласы бу китапны күргән буладыр иде. Аның безнең арага керүе шактый иске заманда булырга кирәк. Аның кулъязмалары күп очрый. Беренче мәртәбә Казанда 1846 елда басылган.

«Бакырган китабы» шәрык әдәбиятындагы «диван»нар тибында тәртип ителгән. «Диван» дип шигырьләр (лирика) мәҗмугасы атала. «Бакырган»да исә ахырда назым белән язылган хикәяләр дә дәрҗ ителгән[3]. Гадәттә, диван бер генә шагыйрьнең шигырьләреннән тәшкил итеlә. Ләкин төрле кешеләрнең

[1] Тәгаллекълы – бәйләнешле.
[2] Иҗазәт – рөхсәт.
[3] Дәрҗ ителгән – кертелгән.

шигырьләреннән җыелып тәртип ителгән мәҗмугалар да очраштыргалый. Мәсәлән, чыгтай әдәбиятындагы Бәхши (баксы – шагыйрь) мәҗмугасы шул җөмләдән. Бу мәҗмугада Аллаһияр, Шәйдай, Нәсими, Мөшәррәф, Рәүнәкъ шикелле шагыйрьләрнең шигырьләре җыелган. Безнең «Бакырган китабы» да – шундый җыентык-мәҗмугалардан берсе.

Шәрык әдәбиятында бер гадәт бар: шагыйрь үзенең имзасын шигырьнең тышында түгел, бәлки эчендә куя. Ничек итеп булса да туры китереп (күбрәк шигырьнең ахыргы юлларына), ул үзенең исемен яки мөстәгар[1] имзасын (тәхәллүсен) кыстыра. Бу гадәтнең, әлбәттә, бер яхшы ягы да бар: шигырь югалмаган вакытта, шагыйрьнең исеме дә югалмый. Бу ысулда имза кылу хәзер безгә күп әсәрләрнең кемнеке икәнен белергә ярдәм итә. Шуның аркасында без «Бакырган китабы»ның бер генә кеше әсәре булмавын һәм кайсы кисәкләрнең кемнәр тарафыннан язылганлыгын белә алабыз.

«Бакырган китабы»нда шушы исемнәр белән имзаланган шигырьләр очрый: Сөләйман, Әхмәд, Шәмседдин, Колшәриф, Ходадад, Иканый, Габиди[2]. Болардан беренчесе – Бакыргани үзе. Ул имзасын төрлечә куйган. Күбрәк ул үзен «Кол Сөләйман» дип атый. Мондагы «кол» сүзе, – әлбәттә, «кол», «бәндә», «Алла колы» мәфһүмендә булган[3] бер кушамат. Бәгъзан ул үзен «Сөләйман» дип, «Хәким» дип, «Хәким Сөләйман» дип, «Хәким Хуҗа» яки «Хәким Хуҗа Сөләйман» дип йөртә. «Бакыргани» ләкабе бары бер урында гына, китабының иң башындагы шигырьнең ахыргы юлында гына очрый. Шуңар карап, бөтен китап «Бакырган китабы» аталган булырга кирәк. Монда ул

[1] Мөстәгар – кушамат.

[2] «Бакырган китабы»на тупланган шигырьләрнең авторлык мәсьәләсе бүген дә ачык кала. Китапның төрле авторлар әсәрләреннән җыентык булу версиясе бүген дә яши. Күп кенә шагыйрьләр биографиясенә ачыклык кергән. Мәслән, Икани яки Әйкани – Себер ханлыгы шәйхе, шагыйрь булуы билгеле. Габиди (Гобәйди), Ходадад һ.б. – Азәрбайҗан һәм Иран классик поэзиясе вәкилләре дип санала һ.б.

[3] Мәфһүмендә булган – аңланган.

әйтә: «Минем атымны сорасалар – Сөләймани Бакыргани», – ди. Ләкин, «Сөләйман»ның, «яи нисбәтә» белән «Сөләймани» формасында язылуы башта бер-бер кулъязмада хата язылып, шуннан басмага кереп, тәкрар[1] ителә торган бер яңгыш булырга кирәк. Башта ул, вәзенгә туры китерү өчен, «изафәи фарсия» белән «Сөләйман Бакыргани» булгандыр. Югарыда китерелгән төрле язмаларның, әлбәттә, Сөләйман Бакырганиныкы булуында шөбһә тотарга мөмкин түгел. «Әхмәд» имзасы Хуҗа Әхмәд Ясәвинеке булырга тиеш. Ул күбрәк «Кол Әхмәд» дип, бәгъзан «мескин Әхмәд», «Кол сәр[2] Әхмәд», «Таҗ Әхмәд», «Хуҗа Әхмәд» дип куя. Бер урында гына ул исемен тулы итеп яза:

> «Ясәви Кол Әхмәднең ошбу сүзе
> Гаҗәп ирмәс бакыб күрер сердин күзе».

Яки:

> «Солтан Хуҗа Әхмәд Ясәви әйде бу хикмәтне
> Ишетсен дип җөмлә җиһан дөньяны салиб китәрем[3]».

Өченче шагыйрь имзасын күбрәк «Шәмседдин»[4] дип, бәгъзән «Шәмс» яки «Шәмс гасый[5]» дип куя. Дүртенчесе күбрәк «Колшәриф»[6] дип, кайвакыт «Шәриф» дип кенә имза итә.

Башкалар, югарыда язылганча, бер генә төрле имза истигъмаль итәләр. Бу җиде имза – ешрак очрый торган имзалардан.

---

[1] Тәкрар ителә – кабатлана.

[2] Сәр – баш, башлык.

[3] Салиб китәрем – инкяр итәрмен.

[4] Шәмсетдин Тәбризи – Мәүләна Шәмсүлхакк вә-д-дин Мөхәммәд ибн Али ибн Мәликдад Тәбризи (1185 тирәсе – 1248), суфи-шагыйрь, фикер иясе. Җәләлетдин Руминың (1207–1273) остазы санала.

[5] Гасый – гөнаһлы.

[6] Колшәриф (?–1552) – Казан ханлыгында дәүләт эшлеклесе, дин башлыгы, суфи шагыйрь. Шагыйрьнең безнең көннәргә унлап шигыре һәм бер сюжетлы поэмасы – «Кыйссаи Хөбби хуҗа» һәм «Зафәрнамәи вилаяте Казан» («Казан вилаятенең җиңүе») язмасы килеп җиткән. Колшәриф үзенең остазлары итеп Хуҗа Әхмәд Ясәвине һәм Сөләйман Бакырганины саный. Колшәрифнең дүрт шигыре «Бакырган китабы»на кертелгән.

Алардан башка тагы берәр генә шигырьдә очрый торган исемнәр бар ки, аларны да аерым кешеләрнең тәхәллүсләре дип уйларга мөмкин. Мәсәлән, «Шәһа Шоһуди бер гөнаһ гасый колыңдыр йа илаһ», «И, Газәли, гыйшык мәйданында җуландин нәсүд[1]». «Бел, Нәсими, чарлаб әйтүр хуш уганың кадәр», «И, Фәкыйри, һич кеши мәүт илкидин табмас нәҗат», «И, Тагый, һәр нәдамәт әмерлә булсын бунсар», «Чөнки Касыймны җәда әйләр икәнсән гакыйбәт», «Бу Гариби урта нәүбан гыйшкында булды әсир». Менә бу шигырьләрдәге исемнәр: Шоһуди, Газәли, Нәсими, Фәкыйри, Тагый, Касыйм, Гариби – һәркайсы берәр кешенең имзасы булырга кирәк. Шулай булганда, безнең «Бакырган китабы» – 15 ләп кеше тарафыннан язылган (коллективный) бер әсәр яисә шуларның таркау әсәрләреннән җыелып, соңыннан бер-бер кеше тарафыннан тәртип ителгән бер мәҗмуга булып чыга. Бу фикерләрнең соңгысы хакыйкатькә якынрак булырга тиеш. «Бакырган китабы»н язуда иштиракь иткән[2] кешеләр Хуҗа Әхмәд Ясәвинең тыгыз бер хилка тәшкил иткән мөридләре булгандыр дип уйлана. Өслүб, фикер, аһәң вә рух берлеге шуны күрсәтә: әгәр дә шул имзалар булмаса иде, әсәрне баштанаяк бер кеше тарафыннан язылган дип уйларга мөмкин булыр иде.

Аларның араларында иң «шагыйрьрәк»ләре – Сөләйман үзе. Аның хисси шигырьләре чын, куәтле тойгы белән сугарылганнар. Башка иптәшләренең шигырьләрендә күбрәк урын алган вәгазь-нәсыйхәт гонсыры[3] Сөләйманда азрак. Күбрәк шигырьләрен ул гыйшыкка, Алла гыйшыгына багышлый. Хәтта аның күп шигырьләрен аерым-аерым алып укысаң, гади дөньяви гыйшык хакында яза дип уйларга мөмкин. Аның бу «хөрлеге» дә аның тегеләрдән өстен булуын күрсәтә. Хуҗа Әхмәд Ясәви шигырьләре хакында, әлбәттә, сөйләп тору гаҗәп түгел. «Диване хикмәт» хакындагы фикердә без аның иҗаты белән

[1] Нәсүд – кешелек табигате.
[2] Иштиракь иткән – катнашкан.
[3] Гонсыры – өлеше.

танышкан идек. Шигърият ягыннан караганда Шәмседдин, Ходадад һәм Гобәйдинең шигырьләре, Бакырганидан кала, башкалардан алдарак торалар. Гобәйди – яхшы гына истигъдадлы[1] шагыйрь. Аның «Диване Гобәйди» аталган, «Диване хикмәт» шикелле аерым хикмәтләрдән тәшкил ителгән китабы безнең Идел буенда да укылган. Бәгъзы иске хосусый көтепханәләрдә аның кульъязмаларын очратып була. Артык рәваҗ[2] әсәр булмаганга, ул бастырылмаган булырга кирәк. Колшәриф белән Иканый хакында артык мактаулы сүз әйтеп булмый: алар рухсызрак, шигырьләрендә шаблон вәгазь-нәсыйхәт хөкем сөрә.

«Бакырган китабы»н мөндәриҗә ягыннан икегә аерырга мөмкин: аның бер кыйсеме лирика булса, икенче кыйсеме риваягә керә. Баштагы, лирика кыйсеме шагыйрьләрнең үз хисләрен, үз фикерләрен бәян итә[3] торган вак-вак шигырьләрдән мөрәккәб[4]. Бу – тәсаувыфи лирика; алар тагать-гыйбадәткә, дөньяны куярга, дәрвишлеккә өндиләр, дөньяның фанилыгын, гомернең кыскалыгын, үлемне, кабергә керүләрне искә төшерәләр. Һәрбер тәсаувыф шигырьләрдәге шикелле, аларда да «яр», «гыйшык», «висаль»[5] зур урын ишгаль итә[6]. Ләкин «Бакырган китабы»ндагы шигырьләрне без тәсаувыф әдәбиятның иң гүзәл чәчәкләреннән дип әйтә алмыйбыз. XV гасырның чыгтай шагыйрьләре шигърият һәм тирәнлек ягыннан Бакырганилардан күп алда торалар. Боларда тик самимиять кенә артык булса булыр. Лирика кыйсеме «Бакырган»ның өчтән ике өлешен ала. Шигырьләрнең 44 е – Сөләйман Бакыргани тарафыннан, 21 е – Шәмседдин, 19 ы – Иканый, 13 е – Гобәйди, 12 се Хуҗа Әхмәд тарафыннан язылганнар; Колшәриф белән Ходададныкы дүртәр генә шигырь.

[1] Истигъдадлы – сәләтле.
[2] Рәваҗ – таралган.
[3] Бәян итә – аңлата.
[4] Мөрәккәб – оешкан.
[5] Висаль – кавышу.
[6] Ишгаль итә – били.

«Бакырган»ның ахырдагы ривая кыйсеме көйләп язылган сигез хикәядән гыйбарәт. Бу хикәяләрдән өчесе пәйгамбәрнең һәм кызы Фатыйманың үлүләре, пәйгамбәрнең бәйрәмдә, дөя урынына, бер ятим баланы аркасына күтәреп йөртүе хакындагы хикәяләр Шәмседдин тарафыннан, мигъраҗны һәм Ибраһимның Исмәгыйльне корбан итүен сөйли торган икесе Сөләйман тарафыннан язылганнар. Пәйгамбәрнең сөекле углының үлеме хакындагы хикәя «Габидулла» дип имзаланган. Бу Габидулла, ихтимал, шул ук «Гобәйди»дер. Безнең халык арасында бик мәшһүр булган «Ярым алма китабы» исемендә аерым китап булып басылып бик күп таралган хикәя дә – Бакырган китабындагы хикәяләр җөмләсеннән. Аның ахырында имзасы юк. Өслүбенә караганда (назымның һәрбер юлы «тидия, ирдия, кылдия» дип бетә) аны Сөләйманга да, Шәмседдингә дә нисбәт бирергә мөмкин, чөнки шунда ук аларның һәр икесенең шул тарызда кафияләнә[1] торган хикәяләре бар. Гомумән алганда, хикәяләр һәммәсе бертөрле үк өслүбтә, бер үк рухта язылганнар. Аларда үзенә бертөрле назик шигърият, инсанның күңелен аңлау булганлыгын инкяр итеп булмый. Аларның күңелгә тәэсир итәрдәй, драматизмга малик[2] урыннары юк түгел. Хикәяләрнең зурлыклары төрлечә – бер биттән биш биткә кадәр.

«Бакырган»ның иң ахырында шактый озын (11 битле) бер хикәя дәрҗ ителгән. Бу хикәя үзенең мөндәриҗәсе белән бу китаптагы башка хикәяләрдән бөтенләй аерым тора. Ул – «Газәвате хәзрәте Гали», «Кисекбаш» шикелле, баш каһарманы Гали булган сугыш кыйссалары тибындагы бер әйбер. Мөндәриҗәсе шушыннан гыйбарәт: Җәнадил шәһәренең кяфер патшасы, мөселманнарны зәгыйфьләндерер өчен Галине үтертергә карар биреп, бер җөһүдне[3] Мәдинәгә җибәрә. Ләкин Әхтәм исемле бер сахабәнең фидаилеге, үзен-үзе Гали дип күрсәтүе аркасында, җөһүд – Гали урынына аның башын кисеп алып кайта. Бу

[1] Тарызда кафияләнә – рәвештә рифмалаша.
[2] Малик – ия.
[3] Җөһүдне – яһүдне.

вакыйганы ишеткәч, Галинең бик ачуы килеп, Әхтәмнең үчен кайтарыр өчен, Җәнадилгә китә. Анда үзен Галинең шәкерте дип танытып, күп баһадирлыклар күрсәтә, кара-каршы сугышта Җәнадилнең бик күп батырларын, шул җөмләдән теге җөһүдне дә үтергәннән соң гына, үзенең кем булуын белдерә. Патша Галигә каршы йөз мең гаскәр чыгара – Гали аны тар-мар итә. Ахырысында кяферләр, хәйләгә керешеп, Галинең йөри торган юлына чокыр казып куялар. Дөлдел бу чокырга арт аяклары белән бата. Гали чокырга төшеп кала, Дөлдел качып Мәдинәгә кайта. Хәл мәгълүм булгач, Рәсүлулла, Җәбраил фәрештәнең канатына утырып барып, Галине коткара. Шуннан соң Гали, кяферләрне җиңеп, Җәнадил шәһәрен алып, бик күп ганимәт[1], маллар алып кайта. Шул малдан Әхтәмнең балаларын тәэмин итәләр. Менә бу хикәяне «Хәтаи Сакый»[2] дип имза кыла торган бер кеше язган. Ул хикәянең башында үзе турысында әйтә:

«Хәтаи Сакыя бу бәндәгълектә[3]
Хәшердә[4] куймагай шәрмәндәлектә[5]».

Хикәя шушы мисраглар[6] белән тәмам була:

«Кылдым назым бу кыйссани битәкълид
Хода тәкълидме кылмаймы тәхкыйк[7]».

* * *

«Бу ирди кыйссаи Әхтәм ки, аңла
Хәтаи Сакыйның назымыны тыңла».

[1] Ганимәт – трофей.
[2] Хәтаи Сакый – Шах Исмаил Исмәгыйль Хәтаи Сәфәвинең (1487–1524) тәхәллүсе.
[3] Бәндәгълектә – коллыкта.
[4] Хәшердә – ислам динендә үлекләрне тергезеп бер җиргә туплау, җыю.
[5] Шәрмәндәлектә – оятлы, оятлы ителгән.
[6] Мисраглар – шигъри юллар.
[7] Тәхкыйк – хакыйкатькә чыгару.

Менә шушы сүзләргә караганда, бу хикәяне «Бакырган китабы»на соңыннан гына теркәлгән дип уйларга мөмкин. Бу кеше үзенең тәкълид итүе[1] турысында сөйли. Белмим, ул нәрсәгә тәкълид кылгандыр, һәрхәлдә, аның мөндәриҗә ягыннан «Бакырган»дагы хикәяләргә тәкълид итеп язылганлыгы күренми. Бу хикәя, ихтимал, соңыннан гына «Бакырган китабы»на теркәлгәндер. Аның теле дә бераз җиңеллерәк төсле; «торур» урынына «дыр» истигъмаль ителгәләгән.

Гомумән, «Бакырган»ның теле асылда чыгтайча булса да, ул бертөрле генә түгел. Анда гарәп-фарсы күп катышкан авыр телле шигырьләр булганы шикелле, шулар белән рәттән үк бик җиңел вә садә[2] тел белән язылганнары да бар. Күчерүчеләр тәэсирендә Бакырганның теленә беркадәр татарчалыклар катышкан. Шигырьләрнең күбесе кафия урынына бер үк сүз яки җөмлә белән тәмамланган мисраглардан тәшкил ителгәннәр.

## III
## *«Ахырзаман китабы»*

Халык телендә күбрәк «Тәкый гаҗәб китабы» дип йөртелә торган бу китап – татар арасында иң таралган, һәрбер мәктәп баласына укытылып килгән китаплардан берсе. «Ахырзаман китабы» назым белән язылган, кечкенә кулда 16 битле китап булып, беренче мәртәбә Казанда 1847 елда басылган. Шуннан соң соңгы заманнарга кадәр бертуктаусыз тәкрар[3] басыла килгән. Назымы бәхре һәзәҗ (мөфагыйлен, мөфагыйлен, мөфагыйлен) вәзенендә; һәрбер дүртьюллы бәйт «андин артык тәкый гаҗәб таңлары вар» дигән җөмлә белән тәмам була. Шуңар күрә халык аны «Тәкый гаҗәб китабы» дип атаган.

Бу китап Сөләйман Бакырганига нисбәт бирелә; чөнки аның ахыргы бәйтендә без «Кол Сөләйман» исемен очратабыз:

[1] Тәкълид итүе – иярүе.
[2] Садә – гади.
[3] Тәкрар – кабат.

«Кол Сөләйман тагать кылгай[1], гафу кылгай,
Уганым[2] әсбабны куй виргәй,
Ахирәтдә тагать берлән рәхем[3] кылгай,
Андин артык тәкый гаҗәб таңлары вар»[4].

Фикеребезчә, мәнзумәнең[5] ахырында Кол Сөләйманның исеме зикер ителү[6] аның Бакырганиныкы булуын исбат өчен җитәрлек дәлил була ала. Шулай ук аның телендә «уган» шикелле бик борынгы чыгтай сүзләренең очравы да аның Урта Азиядә XII гасырлар тирәсендә язылуына дәлаләт итә[7].

Безнең татар арасында «Ахырзаман китабы»н XIX гасырдагы татар язучыларыннан Утыз Имән авылының[8] имамы Габдерәхим муллага нисбәт бирүчеләр булган. Ләкин бу – һич асылсыз, җөзафән[9] әйтелгән сүз. Шул ук Габдерәхим муллага «Бәдәвам» китабын да нисбәт биргәннәр. «Бәдәвам»ның аныкы булуын Мәрҗани дә инкяр итеп, «җөзаф сүз» дип атаган («Мөстәфад әл-әхбар», җилд I, 25 бит). Каюм Насыйри 1877 елгы календаренда Габдерәхим Утыз Имәни хакында яза һәм аның әсәрләрен саный, ул әсәрләр арасында «Ахырзаман китабы» телгә алынмаган.

Ләкин бу әсәрнең Урта Азиядә язылган булуы хакында шөбһәгә төшерә торган бер нәрсә булса, ул да аның теледер. Ул саф чыгтай телендә язылмаган: анда чыгтай сүзләре һәм формалары белән татар вә госманлыныкылар кара-катыш очрыйлар. «Түкәл»,

[1] Дөресе «кыйлгыл» булырга кирәк. *(Авт. иск.)*

[2] Уган – чыгтайча «Алла», «Тәңре» мәгънәсендә. *(Авт. иск.)*

[3] Рәхим. (*Авт. иск*)

[4] Басмада күбесенчә «дыңлары вар» дип басылган булса да, бу, әлбәттә, хата. Чөнки бу сүзне «тыңлау» (дыңламак) масдарыннан чыгарылганда, җөмләнең мәгънәсе калмый. «Таңлары» (таңлары) булып, «гаҗәп» мәгънәсендә булган «таң» сүзеннән чыккан булырга тиеш. Безнең татар телендә «таң, гаҗәпкә калу», «таң төшү» (күз төшү) шикелле гыйбарәләр бар. *(Авт. иск.)*

[5] Мәнзумәнең – дастанның.

[6] Зикер ителү – телгә алыну.

[7] Дәлаләт итә – дәлил була.

[8] Казан губернасында Чистай өязендә *(Авт. иск.)*.

[9] Җөзафән – ялгыш.

«тәкый», «уган», «камуг» шикелле чыгтай сүзләре белән бергә без анда «уруш», «әл», «сагь», «вар», «вирдем», «ичрә», «үзрә» күк госманлы, «кул» (рука)[1] дигән күк татар сүзләре, «булгай», «тикәй», «айгали», «кылгыл», «белең», «чыкубән», «тәнләригә», «утига», «атлыг», «андин» шикелле чыгтай формалары белән бергә «белмәз», «чыгуб», «уфтанмай», «җанины», «ирләренә» күк татарча вә госманлычалыклар очратабыз. Әлхасыйль, «Ахырзаман китабы»ның теле «Бакыргани» китабындагы Кол Сөләйман теленнән шактый аермалы. Соң бу нилектән алай?

Без моны бары тик соңыннан, күчерүчеләр аркылы булган тәэсир дип кенә әйтә алабыз. Мәгълүм ки, XIX гасыр башына кадәрле бездә китап басу булмаган; китаплар халык арасында кул белән күчерелеп кенә таралганнар. Һәрбер күчерүче, үзе дә сизмичә, күчергән китапларының теленә азмы-күпме үзгәрешләр керткән. Мондый күчерүчеләр бик күп булып, ничә гасырлар буенча килгәнгә, бу үзгәрешләр, җыела-җыела, кайбер күбрәк укыла торган китапларның телен асыл нөсхәдән әллә никадәр ераклаштырганнар. Күчерүчеләр татар булганга, чыгтайчаның татарлашуы бер дә гаҗәп түгел. Бигрәк тә чыгтай теленең татар теленә якынлыгы, күп сүзләрнең аермасы бары тик тәләффыз[2] вә имлада гына булуы моңар киң юл ачкан. Шуңар күрә, мәсәлән, «киши»нең – «кеше»гә, «иш»нең – «эш»кә, «чыкуб»ның – «чыгыб»ка, «әрләригә»нең «ирләренә»гә әверелүе бер дә искиткеч эш түгел; шулай ук, татарча «элек» сүзе белән саташтырылуы ихтимал булганга, чыгтайча «илик»нең татарча «кул» яки госманлыча «әл» формасында язылып китүе дә табигый. Чыгтайча сүзләрнең госманлыча белән алыштырылуы да – татар күчерүчесе өчен бик мөмкин эш. Чөнки безнең татарның борынгы «китапча», ягъни әдәби теле шул чыгтайча, госманлыча һәм татарчадан оешкан бер тел булганга, чыгтай вә госманлы әдәби әсәрләре ике яклап безнең татар арасына кергәнгә, безнең әдәби телгә

---

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[2] Тәләффыз – сөйләмдә.

аларның һәр икесенең тәэсире була килгән. Бу тәэсирне без, югарыда күрелгәнчә, Идел буенда язылган иң борынгы әсәрләрдә үк мөшаһәдә итәбез[1]. Шуның өчен дә без «Ахырзаман китабы»нда «варгай» шикелле аерым госманлы, аерым чыгтай тәэсире белән ясалган сүзләрне очрата алабыз.

Бу урында күңелгә бер сөаль[2] килә: ни өчен соң «Бакырган»-ның теле әйтерлек үзгәрмәгән дә, «Ахырзаман»ныкы шулкадәр үзгәрешләргә дучар булган? Моның бер сәбәбе – «Ахырзаман»-ның теле Бакырганнныкына караганда җиңелрәк булуы булса, икенче сәбәбе – «Ахырзаман»ның, күләме дә кечерәк булганга, халык арасында күбрәк укылып, күбрәк мәртәбә күчерелгән булуыдыр.

Һәрбер шәкерт малае өчен бу кечкенә китапны күчерү бик ансат эш булган. Теле гаммәгә[3] ансат аңлашылырлык булуы да аны халык арасында бик мәкъбүл[4] ясаган. Шуның аркасында ул тагы да күбрәк мәртәбә күчерелгәндер. Аннан соң китапларның телләрен аларны баскан вакытта матбага мосаххихлары[5] да бик үзгәртәләр. Моны күрер өчен, күп мәртәбә басылган китапларның беренче басмалары белән соңгыларын чагыштырып карау җитә.

«Тәкый гаҗәб китабы»ның мөндәриҗәсе ахырзаман галәмәтләрен һәм кыямәт көнен кыскача тасвирдан гыйбарәт. Ләкин бу – кыска булса да, көчле хис белән язылган шигъри тасвир. Ул гәрчә кыямәт хакында мөселманнар арасында таралган игътикадларга бина кылынса да[6], аерым вакыйга вә манзараларны[7] күз алдына китерүдә мөәллиф[8] үзенең хыял юлы белән бара, дөрес, аның тасвирларын тулы дияр хәл юк; ләкин, шуның белән бергә,

[1] Мөшаһәдә итәбез – күрәбез.
[2] Сөаль – сорау.
[3] Гаммәгә – халыкка, массага.
[4] Мәкъбүл – яхшы кабул ителгән.
[5] Матбага мосаххихлары – типография төзәтүчеләре, корректорлары.
[6] Игътикадларга бина кылынса да – ышануларга нигезләнгән булса да.
[7] Манзараларны – күренешләрне.
[8] Мөәллиф – китап язучы, автор.

анда күңелгә, шигъри хыялга тәэсир итәрдәй аерым эпизодларны җанландырып күз алдына китерердәй манзаралар бар. Мәсәлән, Әбү Җәһилнең Мөхәммәдтән шәфәгать эстәүләре, Адәм пәйгамбәрнең, йөгереп килеп, «углым» дип, аның муеныннан кочаклаулары, Мөхәммәднең, анасын күргәч, «анам, кечкенәлектә ятим калдым синнән» дип, аны кочулары, гөнаһлы өммәтенең читен хәлен күреп, уфтанып, маңгай тиреләрен агызып, газап чигеп торулары – шундый матур тасвирлар җөмләсеннән. Гомумән, бу поэма укучыга шундый тулы вә бөтен тәэсир бирә ки, безнең татар карчыкларының, аны укыганда яки тыңлаганда күңелләре тулып елаулары бик яхшы аңлашыла. Ул гүя бер дини кантата[1] өчен мәүзуг итеп язылган төсле тоела. Аның:

«Йирне нитәк[2] яратди ирсә, күкне һәман[3],
Айны нитәк яратди ирсә, көнне һәман», –

дип башлануында гүяки тантаналы музыка аккордлары яңгырыйлар. Безнең халыкта бу китапны укыр өчен махсус булган бер көй бар.

Бу поэманың каһарманы – Мөхәммәд пәйгамбәр. Бөтен изгеләр, пәйгамбәрләр, фәрештәләр кыямәтнең һәйбәтеннән[4] тетрәшеп, тел ачып сүз әйтергә куркып торган чакта, аңар, Алланың дустына, бу хөкем мәйданына тыныч кына, өстән торып (христианнарның Гайсәсе шикелле, тәхет өстендә утырып кына) карап утырырга мөмкин булган вакытта, ул, аһ орып, тирләппешеп, өммәтенең котылуы өчен тырышып йөри; бер генә сулыш мөэминнәрне кайгыртудан бушанмый, алар өчен Алласына ялварып, сәҗдәдән башын күтәрми; Алла хозурына хөкемгә барганда, өммәтен башлап бара: «Минем өммәтемне яндырмагыз, газап кылмагыз!» – дип, җәһәннәмгә, зобаниларга Алланың үзеннән узып гайрәт ора: Алладан: «Өммәтеңә тәмугны хәрам

[1] Кантата – бер нәүгъ музыка әсәре *(Авт. иск.)*.
[2] Ничек. *(Авт. иск.)*.
[3] Шул ук вакытта. *(Авт. иск.)*.
[4] Һәйбәтеннән – мәһабәтлелегеннән.

кылдым, аларга җәннәт бакчаларын бирдем. Күңелеңне тыныч тот, дустым» дигән вәгъдәне алгач кына, ул бераз тынычлана; шул вакытта ул, рәхәтләнеп, үзенә ияргән өммәтне ата-анасына күрсәтә; аннан соң мәхшәр халкын башлап мәңгелек җәннәткә таба алып бара; хурлар, гыйльманнар[1], оҗмахтан чыгып, аларны каршы алалар. Шуның белән бу киң вә иректе сызыклар белән ясалган картина тәмам була.

Мөәллиф үзенең ахырзаман галәмәтләрен, кыямәт көнен тасвирында гомум ислам галәмәтендә хөкем сөргән игътикадлардан[2] артык читкә чыкмый; тик шигъри тасвирларында гына үзеннән беркадәр тәфсыйлат[3] арттыргалый. Мөселманнар арасында әшрате сәгать[4] вә кыямәт әхвале хакында таралган төрле игътикадларның ни дәрәҗәдә асыл рәсми ислам гакыйденә[5] һәм Коръән-хәдискә туры килү-килмәве мәсьәләсе, әлбәттә, безнең тикшерү даирәбезгә вә төп максатыбызга керми. Ислам галәмендә бу ышануларның ясалуларына христиан вә яһүд игътикадларының, алардагы әсатыйр[6] вә хорафатның бик зур тәэсире булуы шөбһәсез. Рус мөстәшрикъ руханиларыннан мәшһүр миссионер, поп Ефим Маловның[7] «Ахырзаман китабы»н христиан дине ноктаи назарыннан карап тәнкыйть кылган

[1] Гыйльманнар – җәннәт хезмәтчеләре.

[2] Игътикадлардан – ышанулардан.

[3] Тәфсыйлат – аңлатулар.

[4] Әшрате сәгать – ахырзаман.

[5] Гакыйденә – ышануына.

[6] Әсатыйр – борынгылар турында булган мифик әкиятләр, мәсәлләр, легендалар.

[7] Малов Евфимий Александрович (1835–1918) – миссионер, дин галиме, ислам дине белгече, илаһият докторы (1901). Ислам догматикасын, гарәп һәм татар телләрен яхшы белгән Малов мөселман-татарлар һәм яһүдләр арасында актив миссионерлык эшчәнлеге алып бара: православие динен актив пропагандалау, мөселман руханилары һәм җирле халык белән ачык бәхәс алып баруны беренче планга куя. П. Әхмәров белән берлектә татар телендә мөселманлыкка каршы «Библия һәм Коръән тәгълиматлары Адәм турында» (1885), «Библия һәм Коръән тәгълиматларында Моисей кануны» (1889), «Ахырзаман турында Мөхәммәд тәгълиматы» (1897) исемле хезмәтләр бастыра. «Ахырзаман китабы»н рус теленә тәрҗемә итә.

бер тәфтише бар[1]. Ул анда мөселманнарның кыямәт галәмәтләре хакындагы игътикадларының нинди христиан вә яһүд китапларындагы сүз вә хәбәрләр тәэсирендә мәйданга килгән булу ихтималын тикшерә; аларның һәртөрле апокрифлар[2] (христиан әсатыйре, гайре рәсми инҗилләр), апокалипсис шикелле христиан дини китапларындагы хәбәрләр һәм яһүд әсатыйре вә хорафи китаплары тәэсире астында ясалганлыкларын исбат итәргә тырыша. Китапның ахырында, бу хактагы ислам игътикадларының үзләренеке булмавына, бинаән галәйһи батыйльлыгына истинадан[3], мөселманнарга хитабән[4], аларны бу хорафатны ташларга, «хак булган» христиан игътикадларына ышанырга өндәп, «пәдәранә»[5] бер нәсыйхәт биреп китә.

XIX гасыр ахырында татар муллалары арасында да «Ахырзаман китабы»на каршы бер хәрәкәт туган. Бу китапта хорафат күп дип, мөселманнарның нык иманын какшатуы ихтимал дип, аңар каршы голяма[6] җиһад[7] ачкан. Моның сәбәбе – китапта бәгъзы бер кыямәт галәмәтләренең булачак вакытларының еллары тәгаенләнеп күрсәтелүдер. Анда, мәсәлән, «Гайсә ингәй тәмам төгәл тукыз йүздә», «тукыз йүз дә ун бишдә Яэҗүҗ чыкгай» шикелле сүзләр бар. Вәхаләнки,[8] һиҗри тугыз йөзенче ел күптән узып киткән, әмма ул эшләр берсе дә булмаган: Гайсә да иңмәгән, Яэҗүҗ дә чыкмаган. «Ахырзаман»ның мөәллифе бу тарихларны нигә иснадән[9] ул кадәр төгәлләп язгандыр, анысы мәгълүм

[1] Изв. О-ва археологии, ист. и этногр. при Казан. Унив. 1897 г. Том XIV, вып. I «Окончание мира» Е. А. Малов. *(Авт. иск.)*

[2] Апокриф – дини әдәбият (яһүд һәм христианнар) нигезендә канунга кертелмәгән дини вакыйгаларга, изгеләргә һәм чиркәү тарихына багышланган әсәр.

[3] Бинаән галәйһи батыйльлыгына истинадан – шул сәбәпле дөрес түгеллегенә таянып.

[4] Хитабән – эндәшеп.

[5] Пәдәранә – аталарча.

[6] Голяма – галимнәр.

[7] Җиһад – сугыш.

[8] Вәхаләнки – чынлыкта.

[9] Иснадән – нигезләнеп.

түгел; әмма, безнең голяма уенча, шушы сүзләрнең халыкның әшрате сәгатькә, кыямәт якынлыгына иманын какшатырга сәбәп булуы ихтимал булган; ислам дошманнарының кулында да ул надан халыкны әгъва кылырга[1] бер корал булып, христиан миссионерлары аңар игътибар итеп, үз юлларында аннан файдаланырга тырышулары мөмкин булган. Безнең татар халык гаммәсенең исә бу китапка Коръән сүзенә ышанган күк ышануы билгеле. Менә безнең муллалар шул рәвешчә фикер йөрткәннәр[2]. Хәтта бу китапны бастыруны туктатырга кирәк дигән фикергә кадәр җителгән. Менә шул вакытта бу китапны якларга бер каһарман чыга, Бәләбәй өязендәге Чокыр авылының имамы Гали Салих углы[3], татар халкы каршында мөкаддәс булган бу китапны яклап, «Замме назыйр» («Охшаш өстәмәләр») исемендә бер рисалә яза. «Гали Чокрый» дип имза кылучы бу мулла – XIX гасырның иске рухтагы татар язучыларыннан берсе. Үзенең әсәрләре белән ул заманасында яхшы гына шөһрәт казанган. Үзе шагыйрь дә булып, назым белән дә язгалаган. Аның «Замме назыйр»е көчле ышану һәм үзенә күрә матур вә оригинальный өслүб белән язылган. Урыны-урыны белән Гали Чокрыйның өслүбе мөсәҗҗәгъ[4], хәтта бәгъзан мәүзүн[5] нәсергә әверелеп китә. «Замме назыйр» китабыннан кайбер кыйтгаларын түбәндә күчерәбез. Гали Чокрый «Ахырзаман китабы»ның Сөләйман Бакыргани тарафыннан язылганына ышанган; ул аның хакында: «И, яраннар[6], бу китапны тасниф кылган[7], Кол Сөләйман диеп безкә мәсмугъ[8] улган, Бакыргани диеп монда мәшһүр улган», – ди. Икенче бер урында әйтә:

[1] Әгъва кылырга – котыртуга.

[2] Халыкның өч йөз ел какшамаган иманы, белмим, ничек алай тик торганда какшап китәсе булгандыр инде! *(Авт. иск.)*

[3] Мөхәммәтгали Габдессалих улы Киеков (1826–1889) – суфи шагыйрь, мәгърифәтче.

[4] Мөсәҗҗәгъ – рифмалаштырылган.

[5] Мәүзүн – тезмә.

[6] Яраннар – дуслар.

[7] Тасниф кылган – язган.

[8] Мәсмугъ – ишетелгән хәбәрләр.

«Илдә мәшһүр назым берлә «Заманахыр китабы»
мәшһүр улды.
Җөмлә мөэмин коллар арә мәншүр[1] улды.
Ләкин бәгъзы мөэмин моңа мөнкир улды[2].
Күп кешеләр бу китапка бәхәс кылды.
Батыйль[3] сүзләр язган дип гарыз кылды[4]».

Тугыз йөз тарихы хакында ул яза:

«И яраннар, бу китапның тарихлары
Үтеп киткән булса да сарихлары[5],
Шул ук вакыйг аның касд сәхихләре[6],
Аның касды үз вакытының җәһилләрен
Әнбия ирде вәгазе берлән гафилләрен
Тагать кылмай йөргән кяһилләрен[7],
Бәрәкалла, күп гафилне тәнбиһ кылган[8]
Хәрислекдин[9] мәнгы идүб[10] тәүҗиһ кылган[11]
Кыямәтне тәкъриб идүб[12] тәкърир кылган[13]
Чөнкем әксәре кауме[14] аның көрди[15] булган.
Көрди халкы ул вакытта җаһил булган,
Һәр кавемнең гаклы микъдар пәнде[16] булган.
Гәр аларга мең ярымда Дәҗҗал чыккай дисә,
Анлар кылу бәндин калебендин хәүфе чыкгай,
Йырак саюб шаид анлар җәзем[17] кыйлгай,

[1] Мәншүр – таралган, бастырып таратылган.
[2] Мөнкир булды – инкяр итте.
[3] Батыйль – яраксыз.
[4] Гарыз кылды – аңлатты, сөйләде.
[5] Сарихлары – ачык.
[6] Касд сәхихләре – нияте туры, дөрес.
[7] Кяһилләрен – ялкауларын.
[8] Тәнбиһ кылган – уяткан.
[9] Хәрислыкдин – комсызлыктан.
[10] Мәнгы идүб – тыеп.
[11] Тәүҗиһ кылган – мөрәҗәгать иткән.
[12] Тәкърриб идүб – якынайтып.
[13] Тәкърир кылган – аңлатып сөйләгән.
[14] Әксәре кауме – кавеменең күпчелеге.
[15] Е.Малов «көрд» (курды) дип тәрҗемә кылган. *(Авт. иск.)*
[16] Пәнд – үгет, вәгазь.
[17] Гөнаһ. *(Авт. иск.)*

Яхуд аның морады бездән соңдыр
Бездән соң тукыз йөздә дигән сүздер,
Дәҗҗал Мәһди чыкар анда дигән сүздер,
Тәхкыйк[1] аның заманы меңдән уңдур
Тукыз йөзне кушсаң аңа тугры юлдур,
Китаблар тәкриринә бу мәгъкульдер
Гайсә, Мәһди, Дәҗҗал, бер көн чыкса кирәк,
Әшрат сәгать бер көн вакыйг булса кирәк,
Моны тасдыйк кылу важиб булса кирәк.
Бакыргани тарихы үтмәк илән
Аны тәкзиб[2], җаиз[3] ирмәс сүкмәк илән
Тәэвил кирәк, аңа инсаф итмәк илән
Тарих мең дә ике йөзне үтүб китсә,
Мең дә биш йөз һиҗри тарих кариб[4] килсә,
Шул арада Дәҗҗал, Мәһди килеп китсә,
И яраннар, моны тәкзиб кыйлмаңызлар,
Якын булган гакыйдәне куймаңызлар,
«Заман ахыры китабы»ны җуймаңызлар».

Шулай итеп, Гали Чокрый, Бакырганины яклап, аның хаталарын юлларга тырыша. Аның бу турыда тоткан юлы, соңгырак заманда Коръән аятьләрен тәэвил кылып[5], яңа фән нәзарияләренә[6] туры китерергә азапланучы җәдитчеләрнең методы белән нәкъ бердер.

## IV
## *«Хәзрәте Мәрьям китабы»*

Сөләйман Бакырганиның татар арасында таралган шушы исемдәге тагын бер кечкенә әсәре бар (басмада кечкенә кул 8 бит). Бу – бәхре мәдид (дүрт мәртәбә «фагыйлатен фагыйлен»)

[1] Тәхкыйк – шиксез.
[2] Тәкзиб – ялган.
[3] Җаиз – дөрес.
[4] Кариб – якын.
[5] Тәэвил кылып – тәфсир итеп.
[6] Нәзарияләренә – теорияләренә.

вәзене[1] белән язылган көйле бер хикәя. Дөресрәге, ул милли төрк вәзене белән язылган. Төрк халыкларында бу – бик таралган шигырь үлчәме. Төрк халыклары, әле гарәпләр белән таныш булмаган вакытта да, шул вәзен белән яза торган булганнар: мәсәлән, Орхон ташларында да без шул ук үлчәү белән язылган бәйтләрне укыйбыз. Берничә мәртәбә Казанда 1878 елда басылган бу әсәр хакында кыска гына бер тәфтиш язган Матвеев аның Урта Азиядә җәһрия дәрвишләренең мәҗлесләрендә Хуҗа Әхмәд Ясәвинең хикмәтләре шикелле үк хор белән укылганын сөйли[2]. Димәк аның Сөләйман Бакыргани тарафыннан язылган булуында шөбһә юк.

Хикәянең ахыргы бәйте дә шуңар дәлаләт итә[3]:

«Гариф ябан гизар тик,
Нәкъкаш туны бизәр тик,
Данә-энҗе тезәр тик,
Кол Сөләйман ирдия».

Бу хикәянең мәүзугы[4] мөселманнар арасында Гайсә пәйгамбәрнең анасы Мәрьямнең вафаты турысында шаигъ булган[5] бер легенда. Бу садә генә мәүзугны Бакыргани үзенең матур, шигьри каләме белән гүзәл бер поэмага әвереләдергән.

Хикәянең мөндәриҗәсе шушы: башта Гайсәнең дәрвишлеге, могҗизалары сөйләнә. Ул анасын, дөньяны куеп, тау араларына барып гыйбадәт кылып торырга өнди. Алар, Тәбиян тавына барып, сумга ясап, шунда тагать-гыйбадәт белән мәшгуль булалар. Көннәрдән бер көнне, Гайсә өйдә юкта, Мәрьям ананың җанын алырга Газраил килә. Мәрьям аннан, углы белән бәхилләшер өчен, аның кайтканын көтәргә сорый. Газраил көтми, җанын ала. Гайсә, кайткач, анасын йоклый дип белеп, бик озак көтә;

---

[1] Вәзене – үлчәме.

[2] Изв. О-ва Арх. Ист. и Этногр. при Казан. Универ 1895 г., том ХШ, вып. 1. С.М. Матвеев, «Мухаммеданский рассказ о св. Деве Марии». *(Авт. иск.)*

[3] Дәлаләт итә – дәлиллек итә.

[4] Мәүзугы – сюжеты.

[5] Шаигъ булган – таралган.

ул торганчы дип, әллә никадәр вакыт ашамый. Ахырда: «Анаң үлде», – дип, күктән аваз килә. Эшне белгәч, Гайсә бик кайгыра, елый. «Инде нишләрмен, ничек торырмын», – ди. Шулвакыт, иленә барырга кушып, Алладан әмер килә. Гайсә, халкы арасына барып, анасына кәфенлек сорый – һичкем кәфенлек бирми. Ул нәүмиз булып кире әйләнеп кайтканда, инде күктән фәрештәләр иңеп, Мәрьям ананы кәфенләп, җеназа укып күмгән булалар. Шулвакыт Гайсә, Ходага зарилык кылып[1], анасының йөзен күрер өчен, кабернең ярылуын сорый. Кабер ярылып, чәчәкләр арасында Мәрьям терелеп чыга; ике мәртәбә үлем ачысын татырга мәҗбүр иткән өчен, углын шелтә кыла: «Дөньяга бакма, малга күңел бирмә, Хак коллыгын куйма», – дип, аны нәсыйхәтли. Хикәя шуның белән тәмам.

Бу хикәя Робгузида да бар. Катанов аның бер вариантын Турфан шәһәрендә шәркый Төркестандагы төркләр авызыннан ишетеп язып алган. Коръәндә бу кыйсса юк. Матвеев аның христиан апокрифларыннан алынганлыгын сөйли.

«Мәрьям китабы» бик садә өслүб белән язылган. Телендә татар һәм госманлы тәэсире юк диярлек. Һәрбер бәйт «тидия, ирдия» шәкелендә[2] тәмамлана. Кафия[3] бәйтнең әүвәлге өч юлында бар белән юк арасында. Бәгъзан вәзен дә аксый төшә. Урыны-урыны белән, вәзенгә туры китерү өчен, җөмләләрнең бөтенлегенә зарар китерелгән. Шушы ук кимчелекләрне без Бакырганиның «Ахырзаман»ында да очратабыз.

[1] Зарилык кылып – «Аллага зар кылу, күңелен бушату» мәгънәсендә.
[2] Шәкелендә – формасында.
[3] Кафия – рифма.

## ТЕКСТЛАРНЫ ГАМӘЛДӘГЕ ЯЗУГА КҮЧЕРҮЧЕЛӘР ҺӘМ ШӘРЕХЛӘҮЧЕЛӘР

*Ахунов А.М.* – филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

*Гомәров И.Г.* – филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

*Гарипова Л.Ш.* – филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

*Хөснетдинова Г.А.* – филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.

## ЭЧТӘЛЕК

**Кереш сүз** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .5

**Беренче бүлек** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .17

Мөкаддимә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .17

Мәдхәл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .29

I. Борынгы төркләрдә дөньяга караш
һәм халык әдәбияты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .29

II. Борынгы төркләрдә язу сәнгате . . . . . . . . . . . . . . .51

III. Орхон ташбилгеләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .71

IV. Суфилык һәм аның шәрык әдәбиятларына тәэсире . . . .90

V. Уйгурларда әдәбият . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .116

VI. Чыгтай әдәбияты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .139

VII. Сәлҗук вә госманлы әдәбияты . . . . . . . . . . . . . . .168

**Икенче бүлек**

Татар теле вә әдәбиятының тарихи язмышы . . . . . . . . .188

Идел буенда иң борынгы тел ядкәрләре . . . . . . . . . . .224

«Коман мәҗмугасы» (Codex Cumaniecus) . . . . . . . . .224

Болгар кабер ташлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .232

Ярлыклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .239

Идел буенда чыгтай әсәрләре . . . . . . . . . . . . . . . . . .254

«Кыйссас әл-әнбия» Робгузи . . . . . . . . . . . . . . . . .254

«Диване хикмәт» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .263

Сөләйман Бакыргани вә аның әсәрләре. . . . . . . . . . .273

I. «Хәким ата китабы» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .273

II. «Бакырган китабы» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .279

III. «Ахырзаман китабы». . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .286

IV. «Хәзрәте Мәрьям китабы» . . . . . . . . . . . . . . . . .295

Текстларны гамәлдәге язуга күчерүчеләр
һәм шәрехләүчеләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .298

**ДУХОВНОЕ НАСЛЕДИЕ**
**поиски и открытия**
Выпуск 15

Редактор А. А. Давлетова
Компьютерная верстка Н. Т. Абдуллиной
Дизайн обложки А. В. Булатова

Подписано в печать: 08.12.2022 г.
Бумага офсетная. Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс».
Усл.-печ. л. 17,4. Уч-изд. л. 14. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20